www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Муса ҖӘЛИЛ. Бер үгет. *Шигырь.* ....3
Рөстәм ВӘЛИЕВ. Дөнья гаме. *Роман.* ....4
Рәниф ШӘРИПОВ. Җомга. *Поэма.* ....56
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Тузгытылган көч. *Бәян.* ....62
Илсөяр ИКСАНОВА. Гомерем фасыллары. *Шигырьләр.* ....101
Рәфкать ШАҺИЕВ. Китмә, әти! *Хикәя.* ....105
*100нче бит:* Рүзәл МӨХӘММӘТША. Сәламәт тәндә... сәләмә рух? ....100

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ**

Җыры белән җиңгән дошманын *(Р.Низами, М.Мирза, Ф.Мөслимова, Г.Морат, Л.Лерон, Р.Зәйдулла, Г.Корбанова, Р.Сәлахов, Ф.Гыйләҗев, Э.Һадиева, Р.Мөхәммәтша шигырьләре).* ....115
Афзал ШАМОВ. Ике очрашу. ....126
Әлфия ШАМОВА. Бер фоторәсем тарихы. ....128
Хәнәфи БӘДИГЫЙ. Муса Җәлил әсәрләренең поэтик лингвистикасы. ....130

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ**

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. «Вакыт, әфәнделәр, вакыт!» ....121

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Рифат СВЕРИГИН. Күңелендә галәм чиксезлеге... *(Солтан Шәмсигә 70 яшь).* ....143

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Рабит БАТУЛЛА. Күзен ачкач, Зөләйха нәрсә күрде икән? ....153

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Ерак Көнчыгышта татарлар. ....157

**ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ**

Рифә РАХМАН. Кол Гали һәм Тукай. ....172
Мәкаль өмәсе дәвам итә. ....175

**АК ҖИЛКӘН**

Элина ЗӘКИЕВА. Аның тәне дә көчле булган. ....176
Ким ШАКИРОВ. Көтелмәгән очрашу. ....180
Хикәя яза аласызмы? *(Р.Әхмәтов, М.Фәйзуллина, А.Хәсәнова, Л.Хәсәнова, А.Гиесхонов хикәяләре).* ....183

**ШАЯН СӘХИФӘ**

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....187

«Казан утлары» архивыннан. ....124
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.1268).*
✆: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.01.2016, график буенча 29.01.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-208. Тираж 4005.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2016 ел

## Бер үгет

*Кешелек турында*

Мин күп күрдем филдәй кешеләрне:
Киң күкрәкле, тимер бәдәнле.
Тик күрәсе иде эше белән
Кеше булган иң чын адәмне.

Кем сокланмас көчкә, тимер сынса
Һәм су чыкса баскан эзеңнән.
Тик ни файда, көчең филдәй булып,
Эшең булса чыпчык тезеннән.

Эзе калсын керсез намусыңның,
Ни үтсә дә синең кулыңнан.
Көчлелегең белән горурланма!
Кешелегең белән горурлан!

Һәр адымыңда синең туры акыл,
Көчле йөрәк эзен күрсеннәр;
Кылыч белән түгел, турылык һәм
Чынлык белән көчле кешеләр.

Син яшәмә җирдә файдасыз бер
Түмгәк булып тигез урында.
Янып калсын гомрең маяк булып,
Үзеңнән соң килгән буынга.

Утта булган балчык кире купмас,
Эштә булган тимер тутыкмас.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас,
Каберенә эзне суытмас.



Рөстәм
Вәлиев

# ДӨНЬЯ ГАМЕ*

РОМАН

**Беренче бүлек**

**1**

Дала буйлап атлаучы дәрвиш юлының азагына якынлашты, әмма шәһәргә кадәр чакрым чамасы калгач, читкә тайпылды да төн кунар өчен борынгы калкулык итәген каплаган куе куаклыкны сайлады.

Кала чигендә сакта торучыларның үзара сүз алышуы, якында гына төнгелеккә туктаган көтүчеләрнең тәмләп гәпләшүләре, алар яккан учактан чәчрәгән алсу-кызыл чаткылар, тигез җир буйлап аккан елга суының ташларга бәрелеп чәчрәве, биектә-биектә йолдызларның җем-җем килүе, хуш исләргә күмелгән җылы, уңайлы караңгы урыннарда җанварларның мәхәббәт уеннары... җирнең бар почмагында һәрвакыттагыча тормыш дәвам итә һәм болар дәрвишнең күңелендә үткәннән калган кайтавазларны — хатирәләрне кузгатты. Әмма бу үткәннәр аның шәхси тәкъдиренә кагылмый, алар аның озын-озак сәяхәтләрендә онытылган, эреп юкка чыккан кебек иде.

Тәүге тапкыр ул монда йөз егерме җиде ел элек булган иде. Ул вакытта ныгытма диварлар белән уратып алынган агач һәм балчык өйләр Җаек шәһәрчеге дип атала иде. Калкып торган тузанлы мәйданда дар агачының тырпаеп калган терәкләренә симез-юан чучкалар ялкау гына ышкынып тора; идарә ишеге төбендә почык борыны кубалакланган яшь кенә солдат зарыгудан нишләргә белми таптана. Мәйдан читендәрәк күбенгән гөмбәзле чиркәү тора, аның капкасыннан таза гәүдәле казаклар ниндидер каралҗым авыр әйбер өстерәп чыгарды. Бу каралҗым авыр нәрсә танавына кан катыш тузанга баткан божра киертелгән көрән аю түшкәсе булып чыкты. Дәрвиш әлеге вакыйганың каладан чыгу юлында очраткан сергач татарлары белән бәйле булуына төшенде. Чиркәүдән тыелган аралыктагы тамашалары көенечле тәмамланган, күрәмсең.

---

* *Журнал варианты.*

---

Рөстәм ВӘЛИЕВ (1936) – *язучы; «Верность» (1960), «Лето тихого города» (1975), «Земля городов» (1979), «Заботы света» (1986), «Вино любви» (2002) кебек ике дистәгә якын китап авторы. Россия Язучылар берлеге әгъзасы (1966). Д.Н.Мамин-Сибиряк исемендәге премия лауреаты (2002). Чиләбедә яши.*

Кала тыныч кына көн күрә кебек, тик анда дары исе аңкый, үтереш, курку-дәһшәт хөкем сөрә иде. Бер ел узгач, Емельян казакның үч алу оясына әйләндергәнен оныттырыр өчен, каланың исемен Уральскига алыштырдылар.

...Озын юл үтеп йончыган дәрвиш йокысыз төннән соң тәмам алҗыды. Черем итәргә дип ятып, иртән йоклап калганын да сизмәде. Ул калага кергәндә, ыгы-зыгы башланган иде инде. Бераздан, шау-шу тына төшкәч, дәрвишкә мөәзиннең өзек-төтек сүзләре генә килеп иреште.

Кала читендәге балчык белән сыланган алачыклар кояшның кайнар ташкынына сабыр гына түзеп утыра. Тал чыбыгыннан үрелгән читәннәр җиргә таба авышкан һәм, иртәнге буталыш, ыгы-зыгыны күреп калыгыз дигәндәй, тишек-тошыклар киерелеп ачылган. Хуҗабикәләрнең карлыккан тавыш белән кычкыргалап алуы, бала-чаганың шатланып чинавы, тавыклар кытаклавы, этләрнең ырылдавы — болар бар да дөньяны аркылы-торкылы гизгән күп төрле гавам-кавемне очраткан дәрвишкә бик тә аңлаешлы иде. Корыклары авышкан кыек капка төбендә әнисенең кәлүшен өстерәгән җиде яшьләр чамасындагы кыз басып тора. Ул саргылтым көчекне ике кулы белән күкрәгенә кыскан. Йокысыннан айнып җитмәгәнгәме, караңгы чырайлы, әмма матур кыз баланың дәрвишкә исе китмәде. Көчек никадәр генә шәп, тере булмасын, кызның кулларында ул ниндидер фәкыйрьлек тамгасы булып күренә. Бичара кызның төс-кыяфәтендә аерылышу галәмәтен сизеп алды ул. Шәһәр исә балкый, шау-гөр килә, тузан болытлары оча һәм бер мәлгә күк йөзе күз алдында төсен җуеп ала.

Бер мизгелгә шәһәрнең чик-сызыклары югалды, дәрвиш һушыннан язгандай булды, аннары ул киң һәм бушап калган үзәк урамны, ялтырап торган ике көпчәктә барган хатын-кызны күрде. Тик дәрвишнең исе китмәде, аңа охшаш машинаны Истанбулда күргәне бар иде. Танылган шымчы Абдул Хәмид, эңгер-меңгер төшкәч, яр буйлап йөреп кайтырга ярата иде. Шулай бервакыт артыгын куып, ул Истанбул бугазына чумды. Башта, бөке кебек, судан түгәрәк фәс калкып чыкты, аның артыннан шымчының күгелҗем баш түбәсе күренде. Дәрвиш тыныч кына аңа үзенең кәкре башлы таягын сузды һәм булдыксыз йөртүчене ярга тартып алды. Тегесе исә, бугазыннан аккан тозлы суга тончыга-тончыга, әшәке итеп сүгенде. Дәрвишнең суга манчылган тар җилкәгә таягы белән бер сыптырып алырга теләге булса да тыелып калды: чөнки бу адәм ниндидер сәүдәгәр яисә министр гына түгел, танылган шымчы иде.

...Кара-кучкыл йөзле хатын кояшка чагылган күзен кыскалап ала; озын күлмәгенең чәчәкле итәге җил белән күтәрелеп китә, аннары тулы төз аякларына килеп урала. Аның артыннан, кызганыч тавыш белән чинап, йонлач эт чаба. Һәм бу яшь, сәламәт, карап торышка бик бәхетле күренгән хатын-кызда да дәрвиш ниндидер аерылышу сагышы тойды.

— Иншаллаһ, — дип куйды ул, аңсыз рәвештә, — бар да синең иркеңдә, Аллаһым.

Ул мәйданга карап торган өй-кибетләр рәтеннән атлады. Аларның өске катлары яшәү өчен бүрәнәдән салынган, аскы каты — таштан, тәрәзәләренә тимердән рәшәткәләр куелган, таштан эшләнгән болдыр өстенә алтакта эленгән. Кибетләр рәтеннән соң олы урам Татар бистәсенә илтә. Яшел түбәле йортларның тәрәзәләрендә матур-матур пәрдәләр күзне иркәли, биек капкалары сырлап эшләнгән агач баганаларга утыртылган. Нәфис манараларда, акшарланган диварларда кызгылт төс уйный. Монда өч мәчет булып, барысы да агачтан, алар карар күзгә Болгар һәм Казан мәчетләренең борынгы күчермәләрен хәтерләтә кебек, аларның тузаннары хәзер, җитез җилгә ияреп, Азия киңлекләренә оча.

Бистә буйлап эссе һавада намазга чакырып азан тавышы таралды. «Ләилләһи-ил-аллаһ!» — дип, дәрвиш адымын кызулатты. Әгәр шәһәрдә булмаса,

намаз вакыты җитүгә, шул урында гына тезләнер иде. Әмма монда бер урамның казак балалары икенчесенә каршы сугыш игълан иткән: берсен-берсе узып ташлар, кулдан эшләнгән уклар оча, утлы шартлаткычлар гөрселди, балаларга хас чыр-чу күтәрелгән иде.

Якындагы мәчеткә кереп гыйбадәт кылганнан соң, дәрвиш, яшеллеккә төренгән ишегалдыннан тузанлы тыкрыкка чыкты. Аның яныннан гына шәкертләр йөгереп узды. Каядыр ашыгалар, күрәмсең. Бәлкем, берәрсе мәрхүм булгандыр да шунда чабалардыр. Мәет озату да — эш, кәсеп. Монысы, ябык, иске, таланып беткән киемлесе, мөгаен, бай, хәлле сабакташына самавыр куярга йөгерәдер. Ә бәлки ниндидер сәүдәгәр белән Мәкәрҗәгә ярминкәгә барырга килешкәндер, анда ул трактирга идән юучы яисә базар мәйданын себерүче булып яллана ала һәм бер айдан ничәдер сум белән кайтып төшә.

Дәрвиш, бер малайны дәшеп туктатты да аннан ябык кына, басынкы, юаш Габдулла исемле шәкерт турында сорашты.

— Сез, мөгаен, Габдулла әфәнде турында сорыйсыздыр? — Шәкертнең аксыл күперенке битендә шаян-шук чаткылар күренеп алды. — Гыйбадәттә булмады ул. Үзенең хөҗрәсендә тәмәке тартып утырадыр әле. — Аннары җитди итеп: — Әйе-әйе, аңа хөҗрә бирделәр! Гомәр хәлфә хаҗ сәфәрендә булганда, кечерәк сыйныфларга дәрес тә бирде әле. Ул анда кара такта куйды, аңа акбур белән язды. Аннары аңа акбур кеше сөякләреннән ясалган, дип аңлаткач, туктады.

Шәкерт сикерә-сикерә чабып китте, дәрвиш чаттан уңга — «Мотыйгия» мәдрәсәсенә таба борылды. Элегрәк тә ул монда туктала иде, шунда бала чактан ятим калган яшь мәхдүм белән дуслашып китте. Алар әле бервакыт җәй буе икәүләп сәяхәт тә кылдылар.

Мәдрәсәнең капка төбендә туктап, ул як-ягына каранды, дөресрәге, нәрсәдер аны борылып карарга мәҗбүр итте. Юл аша нәкъ каршыда, тимер-томыр сата торган кибет янында, Истанбул бугазындагы хезмәттәшенә ике тамчы су кебек охшаш шымчы эсседә кагаеп тора иде. Дәрвиш, аны белмәгән кеше, тынычлык саклаучы дип уйлыйдыр дип көлемсерәде.

— Барысы да Аллаһ иркендә, — дип мыгырданды дәрвиш һәм капкадагы боҗраны борды. Ишегалдында салкынча, күләгә төшкән. Ботаклары җиргә иелгән сәрви куаклары арасыннан сары ком сибелгән сукмак күренде. Сукмакта сикереп уйнашкан чәперчекләр, карт якынлашкач, тыныч кына читкәрәк авыштылар. Җәйге ачык корылма кырыендагы яшел үләндә җирән мәче сузылган. Корылма тәрәзәләренә эчке яктан алача элегән, ишектә әкрен генә киндер тукыма җилферди. Япманы ачып бер үсмер малай чыкты, күлмәгенең итәге чалбарга кыстырылмаган, йөзе озынча, саргылт, ябык, карап торышка ук йомшак чәче коңгырт сары. Дәрвишне күрүгә, ул кулына тоткан түбәтәен башына чәпәде һәм шатланып, шул ук вакытта оялып, картның каршына килеп басты, күрешергә дип ике кулын сузды.

— Миңа сине гыйбадәттә булмады дип әйттеләр, — диде дәрвиш, күрешкәч. — Бәлки авырыйсыңдыр?

— Мин гыйбадәтне ялгызым гына кылырга яратам, — дип җавап кайтарды үсмер, авырганын, хәзерге вакытта үзен тагын да начаррак хис иткәнен сиздерәсе килмәде. Быел яз унсигез яшен тутырса да, дәрвиш белән соңгы очрашудан соң әллә ни үзгәрмәве, һаман да ябык, кыска буйлы булып калуы өчен уңайсызланды.

— Рәхим итегез, суфый бабай, — диде ул ягымлы итеп һәм авыр киндер пәрдәне ачты.

Карт эчкә үтте. Сары буявы кыршылып беткән идәнгә утырып, халат кесәсеннән дисбе чыгарды. Бармаклары хөрмәнекенә охшаган озынча каракучкыл төшләрне берәм-берәм күчерә башлады.

— Мин самавыр куям, — диде егет. — Безгә беркем комачауламый, бар да ялга таралышты. — Ул елмайды да йөгереп ишегалдына чыгып китте. Күп тә үтми әйләнеп керде, аякларын чалыштырып, карттан бераз читтәрәк утырды. Дәрвишнең күзе ярымйомык, бармаклары исә дисбе төшләрен чак-чак кына кыймылдата.

Җәйге корылмага үтеп кергән агач күмеренең исе шулкадәр тансык, тәмле, аңа чәчәкләр, кояшта җылынган яфраклар, Габдулла яңа гына ачкан калай савыттагы чәйнең хуш исе өстәлеп, башны әйләндерә. Егет тиз генә чыгып, самавырны алып керде һәм идәнгә бастырды. Самавыр рәшәткәсе аша җемелдәгән күмернең кызыл төсе идәнгә күчте. Габдулла чәй пешерде, аннары киндер капчыкның төбендә калган тозлы эремчектән катырылган кечкенә йомарламнар белән җәлпәк төче көлчәләрне өстәлгә бушатты.

— Шикәрем генә бетте. — Ул касәгә чәй агызып карт алдына куйды. — Өченче елым инде үземне үзем туйдырам, суфый бабай. Балык тотам, бай балаларына укырга булышам. Өйдән-өйгә йөреп Коръән укыйм. Җеназага йөрмим, ярминкәләрне дә яратмыйм.

— Ник?

— Йөрмим. Безнең гореф-гадәт, йолалар кырыс, күз яшьләре кабул ителми, хатын-кызлар кайгыдан сынсалар да сиздермәскә тырыша, ир-атларны таштан яралган диярсең...

— Газап-михнәт турында кычкырып йөрмиләр, — дип, үгет-нәсихәт бирде карт.

— Шулайдыр, мөгаен. Елый алмаган кешеләрдән көнләшәм мин. Әмма үзем күз яшьләремне тыя алмыйм... Белмим, бәлки мин йомшак, көчсездер. Утын кисәргә китүем хәерлерәктер.

— Ай-һай, синең турында артык горур, диләр. Алай ихатадан ихатага йөрмәссең. Син бит мәхдүм баласы, мулла оныгы, сезнең нәселнең җиде буыны мулла булган.

— Мине дөрестән дә тәкәббер, һавалы, диләр. Ләкин ул алай түгел, суфый бабай!..

Карт, кулын сузып, учын үсмернең ябык иңенә куйды.

— Улым, — диде ул, ачы көлемсерәп, — дөньяда хыялланудан да яхшы нәрсә юк. Әмма ул бик азларга гына бирелә. Көнкүрештә кайнашу күңелне вагайта; байлык һәм танылу бала кулындагы уенчык кебек, аны төшереп югалтырга мөмкин. Безнең тәнебез туфрактан барлыкка килгән һәм туфракка әйләнәчәк. Шагыйрь болай дигән:

Тәүге сулыш алган мизгелдән
Ашыга җан югалу көненә.

Мәгарри бит бу! Фәкыйрь дәрвиш ул юлларны каян белә?

— Дөресен әйтегез, сез дөньялыкта танылган һәм гыйлем иясе кеше идегезме?

— Мин чүп җыючыдан да ярлырак идем, — дип җавап бирде карт. — Хәзер байлыгымны алтын белән чагыштырмыйм. Менә синең белән китәрбез дә, борынгы китапларның зирәклеге сәүдәгәрнең сатып алучы белән сүз көрәштерүеннән әйбәтрәк икәненә төшенерсең.

— Китәргә? — дип кабатлап сорады егет. — Тыныч кына дога кылыргамы? Әмма безнең гомер башкалар өчен бәхет түгелмени?

— Юк, улым, рухны аңлау өчен, ирекле булырга кирәк.

— Рух никадәрле хакыйкатькә күтәрелергә мөмкин соң?

— Хакыйкать шунда: дөнья тәртипкә салынган һәм анда сәбәпләр нәтиҗә

белән бәйләнгән, галәм галәм белән тоташа, гамәлдәге кайбер нәрсәләр башкаларына әверелә. Галәмнең шаккатыргыч гаҗәеп яклары бетмәс-төкәнмәс, аның очы-кырые юк.

— Әмма дөньяда яманлыклар да күп.

— Дөньяда бар да: яманлык та, яхшылык та җитәрлек. Бoҗраның кара тәрткесенә төртелсәң, шуны бел: кайдадыр югары урында син кичергәннең капма-каршысы бар. Җир тышча белән капланган һәм менә нәкъ ул вакыйгалар һәм күренешләр белән боҗра буенча идарә итә. Югарыга менеп җитә дә егылып төшә, сиңа алмашка исә Искәндәрме анда, Әфләтунмы — башка берәү баса. Бар да боҗра буенча хәрәкәт итә, бары тик адәм гомере генә ук кебек турыга китә... Улым, теге рәхәт, бәхетле җәеңне онытмадыңмы?

— Юк, исемдә.

Алар җәй буе каладан калага, авылдан авылга йөрделәр, казакълар көтүләре белән җәйләгән далалар буйлап бардылар, төннәрен карт аңа үзенең озын гомер юлында күргәннәре һәм ишеткәннәре турында сөйләде. Онытылмас җәй булды ул!

Ул арада егет тәгәрмәчләр шыгырдавын, ат пошкыруын ишетеп алды, менә ат тоягы белән капкага типте. Габдулла тиз генә урыныннан торды да чаршауны ачып тышка карады һәм атның акрын гына кешнәвен аермачык ишетте.

Ул ишегалдына йөгереп чыкты һәм Камил мөгаллимне күрде. Тегесе исә кулындагы камчысы белән сукмак тирәли үскән куакларга җай гына селтәнгәләп килә иде.

— Хөрмәтле шәкерт әфәнде, — диде ул күңелле генә, — сез гадәттәгечә йокы симертәсездер инде... шундый көндә!

— Акрын, минем кунагым бар.

— Кем инде ул?

— Суфый бабай.

— И-и! — Ул, ачы миләш капкандай, йөзен чытты һәм җәйге корылмага атлады. Дәрвиш алдында исә ул бик сөенгән кыяфәт чыгарды, бар кагыйдәсенә туры китереп, иелеп сәлам бирде.

Карт исә гади генә: «Исәнме», — дип җавап кайтарды. Элек-электән аңарда Камил кебек имәндәй таза, көяз адәмнәргә карата яшерен нәфрәт сакланып калган. Янып торган йөзе, кыйгачланып күтәрелгән каш, туры зур борын — мондый кыяфәт җиңү яулаган сугышчыныкын хәтерләтә. Киемен күр — ничек фырт киенгән: буйлы һолланд күлмәге, тар балаклы чалбар, штиблет, башында юка бәрхет кәләпүш. Керә-керешкә ул кыбырсый башлады, Габдуллага: калдырсана бу карт сукбайны дигән ишарәләр ясады. Габдулла әле кашын җыерып, әле көлемсерәп дигәндәй, савыт-сабаны җыештырды, аннары картка юлдан соң хөҗрәсендә ял итәргә тәкъдим итте. Әмма карт кире какты: монда — саф һавада рәхәтрәк иде.

## 2

Тояк тавышы, тәгәрмәчләр шыгырдавы куе тузан эчендә йотылды. Җил, тирләгән атның селәгәен эләктереп, читкә ыргыта.

— Киттек елгага, — диде Камил. — Бердәнбер котылу юлы — чишенү дә суга чуму.

Алар, тузан эчендә утырган балчык өйләрне узып, таллык белән капланган сөзәк кичүгә таба көтү сукмагы буйлап киттеләр. Ап-ак каз мамыгы өстеннән агым буйлап өскә күтәрелделәр һәм кырыйларын куе әрәмәлек уратып алган эре бөртекле алтынсыман комлыкка килеп җиттеләр.

Атны туарып, кыяк үлән үскән тирәгә тышауладылар. Камил шунда ук

чишенергә тотынды: штиблет, күлмәк, кәләпүш комга очты. Егеткә егерме ике яшь булса да, малайлыгы чыгып бетмәгән, әмма ул үз-үзен кулда тота белә: ни әйтсәң дә — тирә-якта дан тоткан мәдрәсәнең танылган остазы — ахун улы! Үзе исә Каһирәдәге Әл-Әзһәрне тәмамлап, әтисенең мәдрәсәсендә белем бирә. Өстәвенә озын хикәяләр яза һәм үзенең нәшриятын булдыру турында хыяллана.

— Ант әгәр, син әле белмисеңдер дә, ишетмәгәнсеңдер дә?! — диде Камил. — Шәрифов завод хуҗасы Ибнеәминовка язу ташлаган, диләр. Анда шул вакытка шул урынга мең сум куегыз дип язылган, имеш.

— Шәрифовка аның хәтле акча нәрсәгә?

— Көч белән тартып алу, инкыйлаб өчендер дип беләм. Синең шул дәрвишнең әкиятләреннән башка берәр нәрсә турында ишеткәнең бармы соң? Башкалада, көньяк заводларда ниләр майтаралар! — диде Камил, үз сүзләренә үзе соклангандай. — Сеңлем Диләфрүз исә шәфкать туташы булып язылган!..

— Маньчжуриягәме?

— Халык йортында лазарет ачалар. Бу турыда да колагыңа чалынмадымы? Порт-Артурны камап алу турында да?

— Алайса тиздән җиңү дип кычкырырга да ярый. Шул ук Шәрифов... сугышка китәм дип ни әтәчләнде, — Габдулла көлде. — Бу инкыйлабчы ничек итеп тормышны башкача төзү турында хыяллана икән соң, ул бит безнең бер катлау кешесе икенчесенә каршы бармый дип фараз кыла?

Камил беркадәр каушап калды:

— Чыннан да, аның фикере каршылыклы. Ләкин бергәлек безне күп кенә бәлаләрдән саклап калды, шулай бит.

— Хәзер нәрсәне бәла-каза дип әйтергә дә белмәссең. Безнең кешелек дөньясы картайды, анда элеккеге гадәтләр канунлы санала, кануннар шулай ук искерә. Без үткәнне саклыйбыз, дибез, үзебез бүген яшәгән искелекне яклыйбыз. Безнең искелек дөньясы киләчәктән курка.

— Гафу, син киләчәкне ничек күзаллыйсың?

— Минем алдан күрү сәләтем юк, — дип, кыенсынгандай, җавап кайтарды ул. — Тик мин үземнең ни теләвемне беләм... Балтыйк буйларын күреп, маҗарлар җырын тыңлап, Балбәк каласының ташларын тотып карар идем... халыклар арасында уртаклык бармы-юкмы икәнен аңлыйсым килә. Гарәпләрдә шундый мәкаль бар: «Инҗир агачы икенче инҗир агачыннан күреп, җимеш бирергә өйрәнә». Хәтерлисеңме?

Камил көлде:

— Шул ук гарәпләр: «Хөрмә пальмасына текәлеп карама, ул чит-ятлар белән сөйләшми», — дип тә әйтә.

— Без, мөгаен, мәкальләр буенча эш йөртәбездер. Шуңа үз-үзебезгә бикләнгәнбез.

— Без бит гореф-гадәтне, йолаларыбыз, мәдәниятебезне яратабыз...

— Һәм бу турыда ничек дәртләнеп әйтәбез! Тик хәзер ярату хакында андый ягымлы сүзләр белән сөйли алмыйбыз, чөнки ярату дигәнебез ачы бит. Шәрифов... Әйсәнә, кирәге бер тиен! Үзең нишләргә җыенасың — китаплар язаргамы, балаларга белем бирергәме? Әллә инде инкыйлабчы булырсыңмы?

— Барысын да колачлар идем! — диде Камил. — «Бәхетле Мәрьям» Петербургта басылачак — әйтергә оныткамын.

— Нәрсә диим, тәбрик итәм.

Камил, чынлап та, үзенең бар нәрсәгә көче җитә дип саныйдыр, ахрысы. Дөньяда ниләрдер майтарыла, нәрсәдер какшый һәм җимерелә, яңа катламнар күтәрелә, элеккеге бернигә ярамый дип, яшәп килгән тәртипләрне үзгәртергә

йөргән ниндидер яңа кешеләр килеп чыга. Камил, бәлки, шундыйларның берседер?

Тик нигә, татар әдәбиятында болай да аз урын алмаган мелодрамалар язып мәтавыкланганчы, шуларның барысы турында тәфсилләп язмаска? Аның әсәрләренең тормыш-яшәеш белән, хәтта үзенеке белән дә бәйләнеше бик аз. Әтисе сәүдәгәр кызына өйләнергә тәкъдим иткәч, ай-һай, ничек күтәрелеп бәрелгән иде! Әмма барыбер өйләнде, бер елдан соң шатланып, зур өметләр белән Истанбулга укырга китте, аннары Каһирәдә дәвам итте. Өенә әйләнеп кайткач, сабыр, күндәм хатынының эшләренә комачау ясамавына тагын бер кат инанды. Ул әтисенең мәдрәсәсендә мөдәррис булып урнашты, «Мантыйк», «Мөселман кануны», «Коръән тәфсире»н укый, иҗат итә, Фламмарионны көйләп сөйли. Төннәрен исә чорма тәрәзәсеннән, күзәтү торбасы аша галәмдәге яктырткычларны күзәтергә ярата. Башка шөгыльләре кебек үк, астрономия белән кызыксынуы аны тәмам йөгәненнән ычкындырды... Күңеле түземсезләнеп нидер көтә, көч-куәте ташып тора, ул иртәләрен манарага менеп, намазга чакырып азан әйтә, аның җырлап торган яшь, дәртле тавышы Мәгъмурия тыкрыклары өстеннән әйләнә.

Күңеле төшенке вакытларны ул чамасыз авыр үткәрә. Көчле ярсуы өметсезлек, курку һәм ышанмау хисләре белән алмашына. Менә хәзер дә Габдулланың яңа хәбәрләргә тотнаклы мөгамәләсе аның кәефен бозды.

— Ярар, ташла хикәяне, — диде ул, күңелсезләнеп. — Беләм, ул сиңа ошамый... Аннары: әйдә, атны коендырабыз, — дип, кара тирәклеккә таба йөгерде һәм бурлының тышавын салдырды.

Атны коендырдылар, үзләре дә туйганчы йөзделәр дә кайтырга җыендылар. Камил бурлыга җиңел генә камыт кидерде, дирбиясен төзәтте, мичәүкәләрен тарттырды, шул арада үзенең шәкертен өйрәтергә дә онытмады:

— Син, Габдулла, ул дәрвишләрең белән азрак аралашырга тырыш. Синең шикеллеләрнең башын әйләндерү өчен алар шундый томан очыралар. Көлмә, зинһар, мин үзем шәхсән юк-бар сүз, сафсатадан тәмам гарык.

Ярымчүлле бу якларга идарәчеләр элек-электән үзләренә кирәкмәс адәмнәрне сөргәннәр; төрле фетнәчеләр мондагы җирле халык янына сыену урыны эзләп качкан. Җирлеләр арасында бигрәк тә поп, муллалар, дәрвишләр, качкын солдатлар һәм сөргендәгеләр аерым хөрмәттә булган. Сәләмә киемгә төренгән кайсыбер маҗарачы ярылган киң тәресе белән чукындыруы була, ыжгырып торган казак шунда ук, күзләрен яшьләндереп: «Фатихаңны бир, атакай», — дип сорый башлый. Мөселманнар яшәгән җирлекләрдә дәрвишләргә зур хөрмәт белән карыйлар, тик алар арасында да төрлеләре очрый. Әмма суфый бабайны ошатты Габдулла. Аңа калса, карт үзенең күңелендә халык алдында үтәлмәгәннең ачы юшкынын һәм ниндидер котылгысыз хакыйкатькә ышанычын йөртә...

...Кайтыр юлны сүзсез үттеләр. Зур Михайловскоега җиткәч, Камил:

— Әйдә безгә, кичке ашны бергәләп ашарбыз, — диде. — Әти син килгәнне ярата.

Габдулла башын чайкады.

Әмма ахырдан бармавына үкенде. Мотыйгулла хәзрәт Габдулланы әле малай чагында ук иркәләп куенына сыендырды, аңа үзенең китапханәсеннән Хафиз, Мәгарри, Сәгъди китапларын бирде, шигырь төзелешен — гарузны өйрәтте һәм өенә җыелган яшьләргә аны акыллы, китап сөюче буларак тәкъдим итте. Юк-барларга ышанудан ерак торган Мотыйгулла хәзрәт балаларын заман рухында тәрбия кылды: кызлары укымышлы, музыкаль белемле, калада исеме танылганнар арасында хөрмәт белән телгә алыналар. Олы кызы Галия

— җырчы, артистка булу теләге белән яна, дөрес, башка җәмгыятьтә булса, хыялы тормышка да ашкан булыр иде. Диләфрүз әле бик яшь, ул һәр нәрсәдә яңалык кына эзли, киләчәкне гел алсу төстә генә күреп куана, сөенә.

Элеккеге нигезләр какшап, үзгәрешләр булачагы турында күп сөйлиләр, хатын-кыз иреге турында да сүзләр күп йөри; абыйсы бу вакыйгаларның уртасында кайный; якын кешеләренең җәмгыятьтәге эшчәнлеге, әйтерсең, бары аның өчен, алда көткән гаҗәеп матур киләчәк өчен. Аның балаларча тәэсирле самими теләкләре абыйсына яктылык сирпи кебек, Габдулла да Камилне ничектер үзенчә якын күрде. Әмма аларның өйләрендә сирәк була иде.

Йөреп кайтканнан соң, ул хөҗрәсенә керде, иске киез җәелгән тар агач сәкегә сузылды һәм, тәнендә рәхәт оеганлык тоеп, күзен йомды.

Йокылы-уяу изрәп ятканда, колагына: «Әниемне алып китмәгез, әниемне алып китмәгез!..» — дигән тавыш керде. Озын киндер күлмәкле, чәче кырып алынган, яланаяклы малай — бу үзе иде. Димәк, Габдулла үзен күрә, үзенең карлыккан, үзәк өзгеч тавышын ишетә.

Ир-атлар әнисенең гәүдәсен яшел чатыр капланган җеназага сала. Ул алар артыннан калмаска тырышып, кар өстеннән яланаяк йөгерә. Ир-атлар кызу-кызу атлый, ул алар артыннан җитә алмый туктап кала, аяк астындагы карның салкынлыгы тәнгә үрмәли, коры суык тамакны ярып эчкә үтә. Карлыккан тавышы белән сулкылдап, ул кире борыла...

Әнисен мәчеткә алып киләләр, мулла дога укый, иелеп, кулын чатыр кырыеннан йөртеп чыга һәм: «Яхшы кеше идеме?» — дип сорый. Аның артында торган ир-атлар беравыздан: «Яхшы кеше иде», — дип җавап кайтара. Аннары җеназаны мәчеттән алып чыгалар. Кабер казучылар, зираттагы көпшәк карны таптап, сукмак салган. Кызгылт балчык өеме янында яңа казылган кабер авызы ыржаеп тора.

Тизрәк уянырга кирәк, һәм ул күзен ачты. Саташумы бу? Искә төшерүме? Әнисен ул яхшы хәтерли. Малайга яшь тулганда дөнья куйган әтисе дә истә кебек. Икенче кат кияүгә чыкканда әнисе калдырып торган карчык та хәтерендә, Кушлавычтагы крәстиян гаиләсе дә, аннары Кырлайдагы асрамага алган гаиләсе дә күз алдында. Инде Газизә апасы алдырганчы тәрбияләнгән һөнәрче ир белән хатынны бик яхшы хәтерли.

Унөч яшендә ул үзен күп истәлекләр белән бәйле озын гомер юлы узган кеше кебек тойды.

...Ул урыныннан күтәрелде, торакта үзенең почмагын аерып торган чаршауны кырыйга тартты, сәкеләр арасыннан барып тәрәзәне ачты. Тышта эңгер-меңгер куерып килә, елга өстеннән искән кичке дала җиле су исенә әрем һәм чабыр исләрен ияртеп китерде. Бакчадан ишетелгән тавышлардан дәрвишнекен аерса да, икенчесенең кем икәнен тәгаенли алмады. Аннары таныды: элеккеге сабакташы Хикмәт икән. Кышын ул, мәдрәсәдән китеп, Шәпинең төрле ашамлыклар сата торган кибетенә урнашты, чана тартып бистәләрдә, якын-тирә авылларда китап белән сәүдә итте. Барлык кибетләрдә дә китап саталар иде. Өстәвенә, Хикмәт әлифба әзерләү белән дә мәшгуль булды. Агач шакмаклар ясый, аларга хәрефләр ябыштыра һәм менә — әлифба әзер.

Аның мәдрәсәдән китәр исәбе юк иде, әмма ярдәм итәр кешесе булмады, башка төрле өстәмә акча эшләү юлын исә таба алмады. Үткенрәк шәкертләр җеназаларда эшләп алды, ярминкәләргә йөрде, далага китеп, казакъ балаларына сабак укытты. Иптәшләре әйткәнчә, Хикмәт — сарык бәрәне, аның кулыннан мондый эшләр килмәде. Кибеттә ул ач булмады, өс-башы бөтен иде, әмма мәктәпне бик сагынды һәм аз гына буш вакыты килеп чыгуга, шунда йөгерде.

Габдулла тәрәзәне яба төште һәм әкрен генә, өйгә терәп салынган ачык корылмага чыкты. Тамагы кипкән иде. Тәбәнәк өстәлдәге тар муенлы чүлмәктән рәхәтләнеп су эчте. Аннары тамагы нык ачыкканын абайлады. Тартасы килү теләге туды. Шулай бервакыт ул үзе өчен ачыш ясаган иде: тәмәке тарту ачлыкны баса икән. Әүвәл баш әйләнә, тамак төбен яндыра, озак та үтми, ашыйсы килми башлый. Ул, борылып, хөҗрәгә керде, сандыгын ачып, тәмәке алды да кабаттан җәйге корылмага чыкты. Баскычның соңгы басмасына утыргач, тәмәкесен учына яшереп тарта башлады.

Камил белән барасы, кичке ашны шунда ашыйсы булган, дип үкенде ул. Хәзрәт аны ярата, үз күрә, рәхәтләнеп сөйләшеп утырган булырлар иде. Тик йортта хатын-кызлар да бар бит әле?.. Алар өчен ул ярлы шәкерт, гап-гади бер малай. Ипи-тозлы, кунакчыл шат йорт гадилек һәм һавалылыкны бергә сыйдырган. Анда аяныч мин-минлек хөкем сөрә һәм хуҗалар башка бай йортларда ничек, үзләрендә шундый мохитне булдырырга тырышканнар...

Аяк тавышлары ишетелде. Дәрвиш белән Хикмәт бакчадан чыкты.

— Хәлең ничек, улым? — дип сорады карт.

— Рәхмәт, сәламәтмен. — Габдулла эченнән генә картның китүен теләде.

Карт китте. Нәрсәдәндер кыенсынган Хикмәт көлемсерәп сүз башлады:

— Тыңлале, Апуш, мәхәббәт бар иҗатчылар тарафыннан да ихтирам ителә. Төн — гашыйклар өчен оҗмах, диләр.

— Дөрес, — диде Габдулла, елмаеп. — Шигырь яздың, ахры?

— Булдыра алсам иде!.. Апуш, бакчадагы чатырга, әйтик, тыйнак кына бер кеше... әйтик, бер кыз килсә, ни әйтерсең? Сүз бирәм, бераз гына утырабыз да китәбез. Ян капкадан керербез дә шыпырт кына шуннан чыгып сызарбыз, ә?

— Бар, алып кил үзеңнең тыйнак кызыңны, — диде Габдулла. — Тик шуны бел: күрше ишегалдындагы Гомәр хәлфә бик соң ята.

Ул суган суфыенең көлкеле вәгазьләре турында кайчандыр Диләфрүз сөйләгән иде.

— Ха-ха-ха, — дип көлгән иде Диләфрүз, — ул карт азгынга әйтегез әле, үзенең асравын тынычлыкта калдырсын!

Диләфрүз исенә төшкәч, аны сагыш биләп алды.

Асрау... исеме ничек иде әле? Матур кыз иде бугай. Бәлки Хикмәт белән очрашуга ул килгәндер, агачлар арасыннан ишетелгән тыенкы гына көлү авазы анныкыдыр?

Җәй ахырында шәкертләр мәдрәсәгә әйләнеп кайта. Олырак яшьтәге азгыннар һәм чит кеше хатыннарын ауларга яратучыларниләр генә сөйләми?! Җирәнгеч тоелса да, озын караңгы кичләрдә шуларны тыңлагач, бу күңелсез, сәер ялыктыргыч төннәр җиңелрәк үтә. Йолдызларның берсе артыннан икенчесе атылганын күрәсең дә, күңеләңә тынычлык иңә: фәрештәләр йокламый, алар җиденче кат күккә күтәрелергә маташкан иблисләргә таш ата. Сине гөнаһлардан саклаучы фәрештәң дә уяу — менә йомшак кына җил уң яңагыңнан сыйпап китә. Бу ул — синең фәрештәң, гөнаһтан саклый. Егет кулы белән йөзен каплый һәм аның кайнарлыгын тоя. Юк, юк, үзеннән олырак сабакташлары эшләгәннәрне ул беркайчан да кабатламаячак!..

Бистәнең иң кырыендагы алачыкта Фатыйма яши. Бу алачык ирекле мәхәббәт атавы, анда ике гөнаһлы болытка әверелеп йөзә. Фатыйма яныннан шәкертләр өзелми. Мәет юып алган тиеннәрен учларына кысып, алар алачыкка йөгерә, әйтерсең, тормыш йолаларын үтәргә ашыгалар — гөнаһны, яшәүнең бөтен тәмен тоймакчы булалар. Хәлдән таеп йокыга киткәч, төшләренә хур кызлары, оҗмах алмалары, Сират күперен кичү керә. Кайберләре, җәһәннәмгә егылып төшүләрен күреп, куркудан кычкырып уяна: андыйларны сәлперәйгән тиреле, әмма җылы һәм тере хатын-кыз кулы тынычландыра.

Фатыйманың сандыгында ниләр генә юк: киптерелгән яшькелт коңгызлар, үлән, тамырлар дисеңме. Ирләренең ирлек куәтен арттырып, шул дәрттән балага узарга теләгән яшь киленнәр яшертен генә аннан үләннәр ташый. Никтер аның ул үлән-тамырлары үзенә ярдәм итми, ул да, югыйсә, бала телидер? Ләкин юк, имеш-мимешләр аңа каргыш төшкән, ди. Аны иблисләрнең берсе — Һарутмы, Марутмы хатынлыкка алган, имеш...

Габдулла җиңелчә борчулы киеренкелек белән агачлар арасына күз йөртеп тыңланды: кызның көлү тавышы ишетелмәсме, ачык төстәге күлмәге чагылып китмәсме? Ул тирән сулыш алды һәм, башын артка ташлап, күккә карады. Биектә-биектә, ай яктысында әле аксылланып, әле икенче төскә кереп алмашынган дала елгасы кебек, Киек Каз Юлы күренә. Зәңгәр очкыннар белән ялкынланып, Зур Эт йолдызлыгының иң якты йолдызы балкый.

Егет урыныннан торды һәм, тәмәке тартырга теләп, үзенең хөҗрәсенә юнәлде. Ул, кунагын борчымаска теләп, тавышсыз гына кергән иде. Әмма карт анда юк иде. Габдулла аны җәйге корылмада да тапмады. Бичара карт үпкәләп киткән, ахры. Хәерле юл сиңа, дәрвиш! Ул аның юлда булуына шикләнмәде. Аңа, сәфәрчегә, кич ни, төн ни: төнге җанварлар аның күңелен сөендерә, усал сәяхәтче өчен ул табыш түгел... «Үзе белән өндәде бит мине», — дип дулкынланып уйлады егет. Җиңелчә үкенү хисен сагыш алмаштырды. Бер җәйне, ай-һай, ничек әйбәт үткәргәннәр иде алар!

Егет, ялын төрләндерер өчен, дәрвишкә ияргән иде, җае чыкса, казакъ балаларын укытырга да өметләнде. Әмма бу бичара, хәлсез картта нindидер серлелек яшеренгән иде кебек. Нәкъ менә ул гомернең очсыз-кырыйсыз булуын, һәркемгә карата шәфкатьле, миһербанлы булырга кирәклекне, хакыйкатьне ярату — ышану хисләрен үзендә туплаган иде шикелле. Аның белән бер көндә елны әйләнеп чыгарга була, бер елы исә — вакытка тиң. Менә шушы тоемлау аны бәхетсез карт белән очрашуга этәрде микән, бәхетсез дип... бәлки ул үзен бәхетле сизәдер, чөнки чарасызлык дигән төшенчәне белми, ахмак, тормышка ашмаслык булсын — шулай да өмет өмет инде ул.

### 3

Ничәдер көн узгач (ул исәбен алып бармады), читләрен тирәкләр, чәнечкеле куаклар урап алган «кыргый урман» эчендәге кечерәк кенә аланда төн кунарга тукталдылар.

Иртән алар бала елаган тавыш ишетеп, гаҗәпкә калды: бу урыннарда кеше яшәми, сирәк-мирәк утарлар бар, алары да яр буйларына урнашкан, монда бит хәтта елга да юк. Бәлки төлке балаларыдыр? Әмма дөрес ишеткәннәр: бала елый!

Тармакланып үскән кәкре кәүсәле кыргыз каены янында көймәле арба күренде. Аның тирәсендә кемнәрдер кайнаша. Болар якынлашуга, ачы тавыш таралды:

— Якын килмә! Тукта, дим, тукта! — Кечкенә буйлы арык гәүдәле ир-ат, җиңел коралын алып, аларга төбәде. — Якын килмә, атам!

— Бу башсыз тидерә алмас, анысы, — диде Дәрвиш. — Әмма ату тавышы балаларын куркытырга мөмкин. Күр бичараларны, аналарына ничек сарылганнар.

Әни кеше ул арада ике зуррак кызын калдырды да итәгенә тагылган кечкенәсе белән иренә таба атлады:

— Тукта, Мамадыш. Күрмисеңмени, болар киң күңелле мосафирлар, мөселманнар. Безгә начарлык кылмаслар. — Аннары сәфәрчеләргә карап: — Курыкмагыз, килегез монда, — диде.

Арбага баулар белән ныгытып бәйләнгән сандык янында, чүпрәк-чапрак арасында алганны-салганны белми бер ир бала елап ята. Арбада малай белән сандыктан кала берни юк. Балага дүрт яшьләр тирәсе булыр.

— Улыбыз авырып китте, — диде хатын һәм арба янына килеп, ирексездән чүпрәкләрне ачкалап куйды, юлчылар бичара малайны күрсеннәр, янәсе. — Елый да елый... нишләргә дә белгән юк!

Дәрвиш, хатынны тыныч кына читкәрәк этеп, арба янына килде. Кечкенә буйлы ир-ат та коралын үзеннән калдырмый каршысына килеп басты. Коралы агачтан икән, кирәге-ние чыга калса, куркыту өчен ярар дигәндер, күрәмсең. Күсәк тотса, ышанычлырак булыр иде.

Көлемсерәгән дәрвиш чүпрәк-чапрак арасыннан малайны аралап алды. Аны бер кулы белән ныгытып тотып, икенчесе белән чүпрәкләрне җиргә ташлады һәм шулар өстенә малайның авыртудан бөгәрләнгән арык гәүдәсен салды. Аннары үзенең юл капчыгыннан пыяла савыт чыгарды, аның майланган чүпрәген салдырып, савытка бармагы белән манып алды һәм шифалы дару белән малайның шәрә корсагын уарга тотынды. Бала кычкыруын дәвам итсә дә, тавышы үзгәрде.

— Зарар юк, — дип мыгырданды дәрвиш. — Койрык маеның шифасы тими калганы булмады моңарчы. Кайнаган су әзерлә! — дип боерды ул хатынга.

Учактагы күмер сүнеп бетмәгән икән, хатын ташлаган коры ботак-чатак шундук янып китте.

Су кайнап чыккач, хатын аны калай савытка салып картка сузды.

— Хәзер яшел чәй эчерәбез дә йокларга салабыз, — дип сөйләнде ул. — Уянгач, менә моны бирерсең... — Хатынга тозлы эремчектән ясалган коры корт йомарламы сузды. — Иншалла, — диде ул, малайның сирәк кара чәчле башы тирәли кулын йөртеп. — Чәчен алырга кирәк. Калага кайткач, малайны сөннәткә утыртыгыз.

Хуҗа инде арба тирәли мәш килә, бауларны тарттырып бәйләде, аннары арбага чәйнек, казан, өчаякны алып салды да кулына чыбыркысын тотты.

— Сиңа әйтәм! — диде ул, тавышын күтәреп. — Акрын кыймылдыйсыз. Барып җитәсе бар.

— Кая юл тоттыгыз? — дип сорады дәрвиш.

— Ә-ә, сихерче, — картны әле генә күреп алгандай гаҗәпләнгән чырай чыгарды ир-ат. — Уһу, сихерче Мидхәтне савыктырган, кара нинди тылсымчы! — Ул картны әрли, әмма үзе канәгать, бары аңа түли алмавы өчен генә гарьләнә иде бугай. — Йә! — дип кычкырды да чыбыркысын шартлатты.

Хатын йоклап киткән улын кулына күтәрде һәм чирәмнән авыл юлына төште. Аның артыннан ат кузгалды, арба кырыеннан хуҗа, арттан җитәкләшеп кызлар атлады. Юлга чыккач, хатын кырыйга тайпылып, арбаны уздырып җибәрде дә кызлары белән бергә китте.

Озак бардылар. Кояш кичкә таба да сүрелмәде. Шул вакыт эчендә юлда бер тере җанны очратмадылар.

Малай әнисенең кулында йоклавын дәвам итте, кызлар боек кына бер аяктан атлады, барысы да, авызларына су йоткан сыман, үз алларына карап барды да барды.

Ниһаять, ат туктады һәм хуҗа, ачуы килеп, чыбыркысы белән аяк астындагы тузанны туздырды.

— Ат арды, — диде хатын.

— Ничек арган, ничек арган? — дип кычкырды ир-ат. — Нәрсә суган сатасың!

— Ат арган, — дип кабатлады хатын. — Азрак ял иттер.

Ул арада малай уянды һәм ашарга сорап еламсырый башлады. Әнисе, карт кушканча, аның кулына корт кисәген тоттырды. Малай авызын чапылдатты, хатын аны чирәмгә утыртты да үзе куак артына китте.

Ир кисәге кабаланмый гына атны туарды, аның башыннан сыйпап, үзенең бер дә юкка дуамаллавы өчен гафу сорагандай итте.

— Гафу итегез, Мамадыш абзый, — диде Габдулла. — Сезнең исемегезне әйтәм... Мамадыш бит авыл атамасы. Сез әллә шул яктанмы?

Тегесе дәшмәде.

— Әйе, — дип раслады куак артыннан килеп чыккан хатыны. — Без Мамадыш авылыннан. Иремнең исеме — Фатих.

— Нәрсә ялганлыйсың! — дип ярсыды Фатих-Мамадыш. — Минем борынгы бабамны Мамадыш дип атаганнар, мин дә Мамадыш! Авыл юк, барысын да үтерделәр, бөтенесен җир йотты! Шуңа безнең җир кеше сөякләреннән генә тора. Күптән инде, бик күптән! Ул теш арасыннан кысып чыгарып әйтте. Бу минутларда шул чакларны кабат башыннан кичерде бугай.

— Аллаһы Тәгаләнең болгарларга ачуы килеп, аларны Котлыгъ Тимергә тотып биргән. Өч көн эчендә Котлыгъ Тимер Болгар каласының көлен күккә очырган, исән калган халыкны, башка монда эзләре булмасын дип, куып таратырга боерган. Җанбакты карт, үз буыны белән Җанбакты авылын торгызган. Тәтеш карт нәселе Идел елгасы янына килеп чыккан һәм Тәтеш авылына нигез салган. Мамадыш карт Нократ елгасы янында тукталган һәм Мамадыш авылы аякка баскан. Кемнәрдер Уралның көньягында тамыр җибәргән, кайсылары диңгез буйларын сайлаган, гомумән, дөньяның төрле ягына таралышканнар. Мамадыш карт вафат булгач, аның исемен аннан соң килгән буынга кушмадылар, чөнки аның хөрмәтенә авылыбыз Мамадыш дип аталды... Хәзер авыл юк. Телисезме, юкмы, мин — Мамадыш! Эзләп тапсыннар мине. Кайда мин?! Тапсыннар да үтерсеннәр, сөякләремне акбурга әйләнгән җиргә илтсеннәр.

— Әти, әти, — дип чакырды улы, — әти, син бит үрдәк атам, диден. Үрдәк ите ашатырмын, диден...

— Ә-ә, улым, — әти кешенең тавышы үз көенә кайтты. — Һәр нәрсәнең үз чираты. Үрдәген дә атарбыз, ашын да пешерербез, аннары юлыбызны дәвам итәрбез. — Ул, сөйләнә-сөйләнә, атны агачка бәйләде. — Бик йончыгансың, азрак суын. Түз, картлач, Аллаһ безгә түзем булырга кушкан.

Балаларны йоклаткач, хатын учак янына елышты. Мамадыш кырын ятты, төргән тәмәкесен тарта-тарта, үзалдына сөйләнде:

— Көчсез, аңгыра җанварларны эш берләштерә һәм бергәләп тормышны җигелеп тарталар! Без аларның бернинди максатлары да юк дип уйлыйбыз, ю-ю-к... Һәр бөҗәк үзенә билгеләнгәнне үти, хезмәттәге үз өлешен башкара. Үзе өчен генә түгел, үзе ишеләр төркеме өчен дә тырыша. Әйе, үзе ишеләр өчен, — дип кабатлады ул уйчан гына. — Ничек тырышып кәрәзләрне ширбәт белән тутыралар, бергәләп килешеп үзләренә торак төзиләр. Ә без... кайнашкан булабыз, рәнҗетәбез, якыннарыбызның сыерларын тартып алабыз, бер-беребезне пеше чыбык белән суктырабыз, җәзалыйбыз...

— Гаҗәпләнмәгез, — диде хатыны соңыннан. — Ул шулар хакында сөйләнергә ярата. Авылдашлары гел аның янына сырышты. Дөнья мәшәкатьләрен хәл иткәндә, ул беренчеләрдән булып ябышты, башкаларны да өйрәтте, аларның искелеккә ябышып ятуларын гаепләде, ярлы тормышта яшәүләре өчен орышты. Мулла да аның белән сөйләшеп карады, башкалар исправник чакырту белән дә янады, әмма мондый сүзләр сөйләвеннән тыя алмагач, кулларын селтәделәр: янәсе, вәгазе өчен акча сорамый...

Төн уртасы якынлашты, балалар күптән тирән йокыда. Дәрвиш тә чапанына

төренеп, баш астына капчыгын кыстырды да учак тирәсенә чүмәште. Мамадыш утырган көе генә йокымсырый. Менә ул сискәнеп уянды да хатынына кыска гына:

— Киттек, — диде.

Хатын, ишетмәгәндәй, чыбык-чабык алып учакка ташлады. Ялкын телләре аның озынча ябык йөзен, керфекләренә ябышкан күз яшен яктыртты.

— Киттек, — дип кабатлады ир-ат һәм итек очы белән аяк астында яткан чапанын читкә тибеп, сикереп торды.

Хатын да аягына басты, чапанны кулына алды да күндәм генә куак артына атлады. Мамадыш та, борын астыннан мыгырдап, аның артыннан иярде: әллә хатынын сүгүе, әллә үз-үзен юатуы — белмәссең. Икесе бергә караңгылыкка китеп югалды. Габдулла чапанын җәеп ятты һәм шунда ук йокыга талды. Иртән ул суыктан калтырап уянганда, Мамадыш арба янында утыра иде, коралын тез арасына кыстырып, сабыннан тоткан. Шул көе ул соңгы кеше уянганчы утырды. Дәрвиш, торып, инеш буена төште, менгәч намазга оеды. Аның артыннан хатын уянды, ул арада малайның тавышы ишетелде. Әнисе инештә аның бит-кулларын юдырып менде.

Алар юлга кузгалганда, тирә-як куе томан эчендә иде. Әмма тургайлар үләннәргә тияр-тимәс очкалап, иртәнге җырларын сузды. Ярты сәгать тирәсе узуга, томан таралды, алларында бар кайнарлыгы белән дала җәелде, тургайлар да, канатларын каккалап, югары күтәрелде. Даланы эңгер-меңгер каплаганчы, эссе кояш астында бардылар да бардылар.

Мамадыш ул кичтә чәен эчте дә арба янына күченде һәм гадәттәгечә коралын очлы тезләре арасына кыстырып, сабына ныгытып кулы белән ябышты.

Хатыны ире янында булмагач, үзен иркенрәк хис итте һәм юлчылар белән дә теләбрәк сөйләште:

— Ирем кызып китсә, беркадәр бутап җибәрә. Мамадыш авылы, әлбәттә, үз урынында тора. Кая китсен инде ул? Соң анда бит халык яши, мең еллар инде. Мамадыш карт исә аның борынгы бабасы булуына ышанырга кирәктер, аларның нәселе бик борынгы. Мамадыш ыруыннан ул ялгызы гына калды. Бәлкем, Аллаһы Тәгалә безнең улыбызны тартып алмас әле. Алса, тагын бирер.Кая баруыбызны беләсегез киләме? Себергә кузгалдык. Анда җир күп, теләгән кадәр алып була, диләр. Туган җирне ташлавы бик авыр булды, әмма башка түзәр чамабыз калмады. Җиребез начар безнең. Мамадыш әйтә: артык күп кеше җирләнгәннән, ди. Исәннәре атсыз-тунсыз дигәндәй, көчхәлгә очын-очка ялгап бара. Сабан бетүгә, җан башына салына торган салым өчен акча эшләргә таралалар. Кемдер балта эшләренә китә, кемдер Иделдә йөкче булып яллана, кайсы мич салу эшен белә, икенче берсе итек баса. Аты булганнарның язга таба аты аяксыз кала, хәтта үзенең җир кисәген дә эшкәртә алмый. Минекенең аты юк иде, шуңа бар гомерен читтә эшләп уздырды. Баштарак, өйләнешкәч, менә бер-бер артлы малайлар туар, имана җире артыр, ат алырбыз, эшләр уңайга китәр дип өметләнде. Әмма Аллаһның насыйбы безне читләтеп үтте, берсе артыннан икенчесе кызлар алып кайттык. Мамадышның күңеле төште. Үзенең имана җирен һәр елны уртакка эшләүчегә бирә дә, балтасы белән өтергесен кыстырып, чыгып югала. Уртакка эшләүче имана җире өчен сыерга азыклата бер капчык тары бирә дә шуның белән вәссәлам... баштарак утарларда, бай күршеләрдә батрак булып ялланды, аннары инде балта эшләренә тотынды.

Без алай байлардан көнләшмәдек, гаиләсе ишле ярлыларга кызыктык. Аңлыйсыздыр, әгәр гаилә башлыгының ике-өч өйләнгән улы булып, бар да бергә тормыш тартсалар — картлар җәй буе үз хуҗалыкларын алып бара,

яшьләр алпавытларда көнлекләп эшли: күз алдыңа китер — өч-дүрт сум. Кайсы ир-атлар төрле эшләргә китә, хатын-кызлар өйдә киндер, җитен талкый, йон эрли, киндер баса. Шулай итеп өс-баш, аяк киемлек кырып-себереп җыялар.

— Безгә әле... барасы да барасы! — Ир дилбегәне какты да атны куе чытырманлыклар аша юлга әйдәде. Арба артыннан хатын, аннары бер-берсен җитәкләгән кызлар теркелдәде.

Каршыга арбалылар очрый башлады. Зур тәгәрмәчләр, алагаем үгезләр, чайкалып барган зур-зур камытлар. Арбаларда — утарга күптән түгел күченеп килгән кешеләр.

— Бәлки сезгә ул кадәр еракка барып йөрмәскәдер, — диде Габдулла, — бәлки Костанайның калдау җирләрендә тукталыргадыр?

Мамадыш җавап бирмәде, әмма бераздан үзенекен әйтте:

— Адәмнәр йөриләр, йөриләр... һәркем үзенә язганны яшәп бетерергә тырыша. Минем бабай, адәм баласы хәрәкәттә булырга тиеш, ди торган иде. Ни өчен халык яши? Аның җирен, ризыгын тартып алалар, аның динен кысалар, ул исә яши. Нигәме? Чөнки ул хәрәкәт итә. Хәрәкәттә бәрәкәт — бабам сүзләре бу...

Офыкны алсу томан каплады, аннары ай калыкты һәм кылганнар өстенә көмешсыман үтә күренмәле яктылык сибелде. Алар бардылар да бардылар. Буаларда бакаларның кичке тамашасы башланды, сазлыкларда күлбогалар ауга чыкты.

— Тр-рр, тукта, бурлы. Сез, Алла бәндәләре — дәрвишләр, сихерчеләр сез, сихерчеләр, — дип сөйләнә-сөйләнә, ир-ат арбадагы сандыкны тотып торган бауларны чишеп атты. Күлмәк астыннан бауга тагылган ачкыч чыгарды һәм йозакны ачты. — Карагыз, менә ул минем машинам! Ул ниндидер торбалар, почмаклыклар, пружина, болтлар тартып чыгарды. Болардан тыш тәгәрмәчләр, май савытлары, хәтта примус та бар иде. — Күрдегезме? Нефть белән эшли. Шәп, көчле машина. Хет урман кис, хет бакчага су сиптер. Тегермәнгә дә урнаштырырга була — ашлык тартасың. Менә шундый машина, — диде дә тиз генә барын да тутырып, сандыкны йозакка бикләп тә куйды. Аннары бау белән ныгытып бәйләде. — Шәп туфраклы җиргә барып ирешкәч, сөрәчәкбез, орлык чәчәрбез, яшелчә дә утыртырбыз. Машинаны әйбәтләп майлармын да яшереп торырмын. — Аның ябык йөзе үлгән кәлтәнең кипкән тиресе сыман җыерылды, күзе исә төнге ерткыч күзенә охшап калды, әмма яхшылап карасаң, анда өмет катыш шашкын бер очкынны шәйләргә була. Бичара Мамадыш сандыкта машина түгел, ниндидер тимер кисәкләре белән примус кына икәнен дә аермый, ахры. Үз авылына әйләнеп кайтса, хәерлерәк булыр иде дә...

Ул кичтә Габдулла һәм дәрвиш иртән үз юллары белән китәргә сөйләштеләр. Киткәндә, Габдулла шулай да хатын белән сөйләшеп карарга булды.

— Күрмисез мәллә, ирегез акылдан язган.

Хатын ышанмыйча башын селкеде.

— Соң, аңлашыла бит инде, кем белән сөйләшсә дә!

— Мин дәме? — диде хатын. — Аның белән кая барганымны белмәгәч,— димәк, минем дә башым киткән дигән сүз! Балага узуым да акылдан шашумы, Аллаһ монысында безгә малай җибәрәчәк.

Ул акылсыз, әмма яшәргә омтыла, шушы хәерче, авыр, гадел булмаган тормышта уллары булуын тели икән, монысы — акыллылыктыр, шәт. Йөдәгән, интеккән бу адәм җәннәт рәхәте өметләнми, тормышның дәвам итүен тели. Үзләренә бәхет язмаган икән, бу теләкнең улларында дәвам итәсенә ышана...

Үсмер егет шунда Мамадышның үз күңеленә онытылмаслык булып кереп урнашуын сизде.

## 4

Габдулла төне буе төшендә коры, эссе далада адашып йөрүен, нииндидер алсу томанга төренгән күлләрнең ялтыравын күреп, саташып ятты.

Аны Газизәнең каененесе — юаш, беркатлы Тәхәви уятты. Ул Габдуллага апасыннан язу тапшырды, хөрмәт күрсәтеп, тастымалга төрелгән фарфор тәлинкәдәге кайнар пәрәмәчләрне бирде дә чыгып йөгерде.

Тәлинкәнең төбенә коңгырт төстәге хәрефләр белән дога сүзләре язылган иде. Габдулла, көлемсерәп, тәлинкәне битенә якын китерде: борынына көйгән сөт исе бәрелде. Сөйкемле сөяк Газизә мәхәллә мулласының хатыны янына барып йөри иде, тегесе тәлинкә өстенә дога укып кына калмаган — язып та биргән! Әмма пәрәмәчләрдән дә шифалырак тагын ни бар икән соң? Тик башта апасының хатын укыр.

*«Безнең өчен хөрмәтле, зирәк, укымышлы энебез! Синең авыруың хакында ишетеп, без бик борчылдык һәм тынычлыгыбызны югалттык. Әниебезнең: «Бала югалту ачысын күрсәтмә, Ходаем», — дип әйткәнен хәтерлим. Хәзер менә мин бәхетсезегез дә, якыннарымны югалту кайгысын бирмә дип, Аллаһ Тәгаләдән сорыйм.*

*Якты чыраем, син дип сулаган һәр сулышым кайнар утка тиң. Синең яныңа йөгереп бара алсам, ярдәм итәр, юатыр, тамагыңа ашатыр идем! Габдрахман абзаң, Аллаһ аңа гомер бирсен, эшләре белән шулкадәр мәшгуль ки, бер минут буш вакыты да юк, синең хәлеңне белеп кайтсын дип тә әйтә алмыйм.*

*Кадерле энебез, акыллыбыз, күземнең нуры, хәлең аз гына җиңеләйсә, шунда ук килеп җит, апаң сине һәрчак сөенеп каршы алыр, кайнар күкрәгенә кочар. Кил, энем, кил!*

*Аллаһ сине авырту-сырхаудан сакласын, бер-беребезне күрү, ярату бәхетеннән аермасын. Сине хөрмәт итүче, өзелеп яратучы апаң бу хатны күз яшьләренә манып язды, миһербанлы фәрештә сүзләремне сиңа җиткерсен».*

Ул укып тәмамлаганда, үзенең дә күзеннән яшьләре тыелгысыз булып акты. Күңелен җиңелчә җылы сагыш биләп алды, рәхәт иде аңа! Туганкаем! Гомерләре аерым-ялгыз, чит-ят кешеләрдә узды, бары дүрт кенә ел Газизә тутасының бәхетле рәхәт йортында бергә яшәлде.

Әй ул якыннарың янәшәндә булган иртәләрнең күркәмлеге! Менә тутасы уяна, уфылдап ала, кыштыр-кыштыр итеп киенә, менә авыз эченнән генә сөйләнеп самавыр куя. Аннары апасы уяна, аны күрер өчен ятагында чак кына борылу да җитә.

«Хәерле иртә, энем! Белсәң иде, мин бүген шундый төш күрдем, сиңа гына сөйлим, тик барысын да түгел, кызыклы урыннарын гына!»

Газизә тутасының өендә бик рәхәт иде, кече Газизә апасының да монда яшәве — ямь өстенә ямь иде. Хәзер ул йорт, апасы киткәнгә, чит-ят тоела. Бәлки, Газизә апасы Габдрахман приказчикны яратып та чыккандыр, әмма аның яшенә дүрт елны өстәү нигә кирәк булды икән? Менә шуның өчен Габдулла өлкән Газизә апасын да, аның ирен дә (әйтерсең, моңа ул гаепле кичерә алмады.

Җаекка, сәүдәгәр Галиәсгар гаиләсенә алып килгәндә, аңа ун яшь иде. Әтисенең сеңлесе Газизә тутасы Галиәсгарга кияүгә чыккан була, кече Газизә, тәрбиягә алынып, аларда яши.

Халык арасында йөргән сүзләргә караганда, Галиәсгарның эше гел уңучан, әмма аның мул, иркен тормышы турындагысын арттыралар, чөнки аңа нинди авырлыклар белән ирешкәнен ул үзе генә белә. Аның әтисе крәстиян, Казан арты авылыннан, комлы туфраклы җирдән. Һава торышы — тотрыксыз, мондагы

шикелле кансыз, рәхимсез хакимнәр башка беркайда юктыр. Әнисе дөньяга унөч бала китерә, шуларның икесе — ул һәм бер кыз туганы гына исән кала. «Чыннан да, көчлеләр генә исән каладыр, күрәмсең, — диде әтисе Галиәсгарга. — Сине бит ач-ялангач әниең ызанда тудырды. Ике көннән эшкә чыкты, чәчкән җирне чапканчы, аннан әйләнеп кайтканчы синең җаның чыккандыр инде дип уйлыйсың. Әмма син, үксеп елаудан зәңгәрләнгән сабый, исән ятасың».

Галиәсгар нык, таза булып үсеп килә. Әтисе үсмер улы белән бәхет эзләп китә: базарлар буйлап тегермән ташы сыман авыр гәүдәсен өстерәп, кайракчы булып йөри, Бакуда нефть тармакларында эшли, трактирларда идән юа, Әстерхан базарларында да кайнаша. Ниһаять, Әй буендагы Златоуст урманнарына барып җитеп, дегет куа башлыйлар, бу эш табышлы булып чыга. Җаекка килгәндә, кесәләрендә аз-маз маялары була, шуңа йорт-кибет алалар һәм сәүдә эшен башлап җибәрәләр. Галиәсгар үз якларының оста куллары чиккән яулыклар, сөлгеләр, кәләпүшләр ташыды. Дала кешеләрен җәлеп итә торган мондый эшләнмәләрне соңрак приказчиклары күпләп-күпләп кайтарды. Аларга алмашка казакълардан йон алып, авылларга җибәрделәр, андагы оста куллар төрледән-төрле бизәкле шәлләр, кофталар, бияләйләр, шарфлар бәйләде. Үләренә ике атна кала, карт өчен иң куанычлы вакыйга булды: аны, ниһаять, гильдия дәрәҗәсенә яздылар. Әмма улының Кушлавыч мулласы кызына өйләнүен көтеп җиткерә алмады. Галиәсгар үз теләге һәм кызның ризалыгы белән гаилә корды, моның өчен гомере буе үзенең сәүдәгәр булуына рәхмәтле иде. Бары тик гаярь сәүдәгәр генә калалар һәм салалар буйлап йөри һәм үзенә тиң ярны таба ала!

Кыз белән беренче тапкыр күрештергәндә, ни гаҗәп: тәүдә җәлләү хисе баш калкытты. Нечкә буй-сынын озын-атлас күлмәк каплаган, күндәм генә салынып торган ябык беләгенә беләзек кигән, озынча аксыл йөзенә энҗе белән чигелгән калфагы килешеп тора. Коеп куйган ханбикә инде!

Хатыны белән Җаекка килеп төшкәч, кала аңа кызыксыз булып күренде. Хезмәтчеләр арбадагы йөкне бушатканда, алар кунак бүлмәсенең тәрәзәсе янында басып тордылар. Чокыр-чакырлы юл һәм таш җәяүлеләр юлы, тузанга баткан әрекмәннәр, соры, көйгән сәрви куаклары. Аларның йорты янында йөргән чучкалар капканың кирпечтән төзелгән багана төпләрен казымакчы булып актарына.

— Әй, кем бар анда, куыгыз әле шул хайваннарны! — дип кычкырды ул, һәм хезмәтче шунда ук әмерне үтәргә йөгерде.

Ул карашы белән залны айкап чыкты. Моңарчы аның горурлыгы булган зур агач кисмәкләрдәге бүлмә гөлләре дә ялган ялтыравык кебек тоелды.

Язын хезмәтче ишегалдында чәчәк түтәлләре ясады һәм хуҗасы Ырымбурдан алып кайткан орлыкларны чәчте. Май ахырында беренче үсентеләр күренде, җәй башында хуш исле гөлләр — соргылт шәмәхә шеббуйлар чәчәк атты, люпин белән лилияләр дә бөреләнде. Галиәсгар сөенеченнән елмайды. Ураза вакыты, кояш чыкканнан соң, авызга бер валчык, бер тамчы су алмыйсың, тән җиңеләя, тамырларда кан йөреше иркенәя, үзеңне тере, сәламәт сизәсең. Йә Аллам, нинди матур көннәр, аннан да бигрәк төннәре!..

Ураза тәмамланды, һәм җәй дә үтеп китте. Җылы әбиләр чуагы башланды. Газизәнең дә көмәне сизелерлек түгәрәкләнде, әмма ул тәненә ятып торган муслин, атлас күлмәкләренә сыя һәм шуның белән төз-зифа күренә иде. Галиәсгар, түземсезләнеп, бәхеткә күмелер көнен көтә, нәкъ үзе кебек таза, нык, гомерле улы туар дип өметләнә. Әмма хатыны җиде айдан җитлекмәгән елак чирләшкә кыз бала тудырды. Хатынын хөрмәт иткән Галиәсгар хәтта шушы хәлсез җан иясендә дә нindидер нәфислек, нәзакәтлелек, дөресен әйткәндә, аксөяклек күрде. Вакыт узган саен, күңелгә әкренләп шом керде: туташ, сүз дә

юк, бик әйбәт — пианолада уйнар, матур-матур киемнәрдән йөрер, әмма аңа малай кирәк. Матурлыкка матур булмаса да ярар, әмма сала малайлары кебек нык, таза булып тусын, көчле, ушлы, эшен дәвам итүче булсын иде. Ул кичләрен зур буш ишегалдында торган тарантасның канатына утыра да, йолдызлар сибелгән күккә карап, калтыранган тавышы белән авыз эченнән генә догалар укый. Аннары, язмышыннан зарланып алгач, өйгә керә һәм дулкынланып, ашыгып йокы бүлмәсенә уза. Тәрәзәдән сузылып кергән ай яктысында тагын да пакьләнеп күренгән ике нечкә беләк муенына уралуга, бар дөньясын оныта.

Ул барыбер Аллаһның гаделлегенә һәм үзенең бәхетенә ышанды. Һәм, ниһаять, көннәрдән бер көнне, чираттагы юл-сәфәреннән әйләнеп кайткан Галиәсгар каршына, тыны-көне бетеп, бала караучы йөгереп чыкты:

— Сөенче, әфәндем, улыгыз туды!

Алты яшьләренә кадәр улы башка малайлар кебек үк — кирәк кадәрле кире, үзсүзле дә, кирәк кадәрле назлы, ягымлы да булды, бүлмәләр, ишегалды буйлап йөгереп йөрде, әрекмәннәр арасына качкан чебиләрне пырхылдатты, әнисе исә, кыртлый тавык кебек кыткылдап, аның артыннан йөрүдән бушамады. Аннары алар хатынының бертуганының кызы кече Газизәне алып килделәр һәм малайны карауны аңа тапшырдылар. Шулай да өлкән Газизә кызга бик ышанып бетмәде, улын күз уңыннан ычкындырмаска тырышты. Бервакыт улы ике кулын җәеп торган әнисе янына йөгереп килде дә, абынып, аның күпереп торган итәгенә егылды. Улын күкрәгенә кыскан ана ирен чакырды.

— Тыңлале, йөрәге ничек сикерә, — дип сак кына улын аңа бирде.

Галиәсгар малаен кочаклап, күкрәгенә кысты һәм күкрәгенең сул ягы тоташ бер күтәрелеп, бер төшеп торуын сизде.

— Мин аны Амри әфәндегә алып бардым, — диде хатыны, дөньядагы бар чирләрне яхшы белүче француз табибының исемен дөрес атамыйча.

— Һәм... нәрсә диде инде ул?

— Тумыштан, йөрәк авырулы, — диде.

Галиәсгар бит очлары янып торган нык, таза табиб әфәндене күз алдына китерде, маклер Алчинның хатыны шактый вакыт бала тудыра алмаудан дәваланып йөргәнен исенә төшерде, ахырдан хатын табибның үзенә охшаган малай тапты.

Соңрак, кара айгырга атланып далага чапканда һәм кыйшайган ялгыз кабер янында озаклап уйланып утырганда, башына төрле уйлар килде. Әгәр гаеп үзендә икән, ул да хатынын дәваланырга җибәрер иде, улы коеп куйган месье булса булсын иде шунда, әмма ул Галиәсгарның мирасчысы саналыр иде. Тик гаеп нәфис хатынында, дип фикер йөртте ул.

Кызы белән улы бер елда үлеп киткәч, Галиәсгарга дөнья беткәндәй тоелды. Аны күп нәрсәләргә ирештергән көчле рухы чатнады.

— Ходаем, хет кече Газизә малай булмаган шунда! — дип ычкындырды ул бервакыт, сызланып. — Үз улым кебек яратыр, мирасчым иткән булыр идем!

Кайгыны хатын-кызларга хас сабырлык белән кичергән өлкән Газизә йомшак кына әйтә куйды:

— Газизәнең энесе Кырлайда чит-ятлар арасында интегә, чын мәхдүм — укый да, яза да белә, гаҗәеп акыллы, диләр.

— Газизә, сөеклем... Әйдә, кичекмәстән Кырлайга кеше җибәрик! Алып килсен малайны!

Күңел ышанмый, Казаннан унсигез көн буе суыкта чанада килделәр микәнни? Дөрес, Габдулланы эзләп табып, озатуны оештырырга тиешле Бәдри абзый аңа яңа бишмәт, яңа киез итек, бүрек сатып алды, һәм малайны кырык тартмачы Алты-биш Сапыйга ышанып тапшырды, аның хатыны исә юлда аңа

кыска тун кидерде. Хатын үзе толыпка төренде һәм тыгызлап тутырылган кабык сандыкны барлады, өстәвенә бичара Алты-биш Сапыйны ниндидер гаепләре өчен әрләп алырга онытмады. Кеше ышанмаслык хәл, ир — баш, хатын— муен, диләр, монда хатынның теле телгә йокмый!

Озын юл күз камаштыргыч карлары, печән эченә күмүгә карамастан, сызлап авырткан аяклары һәм кырык тартмачының туйдыргыч мыгырдanулары белән истә калды. Атлы юлчылар куна торган ханәләргә тукталганда, аягына баскач, малайның башы әйләнде, төннәрен йоклаганда үзен сикәлтәле юллардан баргандай сизде.

Ниһаять, Җаекка килеп җиттеләр, менә урам, кирпеч тәрәкле, өсте озынча түгәрәкләп ясалган, түбәсе калай белән ябылган капка. Менә тутасы һәм апасы белән түр якка керәләр, каршыларына күпереп торган мыеклы зур гәүдәле абзый килде. Ул туктап, тәмәкесен суыра-суыра, малайга күзен төбәде. Аның карашында малай үзен күргәндәй булды: нечкә муен, бәрхет кәләпүш кигән киң маңгайлы түгәрәк баш, өстендә кыек якалы күлмәк белән җиңсез өс киеме, аягында калын йон оекбаш. Оялса да, башын күтәреп, ачык итеп, зурларча:

— Әссәламегаләйкүм! Иминлек сезгә! — диде.

Ул апасы белән бер бүлмәдә йоклады. Идәндә дә, сәкедә дә түгел, лак белән ялтыратылган аркалы агач караватта! Борынына иләнгән сарык тиресе, сөт яисә пешкән бәрәңге исе түгел, апасының кием-салымыннан сизелер-сизелмәс аңкыган ислемай аңкуы килеп керә, аңа кар өстенә салып чистартылган палас, агартылган чиста диварлар, буялган идән, түшәм, ишекләр исе килеп кушыла.

Апасы Габдулланы ятакка салып, юрганын ян-яктан кыстырып куя һәм аның кырыена утыра да әкиятләр сөйли. Каһарманнары исә көн дә бер үк — матур, кыю патша уллары. Алар турында сөйләгәндә, апасының сулышына гүя ут каба, әйтерсең, ул үз шаһзадәсенең каршына йөгерә...

Иртән уянгач, апасы көлә-көлә аны йолыккалый һәм аның борынына гаҗәеп якын, әнисенең җылы исе бәрелгәндәй тоела. Яңа гына уянган апасының йөзе алланып, шешенкерәп киткән. Габдулла учы белән аның яңакларына кагыла, апасының чәчләре аның битенә ишелеп төшә. Габдулла аның күзеннән, йә булмаса күпереп торган колак йомшагыннан әнисенең чалымнарын тапмакчы була. Галиәсгар абзасы апасына яңа алкалар вәгъдә итте. Бәлки, аның приказчигы Габдрахмандыр... Ул Газизәгә өйләнергә тели бит.

Өйдәге өлкәннәр, хәтта асрау карчык, ишегалды себерүчегә кадәр апасына карата аерым караштa. Габдулла бу ягымлылык астында үзе өчен ниндидер сагыш яшеренгәнен сиземли: бу бит — кыз белән ягымлы итеп саубуллашу лабаса!

Малайны ачы котылгысызлык интектерә һәм беркөнне түзми, читләтеп сүз башлый:

— Газизә апа, үзеңнең балаларыңны да... шулай бик, бик яратырсыңмы?

— Әлбәттә! — дип җавап бирә апасы, алдын-артын уйлап тормый, — сине яраткан кебек бик-бик яратырмын!

Габдулла, көч-хәл белән сулышын тыеп:

— Ә аны? — дип сорады.

— Аны дигәнең кем инде ул?

— Приказчикны инде.

— Алай димә, Апуш. Шуны бел: кечкенәләргә аның кадәр күп сорау бирергә ярамый.

— Ярар, бирмәм, — дип килешә малай. — Уйлармын гына. Анысы беркемгә дә тыелмый.

Апасы дәшми. Йөзен уй, сагыш баса, ул энесеннән юату сүзләре көтә шикелле, әмма малай тынып калган. Аның апасына булган мәхәббәте шундый көчле, башка берәү дә аны Апуш кадәр ярата алмас.

...Пәлтәсе җиңел, барыбер туңмый, чөнки ул тиредән тегелгән, куян бүрек, шарф. Киез итекләре ак, яңа, шуңа авырдан бөгелә. Аның мондый итекне кайчандыр Кырлайга килгән исправникта гына күргәне бар иде. Шарфны исә авылда, тамагына салкын тимәсен дип, мөәзин Гали генә бәйли иде. Карлыккан тамак белән намазга чакырсынмыни?

Малай ишегалды уртасында басып тора. Ак көрт яртылаш күмгән биек койма башында ачы тавышлы саесканнар нидер бүлешә. Малай тирәсендә, сөенечле ырылдап, эте сикергәли. Урамнан чана табаннарының шыгырдавы, атларның пошкыруы, малайларның чыр-чуы ишетелә. Тик аның урамга чыгасы килми. Малайлар таныш булмаганнарга карата рәхимсез кылана. Юк, ул алардан шүрләми, карга төртеп егуларыннан да, хәтта сугуларыннан да курыкмый. Әмма яшьтәшләреннән көчсезрәк булуын сизә, ояла ул. Ярар, аның каравы, берсе дә, үскәч, аның кебек мулла булып, халык алдында вәгазь сөйли алмас әле.

Менә кече капка ачылды, аннан чана тартып Газизә тутасы килеп керде.

— Апуш, абзаң сиңа чана бирде.

— Рәхмәт.

Таудан шуарга ярата иде ул. Аларның тал чыбыгыннан үргән кәрҗин сыман нәрсәләре бар иде, җәен ул тавык утырту өчен хезмәт итә. Асрамага алган атасы аның ян-якларын җылы тирес белән сылады, тирес суынгач су сипте, каткач, тагын сипте. Бозлы чана таудан шуып та күрсәтә иде! Аның төбе ясмык кебек кабарынкы булганга, таудан төшкәндә ул әйләнә-тулгана да бөтереп алып китә. Берчак шулай боз чанасы ычкынып китте дә бәкегә чумды. Үзе дә чак кына чуммый калды.

Төшке ашка кайткан абзасы малайның чана янында басып торганын күрде.

— Йә ничек, бүләгем ошадымы?

— Рәхмәт!

— Нигә шумыйсың? Тауга бар. Авылда шуганың булгандыр бит? Әллә чанаң юк идеме?

— Бар иде, — дип җавап бирде малай. — Боз чанасы.

— Ә-ә! — дип шаркылдады Галиәсгар. — Сыер бугы белән сыланган! Һәм таудан аска в-ы-ы-ж, шулаймы? Әллә малайлардан шүрлисеңме?

— Курыкмыйм. — Ул туңган иде, шуңа иреннәре дерелдәде.

Галиәсгар, шаяртып:

— Менә чанаңны урам себерүчегә бирермен әле! — диде.

— Мә, бир.

Чанасын ишегалдында калдырып, ул урамга чыкты. Анда никрутлар бәйрәм итә иде. Шөлдерләр тагылган, парлап, өчәрләп җигелгән атларның чаналарына бәйрәмдә генә кия торган туннарын җилбәгәй җибәреп, суыктан һәм исерткечтән кызарган чырайлы егетләр төялгән, алар бар көчләренә акыралар иде.

Шунда берәүләренең чаналары ауды, атлар мичәү бауларына буталды. Бер әзмәвер урам уртасында тезләнде. Йөзе кызарган, күзе яшьле.

— Галиҗәнап патша гаскәре саф-фына каб-бул ителде...

Аңа рәхәт, шул ук вакытта ачы да, сагышлы да. Ул күңелле көйгә сузып җибәрде:

Казынька-казачок,
Казак, миленький дружок...

Кызларга да күңелле. Берсе — киң кәшемир шәлгә төренгәне — кулындагы яулыгын болгап җыр башлады:

Не я тебя поила.
Не я тебя кормила.
На ножки поставила,
Уважать заставила,
Коротеньки ножки,
Сафьянны сапожки.

Үзләреннән соң ниндидер әшәке куркыныч сөрем калдырып, алар китеп барды. Шул исне сулап, казакъ балалары чабып узды.

Алар, кибәннән печән йолкый торган озын саплы тимер ыргак күтәреп, ике малайны куа бара. Малайлар яланбаш, берсе — аксыл, икенчесе — кара-кучкыл. Бер кул белән бүрекләрен кысып тотканнар, икенчесендә бозланып каткан ат «алмасы». Габдулла янына җиткәч:

— Нәрсә каттың? Арт сабагыңны укыталар бит!.. — дип кычкырдылар.

Габдулла үзе дә сизмәстән аларга иярде.

— Эләктер мужикны, бир кирәген!

— Мә! — аксылы шаркылдап көлде. Борылып, ат «алмасын» төзәп атты.

Алдан йөгергән казакъ малае лап итеп килеп төште, сүгенә-сүгенә артта калды.

— Шул кирәк сиңа! Кая? Әнә капка...

Чалшайган тәбәнәк капка янына җиткәннәр иде, шулвакыт майга баткан кыска мамык сырмалы егет чыкты.

— Һайт! — дип кычкырып, юри генә казакъ балалары артыннан чапкан булды. Аксыл йөзле малай тамагын ертып акырды:

— Сине тотабыз... тотабыз дим бит!

Габдулла кузгалмады. Кара-кучкыл бүреген киде:

— Мин дә чапмыйм. — Аксылына кычкырды: — Санька, кирәкми!

Санька борылып килде, көлә-көлә, малайларга бүреге белән селтәнде:

— Котыгыз ботыгызга төштеме? Безне куркыта алмассың, Минька безнең белән бит! Кирәк булса, Минька өчен бөтен депо күтәрелә. — Кызуы басылмаган малай, бүреген киеп, шаяртып, кара-кучкылына бәйләнергә тотынды: — Син нишләп чапмадың, Ицик, ә? (Без аны үзебезчәләп Ицхак дип тә йөртәбез).

— Исемә төште, бүген шимбә икән бит. Әгәр, мәсәлән, пәнҗешәмбе...

— Их син, янгырдан соң пәнҗешәмбе ниемә?! Ишеттегезме, нәрсә дип кычкырды Клыков? Мужикны тукма, ди. Ицик, син яһүдме?

— Яһүд, — дип килеште Ицик көлеп кенә. — Белсеннәр, минем абзый Ырымбурда казна раввины.

— Казнаныкы! Казаклар алар синең абзаңнан да казнапырак.

Габдуллага малайлар белән очрашу, таныш булмаган чит тормышны күрү ошады. Чит, әмма шул ук вакытта чит үк тә түгел, чөнки чынында аның асылы нәкъ синеке кебек, хәзергә кадәр үз тормышыңны беркемнекенә охшамаган, бердәнбер дип саныйсың, башкасын уеңа да алмыйсың.

Ицхак бик шаян малай. Ул мәрхүм этисе кебек приказчик булырга тели. Көндезен ул кибеттә сәүдә итәр, кичке аш вакытында бер чәркә акны каплап куяр иде. Көн саен! Тагын бер хыялы бар — өйләнү.

Ул:

— Сез минем әнинең җырлаганын тыңласагыз! Ул, мин өйләнергә ризалашкач, шундый сөенде, — диде.

Сима апа буяучы, тукымалар манарга бары ярлы-ябагай гына йөри, шуңа каланың фәкыйрьләре генә Сима апаның кайгысын белә: аның ике өлкән улы да буйдак иде.

— Бар кайгым — алар буйдак! — дип өметсезлеккә төшә буяучы хатын. — Ни өченме? Әйтәм: Яша сөргендә, Мотяны исә тиздән сөрәчәкләр. Белмисезме? Әйтәм: Мотя да студент.

Ицхак студент булмаячак, унөче тулуга өйләнәчәк. Кияү егете! Урамга уйнарга чыкса да, артыннан анасы йөгереп килеп, пәлтә төймәләрен төймәли, һич югы, башында шәп утырса да, бүреген рәтләштергәндәй итә.

Авылда чакта Габдулланың тимераяк турында ишеткәне дә юк иде, монда Галиәсгар абзасы чын, эләктергечле, «Нурмис» дип аталганын алып бирде. Әмма ул дуслары кебек тимер табанга беркетелгән агач кискәдә шуды. Аны малайларга Саньканың абыйсы Дмитрий ясап биргән иде. Алар берсен-берсе куа-куа, җәяүлеләр сукмагында да, юлда да шудылар, туры килгәндә, извозчик чаналарына ябышып та бардылар. Эңгер-меңгер куергач, шәһәр бакчасына китәләр. Анда казакъ оркестры, газ фонарьлары, шугалакта бөтерелгән гимназистлар, приказчиклар, яшь корнетлар — атлы гаскәр офицерлары һәм түрәләр, шулай ук туташлар... Бу бәхетлеләр буфетларда кайнар чәй эчә, тәм-томнан авыз итә. Әмма извозчик чаналарына тагылып йөрүләр юк...

## 5

Авылдан хәбәр килде: Галиәсгарнең ерак туганы вафат булган, малае белән кызы ятим калган икән. Ул балаларны үз тәрбиясенә алырга булды һәм башта приказчик Габдрахманны җибәрде. Галиәсгар яңа кибет торгызып маташа иде, банк акча бирүне тоткарлады. Абзасы, дулкынланып, банкны ашыктырды, ахырда, акчаны көтеп тормастан, приказчигы артыннан үзе дә китте.

Балаларны алып килделәр. Казанда Галиәсгар аларны баштанаяк киендерде. Яңа өс-башлары кайтыр юлда бераз таушалды таушалуын, барыбер фәкыйрьлекләре йөзләренә чыккан ятимнәрнең арык, килбәтсез гәүдәләрендә бу киемнәр кешечә күренә иде. Кыз, чыркылдап көлә-көлә, өстендәге күлмәген тарткалады һәм бармагын төкерекләп тузанлы сандалиен сөртергә тотынды. Малай сеңлесенә кычкырды, ул да булмады, шапылдатып, ябык арт санына сукты.

Алар килгән көннән өйдә тәртипсезлек башланды. Бала караучының идән паласларының бөгәрләнгән читләрен төзәтә-төзәтә җаны чыкты, артларыннан өзелгән фикус яфракларын җыярга, пычранган җиһазлар, тәрәзә пыялаларын сөртергә чак-чак өлгерде. Кыз ишегалдындагы иске чүпрәкләрне җыеп, курчакларын теләнчеләр итеп киендерде. Мөхәммәтгали сеңлесенә, «теләнчеләр»е белән бергә, чыбык ашатты. Хуҗа бу шау-шуга ике генә көн түзә алды. Инде малай актыгы шкафтагы графинга үрелеп, шактый гына чүмереп куйгач һәм исерек мужик булып кылана башлагач, өчесен бергә хезмәтчеләр яши торган аскы катка күчерергә кушты.

Газизә тутасы кайтарып сорады:

— Габдулланы дамы?

— Әйе, әйе, — дип кычкырды ул. — Габдулланы да.

Бүлмәләреннән куып чыгарылган балаларның хәлен белергә дип, ул аскы катка төште. Кызыксынып һәм бераз җирәнеп, Мөхәммәтгалинең ашавын күзәтте: малай кашыгы белән итне алдына тартып китерә, аннары кулы белән алып авызына тутыра, үзе чапылдатып чәйни, йотмаган килеш инде икенче кисәккә үрелә.

— Ай-һай, ашауга таза син! — дип гаҗәпләнде абзасы. Мөгаен, туймас

тамакны, өстәвенә үтә әрсез, хәйләкәр малайны сыендыруына ул сөенгәндер: андыйлар — өметле!

Мөхәммәтгали, нәрсәнең нәрсә икәнен аңлагандай, бик теләп йомышларга чапты, хуҗа киткәндә, арба тирәсендә булашты, кайтканда, капканы ачып каршы алды: «Исән-имин кайттыңмы, абзам? Юл биштәрләрен алып куйыйм. Хәзер Гыймадига әйтәм, атның тире кипсен, алайса йә иртәрәк эчертер, надан!»

Шаккатарсың: шуның кадәрле оятсызлык, үз-үзенә ышану кайдан килде икән бу малайга?!

— Галиәсгар абзый үлгәч, мин сәүдәгәр булам, — ди ул, дәртләнеп. — Аннан да уздырачакмын. Ул сатып алучылар шундый ахмаклар! Әйтик, менә миннән итек сатып алалар, ди. Итекне тартмага салам, тасма белән бәйлим һәм ялгыш кына идәнгә төшереп җибәрәм. Идәннән икенче тартманы алам — менә, рәхим итегез, дим. Анысында итекләрнең начары. Шулай итеп, яхшылары үземдә кала. — Аннары ул кинәт кенә сорап куя. — Син бу әкиятне беләсеңме? Егетләр һәм кызлар бер карчыкның аулак өенә җыела. Егетләр анда җырлый-җырлый кызларның итәк астына үрелә. Шуннан кызлар болай ди: кем мунча мичennән таш алып килә, шул безнең янда куна кала. Бер егет тәвәккәлләп китә. Мунчага керә. Ташка сузылуга, кемдер кулыннан эләктереп тә ала, мине хатынлыкка ал, югыйсә үләчәксең, ди... Юкка тыңламыйсың син, теге егет баеп китә һәм бай хатынлы да була.

— Бай түгел, мәрхәмәтле. Ул кызны җеннән коткарган.

— Әйе инде, аннары баеган.

— Син төннәрен нигә дип мунчага барасың? Байыйсың килепме?

— Барам. Тамчы да курыкмыйм. Торбадан тавыш та ишеттем инде: «Бум-бум, иң начар атны иярлә!» Каян аласың инде андыйны? Галиәсгар абзыйның атлары җен кебек! — Ул үз ялганыннан канәгать калып көлсә дә, мунчага йөрүеннән туктамады, чыннан да, ниндидер могҗизага ышана иде, ахры.

Соңрак ул зират юлын таптый башлады. Тимер ыргак белән иске төрбәләрне төрткәләп чыкты: хәзинә эзләде.

— Нәрсә аптырыйсың? — диде ул ышаныч белән, — бар да шулай баеган: хәзинә табалар да байыйлар. Әнә Галиәсгар абзый калага килгәндә фәкыйрь булган. Зиратта төн кунганда, ниндидер тавышлар ишеткән: анда юлбасарлар алтыннарын кая яшерергә дип сүз куеша икән. Юлбасарлар киткәч, ул алтынны алган да сәүдәгәр булып киткән.

Газизә туталары көненә әллә ничә мәртәбә сандык актара: авыр атласларны, бизәкле урын-җирне, бүрекләрне, энҗе җеп белән чигелгән сәхтиян башмакларны җилләтә. «Боларның барысын да апасы тизрәк китсен өчен корбан итәләр. Кияүдән бүләкләр килә торды: бал һәм май, баллы саргылт чәкчәк, тагын башмаклар, тагын бүрекләр... Алар боларның барысын да кызны үз йортларына кызыктырып китерү өчен корбан итә. Ашамлык, кием-салым, парчалар исеннән бик озак, авыртуы күкрәген кысканчы йөткерә торган булды, — ул күз яшьләрен тыя алмады.

Өй тирәсендә йөрүче хәерчеләр көннән-көн арта барды: бәлки туй бүген булыр, дигәндәй капка төбен сакладылар. Әмма әлегә сатыш-алыш кына бара. Кызык, сәүдә барган җирдә һәрвакыт хәерчеләр күп була. Бу бай, сәүдә гөрләп барган калада алар бик күп — үткеннәр, тамаклары тук, бер-берсе белән ярышалар. Байлар ашап бетерә алмаганны хәерчеләр юк итә. Изге бәйрәмнәрдә байлар йортында алар өчен махсус өстәл әзерлиләр. Шул вакыттагы ыргый күренешкә карап шаккатмалы: иске-москылар оча, авызлар чапылдый, акыру-бакыру бөтен йортны күмә. Фәкыйрьләр — фәкыйрьләр инде, алар балчык

өйләрдә яши. Киемнәрендә ямау өстендә ямау, терлек сую, сабын кайнату, күн эшкәртү урыннарында шулар эшли. Әмма болар — үзенчәлекле катлау, аерым токым. Хәерчелек — алар өчен мәртәбәгә тиң. Алар арасында да үз байлары һәм хәерчеләре, үз каһарманнары һәм бәхетсезләре бар. Габдулла алар арасында үзенең танышларын һәм якыннарының йөзен күргәндәй булды. Бер яшь фәкыйрьдә ул аермачык Габдрахман приказчикны күрде, араларында берсе Галиәсгар абзасын хәтерләтә, мәхәллә мулласы, көн аралаш мәдрәсәгә килеп китүче полиция кешесенә охшаганнары да бар.

Ул арада туй көне якынлашты. Хезмәтчеләр диварларны агартты, тәрәзәләр юды, паласларны какты, чигүле сөлгеләр элде; киңәйтеп куелган өстәлләрне ялгар өчен ишегалдында такталар кисте; пешекчеләр чормадагы ысланган, какланган азыкларны барлады, базларга кибетләрдән сарык түшкәләре ташыды.

— Аһ-уһ , өлгерә алмыйм! — Бер борчылды, бер куанды өлкән Газизә, ул арада кече Газизә белән Уманская ханым кәләш өчен тегелгән киемнәрне киеп, үлчәп карарга да вакыт тапты. Юлында Габдулланы очратып, апасы гаҗәпләнде: «Бу синмени?» — дип игътибарсыз гына баш түбәсеннән үпте дә алгарак киткән тутасы артыннан йөгерде.

Ниһаять, ул көн килде: озаклап, төркем-төркем булып кунаклар җыелды. Малайның башы әйләнде, күз алдыннан чебеннәр очты. Иртәдән авызына бер валчык капмаса да, ризык исенә күңеле болганды. Ул, мөгаен, үзенең ач икәнен дә сизмәгәндер. Кунаклар арасында шәкертләрне, сабакташларын күрде, алар мәхәллә мулласы белән ахунны озата килгәннәр иде. Габдулла уйлап-нитеп тормый гына шәкертләргә килеп кушылды һәм алар белән бергә өйгә керде.

— Аһ, түбәтәең кайда? — Тутасының шатлыклы тавышы ишетелде. — Ничек инде кунаклар алдында яланбаш йөрисең!.. Ул аңсыз рәвештә чалбар кесәсенә салынган түбәтәен алып киде.

Тантана башланды: бохара халаты киеп алган мәхәллә мулласы (башка вакытларда ул кыек якалы күлмәген киеп, ишегалдында чалгы белән чәчәклек тирәләрен чаба, түтәлләрдә казына) әкрен, мәгънәле тавыш белән, ике шаһитның кәләш бүлмәсенә кереп, кыз үз теләге белән кияүгә чыгамы-юкмы икәнен сорарга кушты. Завод хуҗасы Ибнеәминов белән тегермән хуҗасы Мортазов урыннарыннан торды. Әйләнеп килгәч, алар беравыздан: «Әйе, кыз үз теләге белән кияүгә чыга», — дип тапшырды. Алдыйлар алар, дип уйлады малай, алдыйлар!

Туйда кәләшнең вәли-вәкиле булган Галиәсгар абзый, һәр сүзен өзеп әйтеп, Газизәнең тормышка чыгуына ризалыгын бирде. Шул ук сүзләрне кияүнең вәли-вәкиле Мәүлетов та җиткерде.

— Аллаһы рәхим-шәфкате белән тәрбия кылынган, аның мәрхәмәте белән шундый бәхетле вакытка китереп җиткерелгән Аллаһы балалары бергә кушылалар...

Һәм, ниһаять, амин! Малайның күз алдында очкан чебеннәр мыж килеп торган йомгакка әверелде.

Муллаларның һәркайсы Коръәннән сүрә әйтте, яшерен көндәшлек аларны дулкынланырга мәҗбүр итәдер — тавышлары калтырабрак чыкты. Һәм барысының да, кунакларның да күңелләре чистарынып калган кебек тоелды. Зур-зур кисәкләр белән бал-май керттеләр, һәм һәркем калак очы белән генә тәм-томнан авыз итте: янәсе, ризык аз күләмдә дә җитә, җаның догалар һәм якыннарыңны ярату белән дә туена.

Хуҗалар бүләкләр өләште. Көмеш акча Габдуллага да эләкте. «Миңа аның өчен түләделәр», дигән уй кичте башыннан. Уч төбе тирләп чыкты, акча

шуып, тавышсыз гына паласка тәгәрәде. Ашлар чыгарылды, аннары ширбәт бирелде. Кунаклар аз гына әчкелтем бал эчте. Бу эчемлектән нindидер үзенчәлекле пальма исе килә. Кунакларның йөзе ачылды, тартынулары бетеп, үзара матур гына гәпләшеп утыра башладылар. Күренеп тора: бар да канәгать, бар да шат. Кияүгә үз теләгем белән чыгам дип, үз авызы белән әйтте бит!

Аның тизрәк апасын күрәсе, кочагына сыенып: «Мин сиңа бүләк әзерләдем», — дип, диңгез кабырчыгын сузасы килде. Ул аны колагына куяр һәм диңгез шавын тыңлар. Бәлки Кушлавычта үскән каеннарның кыштырдавын ишетер. Ул канәгать елмайды. Ниһаять, күңелен басып торган канәгатьсезлек акрын гына артка чигенде.

Шәкертләр белән бергә бушаган савытларны ташыгач, ул кунак бүлмәсенә бүтән әйләнеп кермәде. Ишегалдына чыкты, кечкенә капканы ачты. Монда, лапас, ат сарае, печәнлек. Габдулла текә баскычтан тезмәгә менде һәм яңа гына алып кайтылган хуш исле печән өстенә ауды. Аста ат тибенә, пошкыралар, кешнәп-кешнәп куялар. Бу — айгыр — Буран тешләшәдер. Таш җәелгән юлда тояк тавышлары ишетелә, ярлылар, чинашып, көпчәк астына эләкмәс өчен, читкә чаба...

...Ул уянды. Караңгы төшкән, салкынча һавадан тәне куырылып килде. Аста ат тавышлары ишетелми. Мөгаен, хезмәтче аларны эчертергә, берочтан коендырып та алырга дип, елгага алып киткәндер.

— Апуш, Апу-у-уш, син кайда, улым?

— Мин монда! — Малайның күзенә яшь тыгылды. — Мин монда, тутам...

Өлкән Газизә аның өстендәге үлән чүпләрен кагып төшерде, аннары киемнәрен алыштырырга җибәрде: «Тиз бул!»

Ул үзе дә ашыгырга кирәклеген аңлый иде: менә-менә, дуслары белән кияү килеп җитәргә тиеш. Килеп җитәр һәм Газизә апасын алып та китәр. Хәзер инде терсәкне тешләп булмый, бердәнбер энесе буларак, аңа үзен тиешенчә тотарга гына кала.

Кияүне бик күңелле итеп, шау-гөр килеп каршы алырлар, атны туарып, арбасын читкә куярлар: бар, янәсе, алып кит кәләшне! Уяу бул, кияү, саранлашма — бүләкләр бир, диярләр. Аннары кәләшнең ишек төбендә аның энесе, Габдулла, кияүне бүләген биргәнче кертми торачак. Дөрес, ишек төбенә, гадәттә, кечкенә малайларны бастыралар, аңа инде унөч тула, әмма әлегә малайга ун яшьтән артыкны биреп булмый. Ни гаҗәп, күңеленә мондый уй килгәч, хәтта кәефе күтәрелеп китте.

Хәзергә Габдулла, кулы белән кирпеч тәрәккә таянып, атларны кертмәс өчен, капка янында басып тора... Их, атларны йөгәненнән эләктерә алса иде ул! Аны шатлыклы дуамаллык биләп алды.

— Киләләр, киләләр!

Малай ыжгырып чапкан атның тәртә башыннан читкә сикереп өлгерде һәм шул ук мизгелдә аркалыкка чытырдатып тотынды. Бераз ияреп барды да читкә очты.

— Таптадылар, бетерделәр малайны!

— Ник андый бәләкәйләрне кулыгыздан җибәрәсез? Баланы күз уңында тотар кеше юкмыни соң?..

Аягына сикереп басканын күреп, аның турында шунда ук оныттылар да. Дуслары янәшәсендә атлаган кияү, шаяра-көлә, җыелган төркемне иңбашы белән төрткәләп, ике яклап тезелгән кешеләр арасыннан үтте. Малай, этенеп-төртенеп, тиз генә кәләш ишеге төбенә килеп басты. Ул бар көченә ишек токтасына ябышты. Менә кияүне күрде, ике дусты аның як-ягыннан килә иде.

— Алтыннан да, көмештән дә кыйбатрак!.. — дип ярсып кычкырды ул, кияүнең йөзенә бәреп.

Приказчик анын кесәсенә монпаси салды.

— Алтыннан да, көмештән дә кыйбатрак... минем апам...

Приказчик анын кулына ялтырап торган җылы акча сонды. Әмма ул акчаны төшереп җибәрде.

«Мин аны кертмим!»

Кияү малайның кулларын авырттырып кысып, ишек тоткасыннан ычкындырды.

Малай печәнлеккә йөгерде, тузанлы, чәнечкеле печәнгә йөзе белән капланып, үкси башлады. Апасын алып китүләрен ул күрмәде.

Иске китапта, безнең хәтер — хәерле эшләрне туплаучы, диелгән. Алай булгач, хәтердә калганнар бар да яхшы булып чыгамы?

Чаршау белән ябылган бөркү, караңгы почмакта уйланып яткан Габдулла әлеге хәлләрне кабат хәтереннән уздырды һәм догалар укыды да догалар укыды, аннары елады...

**6**

Көзге базарга өлгерергә дип ашыккан сәүдәгәрләр дә ярминкәдән кайтты. Зур Михайловское буйлап берөзлексез арбаларның авыр шыгырдавы ишетелеп торды — балык, ашлык, яшелчә, күн китерәләр иде. Сатучылар тауар саклый торган урыннардан кыштан ук әйтеп куйган йөкләрне: утын, шәмнәр, гильзадары, лампалар, аяк киеме һәм башкаларны чыгарырга ашыкты. Казакълар Төркестан буйлап сарыклар, атлар һәм дөяләр куып китерде, тамак төбе белән кычкырдылар, арба тәгәрмәчләре шыгырдады, даланың арык этләре көтүчеләр яныннан теркелдәде, алар артларыннан өреп калган йорт этләренә борылып та карамады.

Ярминкәдән дә татурак эш төре юк. Элекке вакытларда ярминкә вакытларында хәтта бер-берсен дошман күргәннәр дә килешә торган була. Хәзер дә тыныч кына сәүдә итәләр. Хәер, хәзер тауар кыйммәтләнде, моңарчы телдә йөргән хурлау, тиргәү сүзләренә яңалары: «япошка», «самурай», бөтенләй ишетелмәгән «кацамура» дигәннәре өстәлде. Рәтләр арасыннан кечкенә гимназистларын ияртеп, өрфия челтәргә төрелгән ханымнар йөри, алар яралы һәм авыру солдатлар файдасына акча җыя. Җирле халык авызында шиккә төрелгән сораулар: «Ни өчен Порт-Артурны саклау генерал Стессельгә тапшырылган? Нигә динне таркатучылар иконаны бүләк итеп йөри, генерал Куропаткин ул иконаны кабул итеп алганмы? Ул динне таркатучылар Толстой янына килеп, Беловодьега илтә торган юлны сорашканнармы?»

Шәкертләр ялдан килде. Кемнәрдер туган йортында кунак булган, кемнәрдер ярминкәләрдә хезмәт күрсәткән, кемнәрдер далада мөгаллимлек иткән, кайберләре Гурьевта — балыкчылыкта эшләгән.

«Гайния» мәдрәсәсеннән Габдулланың танышлары Миңлебай белән Сираҗи килде. Алар ике ай Эрбеттә ярминкәдә булганнар: тәэсирләре чиксез күп, акча да эшләгәннәр, әле Сираҗи гыйшык утында янарга да өлгергән. Әмма ул бу турыда, бернинди кызыгы юк дип, сөйләргә теләмәде; Миңлебай исә һәр көнне кичен Сакаев әфәнде ресторанында гармунда уйнаган һәм җырлаган.

— Тик мин акчаны синнән әзрәк эшләдем, — Миңлебайның бит очлары кызарды. — Ярар, хәерле булсын... Апуш, үземне бәхетле дисәм дә ярыйдыр — мин чыннан да җырладым!

— Бик яхшы, — диде Габдулла, — тик мөгаллимнәр янында телеңне тешлә. Ярар, безнең Сираҗи ни кырды анда?

— Трактирда идән юдым, — дип җавап кайтарды Сираҗи. — Башлап җибәрү өчен начар түгел... — Ул хәйләкәр генә елмайды һәм аның дөресен сөйләве булдымы, әллә шаяртуымы — аңлашылмады. — Хәзер дә берәр эш табасы иде. Кирәксә, армия өчен азык-төлек сатучы була алам. Аңынчы, сугыш бетеп куймаса, ягулык өчен тизәк сатсаң да ярый. Хәзер тизәкнең дә бәясе бар.

— Ай-һай, хыялларың!

— Алайса әйтегез, мәдрәсәдән китсәм, ни белән шөгыльләним?

Мәдрәсәдән китәргәме, әллә һич югы мәхәллә мулласы булырга да риза дисәң, тагын алты-җиде елга калыргамы? Бу уй соңгы ел, ел ярымда аларның башыннан чыкмады. Китәргә була, ләкин кая? Сираҗидан приказчик чыгарга мөмкин яисә тора-бара атасының сәүдәсе мирас булып калыр. Әмма хәзерге вакытта сәүдә эше дә дөньяви белем таләп итә, юкка гына акчалы кешеләр иске мәгарифтә үзгәрешләр үткәрүне таләп итмиләрдер... Урыс-татар мәктәбендә укысаң, кимсетүләргә әзер тор: анда синең культураңны түбәнсетәләр, ата-бабаң динен хурлыйлар.

Миңлебайга нишләргә? Аның артист буласы килә. Бу әле яңалык, кыю, әмма куркыныч омтылыш, чөнки элгәреләр бары көйләп дога укуны гына кабул итә. Сәүдәгәрләр клубының сәхнәсенә чыгып бас соң — минутында чыгарып ташларлар, әле өстеңә ташлар да ыргытырлар, ботарланган тәнеңне зиратка индерергә дә рөхсәт бирмәячәкләр. Аңамы соң артист булырга: ни акчасы, ни сүзе үтә торган туган-тумачасы юк, Камил булып ул да, күпме байлыгы, таныш-белешләре була торып, үзенең артистлыкка булган теләген догалар көйләп баса.

...Кечкенәләр Габулланы үз янына чакырды, әкият сөйләвен үтенгәннәр иде, әмма ул җавап бирмәде. Өлкәнрәк шәкертләр әбәт ашы пешерергә дәште. Әбәттә катнашу, димәк, уртак казанга бер кисәк ит салырга дигән сүз, аның исә күптәннән ит күргәне юк.

— Кара, бөтенләй оныткнмын! — дип кычкырып җибәрде Миңлебай. — Мин бит сиңа бүләк алып кайттым. — Һәм сөенеченнән балкып, киндер сумкасыннан китап чыгарды.

Каюм Насыйриның «Фәвакиһел-җөласә фил-әдәбият»[1] әсәре иде.

Габдулла уңайсызланды:

— Мин укыдым аны... әмма үземдә дә шундый китап булыр дип төшемә дә кермәгән иде.

— Киләчәктә алыш-биреш ясарбыз. Менә тагын... Пушкин.

— Рәхмәт! Габдулла бакчага үзе генә китте. Ул Пушкин китабын үзе белән алды. Юл уңаенда битләрен актаргалап, таныш һәм үзе өчен яңа булган шигырьләргә күз салды. Кызганыч, китапта «Руслан һәм Людмила» юк икән.

Менә агач рәшәле бакча. Агачтан ясалган гади капка, аулак сукмаклары куе үлән белән капланган. Пушкин бакчасы. Габдуллага унөч яшь иде, апрель аенда рус сыйныфында дәрес бирүче Әхмәтша учитель аларны шагыйрьнең йөз еллык юбилее уңаеннан шушы бакчага алып килгән иде. Ул үзенең каушавын, куллары дерелдәвен, яшь үсентеләрнең яфраклары лепердәвен, шагыйрьнең шигырьләрен куанып, авыз эченнән кабатлавын бүгенгедәй хәтерли. «Для вас, души моей царицы, красавицы, для вас одних...» Шундый искиткеч матур юлларны яза алган шагыйрьнең тормышы нинди булды икән, кемне яраткан ул, аның үзен кемнәр сөйде икән? «Я вас любил так искренно, так нежно, как дай вам бог любимой быть другим!» — дип язу аның өчен сөенечме, әллә авыр булдымы икән?

Каеннарның ак кәүсәләре ак төтенсыман күккә күтәрелгән, алардан өзелгән

[1] «Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимешләре».

яфраклар сары келәм булып сукмакларга түшәлгән. Өрәңгеләр кызгылт-сары төскә манылган яфракларын коярга ашыкмый әле, алар сагышлы елмаеп бакча күрке булып утыралар.

Габдулла тимгелле кызгылт-көрән зур яфракны кулына алды бит арасына кыстырды.

Рәхимле, мәрхәмәтле Аллабыз, кешеләргә ыгы-зыгы, мәшәкатьләр кирәк микән? Яшә, күр — урман үзенең кызгылт-сары киемен сала... — гомер буе карап туймаслык, шушы гади генә рәсем тудырган уйлардан арына алмыйсың.

Шулчак Габдулла шәкертләрнең ачулы тавышын ишетте:

— Төрек, төрек!

— Ул мөнафыйклар белән шәраб эчә...

— Әй, фәс, кызыл кикрик!

Кала гәзите мөхәррире Ядринцев белән Истанбул талибе Әмрулла урам аша кыйгачлап ашханәдән чыгып киләләр иде. Төрек егете калага узган ел килеп чыкты һәм Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенә сыенды, җәйне казакъ далаларында үткәрде. Һәм менә әйләнеп кайткан, күрәмсең.

Габдулла, бакчадан йөгереп чыгып, шук малайларны куркытты, тегеләре кайсы кая табан ялтыратты.

— Кара, башкисәрләр, — дип кычкырып калды ул артларыннан.

Әмрулла Габдулланы кочаклады. Ядринцев икесен бергә кочар өчен кулын җилкәләренә салды. Кайсыдыр бер кечкенә шәкерт, гайрәтләнеп, якынрак килеп кычкырды:

— Этләр! Өченче сүрәне оныткансыз! Аның аятендә кяферләр белән дуслашу тыела диелгән!

— Мин сине! — Габдулла бер-ике сикерде дә малайны эләктереп алды. — Әйбәтләп тыңла! — Өченче сүрәнең аятендә болай диелгән: «Мәшрикъ тә, мәгъриб тә Аллаһныкы. Кайда гына булсагыз да, йөзегезне Аллаһ кыйбласына борыгыз».

Көлешеп куйдылар да, ул малайны җибәрде.

Габдулла Әмрулла дустының бик нык борчылганын сизде. Йөзе кара наяннар!.. Әмма сәбәбе бөтенләй башкада икән. Терлек белән сәүдә итүче Мулакай байның бик чибәр кызы Фәризә кышны калада чыга. Кызны карт бик иркәли, мәгәр иреген дә әллә ни кысмый икән. Яшьләр каладагыларның йортларында, матди ярдәм күрсәтү җыелышларында очрашканнар, урамда да сөйләшкәләп йөргәннәр. Язын кыз атасының күчеп яшәү урынына киткән. Әмрулла да аның артыннан калмаган. Мулакай кунакны шатланып каршы алган, мактаган да әле: «Минем иркә кызымның туена өлгерүең ничек әйбәт булды!» — дигән. Чыннан да, кияүләре килеп, кызны Тургай далаларына алып киткән.

Ядринцев Габдуллага төрек егете белән бәйле хәлләрне сөйләп чыкты, битендәге яшь тамчысын сыпырып төшерде. Һәм иптәшен юатырга тырышты:

— Һәрвакыт, аңлыйсыңмы, һәрвакыт кешенең шәхси кичерешләре халкының тәртипләренә буйсына — менә шундый мәгънәсез һәм ахмак бөтендөнья кануны.

Әмрулла дәшмәде, бары авыр сулап кына куйды.

— Шайтан белсен! — Ядринцев сүзен дәвам итте. — Кыз туарга да өлгерми, аңа инде кияү дә табып куялар... сәер йола, әмма инде теләк буенча канунга әйләнгән, әхлак кагыйдәсе булган, һәм шушы тәртип хәзер шәхесне түбәнсетү өчен хезмәт итә...

Шулвакыт бакча өстендә зур кәгазь очыргыч күренде, ул әйләнде-тулганды

да карагач ботагына эләгеп калды. Малайлар, чыр-чу килеп, бакчага чабышып керде. Ядринцев сикереп торып малайларга булышырга ашыкты, аның артыннан Әмрулла да йөгерде. Балалар белән бергә, кычкырыша-акырыша, очыргычны ботаклар әсирлегеннән азат итәргә маташтылар. Габдулла, елмаеп, аларның мәш килгәннәрен күзәтте.

Дөнья явыз һәм мәрхәмәтле. Аның гореф-гадәтләре күптәнге һәм мактаулы дисәк тә, алар да яман була ала. Тик кайчан яман буласын белә генә алмыйсың.

Габдулла нәни шәкерт турында уйлады. Ул әйбәт малай, әкиятләр тыңларга ярата, күзендә ихласлык һәм хаклык ярылып ята. Ә бүген... нинди явызлык сирпелде аннан! Бер калада, бер урамда яшәп яткан Ядринцев — аңа чит-ят. Әмрулла, аның белән бер диндә, телләре дә бер үк диярлек — ул да ят. Әгәр Аллаһ кушса, кайчан да булса бу малай дөнья гизәр һәм күпләгән кешене, күпләгән язмышны күрер; диңгезләр кичәр һәм анда да күп төрле халык яшәгәнен белер, аларга хас уртаклыкны тота алыр. Яки инде кибет ачар да гомере буе күрше тыкрыктан ары китә алмас.

Ядринцев малайны агач ботагына күтәреп утыртты, икәүләшеп мәш килделәр, Әмрулла шул арада икенче яктан үрмәләп, очыргычны ычкындырды. Аннары бергәләп буталып беткән җепләрне сүттеләр, озын мунчала койрыкны төзәттеләр. Җибәреп карадылар — очыргыч очып та китте, Әмрулла, башын күтәреп, көлә-көлә, кәгазь кош артыннан йөгерде. Их, кайгыларны онытып булсын иде ул! Һәм, дәрвиш әйтмешли, тормыш бәҗра буенча китәр...

«Әмрулла калада озак тоткарланмас», дип уйлады ул эчке сагыш белән. Бу дуслык аның өчен язмыш бүләгенә тиң иде. Истанбул талибы шагыйрь иде, яшь төрекләрнең җитәкчеләре Кәмал бәй белән Зыя пашаны ул үзенең укытучы-остазлары итеп санады. Габдулла аның авызыннан беренче тапкыр халык җырлары кебек гади, Хуҗа Насретдинның мәзәкләре кебек үткен һәм ачы шигырьләр ишетте. Парижда Кәмал бәй тарафыннан нигез салынган журнал чыгаруны аның варислары дәвам итә, һәм Әмрулла зур горурлык белән хәзергә анда басылган бердәнбер шигырен Габдуллага күрсәтте. Журнал яшерен рәвештә Истанбулга китерелеп, яшьләр арасында таратыла. Париждан ике чемоданга тутырып Кәмал бәйнең фетнәчел журналын алып чыкканда, Әмрулланы поездда кулга алалар, ул ярты ел төрмәдә утыра, аннары илдән кача... Хәзер кая бара? Каһирәгәдер. Ул анда яшь төрекләр партиясенә нигез салган Мостафа пашаның кызы Назлы ханым белән очрашачак... Ә бәлки Иранга китешедер. Анда зур вакыйгалар куерып килә.

Әмрулла белән алар бүтән беркайчан күрешә алмас...

**7**

Калага зимагур, сукбай һәм шагыйрь Мирхәйдәр Чулпаный килеп чыкты. Ул атланып килгән карт алашасын беренче очраган ир кешегә сатып та җибәрде.

Кайчандыр Мирхәйдәр Чулпаный Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсен тәмамлаган, Бозаулык станциясе янындагы бер авылда мөгаллимлек иткән, әмма аны хөр фикерле булуы аркасында куганнар. Шуннан бирле даими сыеныр урыны юк. Һәр җәйне ул Җаек каласына кагылып чыга һәм бер-ике атна мәдрәсәдә яши. Мотыйгулла хәзрәт үзенең элекке укучысына карата мәрхәмәтле иде. Узган килүендә Габдулланы да шагыйрь белән ул таныштырды. Егет белән Чулпаный күптәнге танышлар кебек очрашты.

— Нәрсә, энекәш, кала бакчасына барып, туташлар карыйк мәллә, — диде, — әллә Байбурин әфәнденең ресторанына сугылыйкмы? — Без синең белән

мөселманнар һәм үз динебездәгеләр өчен тырышырга тиешбез. Һәрхәлдә, тәңкә ярым — милләтебез файдасына булсын.

Ул салырга да каршы түгел иде бугай, әмма яшь егет янында шәраб соратырга кыймады. Ул бу хактагы вакыйгаларны ярата, шигырьләр дә белә иде.

Шәраб, син шәп, шәригать кушмаса да,
Йә, дәртләндер күңелне, хушласана;
Син ачы да, тыелган да, шулай да
Тыелырга сыеңнан бармы чара?!

Чулпаныйның шигырьләре артык бормалы-сырмалы, аның югары өслүбтә язуы мыскыллап көләр өчен сылтау булып торды. Әмма егеткә аның шигырьләре ошый иде. Барысына төшенмәсә дә, ул дулкынланып укый һәм үзе дә бормалап-сырмалап тантаналы өслүб белән язарга тырыша. Чулпаный шигырьләрен сәнгатьле укымый, теле кызыксыну кузгатса да, шагыйрьнең фәлсәфәсен артык зур киеренкелек белән игътибарга алу аркасында егетне йончыта. Аның каравы тын сулы Чаган елгасы буенда көйләп утыру рәхәт иде.

Иртән томан, кич тә томан,
Томан баскан җирләрне...

— Ярабби, күпме шигырь укыганым бар, — диде Чулпаный, — әмма дөм-караңгы томан турында моңарчы бер сүз очратканым булмады. Безнең яшәү дә шундый томанда саташкан кебек. Кайчакларда мин, бәетләрне бары безнең халык кына чыгарадыр дип, беркатлы уйларга бирелләм. Ах, шайтан кушканмы: «Мин дусларым янына тулы турсык белән әйләнеп кайттым. Ялган да бәхет китерә икән, дип көлдек». Моны Кордованың зәңгәр күге астында Газәли язган. Сигезенче гасыр, мул сый мәҗлесе. Ну, энекәш, томан... томан!

Чулпаный җир дә сөрми, фабрикада да эшләми, әмма аның кыяфәте берөзлексез хезмәт иткән кешенеке кебек, соңгы вакытларда егет нәкъ шундый кешеләргә тартыла иде. Алар арган чырайлы, өсләрендә сәләмә кием, ашаулары да тыйнак, тормышлары гади, акыллы һәм сагышлы күзләренең талчыгуы аларны сукачы яки машинистка тиңли. Тормыш шартларының начар булуыннан газаплануны күңелләрендәге горурлык тыеп тора, алар барыннан канәгать.

Ашар ризыкларын алар көнлекләп эшләп таба. Әмрулла, мәсәлән, дәресләр бирә, гәзиткә яза, Чулпаный да нәкъ шулай эшли; Ядринцевның да эше көнлекләп. Кайчакларда Габдулла дәрвишне дә алар рәтенә куйды. Тик дәрвиш, кешеләр арасында сирәк күренгән изге рух кебек, кешеләр дә аның барлыгына бик үк ышанмый. Болары, әкиятләрдә әйтелгәнчә, яшәгән ди , булган ди. Әйе, алар яшиләр, таш юллардан йөриләр, үз басуларын сөрәләр, кайгы килгәндә елыйлар һәм иртә вафат булалар...

**8**

Атнага бер тапкыр мәдрәсәгә полицейский килеп чыга. Киң күкрәкле, тупас кына бу адәмнең саргылт мыегы нечкә итеп бөтерелгән. Үзен әллә кемгә санаганын раслап, оятсызлыгы йөзенә чыккан. Әмма ихласлыгы да җитәрлек.

Уку вакытында ул сыйныфларга кереп йөри, мышнап, авыр сулап: «Уф, шабыр тиргә баттым», — дип мыгырдана. Аннары ишек төбенә баса да, күзләрен кыскалап, көнбагыш яра башлый. Бервакыт ул гадәттәгедән озаграк торды. Камил Париж коммунасы турында сөйли иде. Укытуда ул каралмаган, әмма

Камил кайбер чигенешләр ясарга база иде. Ул хисләнеп сөйләде, хәлиткеч мизгелгә җиткәч, онытылып китте — тактадагы картаны йолкып алып, күрсәткеч таягы белән төртеп тиште дә сыйныф буйлап йөртеп чыкты: күрегез, урам җыенына чыгучылар ничек барганнар, янәсе. Чак кына полицейскийның өстенә менмәде. Шунда ук туктап калды һәм агарынып катты.

Баштагы минутта тегесе дә каушап калды. Аннары исенә килеп, көлемсерәде дә тынычлана төште.

— Кара син аны... коммуния, ди, имансыз! Бу сөннәтлеләр бүлмәдә утыралар, үзләре калфакларын да салмаганнар.

Аның тупаслыгы укучылар һәм укытучыны рәнҗетмәде, киресенчә, алар җиңел сулап куйдылар: шөкер, бу томананың башына калфакка бәйләнүдән башкасы барып җитмәгән икән.

Полицейский килүен дәвам итте, теге вакыйга да онытылган кебек булды. Әмма көннәрдән бер көнне мәдрәсәгә могтәбәр кыяфәтле әфәнде кереп, үзен мәгариф министрлыгы инспекторы дип таныштырды. Мотыйгулла хәзрәтне чакырып алдылар, аның каушавы йөзенә чыккан, хөкүмәт түрәсе киләчәге турында остазны алдан искәртмәгәннәр икән. Шуңа хәтере калган. Инспектор, картка ара-тирә күз ташлап, күбрәк Камилгә мөрәҗәгать итте, тегесе чыраен чытып, җиңелчә кабарынып утыра иде.

— Хөкүмәт оешмасына, — инспектор тар учы белән каядыр югарыга изәде, күрәмсең, кайсысы икәнен әйтергә теләмәде, — сезгә билгеледер, шикаять керде. — «Шикаять» сүзен ул чиркангандай теш арасыннан кысып чыгарды.

— Гафу итегез, — диде Камил тыныч кына, — ни өчен ул безгә билгеле булырга тиеш?

— И Ходаем, — инспектор көлде. — Демонстрациячеләр ничек йөргәнне күрсәткәннән соң, үзегез дә белергә тиеш идегез... Аннары ачулы тавыш белән: — Ялган, сафсата! — диде. — Ул кансызлар гимназия бусагасын атлап карасын...

Ниһаять, тавышын үзгәртеп, дусларча сөйләшүгә күчте.

— Хөкүмәт тирәсендә сезнең мәктәпләрегез турында сүз бара. Төгәлрәге, мәдрәсәне кем күзәтүгә алырга тиешлеге хакында. Әлбәттә, мәгариф министрлыгы үз кулына алса, иң дөресе шул булыр иде. Әмма мәктәпләрне башка шәһәрнекеләр өчен тыю фикере дә бар.

Мотыйгулла хәзрәт тыныч кына сүз башлады:

— Әгәр инспектор әфәнде рөхсәт итсә...

— Әлбәттә.

— Безнең бер елъязмада хөрмәткә ия морзаның патша белән әңгәмәсе бар. Ул патшага: «Моңарчы беркем дә бертөрле агачлардан гына урман үстерә алмаган», — дигән, имеш. Урман төрле агачлардан тора, инспектор әфәнде.

— Әйе, әйе, сезне аңлыйм. — Инспектор елмаеп башын селкеде. — Мин дә искә төшерим әле: Дарий патша вакытында фарсыларда буйсындырылган халыкның һәрберсе үзенең хокукларын ни барысы еллык ясак түләве һәм гаскәри бурычына бәйле хәлдә генә саклаган. Күп халыклы идарәчегә үзенең хезмәтчеләре арасында төрле раса һәм төрле телләләрне күрү рәхәт кенә булган. Ул хәтта бер үк төрле фикер йөртүче, бертөрле милләттән генә торган дәүләт төзүне күз алдына да китермәгән. Хәер, тарихны калдырып торыйк, — диде ул, елмаеп. Урыныннан торды да, чаларган кашын җыерып, нәрсә турындадыр исенә төшерде. — Шулай да министрлык сезне үз канаты астына алыр дип уйлыйм. Икмәктер, сезгә һич тә куркасы юк. Сез, хөрмәтле кешеләр, хакимнәргә каршы фетнә таратмассыз бит?

— Министрлык үз мәктәпләрен акча белән тәэмин итә, — диде Камил.

— Ә безнең мәктәпләр попечительләр җәмгыятенең хәеренә көн күрә. Бәлки министрлык безне дә тәэмин итәр?

— Һм-м... сугыш, әфәнделәр.

Аннары ул кискен хәрәкәт белән хуҗаларга иелде дә матәмдәге кебек башын түбән иеп, әмма тигез һәм нык адымнар белән чыгу юлына борылды.

Инспектор килеп киткәннән соң, Камил үзен бик сәер тотты. Соңрак кына бар да аңлашылды. Кала гәҗитендә Уральск өлкәсе хәрби губернаторының хәбәре басылды. Камил әфәнде М.Төхфәтуллиннан, рөхсәт кәгазе буенча, Җаек каласында чит кала кешеләре өчен төзелгән хастаханәдә түләүсез ятак тоту өчен Уральск төбәге мөселманнарыннан җыелган ике йөз сум кырык тиен акча алган икән...

— Кайчан өлгердең? — дип аптырады Габдулла.

— Бер айда җыйдым! Ышанасыңмы? Башкалар бер елда да җыя алмас иде. — Камил мактанса да, уңайсызлануы йөзенә чыккан иде. — Хәйрия эше, карават — дин кардәшләр өчен. Син әллә шуның кызыгын табасыңмы?

Габдулла көлемсерәде генә:

— Дин кардәшләр өчен бер ятак кына аз. Үткән атнада гына Борханкүлдә алты крәстиян яраланган. Хастаханәгә хәер-сәдака бирүчедән җыялар, сакчыларга түләргә дигәндә, акча табыла.

— Шулай, өязләрдә авыл полицейскийлары булдырганнар. Крәстияннар баш күтәрә. Адәм актыкларының тез буыннары калтырый, куркуларыннан теләсә кемне эләктерергә торалар. Безнең арттан да күзәтәләр, бел шуны! Әнә Гомәр хәлфә әле үк: хакимнәр сезнең яңа алымнарыгызны да күреп алырлар, дип кычкыра. Монафыйк, әләкче! Минем турыда ышанычсыз дигән имеш-мимешләр тарата.

Кияүгә җыенганда, апасы, Апушны чит кешеләр янында калдырмыйм, дигән иде. Мескен, аның үзенә дә ире йортында рәхәт түгел. Приказчик, гаилә башы буларак, менә дигән булып чыкты, әмма бик саран, үзенең кибете дигәндә, туган-тумача өчен дә комсызга әйләнә.

Апасы Габдулланы сирәк килгәне өчен битәрли, елап та ала, энесенең борчылуын күреп, ашыга-ашыга акланып та өлгерә.

— Син начар дип уйлама, өебез ашлы-сулы. Үзем дә тук, балалар да, Алла боерса, аякка басарлар.

Габдулланың тутасы йортыннан китеп, берүзе яши башлавына дүрт ел. Ул ярлы, әмма үзен ятим итеп тоймый. Һәм бары хәзер генә, бу елларны мөстәкыйль яшәп, үз язмышына нидер янавын аңлады. Бу — ятимлек иде, изге дәрәҗә йөрткән җиде буын нәселенең ятиме. Әлеге ятимлекнең чагылышын ул һәрдаим көнеленнән генә сизә килде: әйләнә-тирәдәгеләр аның белән хөрмәтләп сөйләшә, бүләкләр бирә, гөнаһларын кимету өчен мәхдүмнең догаларына ышыклана.

Аның күңеле чиста, саф, шул ук вакытта Изге Коръәнне укып чыккан бу кечкенә мәхдүм шундый беркатлы! Аларның авылында киез итек басу остаханәсенең хуҗасы Галимҗан бар иде, бар кеше диярлек аңа ярарга тырышты, берчак малай шушы адәмнең күрешергә дип үзенә сузган кулын алмады.

— Юк, юк! — дип кабатлады ачуыннан һәм чиркануыннан агарынган малай. — Үзен кызыл аракы белән пычраткан адәмгә кул бирергә ярамый!

Итекче бик һавалы, шәһәр эшкуарлары кебек байлыгы белән шапырына. Якташларына арты белән борылган бу тәкәббер итекчегә карап малай тагын өстәде:

— Тәкъвалыкны кабул итмәүче һәрбер тәкәббер йөрәккә хурлык өстенә хурлыктыр, — диде.

Һәрвакыт бердәм булып яшәгән крәстияннар аның бу сүзләрен ишетеп, ничек куандылар.

Аны ихластан яраттылар, әмма бу узгынчы ярату, чөнки ул бер кешегә генә төбәлгән ярату түгел иде. Андый мәхәббәт эченә мәкер яшеренә. Күпме ятимнәрнең күзен буды ул, юлыннан яздырды, күпмеләре, алданып, соңыннан эшлексез һәм теләнчеләргә әйләнделәр. Аллаһ аны коткарды!

Әмрулла юлга җыенды. Иртәгә китәсе дигән көнне Габдулла аның белән төн уртасына кадәр сөйләшеп утырды. Шәкертләр инде күптән тирән йокыда, караңгы коридорда Гомәр хәлфәнең генә, башмакларын чаштырдатып, әрле-бирле йөренгәне ишетелә. Бик теләсә дә, ул пышылдап кына гәпләшкән яшьләрнең ни турында сөйләшкәнен ишетә алмас иде. Вакыт-вакыт бер-ике сүз алышалар да тынып калалар һәм сүз сөрешен хәтерләрендә дәвам итәләр. Шулай итеп, Әмрулланың беренче тапкыр калага килеп чыгуын хәтерләрендә яңарттылар: башта аны хәтта Багдад хәлифәсенең нәселеннән диючеләр дә булды, тик аннары, егет белән полиция идарәсе кызыксынгач, аны талиб дип атый башладылар — тар карашлы бәндәләр шуннан да әшәке сүз таба алмады. Гомәр хәлфә мөфтигә һәм бер үк вакытта жандарм полковнигына әләк язып торуны үзенең бурычы дип санады. Бу ирекле шымчының хәбәрләреннән нидер белү өчен, полковник аннан: «Соң, төрек нәрсә дип әйткән?» — дип сорый. «Сүзләре әллә ни куркыныч түгел, — ди хәлфә, — әмма хәрәкәтләре куркыныч! Бакчада бер кыз белән йөргәндә, ул аны үбәргә маташты!»

Егетләр шаркылдап көлеп җибәрделәр һәм шунда ук тынып та калдылар: башмак чаштырдавы алар ишеге төбендә туктап калды. Бер-берсенә карашып алгач, түзмәделәр, тагын пырхылдаштылар. Алдагы көнне Гомәр хәлфә төрек егетеннән изге урыннарны уравын һәм шулай итеп хәлфә файдасына Хаҗ сәфәре кылуын сораган. Хәлфәнең Мәккәдә булганы бар, әмма фабрикант Мортаза Гобәйдуллин килешүе буенча хаҗ кылганга, аның савабы байга гына эләкте. Хәзер исә Гомәр хәлфә үзен шундый рәхәткә лаек дип тапты.

— Нәрсә дип җавап бирдең инде? — дип сорады Габдулла.

— Үтенечен үтәргә вәгъдә бирдем. Әйдә, мине изге урыннарга китә дип уйласын, мин бөтенләй икенче тарафка юнәләм.

Сүзсез калдылар. Инде аерылырга да вакыттыр, әмма Габдулла кабат сүз башлады:

— Без очраклы рәвештә очраштык, бәлки башка күрешергә дә язмас. Шуны бел: үземнең башка ватандашларыма караганда сине яхшырак аңлыйм. Синең белән сөйләшкәндә яисә менә Ядринцев белән гәпләшкәндә, халыкларның берләшү вакыты якынлашканын тоям. Әмма сине мактау дип кабул итмә, үзем аннан газап күргән кеше, мин бит сизәм... без шулкадәр үз-үзебезгә бикләнгәнбез, наданлыкка батканбыз, юк-барларга ышанабыз, томаналар...

— Миңа сезнең халык ошый, — дип, Әмрулла аның сүзен бүлдерде. — Ярлы, җәберләнгән, әмма туган илегезгә карата ярату хисе сездә без — төрекләргә караганда да көчлерәк! Без мөселманнарның бердәмлеге турында хыялланып, иң гадиен һәм иң беренчесен — туган илгә мәхәббәт хисен оныттык. Юкка гына акыл иясе Намикъ Кәмал бәй үз драмасында нәкъ шул турыда язмаган. Һичшиксез, Төркия — «авыру кеше», һәм авыруны — мин әйтте диярсең! — авыруны анатолий крәстияннары коткарачак. Бары тик анатолияләр генә үз күге, үз икмәге, үз җырлары белән халыкка сәламәт һәм намуслы сулыш өрәчәк...

## 9

Сарай мәйданы каршында булган атышлар турында сөйләделәр, дистәләгән кеше үтерелгән, яраланган хатын-кызлар һәм балалар кар өстендә ятып калган. Нинди дә булса хәвефне күз алдына да китермичә, халык үзенең патшасы янына килгән, ул озаклаган, шул арада канэчкеч жандармнар ут ачкан. Бәла-каза күрүчеләрне җәлләделәр, патша үзе дә гаепсезгә коелган кан өчен газапланадыр, диделәр.

Патшаның мөрәҗәгате дә зарланулы иде: «Неисповедому Промыслу Божию благоугодно было посетить Отечество Наше тяжкими испытаниями...»

Габдулла халык арасында йөргән имеш-мимешләрнең вакыйгаларны бозып күрсәтүен сизде, болар бар да беркатлы, ялган. Әмма чынында виләр булганын аңлап җиткермәде. Ул югалып калды, моңа үз акылы җитәрлек түгел. Мотыйгулла хәзрәтнең әрнүле һәм пәйгамбәрләр тынычлыгы белән әйткән сүзләренә дикъкать белән колак салды:

— Мин нәрсә буласын беләм. Күптән түгел генә тотрыклы булып күренгән нәрсәдән көл өеме генә калыр. Тик мин безнең белән, әлегә үзләренеке арасындагы фикер каршылыклары турында хәбәре булмаган халкыбыз белән ни булырын әйтә алмыйм.

Аның әйткәннәре аңлаешсыз һәм күңелгә тәэсир итми. Коръән дә дөнья бетүе турында телгә ала, әмма бу берәүне дә куркытмый бит? Камил бу турыда ни уйлый икән? Сәясәтче һәм көрәшче Шәрифовның фикере ничек икән?

— Минем сүзләремне хәтерлисеңме? — диде Камил. — Тигезлек турындагы бар сүзләр канкоешка китерәчәк. Берничә мылтыктан берничә ату белән ризасызлар шундук юк ителә... Ай-һай, куркыныч тынлык башланачак хәзер!

Әмма тынлык башланмады. Февраль аенда ук Җаекка берсеннән-берсе котчыкмалы хәбәрләр килеп ишетелде: Гельсингфорста сенат прокурорын үтергәннәр... Мәскәү генерал-губернаторы бөек кенәз Сергей Александровичның җанын кыйганнар... Одесса полицмейстерына һөҗүм иткәннәр... Эшчеләр башкалаларда: Томскида, Казанда, Сарытауда баш күтәргән. Бу зур тизлектә килеп ирешкән имеш-мимешләргә кала кешеләренең әллә ни исе китмәде. Әмма каланың үзендәге вакыйгалар хәйран калдырырлыклары иде.

Алпавытлар калага килеп, хөкүмәт оешмаларын камап алды һәм баш күтәргән крәстияннарны бастырырга казаклар җибәрүен таләп итте. Казакларның хакимият тарафыннан оештырылган махсус отрядлары бар җиргә дә өлгерә алмады, февраль бураннарында батып, өшеп, йокысызлыктан йөзләре каралып, йончыган арык атларда калага кайтып төштеләр...

Камил башта бик нык курыккан иде, хәзер акрынлап үз халәтенә кайтып килә, ниндидер өметләндерерлек хәбәрләр отып алырга тырыша.

Габдуллага, мөгаен, бер генә юл каладыр: мәхәллә мулласы булу, мәктәп ачып, крәстиян балаларына сабак өйрәтү. Өйрәтергә? Әмма ул үзе гыйбадәтләрне калдыра, ураза тотмый, җыеп әйткәндә, адым саен гөнаһ ясый. Аны тәкәббер, диләр. Әйтерсең, башкаларга түбәнсетеп карый. Алар аның күбрәк үзен түбәнсеткәнен белмиләр шул. Дөрес, өйләнүне дә, Хикмәтнең яисә Саша Гладышевның эшен дә, хәтта Камилнең мәшәкатьләрен дә үзе өчен бик мөһим һәм кирәкле санамады. Бәлки шуңа аны тәкәббер дип әйтәләрдер?

Нәрсә белә ул, алда ни күрә?

Сабый чагында бөтен дөньясында ул берүзе калды, һәм аны базарга алып килгән крәстиян: «Асрамага бала бирәм, кем ала?» — дип кычкырды. Шунда ук җавап кайтарган кешесе дә табылды. Менә хәзер: «Кем мине зур кешелек дөньясына ала? Аның бар белемнәре, кануннары, матурлык һәм максатчан төшенчәләре белән берләштерә?» — дип аваз салсам, берәрсе табылыр иде

микән? Бу зур кешелек дөньясы белән элемтәдә булмау, аның акыл ияләрен һәм шагыйрьләрен, дин белгечләрен белмәү, — димәк, ятимлек алга таба да дәвам итә дигән сүз. Тормышымны үзгәртергә кирәк», — дип уйлады ул. Әмма ничек, нәрсәдән башларга? Кем белән?

## 10

Кышның калган көннәрен Габдулла ялгызлыкта үткәрде. Дәресләргә дә әллә ни исе китмәде, Камил белән дә ара-тирә — тәнәфесләрдә генә күрешкәләде, ул да дәресләрен әллә нигә бер генә укытты, һаман каядыр китте, оешмалар буйлап йөрде. Ниһаять, апрельнең шау-гөр килеп торган бер көнендә, кичкә табан, ашыгып кына тулай торакка керде, тиз генә хөҗрәнең чаршавын сыдырды да Габдуллага ташланды:

— Безнең үз гәзитебез булачак... һәм, бәлки, журнал да. Мин бәхетле! Син? Киттек тизрәк, киттек, бүген төн безнеке... Мин инде булачак хезмәткәрләрнең исемлеген дә төзедем, син — беренче.

Алар апрельнең карлы, саф һавалы төнендә бик озак сөйләшеп йөрделәр, чып-чын басылган гәзит аларның тормышын искитмәле үзгәртер иде, диештеләр. Камил узган елның буеннан-буена төрле хөкүмәт оешмалары буйлап йөреп карады, ләкин бар да уңышсыз тәмамланды, ахыр чиктә башкалага үтенеч юллады. Анда да кире кактылар. Мең тугыз йөз бишенче елның башында кабат Петербургка язды. Камилнең якыннары аның ниятен хәвефле, хәтта куркыныч дип санадылар: зур түрәләр аны фетнәче дип санарга мөмкиннәр иде. Менә шушы көннәрдә генә җавап килде, бу юлы да томалап куелган дип аңларга була иде. Камил сизенде: монысында эш пешәргә тора, чөнки җавапта, гәзит чыгару өчен аерым ышанычлар кирәк: хуҗасының маллы-мөлкәтле, матди нигезе булуы кирәк. Шартлар үтәлгән очракта, бу мәсьәләгә кабат әйләнеп кайтырга мөмкин, диелгән иде. Ул киңәш-табыш итәр өчен Ядринцев янына китә.

Ул исә болай дигән:

— «Уралец»ны типографиясе белән бергә сатып алыгыз да иясе булыгыз!

— Нәрсә, хуҗасы сатармы?

— Баш-аягы белән! Шулар белән бергә мине дә сатарга мөмкин, мин төкерәм аңа. Китәм мин. Ник дәшмисез? Киңәшем өчен рәхмәт әйтегез! Киттек, башкалага китүем хөрмәтенә бераз гына тотып куйыйк.

Ядринцев белән бер шешә шампан шәрабен бушатып, аның эчпошыргыч сүзләрен тыңлап арганнан соң, Камил Габдулла янына ашыкты.

Димәк, эш типографияне сатып алуга терәлде. Тик Камилнең акчасы юк. Бөтенләй юк. Ләкин акчаны ул атасыннан алыр, туган-тумачадан сорап торыр, хатынының бирнәсен акчага әйләндерер. Ахыр чиктә танышларыннан бурычка алыр. Тик менә аңа сырышкан дуслары гына кайсы кая таралышып бетте: берсе шау-шулы вакыйгалар тынганчы дип, әтисенең утарына ычкынды; икенчесе сәүдә мәйданында аякка басарга маташа; шайтан алгыры, инкыйлабчы Шәрифов махмырдан бушамый...

Типографияне сатып алганчы ук, Камил, Ырымбур нашире Кәрими белән эшчеләрен өйрәтү мәсьәләсендә килешеп куйган; Габдулла Ырымбурга типография эшенә төшенү өчен китәргә тиеш булачак. Казаннан хәрефләр белән җиһазлар җибәрергә вәгъдә иткәннәр. Ул арада акча да табылды: җитмәгәнен, һич көтмәгәндә, зур мануфактура ширкәте башлыгы Мортаза Гобәйдуллин биреп торды. Камил каушады: «Күктән бәхет яуса, юләр дә уңа», — дип шаярткан булып маташты.

Габдулла тормышындагы бу үзгәрешләргә эчтән генә үзен әзерләде: алда торган сәфәр дә, аннары нәшриятта эшләячәге дә аның мәдрәсәгә башка

әйләнеп кайтмавын белдерә иде инде. Ул әзерләнеп беткәч кенә, Камил кинәт игътибарсыз гына:

— Без Ырымбурга сәфәрне чигереп торырбыздыр, мөгаен. Хәзер типография үзебезнеке, мондагы хәреф җыючылардан эшкә өйрәнерсең, — диде.

Сәфәргә акча юк дип дөресен әйтсә дә була иде. Югыйсә, соңгы тиененә кадәр типография өчен тотылуы каланың бар кешесенә мәгълүм.

Габдулланың бүген бернинди эше юк иде. Апрельнең соңгы көннәре. Урамда җәй башындагы кебек җылы, тымызык һава. Ул Казан мәйданындагы ашханәгә сыра эчәргә керде. Кеше юк диярлек, ябышкак буш өстәлләрне чебен сырып алган, тузанлы тәрәзәләрдә кояш нурлары калтыранып күренә. Пинжәгенең җиңен терсәгенә кадәр кайтарып куйган, кулына стакан тоткан яланбашлы бер адәм буфетчы белән аңлашырга маташа. Менә ул стаканын бушатты да, җиңелчә биеп, залның уртасына чыкты һәм бер мескен җан бирер алдыннан соңгы тапкыр дәртләнеп калгандай, тыпырдый башлады. Шушы кешенең Ядринцев икәнен танычгач, Габдулланың күзе шар булды.

— Исәнме, егет, — дип дәште аңа мөхәррир һәм янына килеп утырды. — Мин, дустым, китәм... Китәм! — дип кабатлады сагышлы тавыш. — Сез, мутлар, ундырышлы җирләрдә яшисез! Акыллым, сездә, татарларда, сагыш, моң мондый... урысларда нинди, беләсезме? Әйдәгез, сарматларны искә алыйк әле...

Бераздан мәгънәсез сүзләр сөйли башлады, тагын стаканын тутырды һәм шунда ук бушатып та куйды. Тик кайсыдыр бер мизгелдә айнып киткәндәй, егеткә текәлде:

— Истәлеккә берәр нәрсәмне алыгыз, — дип пиджагын селкеде һәм аннан бөгәрләнеп беткән сары тышлы китапчык төште. — Менә моны булса да, ә?.. Истәлеккә.

Габдулла ризалашып, китапчыкны кесәсенә тыкты һәм китәргә ашыкты. Урамга чыккач, аны кызганудан кире кабакка борылмакчы итте, тик кермәде... мөхәррир артык исерек иде шул. Вакыйгалар зур тормышның чагылышы кебек тоелса да, Габдулла, чынында минем гомер күптән башланды инде, дип уйлады. Башланды, чөнки котылгысызлык көтелә бит — әле алда күп нәрсәләр көтәдер — үзенә якын кешеләрне табар да, югалтыр да. Яшьлектә ул турыда әллә ни уйлап тормыйсың һәм үкенеп тә өлгермисең... Хәзер Ядринцев ничек жәл!

Хөҗрәсенә кергәч, ул китапчыкның тышын укыды: «Царь-голод. Экономические очерки». Димәк, истәлеккә... Мәңгегә...

Куе караңгылыкның дымлы чирәмендә тычкан уты уйный һәм төн күгәрчене черелди, караңгылык һуштан яздырырлык гаҗәеп хуш исләр белән җавап кайтара.

Кечкенә бүлмәгә җан өреп азапланган шәм яктысында кинәт аны нииндидер тәкатьсезлек шаукымы биләп алды... Ул сәкедән сикереп торды, калтырый-калтырый өстенә киенде һәм ишегалдына йөгереп чыкты, койма аша сикереп төште һәм акрын гына шаулап торган төнге урам буйлап мәйданга таба атлады.

Әле генә күз алдына килгән нәрсә хыял түгел, ул кыз да (тагын кем булсын?) нәкъ шундый ук хисләр кичереп, мәйданның каршы ягыннан йөгереп киләдер, һәм Офицерлар йорты янында алар очрашыр. Кызны көттермәскә теләп, ул йөгерде, аннан алдарак килеп өлгерүенә куанды. Менә ул йорт... Иртәгесен ул бу йортка күзен күтәреп карый алмады, әйтерсең, өйнең икенче каты, авыр аркалар тезмәсе, астагы кибет, капка өстендәге яшел алтакта да аның төнге маҗараларын беләләрдер төсле тоелыр...

Ә бүген... Ул тыныч зур бинаның почмагында, йолдыз атылган саен сискәнеп, һәрбер кыштырдауны, чагылып киткән һәр шәүләне күз уңыннан ычкындырмый басып тора.

Караңгы төшкәч эш сәгате башлана торган бер бичара кыз, аның янына килеп, кунып чыгарга тәкъдим итте. Ул кызга күзләрен тутырып карады, ләкин дәшмәде.

— Бәхетсез егет, — диде төнге күбәләк, аны танып. — Син, мөгаен, акылыңнан язгансыңдыр.

Көндез ничектер ул велосипедта барган Диләфрүзне күрде, велосипедының кыңгыравы кинәт өндәге кебек җырлап куйды: «Аллаһ мәхәббәтләре дәвам иткәннәрне үтерми». Чынлап та, бик, бик чибәр бит ул! Төннәрен исә мәхәббәткә багышланган шигырьләрен язганда, ул гүзәл Хөснибануны күз уңында тотты: кыз үзенең кулын сорап килүчеләргә чишәргә җиде табышмак биреп озата, шаһзадәләрнең иң гаярьләре исә таулар һәм чүлләр аша гаҗәеп нәрсәләр, гыйфритлар белән көрәшергә китәләр дә эзсез-нисез югалалар.

Аның Диләфрүз белән сүз алышканы булды.

— Ишеткәнегез бармы, шагыйрь Дәрдемәнд үз акчасына ятимнәр йорты тота. Үзе дә бәләкәчләрне тәрбияләү белән мәшгуль. Ул шундый бай! Минем көчем бер кызны тәрбия кылырга гына җитәрлек. Габдулла, мин беркайчан да кияүгә чыкмыйм, бар гомеремне фәкыйрь ятимнәргә багышлыйм. Мәктәп ачармын, үзем белгәннәрне өйрәтермен.

— Сөйкемле, матур...

Ул бу сүзләрне ишетмәгәнгә сабышты һәм яңгыравыклы тавышы белән дәвам итте:

— Без үзешчәннәр спектакле әзерлибез. Сез нигә бер дә катнашмыйсыз? Без сезгә менә дигән роль табар идек.

— Гыйфритнеме? Әллә аннан да коточарлыгынмы? Бәлки хәйләкәр приказчикныдыр? — уңайсызланып шаяртты Габдулла һәм велосипедның ялтыраган рулен сыйпап куйды.

— Сезгә велосипед ошый мәллә, нигә үзегезгә сатып алмыйсыз? Шәп машина, шулай бит?

— Әйе.

...Кызның кулы орынган һәрнәрсә шулай матур күренә. Менә алар тарафыннан алынган ятимә кыз; Диләфрүз аңа матур күлмәкләр киертә һәм алар икесе йөрергә чыгалар. Аның тирәсендә бар нәрсә балкый: идарәчеләр кирәк-ярагын җыеп ярминкә рәтләре арасыннан үткәндә дә, шәфкать туташы булып гади ак халаттан сырхауханәгә барганда да, шул гади халатның аңа ничек килешеп торганын күрсәң!

Ул үзе дә чибәр икәнен сизә, очынып алулары да бик килешле. Әйләнә-тирәдәгеләрнең дә ять-яшь кызның башкаларга бәхет өләшкәнен күреп, күңелләре нечкәрер... Ятимәне юындырырлар, корсак тифыннан дәваларлар, матур күлмәк кидереп аның янына китерерләр. Диләфрүз үзе тиф белән авыручылар ята торган хастаханәгә барыр, авыру кызга әкиятләр сөйләр, юындырыр, күкрәгенә кысып җылытыр! Матур күренеш түгел, тик нәкъ менә шундый кайгырту күп мәртәбәгә әйбәтрәк...

Юк, көн коточкыч узды. Төнлә, бәхетле Габдулла, башкаларның шигырьләрен уйлап ятты.

Ул апаларында кунды. Габдулланы чәй белән сыйлаганда, ул серле-иркә карашын энесеннән алмады.

— Мин сине эзли чыгасы идем инде. Син, чынлап та, белмисең, ахры...

Мөхәммәтгали кибет белән арасын өзеп, балта осталарына кушылган һәм алар, бер бай терлекче белән эш белешеп, далага киткән икән.

— Шуннан нәрсә?

— Бәлки сине дә алырлар. Акча эшләр идең. — Апасы бераз туктап торды. — Мөхәммәтгали өйләнергә җыена.

Ул бичара хатынны гаҗәпкә калдырып шаркылдады:

— Юк, мин нәрсәгә барыйм? Мин бит өйләнергә җыенмыйм.

— Син һәрвакыт апаңны ахмак санап көләсең!

Типографиядә, хәреф җыючылар урнашкан идән астына төшеп килгәндә, бер егет белән бәрелештеләр, егет юл биреп йөгереп менеп китмәкче иде, әмма кинәт туктап калды:

— Габдулла?

— Сашка!

— Көтеп тор, мин хәзер.

Май исләре аңкып торган караңгы томан эчендә, гадәти булмаган подвал, тимер кәрәзләр белән чуарланып беткән өстәлләр, машиналар, әле күтәрелеп, әле төшеп торган рәшәткәле җилләткечләр. Шундый машиналарның берсендә иде Ицхак. Озакламый Сашка Гладышев та килеп җитте, оста күренде, ул кешене Камил хөрмәт белән Андрей Савельевич дип тәкъдим итте.

Төш вакыты җиткәч, егетләр каршыдагы ашханәгә җыендылар, Габдулла да, Камилне мастер белән калдырып, аларга иярде.

Сөенеп күзәтте ул балачак дусларын, вакытның, төс-кыяфәтне үзгәртсә дә, холыкны элеккечә калдырганын күреп гаҗәпләнде. Габдуллага алар зур малайлар кебек тоелды.

— Аның өйләнүенә икенче ел инде, — диде Сашка, өстәл янынннан кузгалып. — Ицхак үзенең җилкә чокырын күрә алмаган кебек, хатын чырае күрәсе кеше түгел иде, ярый әле Җаекка Флейшманнар килде. Аларның күп тә түгел, аз да түгел — нәкъ унике кызы бар. Ицхак иң өлкәнен алмакчы иде, аңа: кечесен ал, аның да синең кебек әле сөт эчә торган вакыты, дигәннәр.

— Такылдык син! — дип калын тавышы белән көлде Ицхак. — Цехка кайтырга вакыт, ә ул тузга язмаган әкиятләр сөйләп утыра.

Икенче көнне, дәресләр тәмамлануга, Габдулла типографиягә йөгерде. Һәм һәр көнне билгеләнгән сәгатькә килеп җитә торган булды. Хәреф җыю эшен ошатты ул, шулай ук егетләрне дә. Очрашкан саен, уен-көлкеле балачактан соң бик күп сулар акканына төшенде.

Әмма элекке гадәт буенча шаяру, уен-көлкеләр бары беренче көннәрдә генә булды... Унике сәгатьлек эш көне, ипи табу кайгысы, сәламәтлекләре өчен борчылу һәм курку — авыру килеш син хуҗаңа кирәкмисең, — болар бар да яшьләрне кыюсыз-усал һәм кызып китүчәнгә әйләндерде. Җәлләгән саен алар алдында үзеңне гаепле сизгәндәй ояласың.

«Дөньяда бер падишаһ бар ки, ул падишаһ гаять шәфкатьсездер, аның исеме — Ачлыктыр...» — Габдулла очраклы рәвештә генә Ядринцевтан кулына төшкән «Ачлык-Падишаһ» турындагы китапның битләрен беренче кичтә үк актарып чыкты, аннары кайбер сүзләрнең, мәсәлән, тауар алмашу, өстәмә кыйммәт, көндәшлекнең мәгънәсенә төшенергә теләп, җентекләп укыды: башына, әгәр бу китапчыкны тәрҗемә итүче табылса, үзләренең нәшриятында бастырырга да булыр иде, дигән уй килде. Менә хәзер Канбәкнең фаҗигале үлеме турында уйлап утырганда, китапның баштагы бүлекләре исенә төште, аларны яттан белә икән һәм эченнән генә татарчага тәрҗемә кылды. «Менә бит, үзем үк тәрҗемә итәм, — дип уйлады Габдулла. — Мөгаен, хәзерге вакытта минем өчен эшли алырдай бердәнбер нәрсә — шулдыр».

Әмма тормыш тәгәрмәчләре бернигә карамый әйләнә дә әйләнә. Полицейский да кабат мәдрәсәгә керә һәм үзенең оятсызлыгын күрсәтә башлады. Жандармнар

завод тирәләрендә иснәнделәр, ат арбаларына барган көйгә сикереп менеп юлчыларны тентеделәр: янәсе, пар тегерменненнән каеш урлаган каракларны эзлиләр. Ибнеәминов фетнәдә шикләнгәннәрнең барысын да рәхимсез рәвештә куды һәм алар урынына яңаларны алды... Урамда хәсрәте йөзенә чыккан исерек Шәрифовны күргәннәр. Ул сәүдәгәр малаен тукмап яныннан куган һәм яңадан ярдәм күрсәтү оешмалары эше башлау ниятеннән ваз кичкән.

**11**

Җаек елгасы артында, мещаннар җыелып ял итәргә, чәй эчәргә яраткан Хан урманлыгында, яшерен җыелыш үткәрергә карар кылынды. Алдагы көндә Габдулла Хикмәт белән күреште һәм алар анда көндез очрашырга булдылар. Шуңа иртән бик кабаланмады — тынлыкта әйбәт языла иде.

Көтмәгәндә Камил килеп керде. Дуамал, дип уйлады Габдулла, иртә таңнан урынында тора алмый бит...

— Урамдагы хәлне күрсәң иде! Каланың олысы-кечесе Зур Михайловскоега агыла.

— Нәрсә, анда аю биетәләр мәллә?

— Шулай булса иде! — дип көрсенде Камил.

Ул нәрсәнедер әйтеп бетерми. Әмма озак түзә алмады, сөйли үк башлады. Мотыйгулла хәзрәт янына жандарм килгән һәм шәкертләр фетнәчеләр янына йөгермәсен дип, күзәтергә киңәш биргән. Типография хуҗасы Камилне дә кисәткәннәр. Камилнең күңеле төшкән, урам тулы казаклар, ди. Типографиядәгеләр, билгеле, өйләрендә утырмаслар, җавабын миннән таләп итәрләр, ди. Кибетчеләр дә чыш-пыш килә ди, әгәр эшчеләре баш күтәрә-нитә калса, тәртип урнаштырачакбыз, дип яныйлар ди...

Алар ишегалдыннан чыккач та шау-шу, буталыш, кыштырдау, кычкырыш эчендә калдылар. Камзуллы һәм энҗе белән чигелгән түбәтәйле берәү:

— Сүз дә юк, тыныч каршылык күрсәтү кирәк. Әмма безгә, мөселманнарга, аны аерым үткәрү зарур, — ди.

Почмакта басып торган городовой авызын зур ачып иснәде дә каты итеп тешләрен шыгырдатты. Камзуллы әфәнде шунда ук пышылдауга күчте. Һәр тарафтан фикер агылды:

— Халык гаепли — һәм Аллаһ нәтиҗә чыгара.

— Халык түгел, хулиганнар өере.

— Динне үзгәртүче...

— Минемчә, карт какшаган.

Тавышлар:

— Ислам аркасында гына гарәпләр тугызынчы...

— Хәзер егерменче гасыр, әфәнде.

— Милләт эчендәге фикер башкалыгы аны бетерәчәк...

— Аллаһы табигатьтән аерылгысыз...

Кызлар гимназиясенә якынлашкан саен, халык төркеме бәйләнчекләнә барды.

— Әфәнделәр! Мин әйтәм, әйдә, хакимнәр өере тантана итсен! Мин бәдрәф чистартучы булып китәм һәм аларга җирәнеп караячакмын!

— Шайтаныма олак!

— Ахырын алдан уйлабрак куй...

— Көчкә каршы көч!..

— Явызлык тирән катлаулы!..

— Укымышлы монарх...

— Ха-ха, фәлсәфәче жандарм!

Габдулла килүгә Камилне күздән югалтты һәм Хикмәтне очратып булмасмы дип, тәвәккәлләп төркем эченә кысылды. Тегесе үзе Габдулланы эзләп тапты һәм кулыннан эләктереп, җәяүлеләр сукмагына алып чыкты.

— Мин сиңа гимназия янында җыеласыбызны әйтергә онытканмын.

— Шул кадәрле халык җыелыр дип көтмәгән идек. Моргулис монда сөйләргә киңәш итмәде: килмешәкләр артык күп. Акылдан язган Котбыйга, күр, полицейскийлар бармак белән дә чиртмәде.

Халык төркеме өстендә, атынгалап, язу күтәрелде: «Яшәсен Беренче май — хезмәт бәйрәме!»

Шәкертләр, тәмәке көйрәтә-көйрәтә, ханымнарның ялангач кулларына карап рәхәтләнде. Полицейский, үзен тырыш һәм ышанычлы күрсәтергә теләп, әдәпле генә, арган һәм исе китмәгән кыяфәт белән, гавам эченә кереп кысылды. Төркем кырыена елышкан сумса сатучыны ипле генә куды:

— Ярамый, ханым, ярамый. Сату өчен махсус бүлеп куелган урын бар.

Гавам никтер ышанычсыз, тавыш-гаугалы иде, үзеннән-үзе кузгалып та китте. Алдан — язу күтәргәннәр, алар артыннан механика заводы эшчеләре, күнчеләр, депоныкылар, типографиянекеләр атлады.

Елгага җитәрәк, алдан баручылар адымнарын акрынайтты. Менә беренче рәттәгеләр күпергә керде. Арттан килгәннәргә туктап, бераз көтеп торырга туры килде. Күпернең ике ягында да полицейскийлар һәм Котбый җитәкчелегендәге дистәләп сәүдәгәр тезелгән. Котбый яшәреп киткәндәй булган — бите түгәрәкләнгән, җыерчыклары язылган, башында сарык тиресеннән тегелгән, түбәсе тәбәнәк бүрек, өстендә озын чабулы казаки.

Эшчеләрне алар дәшми-тынмый гына үткәреп җибәрделәр, әмма калган кешеләр якынлашкач, Котбый кулы белән селтәнде:

— Әй-әй, мөселманнар күперне чыгарга тиеш түгел. Бу — күпер. Сират күпере, йә тәмугка егылып төшәрсез, ха-ха-ха!

Кайберләре, чынлап та, читкә тайпылды.

— Дөрес, эссе бүген... өйдә утырсагыз яхшырак.

Тантанага чакырылгандай киенгән вице-губернатор Шидловский кара айгырга атланып килде.

— Әфәнделәр... анагызны!

Котбый вице-губернаторның ботына шапылдатты һәм атны өркетеп кычкырды:

— Безнең бөек әбинең сәрдары дөрес әйтә! Әби патшабикәнең кочагына сыеныгыз!

Караңгы чырайлы Шәрифов туп-туры Котбыйга таба ыргылды. Тегесе читкә каерып өлгерде:

— Адашкан ул! Борыл, әле соң түгел. Төпсез чокырга төшәрсең, үзеңне сакла!

Шәрифов Шидловскийга таба борылды:

— Оят, вице-губернатор әфәнде! Котбыйны сары йорттан махсус чыгармадыгызмы икән, дигән уй туа. Үзегезне елгага тотып атмасын.

Шидловский тыныч иде:

— Ул кемне күпердән ыргытырга кирәген бик яхшы белә! Тик сезнең хакта гына никтер ялгышкан.

— Кабахәтләр, адәм актыклары, — дип мыгырданды Шәрифов, — фиргавеннәр, шымчылар, талаучылар!..

Елганың икенче ягында казакълар даладан терлекләрен куып азаплана иде. Каршылык күрсәтүчеләр сафы шактый алга китеп, инде урманлыкка борылып маташа, күпернең бу ягында калганнарга куе тузан болыты якынлашты. Тагын Котбый тавышы таралды:

— Әй, муллалар, сарыкларыгызны саклагыз! Бу сезнең яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтаручы мәхәллә кешеләре. Мин сезнең әбиегез белән тагын меңне җибәрәм... аралашмагыз, аерылыгыз... әй, ротмистр, тотыгыз!..

**12**

Октябрь уртасы. Урамда пычрак, салкын, соры күңелсезлек. Әмма кала, бәйрәм алды сыман шау-гөр килә: гражданлык иреге бирәчәк патша манифесты турында кем нәрсә ишеткән, шуны сөйли. Барысы шатлык, өмет, әйбәт яңалыктан рәхәтлек кичерә. Листовкалар бу вакыйганы хәтта инкыйлабның җиңүе дип атады.

Октябрь ахырында Камил Казаннан хәрефләр алып кайткан. Гәзитнең чыгуына санаулы гына көннәр калды. Канәгать елмаеп тәмәкесен көйрәтте. Аннары Казандагы хәлләрне бәян итте.

— Патша манифестка кул куйган. Номердан чыктым да Вознесенскийга киттем — андагы халык! Университет ишеге төбендә полиция җыелган. Халыкны тыеп булмый, бинага бәреп керделәр. Мин урам җыелышына эләгә алмадым, тыныч кына үтте, диделәр. Халык таралыша башлагач, казаклар өстенә шартлаткыч ыргытканнар. Ахырдан җайдаклар, төрлесе төрле якка сибелеп, ут ачканнар!..

— Ничек инде, манифест бар бит?

— Инкыйлабчылар өчен бу алдагы көрәшнең бер адымы гына ди... Шул ук көнне социал-демократлар комитеты полицияне коралсызландырырга чакырган ди. Шаккатырсың: комитет Шәһәр коммунасы оештырырга карар бирә, биш йөз кешедән торган халык милициясе төзи...

— Ә безнең монда, әйтерсең, изге бәйрәм! Ибнеәминов сөенеченнән Обыденков ресторанында сый-хөрмәт өләшкән. Нәбиулла бер дигән күңел ачу йорты ачкан.

— Их, дусларым, — дип әйтеп куйды Камил. — Ниләр генә эшләнсә дә, бар да яхшыга кебек. Әйе, мин бит иң кызыгын әйтми калганмын. Шушы көннәрдә килеп җитәргә тиешле хәреф җыючыбыз Сафи фиргавеннәрне бик тырышып коралсызландырган икән. Артларыннан куа килмәсеннәр өчен, үзләрен баштанаяк чишендереп калдырганнар ди! Күз алдына китерә аласызмы?

Кич белән Камил, Габдулла, Сираҗи һәм Миңлебай извозчик яллап Мәгъмуриягә киттеләр. Бакча урындыклары сыман киң, култыксалы баскычтан керүгә, күңелле көй — «Эпипә» ишетелде. Тәбәнәк түбәле каракүл бүрек кигән, йомшак итекле, эре сөякле егетләр аларны хөрмәт күрсәтеп залга озатты. Зур шәмдәлләрдән келәм өстенә, ялтыратылган өстәл һәм кәнәфиләргә, фужер һәм шешәләргә яктылык сибелә.

— Әһә, Җаекның бар чәчәге монда җыелган, — дип мыгырданды Камил. — Манифест байларга күңел ачуны бурыч итеп куйган диярсең. Чыннан да, каланың барлык зур түрәләре монда: сәүдә фирмасы башлыгы Мортаза әфәнде, тегермән, май җитештерү, сабын кайнату заводы хуҗалары, банк хуҗасы Цфасман, әхлак турында зур китап язган элекке укытучы.

Нәбиулла мөхәррир белән аның дусларын үзе каршы алып, өстәл янына озатты. Күрше өстәлдә Ибнеәминов утыра иде. Күнче аларга болай гына, элеккеге танышлары санап башын селкеде һәм кечкенә генә арык гәүдәсенә киң күлмәк кигән бер адәм белән әңгәмәсен дәвам итте.

— Сез озак яткан нинди тауарлар турында сөйлисез, Михаил Аронович! — дип кызды Ибнеәминов. — Бик беләсегез килсә, без заказны әле җитештерелмәгән тауарга алабыз. Аз җитештерәбез — елга нибарысы унсигез мең тире. Илле, йөз мең җитештерү — менә минем ният нинди!

Иркен күлмәкле адәм, башны катырма дигәндәй, кулын селтәде. Ибнеәминов йомшак кына итеп аның күлмәк якасыннан тотты.

— Мин тире иләү һәм юдыру барабаны куйдырырга телим, табыштан кергән акчаның бер өлешен шул эшкә кертергә исәп. Әмма калганы өчен бурычка алырга туры килә...

Банк хуҗасы дәшмәде, башын чайкавын дәвам итте.

— Шомарту һәм тетү машинасы, гашпильләр... пар белән җылыту, Михаил Аронович, хөрмәтлем, кредит кирәк! Күп сорыйм, әйе, әмма мин вакытында кайтарам бит. Шуның кадәрле чимал барында заводны киңәйтмәү — гөнаһ...

— Баш фетнәчеләр сезнең предприятиедә бит, Закир Галеич.

— Абау, сез ни сөйлисез?! Патша конституция вәгъдә итә, анда ачык күрсәтелер... Безгә бу конституцияне көтеп алырга гына!

Сул яктагы өстәлдән юан адәмнең — пар тегермәне хуҗасының мескен тавышы ишетелде:

— Минем өч йөз тәңкәлек ике тегермән каешын урладылар. Полиция каланың астын өскә китерде, аларны ашату-эчертүгә генә дә байтак акча китте. Азатлык килгәч, ни булыр, ә? Бөлгенлеккә төшү? Юк, син полицейский икәнсең инде — үз эшеңне бел!

Ибнеәминов белән банк хуҗасы торды, өске катка кәрт уенына җыендылар, ахры. Өстәлләр арасыннан узганда, күнче Камилгә иелде:

— Гәзитегез чыгу белән тәбрик итәм, Камил әфәнде. Реклама буенча, чур, мин — беренче!

Ул да булмады, сәхнәгә ресторан хуҗасы Нәбиулла күтәрелде.

— Җәмәгать! Сезне сәламләргә һәм күп җәфалар чиккән милләтебезнең хокукларын яклау юлында күрсәткән зур тырышлыгыгыз өчен рәхмәт белдерергә рөхсәт итегез. Безнең сөенечебезгә, безнең җиңүебезгә фатиха биреп, дога кылыйк... Бүгенге көннән безнең, мөселманнарның, Ауропаныкыннан һич калышмаган йортыбыз бар. Ура, җәмәгать!

— Афәрин, данлы Нәбиулла! Афәрин, милләт уллары! Шампан китерегез... Аллаһ хөрмәтенә, патшабыз һәм тәхет варисы хөрмәтенә! Бөек Болгар истәлегенә!..

Өске каттагы бүлмәләргә тар келәм җәелгән ике бормалы баскыч алып менә. Берсеннән Ибнеәминов белән Цфасман кәрт уйнарга күтәрелде. Икенчесендә кеше күренми, бәлки анда — атлас пәрдә артында, чарлакка менә торган тар юл бардыр? Ул да булмады, пәрдәне теге яктан ачып җибәрделәр. Тавышлар ишетелде һәм залдагылар эчкече Котдус белән ярымшәрә бер хатынның җитәкләшеп төшкәнен күрделәр. Хатынны ярым өстерәп, ул залны кисеп чыкты һәм, чак кына чибәркәен екмыйча, сәхнәгә күтәрелде.

— Н-нотык сөйләргә телим! — дип кычкырды Котдус, чибәркәе белән бергә чайкала-чайкала. — Мөселман туганнар, яңа заман килде, кызыл аракыдан көлмәгез, ул безнең яшәешебезгә ләззәт бирә. Минем инде шәхсән, башка «рөхсәт ителми», «оят», «яхшы түгел», дигән сүзләрне ишетәсем килми. Бүгеннән башлап без хатын-кызларыбыз белән диндар мөселман фәхешханәсендә сөешә башлаячакбыз...

Ул хәлдән таеп, аягында басып тора алмаган исерек кызны ычкындырды, тегесе башта еламсыраган тавыш белән чиелдап җибәрде, аннары хахылдарга тотынды. Котдусның муенындагы шарфын йолкып алып, үзенең шәрә түшенә чорнап куйды да идәнгә җәелеп утырды.

— Уйнагыз! — дип боерды Котдус музыкантларга.

Аннан соң менә нинди хәлләр булды: сәхнәгә Шәрифов йөгереп чыкты, элекке сырхавының якасыннан эләктерде дә сәхнәдән этеп төшерде; аңа комачау ясаган кызны аягы белән этеп җибәрде. Аның кулында кәгазьме әллә фарформы — кар йомарламына охшаган нәрсә агарып китте. Залдан ахылдаган тавышлар ишетелде:

— Шартлаткыч!

— Каһәр суксын сезне! — дип кычкырды Шәрифов. — Базарчылар, алдакчылар!.. Күлегезне күккә!.. — Ул кулындагы әйберне залга ташлады. Нәрсәдер дөбердәде, аннары уенчык шапылдаган тавышлар чыгарып шартлады.

Әмма ыгы-зыгының чиге булмады. Залдагыларның кайсы өстәл астына качты, кайсы, урындыкларны аудара-түнтәрә, башын алып чапты, кайсы өстәл өстенә сикереп менеп урындык белән шәмдәлләрне кыра башлады. Сакчылар табибка ташланмакчы иде, әмма куркып читкә сикерделәр: табибның кулында пистолет көпшәсе күренеп тора иде. Шәмдәлләргә өч тапкыр аткач, Шәрифов иңбашы белән тәрәзәгә бәрде, чылтырап пыяла коелды, һәм ул урамга сикерде. Тиздән анда полиция атларының тояк тавышы ишетелде, арба тәгәрмәчләре дөбердәде, тик тынычлыкны бозучы качарга өлгерде, ахры.

Хәзер полицейскийлар ишек төбенә басты һәм күз карашлары белән залны айкады. Тынгы белмәгән Нәбиулла сәхнәгә менеп кычкырды:

— Әфәнделәр, сез яңа гына, сүрелә барган инкыйлабның соңгы авазларын ишеттегез. Тынлык! Сезгә кечкенә генә серемне ачам: бу — бүгенге кичке тамашага махсус кертелгән иде, әйе-е! Хөрмәтле кунакларыбызның теләге булса, без бу зарарсыз шартлауларны-утларны һәр кич кабатлый алабыз.

Агарынган йөзләренә махсус елмаю чыгарган официантлар тәрәзә ватыкларын тиз генә җыеп алды, ауган өстәл-урындыкларны утыртты. Килүчеләр тагын үз урыннарына урнашты.

Ватык тәрәзә аша иркенләп кереп чыккан җил җанланып киткән тавышларны тирә-якка таратты:

— Курыкканга куш күренә, хе-хе!

— Шәп уйланылган! Безнең нервлар гына...

— Менә аларның инкыйлаблары шушы инде. Кызлар, кызлар!..

Бормалы баскычтан кызлар төште.

Әлегә кадәр тын утырган Камил тотлыга-тотлыга сүз башлады:

— Без чыннан да ф-фәхеш-ханәгә эләккәнбез, әфәнделәр! Нәбиулла кеше күзеннән яшергән генә, к-ка-бахәт! — Ул сүгенә белми, бу сүзләрне әйткәндә, аның ирене балаларныкы кебек турсайды.

Исәп-хисап ясаткач, алар урамга чыктылар. Полиция атлары кайсы кая таралышкан.

— Зарар юк, зарар юк, — дип мыгырданды авыз эченнән Габдулла һәм гасабиланып көлде, — бар да бик әйбәт, гаҗәпләнәсе юк. Тик нигә монда музыка китергәннәр соң?

— Без үз көйләребезне тагын кайда ишетә алабыз соң?! — дип җавап бирде Миңлебай. — Бәлки театрдадыр? Әллә тамаша-кәмиттәме? Юк, әфәнделәр, үз көйләрегезне фәхешханәләрдә тыңлагыз һәм шуңа канәгать булыгыз.

Ул кичтә дә, аннан алдагыларында да Габдулланың башыннан, үзен оятсыз рәвештә алдадылар, дигән фикер китмәде. Андый оятсызлыкны ул хәтта сәүдәгәрләрдән дә көтмәгән иде. Манифест, ирек... һәм Нәбиулла милли фәхешханә ача! «Кая китте цензура?! Коллык, тарлык, ким-хурлык?..» Моны ул язды... бер генә атна элек.

Тормыш аны кабат алдады. Әле бер атна элек кенә аңа үзенең иң яхшы фикерләре белән тәңгәл килә торган ниндидер кирәкле, менә дигән хакыйкать ачылган сыман иде. Ни өчен без алданабыз? Без хакыйкатьне хәер, сәдака кебек, ниндидер манифест кебек көтәбез, ни өчен үзебез эзләмибез?

Тулай торакка ул йокларга гына кайтты. Кирәкле әйбергә дип тиз генә базга төшеп менгән кебек, бу караңгы чокырда бераз күз йомып ала да кар тутырган караңгы урамнан типографиягә — керосин исле җылы сөрем эченә йөгерә.

Хәреф кассасы өстендә лампаның саргылт телләре уйный. Ул хәрефләрне ала, шул арада алар аның бармакларында җылынырга да өлгерә, аларны тезеп куя һәм кеше учындагы тармакланып киткән юлларга охшаган язылу рәвеше ясала. Сүзгә сүз кушылып, ул да кеше язмышы турында сөйли. «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?.. Бәс, безнең милләт үлмәгән дә, йокламаган да, һушы гына киткән... Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (веерлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына иттихад вә иттифакъ сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын…»

Ул башын күтәрде, бер елмайды, бер моңсуланды. Казан «Бәянелхак»ы тарафдарлары усал мәкалә белән фикерләрен белдерми калмаслар. Күптән түгел ул бер сәүдәгәр турында үткен фельетон бастырган иде: сәүдәгәр чалмасын урап җан-фәрманга мәчеткә чаба һәм көч-хәл белән... бурычка бирүчеләрдән кереп качарга өлгерә. Алдакчы Сәйдәшев, Мәскәү сәүдәгәрләреннән акча алып, үзен бөлгенлеккә төшкән дип хәбәр иткән. Тик ул гәзитнең нашире булуга, кредиторлар шунда ук аның теге бурычларын кичерәләр, өстәвенә теләсә нинди акчалата ярдәм вәгъдә итәләр. Чыннан да, шайтанны мәчет коткарды!

Гәзит эше Габдулланың тын алырлык вакытын да калдырмады: йә заводка барды, йә сәүдә клубына йөгерде, йә ятимнәр йортын урап кайтты, йә идарәчеләр оешмасының китапханәсе бусагасын таптады, йә конторага кереп төн уртасына кадәр гәзит өчен материаллар барлады. Хатларның исәбе-хисабы юк: идарәче оешмалар; акча капчыкларының юмартлыгы; җәмгыятьтә хатын-кызның урыны турында күләмле трактатлар, кызлар өчен гимназияләр ачылу; милләт турында күз алдына китергесез күп шигырь, рекламалар. Кайберләре хәтта фельетончылар өчен азык та була иде. Әйтик, сабынчы Хисаметдиннең фирмасы «Исмәгыйль Гаспралы» дигән хушбуй һәм сабын чыгара икән. Бакчасарайда яшәп яткан кенәз үз исеме белән сәүдә иткәннәрен белә иде микән? Тагын бер йомры башлысы: «Сабын шәригатьчә җитештерелде», — дип бизәргә тәкъдим итә, шуннан соң башка төрлесен алып та тормаячаклар, ди.

Габдулла хәзер апасы янына ешрак һәм җаны теләгән вакытта бара иде. Апасы энесенең киеменә гаҗәпләнде. Җәйдән бирле ул күлмәген чалбар өстенә чыгарып, башына, урыс осталары сыман, картуз киеп йөрде.

— Син нигә мондый киемнән йөрисең? Алланы бар дип белмәгән бер урыс бае гына шулай киенгән, диләр.

— Кием тек кием.

— Әле сине тарта да, диләр?

— Әйе, — дигән җавабы белән апасын шаккатырды ул.

— Өйдә генә тартырсың. Әйе, әйе! Төтенен гөлләремә өр, юкса аларда ниндидер корткычлар барлыкка килде.

Габдулла елмаеп, кесәсеннән портсигарын чыгарды һәм тәмәке кабызды.

— Камил әфәнделәрнең өендә кунаклар җыелгач тарталардыр, шунда өйрәнгәнсең, мөгаен, — диде апасы.

— Шулай бугай. — Кунаклар тартамы-юкмы икәнен ул тәгаен генә хәтерләмәде. Аннары аңа барыбер дә иде.

— Син заманча, бай йортларда буласың. Хәзрәт үзе сине мактап сөйли, диләр. Акыллы, бай кызга өйләнергә насыйп булсын...

— Миңа бу яулыгыңны бүләк ит әле, — диде ул, нәсыйхәтне ишетмәгәндәй.

— Яулык? Монымы? — Апасы кырыйлары чигелгән батист яулыкны кулына йомарлады. — Нәрсәгә ул сиңа? Мә, ал.

Ул сүзсез генә яулыкны алды да күкрәк кесәсенә яшерде. Аннары үзалдына

аптырап калды: нәрсә булды аңа? Нәрсәгә? Нигә дип апасын серле кыланулар белән уңайсыз хәлгә куя, аңа үз мәшәкатьләре дә җиткән. Көндәлек ыгы-зыгылардан арынып ял итәргә иде аңа.

— Әйдә, Газизә апа, төшке ашны ресторанда ашыйбыз. Яки чана шуабыз?

Газизә көрсенеп кашларын җыерды.

— Минем белән шаярма. Ирем бар... — Бите буйлап күз яше тәгәрәде. Әмма бик тиз исенә килде: — Син бернинди начарлыкка да бирешә күрмә! Безгә борчу салма. Мин уйлыйм... син андый түгелдер, дим... Сәер сөйләшәсең, кыланмышларың сәер. Барысы да, Габдулла акыллы, укымышлы, дип торганда... Сиңа бит безнең яшәү рәвешебез дә ошамый. Байлыкка да исең китми.

Ул дәшмәде. Мөгаен, ул беренче мәртәбә, хәзергә кадәр кешеләрне бергә бәйләп торган һәм ияләнелгән тормыш рәвешенең аларны аерырга мөмкинлеген сизде. Бу бик гади — билбау белән буып күлмәгеңне, башыңа картузыңны киясең дә ирештерәсең: менә сезгә, төкерәм мин сезнең ахмак тыюларыгызга, мин ирекле, ничек телим, шулай эшлим! Һәм шулай эшлә... Әмма аның чит-ят буласы килмәде.

— Ярый, — диде ул, үзен гаепле сизеп, — китәргә вакыт. — Аздан гына апасының туган җанлылыгыннан, сагыштан, билгесезлектән үксеп җибәрмәде.

Ул үзенең арганлыгын сизде. Алай да, алҗуын җиңеп, төнлә мәкаләләрне төзәтте. Аннары Камил керде, сөйләшеп утырып, таң аттырдылар. Иртән — укырга. «Болай мин озак түзә алмам, — дип уйлады ул, — укуны ташларга кирәк. Миңа нәрсәгә ул? Мулла буласым килми, авылда болай да укыта алам...»

> Фикерегезне языгыз да фикергә фикер ялгагыз;
> Фикерләшеп хәлебезне, «Фикер»гә язып елагыз.

Гәзитнең беренче саннарын әзерләгәндә, ул күп язды, әмма шактыйларын ертып та ыргытты. Менә бу юллар кабат әйләнеп кайтты.

Матур салкын көннәр торды, тиз караңгыланды, извозчикларның чана табаннары да чиелдап шуды. Зур Михайловскоеда бер-бер артлы фонарьлар кабынды. Чаналарга яшь нәфис чыршылар төягәннәр. Яңа ел җитә. Мартынов кибетендә чыршы уенчыклары белән котлау рәсемнәре исәпсез күп, кибетнең ишеге көне-төне ябылмый. Яңа ел! Ул йөрешен тизләтергә тырышкандай, кулларын селти-селти атлады.

> Борынгыдан бирле безнең фикеребез тоткын иде;
> Кем соң безне мескен итеп тоткында тоткан иде?

Ашханә яныннан узганда, өзелеп ашыйсы килгәнен сизде, әмма үзен тыеп калды. Чәен катырак итеп ясар да эшкә утырыр. Шулай да үз хөҗрәсе булу әйбәт. Фәкыйрь, әмма үзенеке. Гәзит өчен язмаларны Камил өендә дә әзерләгәне бар, әмма ул анда ничектер тартына. Типографиядә тавыш, һавасы тынчу һәм сасы, аннары эшчеләр белән сөйләшми булдыра алмыйсың. Ул мәдрәсәдән китүне кичектереп торырга булды.

**13**

Төнне Габдулла йокысыз үткәрде, иртә аңа рәхимсез кебек күренде. Һәм үз күзләренә үзе ышанмый кәгазь битләрдәге дәһшәтле сүзләрне укыды.

> Син Хәттаб хәзрәт бул да бар потларны таптап бетер, —
> Кәгъбә Мәнаттан, Лат вә Гоззадан пакь булып калсын.

Дөнья халкы эшләре боларга тапшырылган;
Табигый, бу санәмнәр туры юлда йөрмиләр.

Түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән;
Син рәхмәтең белән бөекләрне түбәннәрдән аер.

Бүген кыямәт: дөреслек кояшы тотылды;
Айлар ярылды, акыллар гаугадан шашып калды.

Ул үзен авыру, хәлсез итеп хис итте, бер тамчы көче, киләчәккә бер тамчы ышанычы калмады.

«Мин иманлы малай түгел идемме, — дип уйлады ул, — минме Аллаһы Тәгаләнең сүзен югары куймадым, минме ышанмадым? Мин кире кайтам! Мин рухымны саклыйм, рухны саклау — акыл көчен, һәм ирекне, һәм тугры хис-тойгыларны саклау бит. Ялганны, явызлыкны, гаделсезлекне кире кактым дип бик өметләнәм».

Тынычлангач, ул эссе капкан урамнар буйлап йөрде. Тузанлы, кояшлы матавыкта Нәфисәнең йөзе чагылып китте дә болыт белән кушылгандай яки кояш нурларында эрегәндәй юкка чыкты. Ул эзсез-нисез югалды — аннары тын гына, тузан белән йотылган көй ишетелде, кыз каядыр якында гынадыр кебек тоелды, әмма күзгә генә күренмәде.

Бервакыт Габдулла аны өнендә дә очратты һәм юл аша каршысына йөгерде.

— Нәфисә!

Кыз читкә тайпылды... Ул шунда гына аның өстенә чапан кигәнен һәм яулык чите белән йөзен каплавын күрде. Кыз куркып һәм күңелсез генә күзен аска төшерде:

— Калдырыгыз, китегез... ничек оят түгел! — диде.

— Бу мин бит, Нәфисә. Сине урларга җыенмыйм.

Ул дәшмәде, япмасы иңеннән шуышты, әмма кыз киемнең якасына чытырдатып ябышкан иде.

— Мин берәүдән дә курыкмыйм, — диде кыз, иренен тешләп. — Курыкмыйм, тик сез нигә... ничек оят түгел. — Соңгы сүзләрен ул уйламый, ятлаган кебек кенә әйтте, үзе дә, мөгаен, ни әйткәнен сизмәгәндер.

— Соң мин бит... — дип мыгырданды югалып калган Габдулла, тик кыз ул арада йөгереп китеп барган иде инде.

Иртәгесен тагын:

— Ник шаяртасыз сез? Бу бит оят.

Үзенең озата барырга уйлаганын турыдан әйтмәс өчен:

— Мин сезгә барырга җыенган идем, — дип алдады. — Әйдә, бергә киттек.

— Ярар, — дип килеште кыз. — Сез мине озата да алыр идегез... әгәр теләсәгез, тик алар бит сезнең минем абыем икәненә ышанмаслар. Хәер, монда сезне күпләр белә бит.

— Кемнәр инде — алар? — дип сорады Габдулла, бераз аңышып.

— Базарчылар! Минем мадамнан чыгуымны күрүгә көлешә башлыйлар, төрле сүзләр кычкыралар. Ничек оят!

Балчык өйләр арасыннан бара башлагач, ул чапанын салып, киндер сумкасына тыгып куйды. Яулыгын да башыннан йолкып, кулына йомарлады.

— Эссе. Сез әти янынамы? Ул бит эштә.

Габдулла аларда кичкә кадәр булды, сүзсез, шыпырт кына, сихерләнгәндәй аның озынча матур йөзенә, килешле иңбашларына, арзанлы беләзек кигән нәфис

кулларына карап сәкедә утыра бирде. Кыз аны сизмәде дә, өйдәге көндәлек эшләрен башкарды, ара-тирә әнисе белән сүз алышты. Бала-чагаларның ыгы-зыгы килүенә дә исе китмәде. Узышлый гына аларның берәрсен кулына ала. Тегесе, Нәфисә аның дөньяга китергән әнисемени, шунда ук тынып кала. Ана тыңгылыгын кайбер кызлар тышкы кыяфәтнең яки холыкның нәселдән килгән сыйфатыннан алалар. Бәлки барлык кызлар да шулайдыр...

Сәрби тутасы үзенең тәрбиягә алган кызын бик ярата, хәтта мадамга бик нәфис эш — чигүче һөнәренә өйрәнергә дә бирде. Әгәр тутасына кызны, мәсәлән, кибеттә сату итәргә яки скрипкада уйнарга, яисә мәктәпкә укырга бирергә кирәк, дисәләр, бик гаҗәпләнер иде. «Нигә?!» дип сорар иде. Мин кызымның бәхетле булуын телим, тормышта нәрсә дә булса белсен, дим, тик әйтегез, сез өйрәткән һөнәрләр аңа нәрсәгә? Аннан башка бәби таба алмасмы? Яки балаларына һәм аларның атасына начаррак пешерерме? Яисә кер уа, сыер сава, тавыкларга җим сала алмасмы? Әллә кияве аның өчен, укымышлы дип, мәһәрне күбрәк бирерме? Юк? Шулай булгач, ник сөйләп торырга?

Менә Юныс абзый кайтты, кыз аңа чиста күлмәк белән ыштан, сабын, сөлге тоттырды. Габдулла аңа ияреп су буена төште һәм юлда Нәфисә белән очрашуның мәзәк килеп чыгуы хакында сөйләде. Юныс абзый борчылып башын чайкады.

— Әйе, сөмсере коелган чагы әле аның. Мадам янына төренеп барырга ояла, күлмәкчән, ачык бит белән барса... ну, мыскыллыйлар, кыйнау белән куркыталар. Хет мадамга җибәрмә!

— Сез нәрсә? Үзе ничек тели, шулай барсын. Менә мин дә билбау буып, картуздан йөрим. Миңа да янадылар, төкердем мин аларга.

— Син аны үзең белән чагыштырма, ул бит кыз бала. Тукта, син аңа бер нәрсә дә әйтмәдеңме?

— Юк.

— Аллага шөкер.

Ике көн Габдулла аның каршына чыкмады, өченче көнне түзмәде, базар мәйданы кырыенда көтеп алды.

— Мин бит сиңа килмә, дидем. — Әмма аның күңеле шат, сумкасын селеккәләп тора. — Йә... мине кич утырмага чакыра аласыз. Валлаһи, килермен!

— Яратмыйм мин ул утырмаларны.

— Ни өчен? — кыз чын-чынлап гаҗәпләнде.

— Яратмыйм... юри кыланганнары өчен.

Нәфисә нидер уйлагандай тын калды.

— Үтенәм сездән, башка мине урамда каршы алмагыз, — диде ул. — Өйгә ешрак килсәгез әйбәтрәк булыр, яме?

— Ярар, — диде Габдулла, тукталып.

Кыз йөгереп китеп барды.

Берничә көн ул тузанлы эссе урамда томанда йөргән кебек йөрде, әмма сагышы басылмады.

Ул Нәфисәнең каршына башка чыкмады, әмма очраклы рәвештә генә күрүгә иреште. Анда да сүз катмады.

Нәфисәне дә әбиләренең язмышы көтә. Чөнки бу тормыш кырыс кагыйдәләре, дине, әхлак төшенчәләре белән кызны курчак ясаган иде. Юныс абзый бергә эшләгән иптәшләре-эшчеләрнең хокуклары турында сүз барганда, акыллы, кыю, улларына да егетләрнең намусы һәм дәрәҗәсе нинди булырга тиешлеген төшендерә ала, әмма үзе берни эшли алмый иде. Эштәге коллык турында белә, әмма аның күңел коллыгы турында белүе икеле.

Кеше шулкадәр көчсез була ала дип моңарчы уена да китергәне юк

иде. Кешене нәрсә коткара ала соң, аның балаларын, бердәнбер кызын? Картның зирәклегеме? Әллә Мамадышның акылсызлыгымы? Шәрифовның инкыйлабчылыгымы? Үзләренең гәзитеме? Аның шигырьләреме?

Ул, җавап табарга теләгәндәй, кырга юнәлде. Меңьеллык курганнары белән иксез-чиксез сармат кыры, аксыл кылганнары, шат елмаюлы кояшы һәм гамьсез җилләре аңа җавап бирде кебек. Әмма дөньяның кайсы телендә икән соң аларның җаваплары?

## 14

Иртәләрен нык суытты, усал җил сукмаклардагы тузанны бер урыннан икенчесенә күчереп йөри. Быел кар төшкәнче үк салкыннар башланды.

Күкшегән чандыр гәүдәсен җилгә каршы ия төшеп, Габдулла иртәләрен Төхфәтуллиннар йортына бара. Ике катлы, манарага охшаш чормалы бу йортка күптән ягыла, аның күпертмә бизәкле түшәмнәреннән, сары кандилләреннән, анда куелган күз явын алырлык ялтыравык керосин лампаларыннан җылылык бөркелә. Җылы диварлар, келәм каплаган җылы идән.

Габдулланың өстендә йон тукымадан тегелгән пәлтә, кыш өчен салкын булса да, ноябрь өчен ярап тора, тәбәнәк түбәле каракүл бүрек, читекләренә киертелгән кәлүшләрне әле яңарак кына сатып алды. Аларның лакланган ялтыравыгы янында җиңелчә генә кимсенү катыш канәгатьлелек хисе тудыра. Кәлүшен ул Мотыйгулла хәзрәтнеке янында салып калдырды. Яңалык дипме, бу каеш аяк киеменә иске күннекенә караганда өстенлек бирелде.

Алар — кызлар һәм Камилнең хатыны, кунактан качмый, киресенчә, Габдулла килгәч, үч иткәндәй, аның чишенеп, ябык тавык түшкәседәй салкыннан зәңгәрләнгән кулы белән пәлтәсен элеп куйган чагында килеп чыгалар.

Диләфрүз аның телен ачмакчы була, ә ул исә башын күтәрми, мышный-мышный язуын белә.

— «Гайния» шәкертләренең кәчтүмегез өчен сезне кыйнарга теләүләре дөресме? Карагруһчылар шундый алар!.. Йөзен капламаган хатын-кызларны мыскыл итәргә дә мөмкиннәр.

— Сез йөзегезне ачмагыз, — дип мыгырданды Габдулла ачулы тавыш белән.

— Ник?

— Шәкертләрне акылдан яздырмас өчен.

— Әһә, безнең шагыйрь мактау сүзләре дә әйтә белә! Сезнең мәхәббәт турында шигырьләрегез бармы? Әллә сез, крәстиян күлмәге кигән хөрмәтле карт кебек, мәхәббәткә шелтә белән карыйсызмы?

Камил сеңлесен йомшак кына бүлдерде:

— Диләфрүз, акыллым, без бит эшлибез.

— Киттем, киттем...

Олы апасы Галия сеңлесенә сүзсез генә, мәсхәрәле түбәнчелек белән карады. Ул, гомумән, бүлмәгә бик сирәк керә, әңгәмәдәшенең сорауларына басынкы гына җавап бирә, инде көлеп җибәрсә, көмеш кыңгыраулар чыңлаган күк тоела. Алар Миңлебай белән дуслар, бергәләп куйган спектакльләрдә уйный да, җырлый да. Кызларга түзеп була әле, әмма Камилнең хатыны үзен шундый итеп тота, әйтерсең аның дәрәҗәле ире һичкемгә билгеле булмаган адәм белән аралаша. Аның Габдуллага карата хөрмәте үзенең ефәк итәге кебек коры һәм кыштырдык.

Камилнең анасы әле көчендә, яшьләр кебек яулыгын артка чөеп бәйли, һәм бүлмәләр буйлап нык, каты басып йөри. Тавышы, өйдә күрсәтмәләр биргәндә,

боерулы чыңлап тора. Аның хакимчәнлеген балалары гына түгел, юк-юкта ире дә сизгәләп куя.

Бу йортта электәгечә иң хөрмәтле кеше — карт, аның беренче укытучысы. Ул, озын тормыш юлы узып, акыл туплаган, әмма әлегә кадәр аның күңеленә ялкаулык һәм битарафлык үтеп кермәгән. Җәмгыятьтә аны мәктәпләргә үзгәртүләр кертүчеләр тарафдары буларак беләләр. Һәртөрле яңалыкларга каршы чыккан кадимчеләр аны күралмый һәм аның өстеннән полицмейстерга әләкләр яза. Жандармнар аның мәдрәсәсенә тикмәгә генә йөрми.

Гәзит турында сөйләшкәндә, ул яшьләрне аңлавын, хәтта эшнең нечкәлекләренә төшенүен яшерми. Трипольдән, Тифлистан, Петербургтан алдырган гәзитләр белән танышып бара, җирле «Уралец»ны укыганда, чыраен чыта: күпме сафсата, авторлар арасында кемнәр генә юк, гәзит андый эзлексез була алмый. Сезгә, ди ул Камил белән Габдуллага, төп юнәлешне ачыкларга һәм тайпылмыйча барырга кирәк. Яңалыкны яклаучыларга терәк булырга һәм кадимчеләргә кискен каршылык күрсәтергә кирәк, гәзит бәхәс урынына әйләнергә тиеш, әгәр ул юк икән, димәк, гәзит тә юк. Әнә карагыз, китап базарын күпме юк-бар басмалар басып алды: елдам сәүдәгәрләр Мәвәраэннәһер, Мәдинә һәм Бохарадан ташып тутырган багу, төш юрау китаплары дисеңме, «ярамый, кабул ителмәгән, яхшы түгел...» кебек сүзләр белән шыплап тулган үз-үзеңне тоту, әхлак кагыйдәләре турындагы җыентыклары дисеңме — исәбе-хисабы юк.

Яшьләр белән сөйләшкәннән соң, ул үзенең бүлмәсенә кереп китә дә шунда югала. Кайчакта Мотыйгулла хәзрәт үз янына Габдулланы чакырып ала. Габдулла, сөенеп, йон оекбашлары белән йомшак кына басып карт бүлмәсенә йөгерә.

## 15

Кайвакытларда өйдә картның барлыгы бөтенләй сизелми. Аның каравы яшьләр шау-гөр килә, музыка яңгырый, йортның зур бүлмәләреннән кызып-кызып сөйләшкән тавышлар ишетелеп тора. Татар гаиләләре өчен мондый иркенлек, карашлар иреге, алдын-артын уйлап тормый бәхәскә керүләр бик сирәк күренеш. Ләкин бу җыелулар шундый купшы уза, күлмәкләр һәм ислемай-хушбуйлар аеруча тантана белән күрсәтелә, гаҗәеп аш-сулы була — хәтта сизелерлек ясалма да килеп чыга. Мул тормышлы булып күренү, сүз дә юк, бик яхшы, ләкин иркен тормышлы өйнең гадилеге кача.

Диләфрүз һаман да үзенең буш сүзләре белән Габдулланың башын катыра:

— Кем соң сез? Менә, мәсәлән, Шәрифов — эсер. Мортаза әфәнде либераллар партиясендә. Әмма хәзер ул икенче партиядә — кадетларда диме. Әллә сез яшерен социал-демократмы? — Ул күзен кыскалап шаяртып-үртәп алды.

— Мөгаен, шулайдыр, — дип ризасыз җавап кайтарды Габдулла.

— Ай-һай! Аннан соң, байый-нитә калсагыз, кадет булачаксызмы? Сезне ураза тотмый, диләр, шул дөресме?

— Дөрес.

— Нигә?

Аның ачуы килде. Кызның анда ни эше бар икән соң? Аны бит бер Диләфрүз генә түгел, күпләр кызыксынып күзәтә һәм аннан нидер көтәләр икән. Менә, янәсе, укуын тәмамлар, дәрәҗә алыр һәм үз катлавы кочагына кайтыр. Мохтаҗлыктан арынуына куаныр, иректе, фикерле булуын онытыр, башкалар кебек, ягъни ниндидер эшсез кеше булып исәпләнгән кырык мең

мулланың берсе булыр... Мохтаҗлыктан арынуны үзенең хөрлегенә алмаштырыр дип уйлыйлар микән алар?

Ул Төхфәтуллиннар гаиләсенә баруын сирәкләтте һәм көчен типографиядәге эшенә сарыф итте. Миңлебай белән Сираҗиның мәдрәсәдән китү фикере көннән-көн катгыйланды. Габдулла да риза, тик сыеныр урын эзләү эшен тоткарлар дип уйлаганга гына ашыкмый иде. Камил типографияне үз йортына якынрак җиргә — сәүдә банкының идән астына күчерде, бәлки аңа да бер чолан табылыр. Ләкин монда тагын да кысанрак булып чыкты. Шулай да, төн уртасына кадәр утырганнан соң, конторада куна калды.

Типография эшчеләрен ул тупас гадилекләре, буйсынмас булулары, гыйсъянча сөйләшүләре өчен үз итте. Кайвакыт Винклер эшханәсе, депо эшчеләре белән кыска гына яшертен очрашулар булып ала. Аннары алар куеннарына нидер кыстырып, тиз арада юкка чыга. Алар артыннан, таштан коелган казаклар мыекларын кабартып, таш кылычларын чыңлатып карап калган кебек тоела. Таштан ясалган арысланнар мәңгелек йокыда. Нәшрият рәссамы Калентьев банк ишегалдындагы тирән сөзәк чокырда әрле-бирле йөренә һәм менә-менә өстән ташлар тәгәрәмәсен дигәндәй муенын җилкәсенә батыра.

— Кабахәтләр, — дип мыгырдады ул, таштан коелган казакка тибеп, һәм нәфрәтеннән агарынды. Бу сыннарны ул округ казак суды әйтүе буенча керү юлына кую өчен эшләгән иде — ләкин соңгы мизгелдә генә сынны яраксызга чыгардылар. Башта, Калентьев әле калыбын күз алдына китергәндә, кабарып торган бүрекләр, калын таш мыеклар, кылычлар аермачык күренмәде. Сыннар ничектер кызыклы иде: алар таш та, шул ук вакытта җанлы да тоелды, аларда сер, билге, илаһилыкка ишарә бар иде. Ләкин аның кулыннан үткәч, казаклар бу серлелекне югалттылар.

Типография эшчеләре дөрестән дә куркыныч сөйләшүләр алып бара — һәм хәзер инде ерактагы вакыйгалар турында түгел: үз хәлләреннән кәефләре кырыла. Типография хуҗасына эш хакын арттыру, эш көнен кыскарту, елга бер тапкыр ике атналык ял бирү турында таләпләр куярга җыеналар. Таләпнең текстын төзеделәр, хуҗага болай гына тапшырыргамы, әллә эш ташлап бирергәме дип фикер алыштылар. Кыюраклары депо һәм Винклер эшханәсе эшчеләре белән берләшеп, баш күтәрүне хуплады. Кайбер куркагraклары Габдуллага өметләнделәр: бәлки ул хуҗа белән бер-ике сүз алышыр да мәсьәлә шундук уңай хәл ителер?

Габдулла риза булган иде. Ләкин Камил дөрт итеп кабынды:

— Син... син бит миңа килгәндә, сигез тәңкә ала идең, хәзер — егермене. Мин һәрвакыт хезмәт хакыңны күтәрә килдем.

Габдулла үзенең элек хәреф җыючы гына, хәзер өстәвенә конторчы да, таратучы да, хезмәткәр дә булуы турында әйтергә теле кычытса да дәшми калды.

— Гафу ит, — диде ул, тыелып, — мин үзем турында әйтмим. Эшчеләр тәүлеккә уникешәр сәгать кургаш тузаны йотып, караңгыда күзләре сукырая, хезмәт haклары — тиеннәр генә.

— Бәлки алар эш ташларга җыеналардыр? — Камил тамак төбе белән акырды. — Әй, чәнчелеп китсеннәрсәнә! — диде ул ахырдан. — Төкерә алар безнең хезмәткә, милләт өчен тырышуымны аңлыймыни алар? Тукта, ә син... анда, типографиядә, берәр сүз таратмадыңмы?

Габдулла сүзсез генә борылды да чыгып китте.

Берничә көн сөйләшмәделәр. Бу киеренке тынлык бик авыр узды. Өченчеме, дүртенчеме көндә Камил үзе Габдулла янына килеп, аны конторага чакырды.

— Сөйләшәсе бар.

— Кичә «Уралец» редакциясендә тентү булган, — ишек ябылыр-ябылмас ашыгып сүз башлады Камил. — Бүген, типография хуҗасы буларак, мине чакыртып алдылар.

— Эш нәрсәдә соң?

— Баш мәкаләдә мөхәррир исеменнән: сайлаулар турындагы яңа кагыйдәнамә ярты халыкны — хатын-кызларны, егерме бишкә кадәрле яшьләрне тавыш бирү хокукыннан мәхрүм итә... — дип язылган. Хәер, үзең дә беләсең. Әйе, тагын өстәвенә большевиклардан өземтәләр китергән: эшче депутатлар Советына — Вакытлы хөкүмәт нигез әзерләгән.

— Аржановмы? Аннан андый кыюлыкны көтмәгән идем. Сиңа нәрсә диделәр?

— Миңамы... Типографияндә листовкалар басыла дип әйттеләр. — Ул Габдулланың күзенә текәлде.

Габдулла да күзен читкә бормыйча җавап бирде:

— Бу турыда берни белмим.

Камил җиңел сулап куйды: күрәсең, ул да хәбәрдар түгел.

— Алай да калада социал-демократлар оешмасы бар, кайбер эшчеләрем алар белән бәйләнештә. Бу турыда миңа пристав читләтеп әйтеп куйды. Сиздерде! Димәк, әлегә берәүне дә эләктермәгән. Мин үз эшчеләремне тотып тапшыра алмыйм бит инде! Ләкин мин... үз артымда ниләр эшләнгәнен белергә тиеш.

— Пристав өркетергә генә теләгәндер, дөрестән дә, бернинди дәлил юк бит.

— Алла кушсын! Тик казанлылар... алар күпне күргән, халыкка коткы таратмасмы? Хәер, Ходай язганын күрербез. «Уралец»ны, мөгаен, ябарлар. Яңа басма артыннан йөрергә кирәк. Минем уйлавымча, урыс гәзите ачсак ансатрак, кала кешеләре миңа ярдәм итәр. Менә авыртмаган башка тимер тарак... Мин бит Думага кандидатурамны куярга уйлаган идем.

— Думага? Чынлап әйтәсеңме?

— Күз алдыңа китер, әгәр депутат булсам... дәрәҗә, абруй. Аннары юк-бар полицейскийлар эшемә борын тыга алмас иде. Ләкин хәзергә бу турыда хыялланып та булмый.

Аннары... вакыйгалар күз иярмәс тизлек белән дәвам итте. «Уралец»ны ябып та өлгермәделәр, Камил шунда ук «Уральский дневник» дигән яңа исемдәге гәзит ачарга гариза язды. Чуалышлар чоры булган 1905 елда ул типография сатып алды һәм аңа рөхсәт тә бирделәр. Ләкин хәзерге хакимият аңардан туу турында таныклык таләп итте: канун буенча наширлек хокукы егерме бише тулганнарга гына рөхсәт ителә. Камилгә яңарак кына егерме өч тулды. Сафсата! Туучы, өйләнүче, үлүчеләрне теркәү этисе кулында... Өч көннән Камилгә кирәкле кәгазь әзер булды. Хәзер ул «Уральский дневник»ны чыгара һәм сайлау кампаниясендә катнаша ала.

Гәзит инде басылды, сайлау алды җыелышларында да катнашты, шатлыктан күктә йөзеп йөргәндә, кинәт судка чакыру килде. Аның өстеннән әләк бар. «Тик кем, кем?» — дип ачыкларга тырышты кызу канлы Камил. Хәер, әләкчене белүдән ни файда? Моңарчы һәрвакыт эшләре уң барганда, кемнендер әшәке әләге барысын да җимерсен әле. Ә бит бу дөньяда барыбер бөтен нәрсә сатылган, алынган. Тормыш юл куешып килешүләрдән генә тора. Юк, ул бирешергә тиеш түгел!

## 16

Озакка сузылган салкыннардан соң, ниһаять, беренче кар явып, каланы аклыкка күмде. Көзге усал җил карларны таратып уйный.

Табигатьтә күптән көтелгән үзгәрешләр кешегә сәер һәм көчле тәэсир итә.

Моңарчы үтәлми килгән эшләрне шатланып, сөенеп башкарганыңны сизми дә каласың. Алар белән дә шулай булды; карга баткан Миңлебай килеп керде һәм катгый рәвештә, бүген үк кунакханәгә урнашу турында хәбәр итте: үзенә сыендырдың, инде хуш, мәдрәсә!

— Нигә бүген, хәзер үк? — дип гаҗәпләнсә дә Габдулла, үзе дә шул минутта ук вак-төякләрен җыеп кунакханәгәме, башка җиргәме китәргә әзер иде инде.

— Бүгенме? Нигәме? — дип кабатлады Миңлебай, елмаеп. — Кар ява, рәхәт... нәрсәдер булды миңа. Сираҗи да шул халәттә. Әйдә, бер — ике!

Җыендылар да киттеләр. Кибетләр яныннан, кар каплаган киң мәйдан кырыйлатып, күптән түгел ачылган «Казан» кунакханәсенә атладылар. Якты матур көн, күзләр сөенеч белән тулы; салкын саф һава күкрәкләрне ярып керә. Әнә малайлар зур сары этне чанага җикмәкче булып кайнаша. Эт бауларны чуалтып качты. Малайлар дәррәү эт артыннан ташланды. Ерактан бозы зәңгәрләнеп күренгән елга яры шау-гөр килә. Яшьләр, җыйнаулашып, тау шуа. Чаналарга төялеп выжлап төшеп китәләр, кайберләре утын чаналарында җилдерә... Диләфрүз дә, мөгаен, андадыр — көяз гимназистлар, ялагай приказчиклар, каникулга кайткан юнкерлар яныңдадыр. Кала бакчасында бозны кырган тавыш ишетелә — шугалакны чистарталар. Кичен ул итәкләр, бүрекләр, кокардалар белән чуарланыр.

«Казан» кунакханәсе кыегындагы киң алтакта ерактан ук балкып тора. Себерүче шома тротуарны тазарта. Кар көртләре буйлап зәңгәрсу очкыннар сибелә.

Итекләрендәге карны себерке белән сыпыргалагач, аларның гайрәте сүнде, кинәт кенә эчләренә шом йөгерде: яле ычкыныгыз моннан, диярләр кебек тоелды.

Ләкин хезмәткәр үзе ишекләрне ачып, аларны төче елмаеп эчкә чакырды:

— Рәхим итегез, әфәнделәр! Исән-имин килеп җитүегез белән.

Кунакларга хезмәт итү тәүлеккә илле тиеннән бер ярым сумга кадәр икән. Айлык түләү — ун тәңкә. Төшке аш кызыксындырса, рәхим итегез, ике төрле ризык — утыз биш тиен. Иртән һәм кичен чәй кертерләр. Яхшы, Габдулла айлыкны алдан түләп куяр — ун тәңкә. Тагын ун тәңкәсе ашауга кала.

Хезмәт күрсәтүче егетләрне өске катка алып менде. Сираҗи белән Миңлебай икесенә бер номер алды, Габдулла ялгызы гына урнашты.

— Монда әйбәт, тыныч, — диде хезмәт күрсәтүче. — Гыйнварда Гурьевтан извозчиклар килә... Ну, бераз шаулап бәйрәм итеп алырлар, аннары тагын тынычлык урнаша.

Габдулла аны тыңлап тормады, үзенә бирелгән номерны күздән кичерде. Иң мөһиме — өстәле бар икән, аны тәрәзә янынарак күчерәсе булыр. Хөҗрәсеннән китапларын, киштәләрне алып килер — бар да булыр. Кунар урыны, эшләр эше бар. Номерда рәхәт, бик җылы.

Чишенеп тә тормыйча, ул ике бүлмә аша урнашкан иптәшләре янына ашыкты. Сираҗи белән Миңлебай, хәлдән таеп, ялкауланып ята. Төшке ашка кадәр ятакта аунап, кичен бәлки йөреп керербез, диештеләр.

— Ярар, калыгыз алайса. Мин киттем, бераз йөреп керәм.

Габдулла урамга чыкты һәм бернинди максатсыз Зур Михайловское урамына юнәлде. Көн искиткеч!

Чанасына кырын ятып, Мортаза Гобәйдуллин узып китте. Өстендә кеш якалы иркен тун, кулында төлке каймалы тире бияләй, ак фетр итекләрен чана кырыена терәгән. Нечкә-сыгылмалы муенын сузып, ат кызуламакчы була.

Мәйданда яткан ап-ак кардан күз чагыла, шат чырайлы сәүдәгәрләр тамакларын кырып кала... Әнә зинданнан качкын солдатларны алып киләләр.

Алар тирәсендә казак хатыннары кайнаша, тоткыннарның кулына күмәч, акча сонмакчы булалар.

Почмактагы чәчтарашханәдән, хуш ис аңкытып, мөселманнар өчен яңа күңел ачу йорты ачкан Нәбиулла чыкты. Бүтәннәргә охшамаган, кызыклы шәхес! Аны каланың бер генә тәкъва кешесе дә мактарга җөрьәт итмәс иде, әмма һәрберсе эченнән генә, ир-ат үткен икән — теләсә кайсы эш аңа уңыш китерә, дияр. Нәбиулла мыек астыннан гына көлә, ул хәйләкәр, халыкның үзе турында ни уйлаганын тоя.

Көтмәгәндә, Габдулла Нәфисәне күреп алды! Зәңгәр җирлеккә кечкенә тимгелләр төшерелгән пәлтәдән, кабарып торган шәл бөркәнгән, бәйләнгән ак йон бияләй кигән кыз җиңел адымнар белән бара, янәшәсендә чәчкәле киң шәлгә уранган Сәрби түти.

Габдулла, елмаеп, хатын-кызларга баш иде һәм үтеп китмәкче иде, ләкин Сәрби тутасы туктады.

— Исәнме, күгәрченкәем, исәнме?! Без менә мадам яныннан. Ай-һай рәхәт икән кар өстеннән атлаулары. Нәфисәне каршы алырга бара башлаганнан бирле үземне әйбәт хис итәм. — Серне ачканын аңлап, бер генә минутка телен тешләде. Көлеп җибәрде дә сүзен дәвам итте. — Әйе, нишлисең. Бичара кыз баланы һәркем җәберли ала. Ләкин!.. — ул кулындагы таякны селкеде.

Габдулла да көлде, аның кызын мыскылларга җыенган базарчының баш очында таякның ничек уйнаганын күргәндәй булды.

— Юныс абзыйның хәле ничек?


— Килмисең, килмисең безгә! Юныс абзаң ютәлли, үпкәсе гыжлый, иске самавыр кебек. Син килеп чык, Нәфисәнең чигүләрен карарсың. Аңа инде аз-маз үтенеч белдерә башладылар, мадам мактап туя алмый. Әй, урамда егетләр белән сөйләшеп тору килешми дә инде, тик без озакка түгел.

Нәфисәнең нур чәчеп торган оялчан-бәхетле йөзе чак кына өскә чөелгән, ул сүзгә катнашмый, әмма дерелдәп куйган озын керфекләре, ирененең сизелер-сизелмәс хәрәкәте — аның барысын да ишетүе хакында сөйли. Гаҗәп, ул үзенең тәрбиягә алган ата-анасы һәм аларның балаларына бөтенләй охшамаган. Тегеләр кызу канлы, башкисәрләр — ул тыйнак, озын, бәхетле, сихри йокыда сыман.

Сәрби тутасы белән Нәфисә китте, Габдулла алар артыннан бик озак карап торды, куып тотасы, кыз белән кар атыш уйныйсы, рәхәтләнеп шаярасы-көләсе һәм аны тауга чакырасы килде. Ләкин ул урыныннан кузгалмады.

*Дәвамы киләсе санда*

*Рус теленнән* **Рөстәм ГАЛИУЛЛИН** *тәрҗемәсе.*



Рәниф
Шәрипов

# ҖОМГА

ПОЭМА

*Закир абый истәлегенә*

Раббым биргән бер хәерле иртә...
Күзләремне ачкан чагымда,
Кояш кебек балкып вә елмаеп,
Закир абый тора янымда.
Ул мунчадан кайткан.
Ап-ак күлмәк кигән.
Иман нуры балкый йөзендә.
Шушы нурлы чырай яктысында
Мин яктырып китәм үзем дә.
Юк, мин генә түгел, бөтен дөнья,
Урамнар да хәтта яктырак.
— Нинди бәйрәм бүген, Закир абый?..
— Җомга ич!.. — ди, миңа аптырап.
Гаҗәп аңа, мин шуны да белмим...
Җомга икән... Гаҗәп миңа да.
Миңа гына түгел, бу юлларны
Укып утыручы, сиңа да.

Ул вакытта, без — Ил сакчылары,
Тернәкләнеп төрле ярадан,
Төрле яктан килеп, укый идек
Юл йөрүнең рәтен яңадан.
Закир абый — минем якын күршем,
Яши идек без бер бүлмәдә.
Сөйли иде, нинди юллар үтеп,
Нинди генә нужа күрмәгән.

---

Рәниф ШӘРИПОВ (1950) — *шагыйрь; «Ян, учагым», «Мәңгелек сер», «Азатлык көне» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Сугыш чыккач, Илен якларга дип,
Чыгып киткән ихлас йөрәктән.
Сизмичә дә калган, чолганыштан
Әсирлеккә килеп эләккән.

Закир абый ипләп сөйли белә,
Йөзе нурлы, тыныч тавышы.
Уйдырма да, әкият тә түгел,
Сүзе газап — хәсрәт агышы.
Закир абый сөйли.
Мин сак кына
Карап алам аның ягына.
Йөрәгеннән аның таш төшә кук,
Күңеленнән әрнү агыла.

...«Украина иде. Без йөзләгән әсир
Авыл буйлап узып барабыз.
Юл читендә халык. Вакыт-вакыт
Тик бер адым иде арабыз.
Кинәт кенә, таза хуторянка,
Чалынганчы сакчы күзенә,
Өметсезлек, үлем арасыннан
Йолкып алды мине үзенә.
Башкалары капладылар безне,
Ә сакчылар берни күрмәде.
Без йөзләгән идек... Нигә мине?
Бусы миңа һаман сер әле.
Җомга иде... Чолганышта калгач,
Чиста күлмәгемне кидем мин.
Әбиемнең догаларын укып,
Барысына әзер идем мин...
Җомга иде, җомга! Мин хәтерлим.
Чиста күлмәк йөрттем һәрвакыт.
Юкса, кыен анда пөхтә булу,
Бер сикереп торып, бер ятып.

Итекче дә булдым, балта остасы да,
Яшәп калдым Һанна янында.
Куллар эшли, ә баш уйлый һаман
Туган җирне, тагын, тагын да.
Шунсы гаҗәп: вакыт уза торды,
Тик, берсе дә мине сатмады.
Әллә холкым белән ярата ттырдым,
Иманыммы әллә саклады.
Хуторянка Һанна соңрак әйтте:
«Колоннагыз озын, зур иде.
Күзләреңдә өмет, авызында дога,
Чыраеңда серле нур иде...»

Ә бер көнне, уйларымны уйлап,
Олтан сала идем итеккә,
Ике солдат белән бер офицер
Пәйда булды кинәт ишектә.

Котым очты... Тыштан сиздермәдем.
Борылмадым, һаман эшләдем.
Беттем, ахры, Раббым, диеп кенә,
Кысылдылар бары тешләрем.
Каушамады Һанна, әйтеп салды:
«Бу — саңгырау, телсез туганым.
Акылы да зәгыйфь. Өйдә генә тора,
Башка эш белгәне юк аның...»
Үле тынлык... Мин эшемне эшлим.
Гүя, бернәрсә дә ишетмим.
Тик ишеттем, татлы аваз булып,
Ябылганын тыштан ишекнең.

Беркем кумый. Ләкин тынгы бирми
Канга, җанга кереп тулган чир.
Кайсы яктан, ничек уйласаң да,
Үз ягына тарта туган җир.
Көч тә җыйдым. Ничек ятыйм монда,
Һанна итәгенә ябышып.
Чыгып киттем. Ни булса да алда,
Раббым язган тик үз язмышым.
«Китмә!» — диде күрше-тирә халык,
«Китмә!» — диеп, Һанна үтенде.
Хәзер аңлыйм, әгәр калган булсам,
Мин югалта идем үземне.
Мин югалта идем иманымны,
Мин югалта идем барысын...
Мин бөтенләй башка була идем...
Юк! Уйламыйм аннан арысын!
Тырышлыгым өчен яраттылар,
Динемне дә хөрмәт иттеләр.
Аңлашканчы үз денсезең белән,
Аңлаш икән денле чит белән.
Чукрак булдым кирәкмәгән сүзгә,
Телсез булдым кирәк вакытта.
Аңладылар — минем иманымны
Җимереп тә булмый, ватып та.
Чукрак булсам, куркак түгел идем,
Телсез булсам, тешсез булмадым.
Әле мине алда көтә иде
Раббым язган язмыш юлларым.

Күрсәттеләр фронт сызыгына
Илтә торган сукмак-юлларны.
«Безнекеләр» никтер, иң беренче итеп,
Бәйләделәр минем кулларны.
Сөйлисем дә килми ул хәлләрне,
Сызлатасым килми йөрәкне.
Сугыш бетте, ә мин дистә елга
Воркутага килеп эләктем...
Ул якларда кышлар, ай-һай, салкын!
Ә мин шофёр булып эшләдем.
Була иде, көннәр-төннәр узды,
Кабинадан бер дә төшмәдем.

Бар гомерең машинага бәйле,
Беркем белми нәрсә күрәсен.
Ул барганда, син дә исән әле,
Мотор сүнсә, син дә үләсең.
Ул вакытта нәрсә ул машина —
Тишек-тошык агач кабина.
Үләм-үләм дигән иске мотор
Мең газаптан гына кабына.
Мин эшләдем көнне-төнне белми.
Үзем күндәм. Төзек машинам.
Кемдер сата, кем сатыла монда,
Ә мин һаман эшкә ашыгам.
Юлда чакта мине беркем күрми.
Яисә эштән кайтып килешем.
Түрәләр йә шикле «зек»лар белән
Булмады һич алыш-бирешем.
Дога белән эш коткарды мине
Бу имансыз, кыргый мәхшәрдә.
Күрер өчен газиз туган җирне
Кирәк иде әле яшәргә.
Чукрак булдым кирәкмәгән сүзгә,
Телсез калдым күпме вакытка.
Аңладылар — мине ватып булмый,
Типкәләп тә, хәтта атып та.
Куркак булу — сак булу ул кайчак.
Тешле булу монда кирәкми.
Кыргый золым иле уртасында
Черек тешең сиңа терәкме?
Дога белән эш коткарды мине.
Әләкче йә сатлык булмадым.
Хыялымда мине йөртә иде
Газиз туган җирем юллары.

Тып-тын гына эшләп йөргән чакта,
Барыбер бит сине күрәләр.
Сигез елдан кайтыр вакыт җитте.
«Китмә! Китмә! — диде түрәләр. —
Менә сиңа Ирек! Менә эшең!
Синең кебек тырыш кеше юк!
Теле барның — теше, теше барның — кулы,
Кулы барның денле эше юк!
Син белмисең, ахры, читтә эшләп,
Тормыш авыр хәзер авылда!
Күпләр качып китү ягын карый,
Мөмкинлеге чыккан чагында.
Нигә кирәк сиңа бу фәкыйрьлек?
Нинди тормыш тора алдында?
Менә сиңа фатир! Менә акча!
Тормыш корып, яшәп кал монда!..»

Хәзер уйлыйм, әгәр калган булсам,
Мин югалта идем барысын.
Мин бөтенләй башка була идем...
Юк! Уйламыйм аннан арысын!

Тырышлыгым өчен ярattылар,
Динемне дә хөрмәт иттеләр.
Үз денсезең белән эшләгәнче,
Эшлә икән денле «зек» белән.
Намаз уку көн дә эләкмәде,
Сәбәпләре аның мең иде.
Атна саен бер бәйрәмем булды,
Ул да булса җомга көн иде.
Мөмкин чакта күлмәгемне юдым,
Дога кылдым моңсу булганда.
Күңелемне юган кебек идем,
Керле күлмәгемне юганда.
Авылыма кайттым, тормыш кордым.
Үз татарым белән никахлы.
Кайчак уйлыйм — күпме гомер бушка...
Дөньясымы, минме гөнаһлы?
Әлегә без бу дөньяда икән,
Бу сорауның юк бит җавабы.
Мин ышанам, Раббыбыз бар икән,
Бу тормышның бардыр дәвамы.
Китәсе бар, «китмә!» дисәләр дә,
Китәсе бар, җитә вакыт та.
Вакыт җиткәч, калып булмый инде
Барлык байлыгыңны сатып та.
Кемдер китә гөнаһларын төяп...
Почмагында денсез өенең,
Денсез туганнарын сугыштырып,
Алтыннары кала өелеп.
Кемгә нәрсә байлык. Минем белән
Намазларым юлга чыгалар.
Чиста күңел, кылган савапларым,
Догаларым тулы җомгалар.
Күңелемне юган кебек идем,
Керле күлмәгемне юганда.
Иманым нык, күңелем пакь минем,
Бернинди кара кер юк анда.
«Китмә! — диләр дуслар, туганнарым, —
Синең кебек ипле кеше юк!
Денсез, имансызлар тулып ята,
Теле барның теше, эше юк!..»
«Китмә!» — диләр, аптыраудан гына,
Ни булса да, инде китәсе.
Мин үземне түгел, сезне жәлләп китәм,
Сезгә әле гомер итәсе.
Әлегә без бу дөньяда икән,
Сорау туа һаман — кем хаклы?
Нәфесеннән шашкан адәмнәрме?
Дөньясымы әллә гөнаһлы?
Беркем белми алдан. Һәркемнең дә
Тик үзендә генә җавабы.
Бу ахыры түгел әле дөньяларның,
Алда әле аның дәвамы.

Раббым биргән бер хәерле иртә...
Күзләремне ачкан чагымда,
Кояш кебек балкып вә елмаеп,
Закир абый тора янымда.
Кулында хат аның, йөзендә нур:
«Карчыгымнан, менә, хат килде...»
Ялганламыйм, Раббым, бер тамчы да,
Бөтен сүзе шулай, хак иде.
Әйтерсең лә яшь кенә бер үсмер
Серен сөйли миңа оялып.
Иң беренче гыйшкы турындамы,
Әллә кул җитмәслек хыялын:
«Икенче ай китте инде, картым,
Шул гомердән бирле кайда син?
Эчкән чәйләремнең тәме дә юк...
Бик сагындым. Кайчан кайтасың?..»

Менә шулай. Тагын нәрсә әйтим?
Аңлаганы аңлар үзе дә.
Иманлы вә нурлы иде аның
Йөзе генә түгел, сүзе дә.
Моңсу уйлар... Минем бәхетемдер —
Нинди шәхес белән дус идем!
Хәзер аңлыйм — ә бит танышканчы
Мин яртылаш әле буш идем.
Яздым әле. Кызыгы юк кебек.
Әллә ул Чын Кеше түгелме?
Бер карасаң, тоташ кыя кебек,
Бер карасаң, нечкә күңелле.
Мин ышанам, Закир абый инде
Ирешкәндер оҗмах түренә.
Ләкин никтер татар йөзе хәзер
Караңгырак булып күренә...

Сәгыйдулла
Хафизов

# ТУЗГЫТЫЛГАН КҮЧ

БӘЯН

## Кичерегез, якташлар!

### I

Фермер... Рәмзил экономистның Сергеевка фермеры булып китүе әллә ничек, соңгы вакытта кергән саташулы төше кебек, ипсез килеп чыкты инде ул. Замана чуалса, үз кочагына эләктергән ташу сыман, кая илтеп ташлаячагын, нишләтәсен дә белмәссең... Арттан коммунизм коручы Ленин эзәрлекли, алда елгыр базарчы Абрам тора. Әйтәсе юк, шомлы, хәтәр мәл... Бу яһүд Чардаклы якларына колхоз-совхозлар таралып, фермер дигән эшкуарлар пәйда була башлагач килеп чыкты. Сергеевкадагы «Гигант» совхозы районда банкротлык дигән яман хәлнең беренче корбаны иде. Әлеге яһүд, ничек әтмәлләгәндер, кулына ике мең гектар җирне эләктерде, сыер фермасы каралтыларын сатып алды. Тик фермер дигәнең, ил түрәләре, район җитәкчеләре көткәнчә, җиң сызганып иген үстерергә, сөт җитештерергә керешмәде. Абрам нигъмәтләр тезгәнче, табын өстәлендәге ашъяулыгың саргаер! Ул һаман да кызык тамашалардан туймаган бала сымак, аукцион утырышларына йөрде. Эшкуарлар белән бәяләрдә ярышты, нәрсәдер алды, нәрсәдер үзе дә сатты... Арбитраж управляющие Равил янәшәсендә бу яһүд бөтенләй үз кеше булып китте.

Менә ул аукционда сатулашып, арзан хакка «Авангард» колхозының тегермәнен кулга төшерә. Сатар өчен он яисә үзенең терлекләренә фураж тарттырырга җыена инде Абрам дип уйлыйсың. Алайса, нәрсәгә тегермән? Көт, тегермәнне көйләде ди сиңа! Менә ул барсеткасын тотып, милек хуҗасы сыйфатында Чәтрәнгә килеп төшә. Кибет янында нәрсәгәдер өметләнеп махмырдан интеккән ирләр җыелган. «Әй, мажыклар, баш төзәтәсегез, акча эшлисегез киләме? Эш бар!» Абрамны шундук урап алалар. Эш хакында сөйләшеп, шартларына күнәләр. Һәм шул ук көнне «Авангард» тегермәнен нигезенә кадәр сүтеп җыю чарасына керешә баш төзәткән ир-ат кавеме. Эшкә өндәү, чакыру кирәкми. Йөз кирпеч кубарып куйсаң — йөз сум! Тимер, кадактан араланган такталың кубометры — 200 тәңкә! Чүкеч, балтаңны ешрак кизәнеп эшлә генә!

Әмма Абрамның күзен аеруча кызыктырганы — түшәм плитәләре. Боларга зерә кытлык! Ызба, сарай, коттедж салырга керешкән яңа урыслар, яңа татарлар, юньчел башкорт, чувашлар элеккечә кирпеч дивар өстенә матча тартсыннармыни? Такта түшәм хәзер музей экспонаты. Бетон плитә кирәк. Тик алыпсатарлар сәүдә итә торган нәрсә түгел бу. Абрам кран белән төшерткән

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

плитәләр каршына чират тезелә. Яһүд барсеткасына кызыл тәңкәләр ява... Кирпечтән, такта, борыстан да баш тарткан кеше юк. Кайсыдыр ООО чыгарган кызыл кирпечкә карарлык түгел — кителгән, ярылган, ә бәясе сару кайнатырлык, бер данәсе 12 сум тора. Абрам исә элекке замандагы сыйфат чүкече чәпәлгән кирпечне 5 тәңкәгә озата. Нарат, чыршыдан торган кызгылт такта да эшкә ярарлык, бәясе бөтенләй пүчтәк, нигә алмаска?

Менә шулай сәүдә итеп Абрам табыш җыя, кесә калынайта. Һәм билгеле, бер нәфес кузгалгач, ул һаман зуррак корылмалар сатып ала. Колхоз амбарлары, дәүләт элеваторы, ферма комплекслары сүтеп сата. Аукцион лотлары Абрам кесәсенә күпме табыш китерде икән? Моны кем исәпләсен. Аукцион — фокус, күз буяу. Чынлыкта, барысы да сатучы һәм алучы гына белгән сумма күләмендә чутлана бит. Яшь хөкүмәт, кара базар корып, үзенә таянырлык варислар — уллар, кызлар үстерергә өметләнде. Абрам, күрәмсең, үзен нәкъ әнә шуларның берсе итеп тойган да инде.

Яһүд фермер «Ленин юлы» колхозына да килеп, рәис, экономист белән бер «шухыр-мухыр»да кул сугышып «мәгәрич» капкач, исерә башлаган Фердинанд әллә көлеп, әлә хурланып әйтеп куйды:

— Син бит козгын, дускай! Ачулан-ачуланма, әйтәм, үләксә козгыны! Элекке заман булса, беләсеңме, мин кем?.. Сиңа өтермәнгә путёвка язасы кеше! Ятар идең сәндерәдә ниләр кылуыңа үкенеп... Ә хәзер син — фермер, эшкуар, Ельцин әйткәнчә, җәмгыятьнең алгы сафында безне җитәкләп баручы кеше!

Әмма яһүд моның сүзләренә һич кимсенмәде, хәтта председатель әйткәннән канәгатьлек табып, елмаеп куйды:

— Исхаков әфәнде, козгын булса ни, акчадан ис килми бит! Алганда бер дә борын җыермыйсыз үзегез.

Эчтән ни рәвешледер, әмма тыштан, чынлап та, үтә сабыр, пошмас бәндә бу яһүд. Зур коңгырт күзле. Юкка-барга ярсып яисә көлеп бәбәгеннән чаткылар чәчмәс. Иң мөһиме — дөньяны ничек бар, шулай күрү. Ә көлү, ярсу булса да астыртын, тик үз күңелең өчен бугай. Хәйлә шулай ук яһүд күзенә бәреп чыкмас. Киресенчә, карашында нарасыйлык галәмәте, нарасыйлык бөркелә... Абрамны бизәгән нәрсәләр — акыл, җитдилек, иҗтиһадлык... Нәкъ шундый алчак сыйфатлары белән Чардаклыдагы түрә һәм эшем кешеләрен үзенә биләп алган Абрам Штельман берчак аулакта туры китереп, Рәмзил каршына килеп басты:

— Миннән акча, синнән эшне оештыру. Компаньон булып, ферманы рәткә кертик әле, хөрмәтле Сәгъдиев!

Нишләсен Рәмзил? Колхоз тарала... Бала-чагасын төяп, карт анасын ташлап авылдан чыгып китә алмый ул. Эшне дәвам итүнең, мөгаен, бердәнбер юлыдыр бу. Тәкъдимне кабул итте, фермерга әйләнде күмәк хуҗалык белгече Сәгъдиев...

## II

Дүшәмбе иртән эшкә килгәч, конторада сәркатип, хисапчы, оештыручы вазифаларын башкарган Зәнфирә сүзсез генә Рәмзил кулына кәгазь сузды.

«Таң» фермер хуҗалыгы башлыклары А.Ш.Штельман һәм Р.Ш.Сәгъдиевны 15 гыйнвар сәгать 11гә Чардаклы район хакимиятендә үтәчәк киңәшмәгә чакырабыз. Оештыру комитеты».

Киңәшмә дигәннәре кофе, кәнфит белән сыйлар өчен генә үткәрелмәс, берәр буза куптарырга җыеналар бугай дип уйлап алды фермер. Ихластыр, «Ленин юлы» колхозы икътисадчысы вазифасын үтәүдән туктап, «Таң» фермер хуҗалыгына Абрам Штельман компаньоны булып күчкәч, ул район хакимияте тарафларына илтәсе юлны оныта да башлаган иде. Күңеленә янә без фәкыйрьләр район башлыкларына нәрсәгә кирәктек икән дигән шөбһәле шик өстәлде. Анасы әйтмешли, ахыры хәерле булсын, заманага һич ышаныч юк...

Абрам әле җомга кичендә генә гаиләсенә, Пермь каласына кайтып киткән иде. Барысы хакында да Рәмзил фермернең үзенә генә баш ватарга калды.

Иртәгесен билгеләнгән сәгатькә хакимият бинасына килгәч, Рәмзил элекке хезмәттәшләрен, дус-ишләрен, эреле-ваклы район җитәкчеләрен очратты. Күренеп тора, монда эшкуарлар, район активы җыелып ята. Ләкин нәрсә турында сөйләшәчәкләр, бу хакта анык кына сүз әйтүче табылмады.

Ниһаять, зал аркылы сәхнә кебек күтәрмәгә түрәләр төркеме үтте. Алдагысын, кара туткыллы сөйкемле ир уртасын шәйләп кемдер пышылдады: «Халиков, Президент аппаратыннан...» Аның артыннан башын ия-ия сәламләп атлаучы кешене таныырга тылмач кирәкмәде. Бу Эдуард Дашкин — Чардаклыда эшләп, авыл хуҗалыгы министрлыгына үрләтелгән үз кеше. Район хакимияте башлыгы Иван Касаткин залга, халык каршына чыккан саен, уңга-сулга башын чөеп төче елмая һәм аренадагы көндәшен нокаутка утырткан мәшһүр боксчы кебек кулларын өскә күтәрә иде. Әмма бүген ул гаҗәп төксе күренде. Аның артыннан атлаган замнар, помнар да эшем кешеләренә хас уйнак чырай белән балкымадылар. «Югарыда берәр үлем-китем юктыр бит», дип борчылып уйлап алды Рәмзил.

Җитәкчеләр дәрәҗәләре буенча тезелешеп өстәл артына утырышкач, Касаткин трибуна артына килеп басты:

— Хөрмәтле агропром җитәкчеләре, хезмәткәрләр! Безнең Чардаклы районы — ашлык үстерү һәм терлекчелек продуктларыннан сөт, ит, май җитештерү буенча махсуслашкан төбәк. Бу ике юнәлеш тә безнең өчен бик тә әһәмиятле. Бүген без сезне чакырып, проблемалар хакында сөйләшергә җыенабыз, — һәм ул кесәсеннән кәгазь чыгарды да районда нинди авыл хуҗалыгы фермалары, предприятиеләр барлыгын, кайсы хуҗалыкта эшләрнең әйбәт оештырылуын укып китте. Тик гадәти докладтагы кебек, эшләүчеләр исемлеген әйтеп, гектарлар, центнерлар күләмен санаса да, хакимият башлыгы нишләптер тирләп чыкты, кулъяулыгын чыгарып еш-еш сөртенә башлады. Инде ул сүзеннән туктап, махмырдагы сымак калтыранып, алдындагы суны эчә башлагач, Дашкин торып басты:

— Иван Харитонович, без бит сездән доклад укуны сорамадык. Ник үзегезне җәфалыйсыз?

Һәм әлеге репликадан соң зал хәлгә аңышты бугай. Үзара гәпләшүчеләр, пыш-пыш килеп сөйләшүчеләр дә тынып калды.

— Утырыгыз әле, Касаткин... — һәм тегесе чөгендер кебек кызарынып урынына утыргач, Дашкин аңа карап болай диде. — Кәгазьдә сезнең барысы да яхшы, ал да гөл, теләсәң ела, теләсәң көл, Иван Харитонович. Әмма без министрлыкка озатылган сезнең реаль цифрлар аркылы бик яхшы аңлыйбыз. Бу районда элекке колхоз-совхозлар бөтенләй таркалган, ә фермер хуҗалыклары йә зәгыйфьләр һәм бик аз санлы, йә, исәпкә бар — санга юк дигәндәй, бөтенләй дә азык-төлек продукциясе җитештерү белән шөгыльләнмиләр. Уйларга да куркыныч, 55 мең сөренте җире булган районда тик 30 мең гектарда гына ашлык чәчелгән. Ни хәл бу, Касаткин? Иң элек менә шул мәсьәләне ачыклыйк без! Яисә сез авыл хуҗалыгы белән бөтенләй дә шөгыльләнмисезме? Берәр яңа бизнеска исәп тотасызмы? Сезнең хакимияттә башлык булып утыруыгызга киләсе елда икенче срок тула. Без һәм монда җыелган халык сездән шул сорауга җавап көтәбез, хөрмәтле Иван Харитонович!

— Әллә кайчан сорарга кирәк иде, — дип залдан кычкырды берәү. — Сез утырткан кеше бит бу!

Шулвакыт Халиков урыныннан торып басты:

— Иптәшләр, әфәнделәр! — Тавышы сабыр иде. — Мәсьәләнең үтә кискен, катлаулы икәне күренеп тора. Тик урыныбызда торып кычкырмыйбыз. Моның өчен трибуна бар. Чыгышларны протоколлаштырырга кирәк. Иван

Харитонович, оештырыгыз! — Һәм ул залга күз йөгертеп чыккач, өстәп куйды. — Йәгез, кемнән башлыйбыз?

Залда байтак вакыт тынлык хөкем сөрде. Тик күпләр сизә, тоя, бу давыл алдыннан була торган хәтәр торыш, бераздан монда мәхшәр кубачак... Әмма кырмыска оясына башлап таяк тыгарга кемнең йөрәге җитәр? Башкаладан килгәннәр килә дә китә, ә син әләкләп кая барырсың... Сәбәп тик шунда.

Ниһаять, сул дивар ягыннан озын гәүдәле, сакал-мыекка чумган утыз биш яшьләр чамасындагы ир уртага чыкты, һаман тавыш-тынсыз гына атлап трибунага күтәрелде.

— Мин — Сәүбан Батыршин, Дөм-дөм фермеры, иптәш Халиков, — диде ул, нишләптер президент кешесенә башын борып. — Бездә «бәтрәк» дип кешегә әйтелә торган сүз бар. Ну, алдын-артын уйламыйча йөрәксенеп утка сикерә торган адәм инде бу. Кушаматым нәкъ шул «Бәтрәк» минем. «Бәтрәк Сәүбан»! Касаткин шайкасы тәмам бетерсә бетерер, әмма сезгә үз башымнан кичкәнне сөйлим, иптәш Халиков!

Мин 1996 елда 300 гектар җир алдым. Яшелчәгә ихтыяҗ зур дип, яртысына бәрәңге утырттым, калган мәйдан кәбестәгә, азык чөгендеренә китте. Бәрәңге бик унды. Тик дәүләткә озатып булмый, хәтта спирт заводына да алмыйлар. Сезнең белән договор юк, диләр. Касаткинга бардым: «Иван Харитоныч, шундый-шундый хәл, ярдәм итегез сатарга?» Гөнаһ аласым килми, нәрсә дисә, шуны әйтәм: «Мин базарга чыгып сиңа бәрәңге сатыйммы? Син хуҗа — син реализуй!» Сатып булмады, бәрәңгедән зыян гына күрдем мин.

Икенче елны үткән эштән сабак алып, 300 гектар бодай чәчтем. Яхшы, элиталы сорт! Алдан элеватор белән договор да төзеп куйдым. Унды бодай, гектарыннан 35 центнер чыкты. Тик янә проблема калыкты. Элеваторны банкрот ясадылар. Тагын Касаткинга керәм: «Иван Харитоныч, транспорт белән ярдәм итегез!» Ә хаким кеше нәрсә ди: «Миндә синең бодайны ташырга автомобильләр колоннасы юк!» Элиталы бодай фуражга, мужикларга көмешкә ясарга китте. Һаман миңа файда юк. Инде хәзер ашлык чәчәргә куркам.

Сәүбан туктап калды. Артык таралып сөйләвен аңлады шикелле. Шуңа хуҗаларның берәр ым ясавын көтте бугай.

— Сөйләгез, фермер, сезне игътибар белән тыңлыйбыз, — диде Халиков.

— Өченче елда мин нишләргә дә аптырыйм бит. Шикәр чөгендеренә керешәсе иде, җыярга комбайн юк. Һаман Касаткинга барам, тагын кемгә керәсең? «Иван Харитоныч, льготалы кредит алырга ярдәм итегез, зинһар, чөгендер комбайны алыр идем!» Ә ул папкасында казынып миңа яңалык әйтә: «Син, Батыршин, техникадан үзеңә табыш алу өчен генә файдаланасың икән. «Газель»ең белән халыкка утын ташыйсың, синең «Беларусь» нефтьчеләргә чокыр казый. Син авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән бөтенләй шөгыльләнмисең икән. Мондый кешегә льготалы кредит бирмибез без». Нишлисең, тора-бара бурычларымны түләр өчен йортны саттым, үзем хәзер булган техниканы саклап яланда будкада яшәп торам. Ә хатын баланы алып әнисенә яшәргә китте. Менә шулай минем фермерлык хәлләре, хөрмәтле вәкил. Йә, әйтегез, алда ничек яшәргә миңа?.. Будкага кереп асылыныргамы, әллә барысына төкереп шәһәргә эш эзләп китәргәме?

Сәүбан, билгеле, җавап көтеп тормады, янә тавышсыз-тынсыз гына сул дивар ягындагы урынына юнәлде.

Аның каравы зал, умарта күчедәй, гөжләргә тотынды. Берничә урыннан кешеләр күтәрелеп трибунага табан атлады. Алдарак килеп баскан җирән ир кабаланып кычкырды:

— Язгыгыз, мин Иске Шырданнан Микуш булам. Микуш Ермолаев! Алдагы

фермер бик дөрес әйтте. Касаткиннан безгә бер ярдәм юк. Эшкә таяк кына тыга ул. Мин дә игенчелеккә тотынып караган идем башта. Колактан убыткага гына чумдым. Налуг җыярга гына мастер Касаткин администрациясе. Бир дә бир! Фермер бездә үзе савым сыеры. Мин дуңгыз асрап кына җан саклап киләм. Анда да хөкүмәткә озатып түгел, халыкка үз белдегем белән сатып... Менә без шулай яшибез, олы түрәләр. Тик президентка барып җитсен! Тагын искечә барса, без барыбыз да аяк сузарбыз... Булды, мин әйттем!

Ермолаев китүгә, сүзгә чират көткән юан ир трибуна артына килеп басты:

— Поляков, Шемәктән. Миндә йөз баштан арткан сыер фермасы. Зарланмас идем, файда күрәм. Сөтне җиңел сатам, юл өстендә булгач. Бөре каласында даими клиентларым бар. Тик җан тыныч түгел. Халык фермерны яратмый, кырдагысын, йорттагысын урлашу көчле. Басуларга мал да кертәләр. Былтыр егерме гектар борчакны авыл көтүе таптагач, акт төзергә дип милициягә бардым. Начальникка гозерне әйттем. Барсуков кымшанмады да: «Мондый вак-төяк белән шөгыльләнү безнең вазифа түгел. Касаткинның безгә сүзе бар ди бу: «Фермерлар халык белән мөнәсәбәтне үзләре җайласын, сез тыгылмагыз!» Башта суд, аннары сәнәкләргә ябышып кан кою китәр, янәсе. Мин хәзер куркып торам инде, утарга ут төртеп китмәсәләр ярый. Мин сорар идем, Халиков әфәнде, бездә соң фермер милке закон белән якланмыймыни?

Менә шулай башкаладан килгән түрәләр каршында зар түгү капчык авызы кебек чишелеп акты, акты... Рәмзил фермер крестьян катламында шундый көчле аһ-зар бардыр, дип башына да китермәгән иде. Фермеры фермер, әмма Касаткин адресына әллә нинди көтелмәгән яклардан да дәгъвалар яуды бит. Трибунага күтәрелгән бер Чардаклы хатыны хакимгә карап, ай-һай, каты сүзләр яудырды:

— Сез иркәйләр, Касаткин безнең турыда кайгыртмый, дип җылыйсыз. Нишләп Иван Харитоныч сезне кайгыртсын? Аның бит үз бизнесы бар. Кияве милициядә башлык, туганы банк җитәкчесе, улы заправка хуҗасы, кызы универмаг директоры аның. Менә шуннан уйлагыз инде хәзер, ничек арзанга гына бензин, солярка кайтарырга да, биш бәясенә халыкка сатарга? Үтемле товарны читтән кайтарып ничек универмаг прилавкаларына шуларны матур итеп тезәргә? Банктан ничек итеп яшертен генә кулга акча төшерү юлларын табарга? Касаткиннарга өсте-өстенә иномаркалар, күзнең явын алырдай коттеджлар, дачалар күктән төшәләр, дисезме? Болар бит барысы да безнең хакимнең башын көне-төне катырган идеяләр. Ул шулай гаиләсен баету бизнесы белән шөгыльләнә. Аның сезнең турыда уйларга һич вакыты юк, иркәйләр. Аңлыйсызмы шуны?

— Болай булгач, аңладык инде. — Эдуард Дашкин салмак кына урыныннан күтәрелде. — Җәмәгать, сезнең сөйләгәннәрне Касаткин һәм аның администрациясе ничек кабул иткәндер, әйтүе кыен, әмма алар минем йөрәккә кадалды. Мин бит монда эшләгән кеше. Иван Харитоныч яшь иде әле ул чакта. Матур иде, һәр яктан килешле иде. Вуз бетергән, агроном. Берничә ел эшләгәч, «Гигант» совхозына директор итеп күтәрдек. Ә үзем сездән киткәндә, аны район башлыгы итеп куярга тәкъдим керттем. Һәм менә нәтиҗәләр... Алар иң башлап минем йөрәккә суга, билгеле.

Эдуард Дашкин авыр итеп көрсенеп куйды.

— Иптәшләр, безгә хәлне төзәтү өчен, иң башлап хаталарны табарга кирәк. Хуҗалыкны, икътисадны көрчеккә терәгән сәбәпләр күчеш заманында ифрат күп. Ашыгычлык, төпкә төшеп уйланмау бар. Фиркаләр сугышы булган. Ә шулай да мин үземә килгәндә, иң зур ялгышымны кадрлар сәясәтендә күрәм. Бер иптәшне бик җаваплы постка куйганда, фәлсәфә корып әйткән дә идем. Иске формага яңа эчтәлек салырга мөмкин. Марксизм белән безнең заман бәхәскә чыга, янәсе. Аныклап әйткәндә, әлеге иптәш ысланган компартия

функционеры иде. Ә хәзер аны базар икътисады өлкәсендәге бик җаваплы постка куярга җыенабыз. Әйдә, хөрмәтлем, яңа якларың, бүгенге тормыш таләп иткән сыйфатларың белән күрсәт хәзер үзеңне! Маркс, Ленинны оныт, Гайдар, Чубайсны тыңла!

Менә минем хата кайда? Методологиядә! Формасы иске булгач, эчтәлеге дә иске инде аның. Сәвит кануннарын яшәү принцибы иткән чиновник демократия заманында хөрлек, тигезлек, иҗтиһад иреге рыцаре булып китә алмый. Киресенчә, ул коллективка зыян гына сала. Тыя, чикли, киртә кора. Мондый кеше яңа заманны үзенеке итеп, яшәү һәм көрәш максаты рәвешендә аңлый да, тоя да алмый. Шуңа ул рухланудан, идеалдан мәхрүм. Нәтиҗәдә үз кабыгына бикләнеп, шәхси рәхәте өчен генә яшәгән адәм актыгы килеп чыга аңардан... Кул кулны юа, илне коррупция баса...

Яңа замана үз баласына таянып кына күтәрелә икән ул, егетләр! Төшендегезме, яңа эчтәлекне яңа формага гына салып була. Чардаклыда кадрларны сайлаганда, аеруча җитәкчеләрне куйганда хаталар байтак булган шул минем. Болар өчен кичерегез мине, якташлар!

Ул кешеләргә карап чал башын иде... Трибунадагылар да, залдагылар да байтакка тынып, үз эчләренә йомылып, уйланып тордылар. Рәмзил дә сискәнеп куйды. Берәү үз вазифасына төкереп, урлашып кенәз булып яшәп ята, ә икенчесе аның өчен йөз кызарта, гафу сорый. Җаваплылыктан азат берәр гамәл бармы дөньяда? Хәер, безнең олы түрәләр халык алдында крокодил яшен түгә беләләр. Нишләсен? Алдан ук, үзегез куйган кеше, дип кычкырдылар бит. Ничектер Касаткин шайкасыннан араланырга кирәк ласа... Иске форма, яңа эчтәлек, имеш, буталган... Фердинандның асылын Дашкиннан да шәбрәк белүче булмагандыр. Әмма өстән йонлач куллы түрә ым каккач, ул, Рәмзил, Зәйтүнәне читкә тибәреп, әлеге бәндәне миллионер колхозга рәис ясап утыртты. Һич фәлсәфә сатмады. Сүзе нык иде: «Энекәш, Исхаков урыны бу! Арага кысылып безнең белән дошманлашма. Яшьсең әле, җае чыккач, сине дә читкә какмаслар...» Кыскасы, шалишь, абзый, бу очсыз яшьләрең Рәмзил өчен түгел синең...

— Ярый, иптәшләр, сөйләшү эчкерсез булды, — диде ниһаять Халиков, аягына басып. — Башкалага кайткач, барысын да түкми-чәчми президентка җиткерәчәкбез. Ә ул үз чиратында Чардаклы районындагы проблемаларга битараф кала алмас, анык чаралар күрер, дип ышанам... Шуның белән бүгенге киңәшмәбезне ябык дип саныйм.

### III

Актив җыелышы ябылуга, халык теле ачылып китте. Райүзәктә, карьяларда иң мөһим яңалык булып югарыдан олы түрәләр килеп, Касаткинны җавапка тарттырырга җыенулары турында хәбәрләр йөрде. Кемдер район тормышында алмашынулар башланасын сизеп шатланды, ә кайсылары кара кайгыга төште. Иван Харитоныч кәнәфидән очса, аларның да югалтыр нәрсәләре байтак бит... Рәмзил Чардаклы тормышында күптән инде, әле башланган февраль бураннары кебек, тузынуны күрмәгән иде. Әйдә, шауласыннар, тузынсыннар. Үз холкына тугры калып, Сәгъдиев күләгәгә, ышыкка посарга, хуҗалык эшләре белән ныграк шөгыльләнергә ниятләде. Штельман әйткәнчә, «Таң» фермасын күтәрергә бик вакыт, әнә бит, югарыдагы җитәкчелек тә, ниһаять, авыл хуҗалыгындагы күрсәткечләр белән ныклап кызыксына башлаган...

Төшлектә кантурга кереп, «Яңа таң» исемле район гәзитен кулына алгач, Сәгъдиевнең күзенә чекерәеп торган рәсми хәбәр килеп бәрелде: «Чардаклы муниципаль район хакимияте башлыгы вазифасына агымдагы елның 5

февраленнән 10 февральгә кадәр сәгать 9дан 18 сәгатькә кадәр хакимият бинасында конкурста катнашучылардан документлар кабул итә.

Конкурс комиссиясе утырышы агымдагы елның 20 февралендә сәгать 11дә хакимият бинасында була. Конкурс үткәрү агымдагы елның 28 февралендә хакимият бинасында сәгать 11гә билгеләнә».

Болай булгач, процесс башланды, дип уйлап куйды Рәмзил, элекке зур түрәнең яраткан гыйбарәсен хәтерләп. Инде Касаткин өере куыла, үчлеләрдә гайрәт арта, үзгәрешләр башланасы ачык...

Ул янә гәзит битеннән кабаланып күз йөгертте. Әһә, бар икән... Менә ул конкурста катнашу өчен кирәкле документлар тезмәсе. Гариза, паспорт, аттестат, диплом, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе... Болар аңарда бар, билгеле. Автобиографиясен дә язар, рәсемгә дә төшәр. Әһә, шуннан салым инспекциясенә, авыл советына, юк ла, хакимиятенә кереп белешмәләр алырга кирәк икән. Врачлардан да, абитуриент вакыттагы кебек, имзалар җыясы бар. «Кая укырга керергә җыенасыз, хөрмәтлем, яшегез бара түгелме?» «Юк, — дияр Сәгъдиев, — укырга һичкайчан соң түгел. Заочно юридик институтка керергә исәп...» Һәм белешмәләрне җыеп конкурс комиссиясенә тапшыргач, анкета тутырасы гына кала...

Әллә соң, диде ниһаять Рәмзил үзалдына, бәхетне сынап карарга мы? Эдуард Дашкин янына килеп, син, Сәгъдиев, мин көткән яңа заман баласы икән, әйдә, кастингта катнаш, энекәш, дип әйтмәс. Көт! Һаман да район башлыгы постына үз мохитеннән һәм файдасы тиярлек кандидат табып китерер. Ә син Штельман утарында, аның канатына сыенып, биргәненә шөкер, ярхәмбикаллаһ, дип ятарсыңмы? Шулай мәхлук, куркак бәндәме соң син... Балачакта ук төшкә кергән алма уйдыгы табуыңны оныттыңмы, Рәмзил? Кайчандыр боксчы булып, көндәшләреңне нокаутка утыртуыңны да хәтерләмисеңме инде хәзер? Әллә Дашкин, Шакиров кебек затсыз фиркачылардан сугылып, тормышка үпкәләдеңме, көрәштән киттеңме? Ә монда Касаткин әтәч булып кагынып йөргән. Яшь, матур, һәр яктан килешле, янәсе. Күрегез, көч кемдә? Рингка чыгып көч сынашсалар, маңгаена берне генә тондырып, артына чүктерәсе адәм бит, югыйсә... Чәчең бакыр, холкың батыр ласа синең, Рәмзил. Колхозны миллионер иттең, димәк, башың да бар. Нигә этрәк-әләмнәргә юл биреп ятасың син? Ә бервакыт алмагач үстереп, кешеләргә алма өләшергә ниятләвеңне оныттыңмы, ир уртасы кеше?! Ә бит еллар уза, халык синнән йөз чөергәнче, уйлаганыңны эшләргә кирәк!

Рәмзил гәзиттә Чардаклы район хакимияте вазифасына конкурс игълан итүләрен күргәч, үзендә шундый йөрәк кагу, аңышмаган бер ашкыну сизде. Бәйге күргән чаптар диярсең. Әйтерсең, янә сабан туйлары килеп җиткән...

## Тамгалы инсан

### I

— Сәгъдиев!

Рәмзил бу кырку, рәсми эндәшкә күнеккән инде. Балачакта таләпчән укытучы, хәрби хезмәт бурычын үтәгәндә — әрсез командир, эштәге тупас башлык шулай үзенә чакырып алды. Тик өннәрдә буталмады, тавыш бирүчене бик тиз төсмерләп алды:

— Әү, Владимир Ильич, әйдәгез, түрдән узыгыз!

Ленинның кием-салымы үткән очрашудагы кебек үк. Тик йөзендә генә үзгәреш, конгырт күзләрендә үчегү, шелтә чаткылары ныграк ялтырый:

— Түргә чакырасың чакыруын... Тик, Сәгъдиев, синең кунакчыллыгыңа

ышанмыйм. Мине хәтта куасың. Әйе, әйе, миңа юл биклисең син. Мулла чакырып өеңне өшкертәсең, нindидер хәтәр оран кычкырттың... Синңа тагын, Сәгъдиев, феодаль язучы Гогольнең исерек чиркәү шәкертеннән үрнәк алырга кирәк булган. Ул бит сихерче хатыннан үзен сызык белән урап араланырга җыена. Синңа да ятагыңны акбур белән тамгалап, мулладан өшкертеп, миннән котылу чарасын күрергә кирәк булгандыр. Ә болай крепостең бернигә яраксыз, төрттең исә ишелә!

— Сез, иптәш Ленин, дивар, кальгалар җимерергә оста инде!

— Мин сиңа таң калам, Сәгъдиев! — Кунак ачуланып ук кычкырды. — Егерме беренче гасыр кешесе үзең, вуз бетерү хакында дипломың да бар. Ә мине нindидер җен-шайтан, явыз өрәк итеп күрәсең. Бәлки синең өчен албастымындыр? Аңламыйм, валлаһи аңламыйм, нәрсә бу — томаналыкмы яисә сәяси наданлыкмы?

— Владимир Ильич, туктагыз әле, аңлатыгыз. Кем соң сез? — диде Рәмзил, сабырлык сакларга тырышып.

— Сорарга оялмыйсың икән, әйтим, мин пролетариат юлбашчысы, юксылларны яклаучы, үлемсез кеше — Ленин. Ягъни коммунистик әхлак сагында торучы Рух!

— Владимир Ильич, ялгыш ишетмимме? Рух! Сез бит үзегезне Алласыз дип, материалист дип, күпме тәкрарладыгыз һәм менә ишетмәсәң — ишет! Большевиклар, белүемчә, тик материаль дөньяны таный. Димәк, сез үзегезне рух дип атасагыз, алар Ленинны инкарь итәчәк. Юк безнең фиркадә андый коллаборационист юлбашчы, диячәкләр... Сез минем янга рух булып киләсез икән, минем дә Ленин итеп танымаска хакым бар сезне. Йә аның белән саташу бу, йә сез берәр алдакчы, сихер белән яшәгән караңгы зат...

— Рух яшәешен томаналар күзаллый алмый, — диде Ленин. — Сиңа, энекәш, матур әдәбиятны күбрәк укырга булган. Һади Такташ минем турыда ничек дөрес әйтте.

Ул үлмәде,
Җир шары өстендә Ленин
Шәүләсе көн-төн йөри;
Уң кулында канлы байрак,
Сул белән
Куркыныч елларны алга өстери.
Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,
Төрмәләр, подвал, заводларга керә,
Йә коточкыч байрагын тоткан килеш
Ул кинәт килеп чыга зур
Парламентлар өстенә!

Бу юлларны Ильич хисләнеп, илһамланып яңгыратты. Аның үз шәүләсеннән үзе бик канәгать икәнлеге күренеп тора.

— Йә ничек, шәпме?

— Шәп! — диде ирексездән Рәмзил... Тик аның соклануы шагыйрь каләменнән бигрәк Ленин хәтеренә юнәлгән иде. Тугызынчыдамы, унынчыдамы Мөслиха апалары ятлатты бит «Гасырлар һәм минутлар» поэмасындагы әлеге юлларны. Тик хәзер исендә өзек-төтек тасвирлар гына торып калган. Рәмзил каршында чынлап та даһи Ленин тора бугай шул...

— Монда Владимир Маяковскийны да искә төшереп үтәргә кирәк. Нәрсә дигән бу шагыйрь? «Ленин — тереләрдән дә тererәк кеше!» Менә шулай, энекәш, яшим мин! Яшим һәм пролетар гаделлек, сыйнфый әхлак сагында торып көрәш алып барам, — диде чакырылмаган кунак тантана белән.

Һәм әлеге сүзләрдән соң ул кисәк Рәмзил каршына килеп басты, җитди, хәтта нindидер бораулы карашын аңа текәде. Иргә авыр булып китте. Еш-еш сулады, нindидер сүзләр әйтергә җыенды, әмма башы таш кебек каткан иде...

— Инде хәзер сиңа килик, эшкуар, — диде Ленин һәм кулларын кесәсенә тыгып йөренергә кереште.

— Тагын миңа нинди гаепләр тагарга җыенасыз, Владимир Ильич! — дип ниһаять телен әйләндереп сорый алды ир.— Люмпен, дип ачуландыгыз, колхозны таратуда гаепләдегез, нахак бәлаләр тагучы кеше итеп тә орыштыгыз мине. Йә, тагын нәрсәдә минем гөнаһ?

— Син властька омтыласың. Хаким булырга телисең.

— Моның нәрсәсе начар соң? — дип ихлас аптырады Рәмзил.

— Без кызыл директорларны, халык комиссарларын, сәвит рәисләрен үзебез дә күтәргән кеше. Тик большевиклар заманында җитәкчелек урынына кемне кую мәсьәләсен халык хәл итте. Менә, әйт әле, синең кандидатураны берәр җыелышта тикшерделәрме?.. Парткомның тәкъдиме бармы? Шунысы да бик мөһим: сиңа нинди характеристика бирелә?.. Уңай сыйфатларың нинди, тискәреләре дә бардыр, беләбез, бәндә хатадан хали түгел. Боларның барысы да халыкка мәгълүм булырга тиеш бит, ә, Сәгъдиев?

Юлбашчы, фикер җебен эләктереп алырга теләгәндәй, кызу-кызу идән буйлап йөренеп алды һәм янә Рәмзил каршына килеп басты:

— Сезнең Сибгат Хәким атлы шагыйрьнең бик гыйбрәтле юллары бар. Зур эшләргә чакырып ил дәшсә, «Күңелем Ленин белән сөйләшә», ди ул.

Казан әле, Казан уянмаган,
Яфрак белән яфрак серләшә.
Йөрим таңда Ленин урамында –
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Шулай дигән бит шагыйрь, дөрес хәтерләдемме, Сәгъдиев?

— Дөрес! — дип җөпләде аны Рәмзил. — Сез безнең милли сүзгә гаҗәп игътибарлы булгансыз, Ильич. Әллә кемнәрне укыгансыз!

— Ихлас сүзне без нинди телдә дә олыладык һәм олылыйбыз. Партия эшендә мөһим винтик ул. Сизәсеңме, юлбашчы белән халык, хезмәт кешеләренең берлеген ифрат дөрес тотып алган безнең фирка шагыйре. Җитди эш, вазифага керешер алдыннан Ленин белән сөйләшергә, хәтта җанны ачып серләшергә үк кирәк шул. Рухың белән әзерме син, нинди ният-планнарың бар һәм иң мөһиме: эшче-крестьян тормышын яхшыртуга нинди анык өлеш кертергә җыенасың син, Сәгъдиев? Хакимнән үрнәк ал!

Югыйсә тота да, урамнан кереп берәү Чардаклы халкына түрә булырга җыена. Юк, мин моңа отыры каршы. Халыктан качып башкарылган эшнең нәтиҗәсен алдан ук әйтә алам мин сиңа... — Ильич бер кулы белән бөеренә таянып, икенчесе белән селтәнә башлады. — Ифрат начар! Педагогик шкала буенча бәяләгәндә — икеле... Коррупция, урлашу, алдашу, икътисад торгынлыгы һәм халык хәерчелеге — менә болар синең власть белән идарә итү җимешләре, Сәгъдиев. Юк, болай гына да түгел, сине үзләренчә биетеп, сигезаяк булып бар каныңны суыргач, синнән югарыдагы хакимнәр җәсадеңне йә урамга тибеп ыргыта, йә төрмәгә илтеп тыга... Аңладыңмы, эшкуар?

— Киңәшегезне ачык әйтмәсәгез дә, тел төбегезне сиздем, юлбашчы. Сез минем идарә эшчәнлегенә тотынуыма каршы. Янәсе, халыктан аерылам, бүре законы белән яшәүче түрәләр, буржуазия мохитенә тыгылып, үземә һәлакәт әзерлим. Шулаймы, юлбашчы?

— Нәкъ шулай, — диде Ленин, йөзенә канәгатьлелек хисе чыгарып. — Бездәге һәр кеше сыйныф психологиясенә тугры калырга тиеш! Шунсыз без таралабыз.

Рәмзил үзен читлек каршына куып китерелгән җәнлек хәлендә тойды. Йә аучы коралыннан өркеп тоткынга әверелә, йә үзе аучыга ташланып, ирекkә ыргыла... Бу киеренке халәтне ул бер кат татыды инде. Эдуард Дашкин рәис постына кандидат булган Сәгъдиевны аучы җитезлеге белән ятьмәгә эләктерде. Ул чакта яшь иде, тәкъдим ителгән рәислек башын ташка бәреп омтылган нәрсәсе түгел иде, аннан ваз кичү бәрабәренә ирекkә ычкынды. Ә хәзерге ятьмә күпкә куркыныч, мәл дә хәтәр. «Аучы»га кискен борылып өстенә ыргымаса, ул, Рәмзил Сәгъдиев, мәңге читлек колы, мәхлук булып калачак. Фиркачеләр өчен ул «ак чәүкә», асылы белән ят, номенклатура кешесе була алмый. Юлбашчының сыйныф психологиясе дигәне коллык психологиясе бит ул... Тап, Рәмзил, мәкерле богаудан котылу юлын ват, җимер өстеңә ыргытылган мәкерле ятьмәне. Рәсәй тормышында торгынлык сазлыгын хасил иткән демократик централизм, вертикаль идарә системасын номенклатура иләге яшәткәнен аңладың бит син. Димәк, бу киртәне дә юлдан алып ташларга кирәк! Чын хөррият үз эчендәге инкыйлаб аркасында гына яулана бит ул, Рәмзил!

— Ильич, сез ник һаман халык та халык дип авыз суын корытасыз соң? Гавам сезнең өчен шешәгә бөке генә түгелмени?! Хаҗәте чыкса, кулда, кирәкмәс булса, куылуда: «Җәмәгать, өчтән артык җыелмагыз, таралыгыз, тарал! Ләчтит сатмагыз, эш эшләргә кирәк!» Һәм сезнең өчен тагын халыкның йөгәнле булуы яхшы. Тезгенне кай тарафка тартсаң, ул шунда барсын! Бер аякка басып, җырлап атласын: «Смело, товарищи в ногу, духом окрепнем в борьбе...» Менә кайда ул юлбашчыны сихәтли торган гавам. Шулаймы? Ә син дулкынланып торган халык диңгезе өстендә ялкынланып телмәр тотасың, мәйданга кырку лозунглар ыргытасың. Тегене долой, моны долой... Яшәсен революцион халык! Массаларның җанына, уй-фикерләренә иблис Мефистофель кебек син хуҗа. Юлбашчыга тагын моннан да зуррак ләззәт бармы, ә, Ильич?

— Син, Сәгъдиев, каян беләсең боларны? — дип үтә гаҗәпләнде Ленин. — Әллә нәселдә большевик бармы?

— Мин, Ильич, сезнең 1918 елда фиркадәшләрегезгә сөйләгән речегез белән дә таныш: «Эшче-крәстиянннарны шундый итеп тәрбияләргә кирәк ки, алар үзләренең дәүләтен дошманнардан саклар өчен һич икеләнүсез башларын салырлык булсыннар!» Монысы да дөресме?

— Ул вакытта бит картага совет властеның язмышы, яшәү-яшәмәве куелган иде. Аны тоташ шәһитлек кенә коткарды. Әйе, ил азатлыгы өчен юксылларны һәлак булырга өндәдек без.

— Алай... Сездән күреп варисларыгыз корбан бирү, шәһитлеккә бару, стахановчылыкка чакыруны, биргәнгә канәгать булырга, ягъни каешларны буарга өндәүне совет властеның бөтен яшәү дәверенә суздылар. Дәүләт дигән Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ һаман авызын ачып, бир дә бир, дип яшәде. Ә сезнең, Ильич, данлыклы фиркагез халыкка үзе нәрсә бирде соң? Аның социаль тормыш хәлен, мәгыйшәтен күтәрерлек ниләр эшләде?

— Ничек, сезнең тирәдә безнең гүзәл социаль программаны белмиләрме? Бу коммунизм — җирдә оҗмах ясау, һәркемне бәхетле итү! — дип сайрар кош кебек канатланды кунак. — Ул безнең иң бөек идеал!

— Әй, Ильич, югарыдан бөек тә бөек, дип туктаусыз колакларга тукыгач, сезне безнең халык чынлап та бөек итеп санады. Тик, зинһар, сез үзегезнең даһилыкны тумаган атка йөгән кидерү белән бәйләмәгез әле!

— Кызыксынырга рөхсәт ит, нинди сәбәп аркасында син миңа шундый гаеп ташлыйсың инде? — «Кунак» күзләрен кыса төшеп янә әңгәмәдәшенә текәлде.

— Ачык түгелмени? Бердән, бу кысыр вәгъдәләр өләшү халык каршында җилкуарлык галәмәте, икенчедән, шәкертләрегезгә бик начар үрнәк. Инглиз язучысы Герберт Уэлс сезне исән чакта ук «Кремль хыялчысы» дип атады. Сезнең фирка дөрестән дә хыял артына ышыкланып замана мәшәкатьләреннән, биргән вәгъдәләреннән качкан саламторханнарны тудырды. Биш-алты елга кәнәфигә утырган һәр түрә дистәләрчә елларга сузылган программа төзеп, хакимлеген сакларга, ил башында торырга күнекте. Һәм халык та туктаусыз вәгъдәләр иллюзиясендә яши... Менә сезнең гүзәл коммунизм программасының, бөек идеалның безнең башка төшкән әче җимешләре кайда, хөрмәтле Ленин?

— Бу сезнең субъектив бәя, Сәгъдиев, йә, шуннан нәрсә?

— Шуннан шул, юлбашчы, сез мине сердәш булырга өндәдегез. Тик мин ахирәтегез булалмыйм. Сез сүздә һаман атмаган таң белән юанасыз, эшкә ашмаслык идеяләр белән яшисез. Вәгъдәләрегез дә һаман киләчәк өчен. Ә тәхетнең үзегезгә патшалык, оҗмах рәхәте бирүен исләп, аны кулдан ычкындырмыйсыз сез... Һәмишә юлбашчы булып каласыгыз килә. Мин шәхсән бүгенге көн белән яшим. Үзем өчен, якын-тирәмдәге кешеләр өчен мөһим булган бурычларны билгеләп, аларны кичекмәстән хәл итү ягында торам...

— Ялгышасың, — дип Рәмзилнең сүзен өзде Ленин. — Ил, халык, җәмгыять каршындагы бурычларны, Сәгъдиев, партия съездлары, юлбашчылар билгели. Ә массалар аларны гамәлгә кертү өчен көрәшә. Мохит әгъзасы, винтик булгач, сезгә дә кагыла бу, хөрмәтлем!

Юк, юлбашчы Рәмзилне үз ятьмәсеннән ычкындырырга теләми. Җепләрне, үрмәкүч сыман, һаман ныграк үрә, гәүдәне тыгызрак урый бара. Ленин бит бу! Инде аяк, куллар тыңламый, сулыш та киселә... Нишләргә, ничек ычкынырга соң бу ятьмәдән?

Рәмзил күзләре белән текәлеп, кымшанмыйча каршында басып торган «төнге кунакка» карап бар куәтенә кычкырды:

— Китегез моннан, югалыгыз!

Хатыны Мәрзиянең, иңнәреннән тотып селкә-селкә, куркып эндәшүеннән Сәгъдиев уянып китте:

— Рәмзил... Рәмзил, ник кычкырасың, кемне куасың?

— Каһәр суккан, «кунак» тагын килде... Янә бастырылдым бит. Ничек котылырга? — дип тәшвишләнеп уйланды ир.

## II

Иртән торгач, Рәмзилнең төнге кунак хакында кичерешләргә чумарга вакыты булмады. Бүген конкурс комиссиясенә документлар тапшыруның соңгы көне. Анкета сорауларына җавапларны Зәнфирәдән бастырып алырга һәм бар кәгазьләрне барлап хакимияткә илтергә кирәк иде. Ашык-пошык кына капкалады да, машинасын кабызып, Сергеевкага юнәлде. Ильич юкка борчыла, урамнан кергән һәр кеше район хакимиятенә башлык була алмый. Анкета аерым-аерым җаваплар тезмәсе кебек булып күренсә дә, асылда ул район башлыгына дәгъва иткән кешедән киң күләмле социаль үсеш программасы таләп итә икән. Идея бирү бер хәл. Аны экономик яктан нигезләргә дә кирәк бит әле. Гамәлгә ашыру юлларын күрсәтергә Рәмзилнең исәп-хисап белән мавыгып тулы бер көне үтте. Бигрәк тә райүзәкнең социаль-экономик үсешенә бәйле сораулар конкрет чаралар күрүне көтә икән. Чардаклыда, һичшиксез, ташландык хәлгә килгән элеваторны тергезеп худка җибәрергә кирәк. Шулай ук сөт заводын реконструкцияләү беренче бурыч. Колбаса җитештерү турында да кичекмәстән эш башлау мөһим. Югыйсә, үзләре казылык, тутырма сыман тәм-том ясап сату урынына, каладан сыйфатсыз ризык ташыйлар. Тире, мех эшкәртү цехы да булсын Чардаклыда. Боларның барысын

сафка бастыру өчен дәүләттән кредит алырга булыр. Рәмзил якынча исәпләп, әлеге предприятиеләрнең күпме файда китерәсен һәм бурычларны кайтаруга күпме вакыт китәсен дә чамалап куйды. Комиссия кызыксына икән, экономист буларак ул Чардаклының үсеш программасын шартлатып дәлилләп бирәчәк.

Авыллар икътисадын, үстерү мөмкинлеген ул аеруча яхшы күзаллый. Терлекчелек, игенчелек өлкәсендә үзе күптән уйлап куйган чараларны да ныклы исәп-хисап белән нигезләп программасына кертте. Дөрес, авылда мәдәниятне күтәрүгә карата планнары сыеграк. Әмма күренеп тора, кеше яшәгән җирдә яхшы клуб, бай китапханә, җиһазланган спорт залы булырга тиеш. Боларның да кәгазьдә генә калмаслыгына ышана булачак хаким. Планнары хуплана икән, Сәгъдиев команда төзеп, кем әйтмешли, җиң сызганып эшкә керешергә әзер.

Чардаклыга документларын тапшырырга килгәч, көндәшләре кемнәр, конкурс комиссиясе нинди абзый, әфәнделәрдән тора — олы вазифага дәгъвачы болар белән юри генә дә кызыксынмады, язмышын үзе төзегән программага тапшырып эшенә кайтып китте.

— Булды, бирдем, хәзер инде көтәргә генә калды, җаным, — диде ул Мәрзиягә. Тегесе исә ире куптарган мәрәкәгә тырнак очы кадәр дә өмет багламады.

— Көт, көт син, Юлий Цезарь! Утыртасы кешеләре әллә кайчан билгеледер әле. Йөрисең кеше көлдереп... Теге вакытта да, нихәл, председатель, дип күзеңне ачырмадылар. Әй, сабак алмаса да алмас икән кеше...

Өйдә Рәмзил янә Ленин турында саташулы уйларына әйләнеп кайтуын сизми дә калды. Телевизордан яңалыкларны күзәтә иде, Владимир Мединский атлы Дума депутатына ияреп, бертөркем сәясәтче, эшкуар һәм студентлар Ленин мавзолее янәшәсендә пикет оештырганнар икән. Кулларында плакатлар: «Владимир Ульяновны җир куенына тапшырырга вакыт!..» «Ленин — явыз рух...» «Рәсәйдәге бәлаләрдә Мавзолей өрәге гаепле».

Үзәк гәзитләрдә әледән-әле мәкаләләр басылып, Октябрь инкыйлабы юлбашчысын әнисе Мария Александровна янына кайтарып җирләргә диган тәкъдимнәр элек тә ясала иде. Әмма Рәсәй коммунистлар фиркасе башлыклары монда үзләренә һөҗүм, кимсетү тоеп, юлбашчыны төрбәдән чыгаруга кырку каршы төштеләр. Инде менә Ленин күптән мәет булса да, фиркаләр сугышын китереп чыгара. Әйтергә кирәк, мылтыксыз, кылычсыз сугыш.

Баксаң, Рәмзил дә юлбашчы белән яу корып ята түгелме соң? Әле менә түзмәде, аңа ярсып, «Китегез! Югалыгыз!» дип кычкырды, өеннән куды. Тик менә өенә аптырый. Чын Ленин белән төшкә кереп аптыраткан юлбашчы арасында нинди уртаклык бар? «Сәгъдиев!» дип ничәнче кат килә бит. Һаман да ирдән гаепләр таба, алдагы гамәлне юрап куркыта, искәртә. Әллә кайчангы заман кешесе булса да, Рәмзилне үз артыннан иярергә ниятли. Нинди баш җитмәслек хәл соң бу? Нәрсә кирәк булган Ленинга Дөм-дөмдәге Сәгъдиевтан?

Әлеге мистик күренешне аңлар өчен, аңа берәр укымышлы зат белән сөйләшеп карарга иде. Ләкин кем бу һәм кайдан табасың аны? Хәлбуки, Рәмзил күңеленнән бу мәрәкәнең үзе өчен әһәмиятле икәнен тоя. Зур эшкә дәшеп алсалар, алдагысы ачык булырга тиеш. «Кунак»ның юрау, куркытулары чынлап та урынлы икән, көрәшкә әзер торсын, йодрыгын төйнәп куйсын ул. Рәмзил өчен рух беренче бит, аннары гына эш-гамәл...

Башта ул хезмәттәше Абрамның үзе белән булган хәлләргә карата мөнәсәбәтен белергә кирәк тапты. Яһүд ике көн элек утарга кайтты. Гаиләсендә кунак булып тазарган бу, шәпләнгән. Күренеп тора, җегәр дә туплаган. Мөгаен, Чардаклы киңлекләрендә тагын нинди эшләр майтарырга дип план да төзегәндер. Ә хәзер, кар баскан февраль мизгелендә, ул бик бирелеп терлек-туарны карады, эшләүчеләр белән озаклап сөйләште.

Штельман Чардаклыдагы яңгыравыклы киңәшмә хакында ишеткән икән. «Безне искә алучы булдымы анда?» — дип искәрмәстән Рәмзилгә дә сүз катты.

— Касаткин доклад кебек нәрсә сөйли башлагач, иң элек «Таң» фермасын телгә алды, Абрам Шаламович. Терлекчелектән зур керем алдылар, диде. Кыскасы, тагын берничә җөмлә әйтеп, сезләрне мактады башлык.

— Шулай булырга тиеш ул. Без синең белән, брат, эшләп күрсәтербез әле! — диде яһүд, мыек-сакаллы йөзен балкытып.

Сәгъдиев та эчтән сөенеп куйды. Югыйсә, хакимияткә документлар тапшыру хакында ишетмәдеме икән, дип шөбһәләнеп тә торган иде.

Штельман тагын бозаулар каралтысында, атлар абзарында булып, малларның көрлеге, ашата торган азыклары белән кызыксынгач, икәүләшеп кантурдагы аулак бүлмәгә кереп утырдылар.

— Ярар, иптәшкәем, миңа мәшәкать калдырмагансың, хатын янында тагын торсам да булган икән әле, — диде ул, Рәмзилнең җилкәсеннән кагып. — Йә, сөйләп җибәр, өйдә ничек, әниең, бала-чагалар, хәләл җефет ни хәлдә?

— Рәхмәт, Абрам Шаламович. Тик үзем белән бик кызык хәлләр туып тора әле. Төнлә янга Ленин килә башлады, кәмит инде бер...

— Ленин?! — Абрам шаккатты. — Ничек? Прямы өеңә киләме?

Һәм Рәмзил ярым җитди, ярым көлке итеп элекке идарә бинасында яши башлагач күргән матавыкларны сөйләп бирде. Үз өендәге хәлләрне кешегә беренче кат чыгара. Яһүд шаркылдап көләр яисә, тапкансың борчылыр нәрсә, дип кул селтәр сыман тоелган иде. Юк, хәлне җитди кабул итә Абрам:

— Партком диварларыннан үтеп, сине тиктомалдан эзәрлекләми инде бабай. Йә сине бик ярата, йә дошман син аңа. Әмма аңламыйм, Путин, Медведев та түгелсең, Зюганов партиясендә дә тормыйсың, нәрсәң белән тарттың син аны, фермер?

— Өй каршында Ленин һәйкәле тора...

Абрам кисәк шаркылдап көлеп җибәрде:

— Бәлки бабай шуннан сикереп сиңа килеп керә торгандыр. Ну, туган, сенсация! Үзәктәге журналистлар белеп алса, матбугат шаулар. Ленинны мавзолейдан чыгарту өчен Мединскийга янә бер факт бит бу. Янәсе, Ленин өрәге фермерга яшәргә худ бирми!

Тынычлангач, алар дөньядагы хикмәтле күренешләр, төрле башка сыймас хәлләр турында байтак сөйләшеп тордылар.

— Күзгә күренмәс нәрсәләрне шәйли, аңлый торган Нострадамус, Ванга кебек затлар бар инде ул, — диде Абрам. — Безнең яһүдтән дә Вольф Мессинг исемле бик шөһрәтле күрәзәче чыккан. Гитлерның үлемен өч-дүрт ел алдан юраган бу. Сугышка кадәр Сталин аны үзенә шәхси багучы ясап тоткан, байтак мәгълүмат алган, диләр... Мессинг исән-сау булса, янына барыр идек тә бит, булмый шул. Хәер, экстрасенсларга кытлык юк хәзер, эзләргә кирәк, Рәмзил дус...

Сәгъдиев, билгеле, Кашпировский, Алан Чумак кебек зәңгәр экраннарда ара-тирә күзгә чалынып киткән мәшһүр экстрасенсларны эзләп ерак юлга кузгала алмый иде. Ул бу серле эшне авылдашы Хашия карчыктан башларга булды. Шөкер, сиксәненче еллар азагында ук Дөм-дөм үзәгенә бастырылган таш Ленинның таңга күрсәтү өндәвеннән кысурлык тапкан багучы исән әле. Авыл кырыендагы агач ызбада малае, килене белән яшәп ята. Карап торуга гап-гади әби, чәчләре чал, бите, кулы җыерчыклы, мәгәр күзләре карчыганыкына охшаш. Текәлсә, әллә ничек хәл китеп куя...

Хашия карчык Рәмзилнең чәй, кәнфит һәм башка тәм-том белән тулган төргәкне өстәлгә куюын күзәтте, гозерен тыңлады да кырт кисте:

— Юк, улкаем, Ленинга минем кодрәт җитми. Монда йолдызлар белән эш итүче кирәк. Син Үзи карчыкка бар! Аксубай төбәгеннән табарсың аны. Үлмәгәндер әле кортка. Үлсә дә, җен-шайтан, иблис-гыйфритне авызлыклаучылар монда бихисап. Сихерчеләр, албастылар, әллә нинди урман ияләре турында да иң кызыклы китапларны шул яклардан яздылар. Сәхибе Нәбирә Гыйматдинова бугай. Аны да күрерсең, бар, улым, шунда юнәл син!

Башына килгәнне, бер ниятләгәнне эшли инде Рәмзил. Абрам белән сөйләште, гаиләсе белән саубуллашты да юлга чыкты. Бәхеткә, көн аяз, юллар ипле. Ялгызы калып, эч пошуга юл куймады ул. Кул күтәргәнен утыртты, хак-фәлән сузсалар да алмады. Гел сорашты: «Сездә икътисад ничек, мәгыйшәттә яңалык бармы, кардәш?» Шулай Чаллы далаларын үтте, Чулман кичте, Әлмәт, Чирмешән урманнарын узды. Һәм утырткан юлдашларын тыңлый торгач, аңлады. Мондагы халык байтакка көйле һәм ипле яши башлаган икән. Кырларны кысыр калдырудан туктаганнар, фермерлар көч алган, крәстиән табыш түмен тоеп, җиңне терсәккә кадәр үк сызганып эшләргә керешкән. «Аллага шөкер, безне хөкүмәт зерә дә кайгырта хәзер, — диде Кәлимәттә утырып Кәминкәсендә төшеп калган сүзчән бер мишәр карты. — Хәлләр хөртләнсә, бушка фураж да өләшәләр, чәчәргә орлык та бирәләр. Бездә халыкның эшкә күңеле үсеп китте, олан».

Бик яхшы, дип канәгатьләнеп уйлап куйды Рәмзил, халык бер тарафта күтәрелсә, икенче җирләргә дә уңай үрнәк ясый. Хәятне ил белән яхшыртырга вакыт инде...

### III

Карурман төпкеленә урнашкан Үзи авылына юлчы караңгы төшеп, йолдызлар кабынгач килеп керде. Төнлә кемне борчыйсың? Кайнар чәе белән итле салкын кабартмасын ашап алды да, машинасында урын җайлап йокларга җыенды. Салкынайтса, моторын кабызып чатырын җылытыр...

Карчык өендә утлар балкый иде әле. Көтмәгәндә капкадан яшүсмер чыкты һәм Рәмзилнең тәрәзәсенә чиертте:

— Абый, ник һаман кермисез, әби көтә!

«Килгәнемне белгәнме?!» Иркен, нурлы, җылы ызбага гаҗәпсенеп килеп кергәч, фәрештә кебек ак киенгән әби каршылады. Чәче дә ак, йөзе дә сурәттәге сыман илһамлы һәм ап-ак аның. Тик күзләре генә зәңгәр... Бу күктән, йолдыздан иңгәндер... Мондый алиһә затка яшь, гомер дигән нәрсәләр дә кагыла алмыйдыр, дип уйлап, Рәмзил югалып калды. Үзен эчтән дә, тыштан да килешсез, тупас итеп тойды. Җитмәсә, әбинең чиста келәменә шыксыз итеге белән кереп баскан бит. «Гафу итегез!» дип тиз ара аны салып бусага төбенә куйды.

— Ерактан килдеңме, улым?

— Ык буеннан, әби.

— Хашия кортка ни хәлдә әле анда?

— Әйбәт, сиңа сәлам күндерде!

— Рәхмәт, кайткач, минем сәламемне дә ирештер үзенә... Ул миңа «Үзи карчык» дигәндер, ә син миңа Акъәби дип дәшәрсең, улыкаем... Чөнки өнәгәнем аклык, пакьлек минем. Каргыш эшләү, бозым кую көтмә миннән...

Багучы сөйләнә-сөйләнә кунакны түгәрәк өстәле артына утыртты, ара-тирә аңа җитди итеп, хәтта ничектер сынап караш ташлап алгалады:

— Йә, мосафир, гозерең нинди?

Рәмзил карчык каршында алдан сайлап куйган сүзләрен тезде. Әмма багучының исе дә китмәде:

— Ленин тырнагына эләккәннәр син генә түгел. Котылу эзләп килүчеләр дә

байтак. Ленинның кем икәнен беләбез. Менә син үзең кем, углан? Адәм низаг сәбәбен кешедән генә эзләмәсен, үзенә дә карасын ул...

Багучы каяндыр кулына алтынмы, бакырмы — билгесез, мәгәр шомарып беткән тәңкә алды, аны Рәмзилнең сул кул чугына китереп йөртә башлады һәм карашын күзләренә текәде. Ир куырылып куйды, бөтен барлыгы белән урыныннан купканын, зәңгәрлеккә йотылганын тойды. Галәмдә әллә йөзә, әллә тик асылынып тора. Тән авырлыгы да юк. Баш кайгысы да... Рәхәт! Рәмзил зәңгәр бушлыкта байтак онытылып торды. Ниһаять, кул чугыннан шома тәңкә алынды, күзләр кабак астына яшеренде... Ир янә өстәл артындагы урындыкка салышкан бәдәнен тойды. Башына «Наркоз кайта...» дигән уй йөгерде. Хет ярый, тәнендә операция артындагы сымак сызлау әсәре сизелми...

Акъәби күзләрен ачты.

— Улым, син үзең дә тамгалы инсан бит! Хәяткә мәгънә белән туа торганнарның берсе. Талигың якты синең. Гадәттә, синең асылдагы кеше үзен яуда, гарасатлы чакларда калкыта. Син Марс йогынтысы астында тугансың. Көчле, тәвәккәл, кыю, омтылышлы... Ә тынычта сиңа юл яру кыен. Күрәм, бик еш затсыз, әдәпсез адәмнәр каршында югалып каласың. Вөждан хөкеменә баш бирәсең. Йә, хәтерлә әле, бала чагында, балигъ булгач, үзеңнең юлыңа каршы төшкәннәргә көрәш ачтыңмы? Эшендә хезмәттәшләрең белән бәрелешеп, дан, дәрәҗә артыннан куасыңмы? Юк, болар синең асылга хас түгел. Һәм менә шул болгавыр мәгыйшәттә синең токым үзен җуя, сына, ямьсез гадәтләргә дә бирелә. Гарьчел, үпкәчел кешегә әверелә әлеге токым. Синең гомердә дә шул төшенкелек дәвере булып узган. Тик син югалмагансың, җуелмагансың, үз асылыңны саклагансың. Аллаһка сыену саклап калган сине, улым. Янәшәңдә иманлы кеше бар. Кем икәнен беләсеңдер?

Иншалла, алда сине зур, колачлы эшләр көтә. Сине танып алачаклар, күтәрәчәкләр. Тирәңә эшлекле кешеләр җыела синең. Яклау да, ярдәм дә өмет итүчеләр күп булачак. Аларның өметен аклау сиңа янә югарырак үрләр яуларга булышлык итәр.

Әйткәнемчә, син тамгалы инсан. Яшәү мәгънәң дә ачыкланган — эш узаманы булу... Әмма тамгалылардан синең үзеңә дә саклану кирәк. Чөнки аларда көнчеллек, хөсетлек галәмәте көчле. Күтәрелгәч, аяк чалучылар, үзләренә баш идерергә теләүчеләр артачак. Яшәү мәгънәңне, асылыңны саклыйм дисәң, сиңа һәмишә ныклап көрәшергә туры киләчәк, улым.

Акъәби тынып калды.

Рәмзил үз йолдызлыгыннан иңгән фаразга артык гаҗәпләнмәде. Багучы аның маңгаена язылганны укыды сыман. Барысы дөрес. Абрам әйтмешли, шулай булырга тиеш! Ул бит абруйлы күрәзәче каршында утыра. Тик әбекәй Ленин турында ник һаман бер сүз дә әйтми? Рәмзил бит төнге зәхмәтләрдән котылу әмәлен табарга дип килде...

— Инде, улым, Ленинга килик, — диде Акъәби, аның уйларын укыган сыман. — Владимир Ульянов та җиргә мәгънә белән килгән тамгалы инсан, әмма ул үзе төзегән фирка денсез шәкертләр гаебе белән авыр язмышка дучар ителде. Үлгәч, мәрхүм җирләнмәде, тәне һаман сыкрап Мәскәүдә, төрбәдә ята аның. Бәдән җирдә торгач, җан да аны ташлап үз юлыннан китә алмый. Безгә янәш дөнья кануны шундый. Димәк, Җиһан, күк капкасы бикле аның өчен. Менә бер гасырга якын Ленин җаны тынычлык тапмыйча һаман безнең хәяттә бәргәләнә. Тик җан үлә, юкка чыга алмый. Аңа монда яшәү әмәлен табарга кирәк. Ленин шул нигездә рух булып калка, элекке кыяфәтләре белән хәзерге кешеләр җанына сыенырга омтыла... Инде синең хәл аңлашыла бугай, улым, Ленин төннәрен синең янга шулай еш кунаклаган икән, димәк, теләге синең җанга үрмәләү

аның... Сизәсендер, сәбәбе ачык, әйттем, син үзең дә тамгалы инсан. Уртак нәрсәләр байтак. Сине яулау аның үзе өчен дә мәртәбәдер. Владимир Ильич көрәш кешесе бит! Күрәм, синең аның белән чәкәләшү көчле...

Инде ничек котылырга сиңа Ленинннан? Менә бу инде чын мәсьәлә... Йокы бүлмәңә, өеңә шәмаилләр эләргә була. Ишек, тәрәзәләр өстенә кашага сыман итеп... Төннәрен үз яныңа мәче ияләштерү дә файда бирер. Өрәк, рух бу җан иясеннән ифрат шүрли... Этәчтән дә куркалар. Тик күреп торам, сиңа бу эшләр ошап бетми. Янәш дөньябызны сафландыруның иң анык юлы Ленин бәдәнен җиргә тапшыру, гыйсъянчыл җанны гарешкә озату да бит, беләсең, улым, бу фарыз эшне гамәлгә ашыру зур сәясәт белән бәйле. Синең белән мин генә хәл итәлмибез. Әмма бик омтылсагыз, үз тирәгездән озата аласыз чакырылмаган кунакны.

— Ничек, әбекәй? — Рәмзил авыз ачып сораганын сизми дә калды.

— Ничекме? — Акъәби бераз елмаеп, сорауны хуплавын белдерде. — Узаман буласың килсә, бу хакта ныклап уйланырга шул. Яшәүне кәеф-сафа кору, байлык туплау чарасы итеп кенә санамаска, игелекле гамьне арттыра төшәргә кирәк. Үзеңә канун яса: тирә-юньдә рәнҗетелгән, кыерсытылган кешеләр калмасын. Бер-берегезгә ярдәм итү, рәхим-шәфкать күрсәтү фарыз гамәлгә әверелсен. Бел, кешеләр мәгыйшәткә карата аһ-зарларын онытса, юлбашчыга да үз тирәгездә канатланып йөрер сәбәпләр җуела. Чөнки Ленин юксыллар җанында тамырланган рух бит. Аны фәкыйрьләр рәнҗеше яшәтә. Житеш, имин тормышлы кешенең гыйсъян юлбашчыга нинди хаҗәте төшсен? Канга батышып инкыйлаб ясауны, хәятне тар-мар китерүне нишләп өнәсен үз тамагын үзе туйдырырга күнеккән кеше. Ә тормышны көйләүнең тыныч юллары бик күп бит. Нигә балтага ябышырга? Менә шулай, улым, гыйсъян җаннан арынуның иң ышанычлы юлы мәгыйшәтегезне бергәләп яхшырту, үз хәятегезгә үзегез хуҗа булу!

— Гап-гади, әмма чынлап та иң ышанычлы юл бит бу, әбекәй! — дип балаларча сөенде ак күрәзәче каршында утырган олпат ир.

— Яшәүнең нигезе гадилектә. Борынгыдан расланган хакыйкатьләрдә. Кешеләр аны катлауландырып тик үзләренә бәла ясыйлар... Ярар, улым, мин күргәнемне сиңа җиткердем. Зирәк инсансың, җанга вакыт көнгә-төнгә бүленми. Шулай ук әкият белән чынлык арасына дивар куелмаган. Өне дә, төне дә бер үк җанга. Инсан һәмишә камилләшү, сафлану юлында булырга тиеш. Уңышлар, казанышлар юлдаш булсын үзеңә!

Хуҗалар җәйгән ястыкта йоклап, иртән коймаклы-каймаклы чәйләр эчеп һәм Акъәби белән янә дә дөнья хәлләре турында сөйләшеп, Рәмзил Үзидән бик канәгать булып китте. Үзендә җиңеллек, иркенлек тойды, киләчәгенә карата ышаныч артты. Югыйсә, төштәге Ленин алдагысына һич өметләндермәде бит. Нәрсә ди әле? «Башлык булсаң бул, имеш. Аннары буржуйлар каныңны эчәрләр дә урамга чыгарып ыргытырлар». Гел куркытты да өркетте. Аны тыңласаң, чынлап та бу тормышка тәмам ят-чит адәм булырсың. Сәясәтчеләр әйтмешли, читән артына, оппозициягә басарга гына кала. «Совет заманында халык эшли иде, заводлар, фабрикалар гөрләде. Без фәлән хәтле самолёт ясадык, трактор-комбайн чыгардык. Кырларда хәзерге демократлар кебек билчән, алабута үстермәдек, әллә ничә миллион центнер ашлык җыеп алдык...

Безнең Рәсәй коммунистлар партиясе, даһи Ленин нигез салган социализмны тергезү өчен көрәшә. Завод-фабрика — эшчеләргә, җир — крестьяннарга! Безнең лозунг: табигать байлыкларын гадел итеп халыкка кайтарырга! Яшәсен компартия! Яшәсен хезмәт халкы! Алга, иптәшләр!»

Инде тәмам искереп, саруны кайнаткан шул телмәрне тыңлап, Рәмзил Сәгъдиевка да рухи читлектә яшәп ятарга туры килер иде. Аллага шөкер, арыначак ул төнге кунактан. Инде Чардаклы җирен дә рухи сафландыру,

чистарту әмәлләрен күрергә кирәк булыр. Хакимият башлыгы булып сайланмаса да, моның өчен башкача юллар табар Рәмзил. Районда күтәрелеп килүче фермер бит әле ул. Тик өметне өзмәскә, югалып калмаска гына кирәк. Рәхмәт, Акъәби, Ак рух! Син ир-егеткә көрәшер өчен дөлдөл ат, зөлфикар кылыч бирдең...

## Кәмит утыргычында

### I

Хуҗалык эшләре белән тоткарланып эңгер-меңгергә калса, Рәмзилнең сыер фермасына сугыла торган гадәте бар:

— Әй, Дөм-дөм карлыгачы, эшләрең түгәрәкләнәме, әйдә кайтабыз!

Бу вакытта Дания сыерларын сауган, Иван дәдә һәм Матрёна түти белән малларны төнгелеккә калдыру хәстәрен күреп йөри.

— Ай рәхмәт, авылдаш!

Һәм ул берничә минуттан инде машина эченә кереп кунаклый. Тегесен-монысын сөйләп ала һәм Рәмзилнең матур итеп уйнатылган милли көйләренә колак салып, уйга чума. Кеше белән аралашканда еш елмая торган көрән күзләргә хәзер сагыш элпәсе куна кебек...

Рәмзил фермер булып килгәч, үзе тәвәккәлләп Свердловск өлкәсеннән ун баш нәселле сыер сатып алды. Бестужев токымлы, елкылдап торган йонлы, төз һәм шома бәдәнле сөйкемле сөтлебикәләр болар. Яхшы ашыйлар, тазалыклары шәп, сөтләре ифрат куе. Рәмзил фермерга савучы табарга кирәк иде. Әмма Сергеевка марҗалары бу авыр эшкә бик атлыгып тормыйлар, тегесенә ялынды, монысына гозерләде, акчаны да мулдан вәгъдә итте. Тик юк эшкә алынучы, хет чиләк тотып үзең сау. Нәкъ шул чакта Дөм-дөмнән Дания килеп чыкты:

— Рәмзил, авылдаш, сиңа доярка кирәк икән... Эшкә мине алчы, бик авыр вакытым, хәлгә кер! Аннары берәр җае чыккач сөйләрмен әле күргәннәремне. Үзе бер гыйбрәтле кыйсса ул.

Алмыймы соң! Бишкуллап эшкә алдылар Данияне. Сыерлар тәрбияләү эшендә осталыгы зур, сөт савып медальләр алган кеше. Хатын-кыз буларак үз-үзен тотышы да күркәм.

Тик бераз пошаманга төшергән нәрсә генә бар — йөреп эшләргә бит. Яз, көз сазга батып атларга калса, ничек түзәр Дания?

— Кайгырма, Рәмзил, өйдә зарыгып көтүче сабыйлар миннән әле тумаган. Абый-җиңги өчен Дания әллә бар, әллә юк. Аллага шөкер, берьялгызым, кайда да җай табармын. Иң дөресе, эшләп китим әле, аннары күз күрер.

Шул көннән башлап «Ленин юлы» колхозының мактаулы сыер савучысы «Таң» фермасының ачык йөзле, уңган эшчесе булып китте. Мәрзия генә иргә берчак вакчылланып сөйләнде:

— Синең ул Даниянне Себердән, иреннән качып кайткан хатын дип гайбәтенә төшәләр икән... Мәтри, тол дип тирәсендә мәче сыман күзеңне бик уйнатып йөрмә!

Әмма кеше хакында җиңел уйларга ярыймы соң?

Авыл, авыл, дибез... Кичекмәстән хәлен ныгытырга, үстерергә чакыручылар күп. Икмәк давай, сөт-ит давай, дип хөкүмәт бабай да һәркөн аваз сала. Мәдәният халкы өчен дә сала кирәк. Янәсе, милләт киләчәге аның кулында... Ләкин авыл иң тәүдә аның кешеләре белән бәйле бит. Димәк, бөтен җитдилеге белән крәстиән хакында анык кайгыртыр чак җиткән. Мәрзия әйткәнчә, кешегә тибеп үтәргә ярыймы соң? Хәлен ачыкларга кирәк, ник каргышлы язмыш төшкән аңа?

Ә бит ата-бабадан ук беләбез. Гаҗәп катлаулы нәрсә бу язмыш дигәнең. Мөгаен, магнит угы кебек сизгер очлыгы бардыр аның. Аз гына уңга кылтайса,

бар эшләрең көйле бара, фортуна дигән нәрсәкәй үзе үк кочагыңа атыла синең. Кулларыңны колачлырак итеп җәй дә эләккәнен ычкындырмау җаен гына кара! Инде язмыш очлыгы сулга авыша икән, өметеңне өз, күпме тырышма, бар нәрсәң кире тәгәрәячәк. Мондый чакта тәвә кошы сыман башыңны комга тык та көтеп ят, бәлки очлык уңга кылтаер...

Бер хезмәт урынында эшләп, якыннан аралаша башлагач, Рәмзил ачык тойды: тормышының иң хәлиткеч мәлләрендә Даниянең язмыш очлыгы гел кире якка авышып торган.

Ул бала чагында Дөм-дөмдәге тиндәшләреннән берни белән дә аерылып тормады. Алар кебек үк инеш буендагы йомшак каз үләнендә аунап бәпкәләр саклады. Җәй чилләсендә кояшка арка куеп бәрәңге, чөгендер утады. Көзен исә олылар янәшәсендә кинәнә-кинәнә бакча, кыр, урман җимешләре җыйды. Хәл алырга утыргач, ул да яшьтәшләре сыман ач тамакка йөгергән кара ипи тәмен тойды. Салкын чишмә суларыннан ләззәт тапты. Иртән торгач, якты кояшка сөенеп бакты ул. Болын сукмагына төшсә, җырлый-җырлый чәчәкләр җыйды, утырып алардан такыялар үрде. Шуларны башына кигәч, үзен гүзәллек алиһәсе итеп тоеп сөенде.

Табигатьтә үз кеше булса да, мәктәпкә бик ияләшеп китәлмәде Дания. Мәгәр хәрефләрне, саннарны яратты, аларны такыя үргән сыман матур итеп тезүдән сөенеч тапты. Китаптагы җөмләләрне кычкырып, мәгънәләрен тоеп укуның үзендә дә белем алу дигән гамәлгә дәрт уятуын тойды кызчык. Әмма мәктәп, белем учагы булып саналса да, харап четерекле дөнья икән...

Бигрәк тә Дания күңелендә сабак ятлату урыны булып калды ул. Озын буйлы, әче тавышлы химия укытучысы Рузия Камилевна формулалар ятлатты. Якыннан һәрчак тәмәке исе аңкыткан базык Баскак Харисович даталар, исемнәр сорап тинтерәтте. Хәтерең тишек икән, хет укуыңны ташла! Ә рус теленнән ятларга да ятларга инде. Тик тере сүзләр, гыйбарәләр түгел. Исем нәрсә ул? Сан нәрсә ул? Фигыль нәрсә ул? Җөмлә нәрсә? Син укытучы Лилия Рәүфовнага бер фигыль әйтеп күрсәтмәсәң күрсәтмә, әмма дәреслектә фигыль хакында кара хәрефләр белән язылган абзацны ятла! Бастырып сораса да, такта янына дәшеп чыгарса да, кагыйдәне шартлатып әйт!

Әдәбият дәресләренә йөри башлагач, Дания әдәби әсәрләрдәге гыйбрәтле һәм мавыктыргыч вакыйгалар, соклангыч яисә күңел кайтаргыч герой, персонажлар белән танышыр, сөю, мәхәббәт тойгылары, әхлак турында кызыклы сабаклар бирелер дип өметләнгән иде. Ул кечкенәдән үк әкиятләр, хикәяләр укырга бик яратты. Мәктәп китапханәсендә эшләүче Наилә апасы кызның бик еш китап алмаштыруына аптырап берчак сорап та куйды: «Син соң укыйсыңмы, Дания, әллә рәсемнәрен генә карыйсыңмы?» Китапханәче үз шиген үзе сынады. Укучылар белән конференция үткәргәндә, әлеге «китап кимерүчегә» доклад ясарга кушты. Яшькә, гәүдәгә әле бәләкәй генә, әмма ничек матур һәм фәһемле итеп әсәр хакында сөйли, уйлый белә икән ул... Тик, кызганыч, Наилә эшкә читтән килгән иде, кияүгә чыгып, Дөм-дөмнән китеп тә барды.

Дания әдәбият укытучысы Зөлфия Хановнаны да Наилә апасы сыман үзе өчен якын кеше, сердәш итеп күрергә теләгән иде. Әмма, чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, ирләр сыман таза, нык, Дөм-дөмдәгеләр әйтмешли, томат гәүдәле укытучы хисси сүзгә бик саран булды. Дәресләрдә күбрәк ятлаган шигырьләрне сөйләтте. Күрәмсең, бу аның яраткан шөгыле: «Гарифуллин, син үткәндә Муса Җәлилнең «Алман илендә» шигырен белмәгән идең. Чык тактага, сөйлә». Колгадай укучы әлке-сөлке сөйрәлеп такта каршына чыгып баса: «Муса Җәлил. «Алман илендә»... Синме соң бу — бөек Маркс иле...» Менә шуннан Заһит инде төртелеп кала. Шигырьнең хәтерендә калган юлларын яңгыратканчы хәтсез вакыт үтә. Булдыксыз Заһит үзе, чынлап та, дошман кулындагы кол, тоткын

яисә әбисенең кыйнап елатылган иркә оныгы кебек булып кала. Тик Зөлфия Хановна өчен Заһит әллә бар, әллә юк... Журнал тутыра яисә дәфтәр тикшерә ул: «Йә, йә, шуннан нәрсә, Гарифуллин?»

Шулай дипме сине беләидем...

Бетховен белән шашынган чагымда...

Уф, мондый дәрестә утырганчы, саф һавада тырай тибүең яхшырак, дип уйлап куя Дания. Гёте диясе урында укучы Бетховен дип ыңгыраша бит... Тагын нинди хикмәтләр чыгарыр?

Шигырь ятлау бурычын үтәүдән тыш, Зөлфия Хановна дәресләрдә үтелә торган һәр язучының тормыш һәм иҗат юлы буенча зур карта төзетә. Кайда туган, нинди авыл, калаларда булган? Һәм кайчан үлгән? Барлыгы ул күпме әсәр язган? «Йәле, Шәйдуллина, синең картада ничә пункт?» Боларны да укучылар үзләренең биш бармагы шикелле итеп белергә тиеш булдылар. Татар әдәбиятын да башка предметлар кебек үк фән итеп күрсәтергә теләдеме икәнни соң мөгаллимә? Тик Дөм-дөмдәге балаларга нигә икән мондый гыйльми фәһем? Иң мөһиме әсәрләрне өйрәнү, зәвык тәрбияләү һәм кызыктырып әдәби китаплар укыту түгелме соң?

### II

Житмәсә, күрәчәккә каршы дигәндәй, Зөлфия Хановна Данияләрнең күршесе иде. Моның бакчасы да, әллә ничә сутыйга җәелеп-сузылып, кызның тәрәзә төбенә үк килеп терәлә. Менә Зөлфия Хановна өмә җыеп бәрәңге утырта, менә чәчәккә күмелә башлаган түтәлләрне өяргә чыга. Тик кешеләрчә кәтмән тотып эшләми бу, каяндыр җиңелчә сука табып алган. Ире Хәнәфине мичәүгә җигә дә үзе сукачы булып китә Зөлфия апаң:

— Әйдә, бахбай, туры бар, буразна бозма... на-на-на!

Тәрәзәдән Дания үзләренә таба мышный-мышный сука сөйрәүче кызгылт йөзле Хәнәфине һәм сабантуй көрәшчесе кебек кулларын гайрәт белән аерып сука тоткан Зөлфия Хановнаны бик яхшы күреп тора. Дәрестәге сүрән укытучыдан бер әсәр калмаган. Көдрә чәчләр тузгып йөзгә сибелгән. Биттә бөрчек-бөрчек тир. Гәүдә пружин сиртмә шае тартылган. Куллар юлдагы кантарларга эләгеп, йә теге якка, йә бу якка авышкан суканы нык тотып, турыга ярдырып бара. «Һәй, Зөлфия Хановна, сука тоту сезгә ничек килешә икән!» дип шәрран ярып кычкырасы да иде Даниягә, ярамый шул — тартар теленнән табар...

Бәрәңгесен җыештырып алгач та, Зөлфия Хановна бакчага бәпкәләрен чыгарып җибәрә. Йоннары аксыл төскә иңеп, каз кыяфәтенә керә башлаган 40 җан иясе хәзер ихатага гына сыймый, боларга иркенлек кирәк. Казлар бакчага хуҗа булып, каңгылдашып, канатларын җәеп бер баштан икенче башка чабышалар. Али бабаның 40 башкисәре диярсең!

Мәктәптән кайткач, Дания тәрәзә каршындагы өстәл артына утырып өй эшләрен карый. Менә ике кулына ике чиләк тотып, бакчага Зөлфия Хановна килеп чыга. Тәти ападан җилләр искән. Шакмаклы ирләр күлмәгенең җиңнәре терсәккә чаклы сызганылган. Аякта резина итек. Юан арт шәрифләрен шыксыз ыштан каплаган... Ул чиләкләрен берәм-берәм тагаракка аудара: «Гули, гули, гули!» Колхоз шофёры Хәнәфинең әрҗә ярыкларына, итек эчләренә, фуфайка кесәләренә тутырып ташыган бодае тәмледер, туклыклыдыр... Казлар кара җирдә, көзге кояш җылысына изрәп йоклыйлар әле. Әмма сакчы уяу: «Кыйгак, кыйгак! Әй халык, торың! Ашарга китерделәр». Мизгел эчендә бакчаны шау-шу, хәрәкәт басып ала: «Кыйгак, кыйгак! Безгә сыйлану хак!»

Даниядә сабак әзерләү гаме сүнә, аның да шул шау-шуга, хәрәкәткә кушылып китәсе килә. Әйдәле, ул казларны инешкә алып төшсен!

— Зөлфия Хановна! — ди ул, ачык тәрәзәдән кычкырып. — Казларыгыз суга тилмерәдер, инешкә төшереп коендырыймы үзләрен?

Хуҗабикә кызга шикчел караш ташлый:

— Яланда, суда таралмаслармы соң? Киек-җанварлар тимәсме?

— Юк ла! Казларыгыз кайда әйдәсәм, шунда барыр.

Ризалык бирелгәч, Дания казларны урамга әйди. Кызык бу инкубаторда чыккан бәпкәләр. Боргаланмыйлар-сыргаланмыйлар, чакырсаң, шундук артыңнан ияләр. Ашаткан, эчерткән яисә тегендә-монда әйдәгән һәр кеше боларга әни дә, әти дә була, күрәмсең.

— Әйдәгез, очабыз! Кем-кемне уза! — дип кычкыра кыз, урамга чыккач. Ә алда болын, аннары камышлы инеш. Аяклар, чынлап та, кытыкланып, сөенеп йөрүгә күчә. Колакларда җил уйный. Лап-лап килеп, стройдагы солдатлар сыман, казлар да чабыша. Хәтта кайсылары очарга ук җыена. «Һәй-һәй, гули-гули, га-га-га! Әнә шулай, әнә шулай!»

Ниһаять, яшелле-аклы йолкыш казлар йөгереп-очып килеп инешкә ыргыла. Су өсте ярминкә кебек болгана, кайный башлый. Кайсы чума, кайсы кагына, кайсылары тырышып-тырышып туфракта ятып каралган томшыгын, муенын юарга керешә. Боларның сөенечен, рәхәт мизгелен Дания дә үз итә, сикергәләп «пикниктагыларны» тамаша кылып йөри.

Кич булып, үз йортларына кайтып кергәч, кызны әнисе берничә рәт тиргәп тә ташлады:

— Каз көтүчесе! Нишләп шулай дөньяңны оныттың? Безнең эшне кем эшләр?

Кырпак кар явып, җиргә чәнчүле салкынлык иңгән бер иртәдә күршеләр бакчасында ыгы-зыгы, шау-шу купты. Дания тәрәзәдән үрелеп карады. Кечкенә тар утарга ябылып, дөнья бетереп каңгылдашкан казлар төркеменнән кызлар, хатыннар алакайларны, акканатларны тоталар, аякларын бәйлиләр, ә фуфайка кигән Зөлфия Хановна тактага тезләнгән дә зур пычак тотып каз суеп маташа. Кыз сихерләнгәнмени, күзләрен дә алалмый. Итек белән басып җиргә кысрыкланган каз, яшәүгә хакы барлыгын белдереп, илереп кычкырып җибәрде: «Кыйгак-кыйгак!» ...Ак муеннан кызыл фонтан бәреп чыкты. Дания тик шулчак кына куллары белән күзен каплый алды:

— Әни!

— Әү, кызым, нәрсә булды? — дип куркып тавыш бирде почмак яктан анасы.

— Зөлфия апа каз суя... Ничек кызганмый мескеннәрне? Хатын-кыз башы белән... Укытучы бит ул, әни!

Сулкылдап күз яшьләре түккән кызы янына кереп, әнисе тәрәзәгә бер генә күз сирпеде һәм барысын да аңлап алды:

— Елама, кызым! Абыең белән бүгеннән үк урыннарыгызны алмашырсыз. Бу тәрәзә зыянлы сиңа.

Әмма сизгер ана кызын ирдәүкә укытучы ихатасыннан читләштерсә дә, аның дәресләреннән берничек тә аралый алмый иде. Һәм тиздән укучы белән мөгаллимә арасында һич көтелмәгән бәрелеш, низаг килеп чыкты.

Хәсән Туфан иҗатын үткәндә, Зөлфия Хановна һәрвакыттагыча шигырь ятларга бирде. «Киек казлар»ны Дания күптән белә. Моңа көй дә язганнар. Башкортстан эфирын яңгыратып бик еш җырлыйлар аны. Мәдәния Акчурина бу шагыйрьнең «Агыла да болыт агыла» җырын яңгыратып бәгырьләрне телә. Хәтерен янә бер кат яңартып, шигырьне сәнгатьчә уку, класста яңгырату мөмкинлекләрен барлады да беренчеләрдән булып тактага чыкты. Үз телләрендә җырлашып, каңгылдашып китеп барган кошлар кәрванына Дания тоткындагы сагышлы шагыйрь күзләре белән карады:

Безнең дә бит шулар сыман
Киткән еллар бар иде;
Кыйгак-кыйгак, илем ерак,
Дигән чорлар бар иде.

Иптәшләренең күзләреннән күреп тора, укуы тәэсирле. Аның казлар булып берничә рәт кыйгылдавы эчтән елау, сыкрау да булып тоелды. Сыйныф беркавым тынып, сагышланып торды. Тик укытучы нишләптер Даниягә ым ясамады. «Утыр!» диде ул, ниһаять.

Менә шулвакыт Данияне ниндидер тискәрелек, үзе дә аңышмаган гыйсъянлык биләп алды. Әле укытучы булып казлар хакында шагыйранә сүзләргә мөнәсәбәт белдерергә тиешле кеше кайчан гына пычрак итек белән ак канатлар өстенә басып, илертеп каз суйды бит... Шагыйрь кебек ирек тәме, матурлык яме турында сөйләп, укучылар алдында рухи алиһә булып басасы зат эшеме соң бу? Ничек берәр сүз әйтми түзәргә була?

— Ник утырмыйсың, Шәйдуллина? Укыдың, эшең бетте, башкаларны да тыңларга ирек бир! — диде укытучы, шактый тупас итеп. Күрәмсең, аңарда да ниндидер эчке уйлану бар.

— Мин казлар хакында Хәсән Туфанның тагын берничә юлын сөйләп китәм, — диде укучы һәм сыйныфташларына карап, юри ашыкмыйча, аерым сүзләрне кабартып әйтеп куйды:

Ята кырда ике ак канат...
Алар күккә
Җилкенми инде:
Төлке тагын иснәнә җилне,
Мыегындагы каннарны ялап...
Ята җирдә
Ике ак канат...

— Аңламадым. Нәрсә булды инде бу, Шәйдуллина?

— Шигырь... Хәсән Туфанныкы! Шул шагыйрьне өйрәнеп ятабыз бит.

— Ә төлке нигә?

— Төлке — аллегория, апа! Төлке кебек, гөнаһсыз, горур кошларны ашаучылар бездә дә җитәрлек!

Зөлфия Хановна кисәк урыныннан сикереп торды, ачуланып, ярсып, кызга бармак янап алды:

— Ә-ә, Шәйдуллина, син әнә кая сыптырасың? Укытучыга кизәнүме бу? Әйе, беләсез, казлар үстердем. Үстергәч, суялар инде аларны. Каз гомере — бер җәй. Әйт, йорт казларын сугым малы ясаудан нинди гаеп табасың син, Айболит?

— Дания — Айболит... Айболит... — дип хихылдашты укытучының алгы партадагы куштаннары Сәмига белән Вәрисә.

— Апа, мин Айболит булсам, сез кем буласыз соң? — Гаҗәп, Даниядә бер каушау, курку әсәре күренмәде. — Айболит докторның дәваланырга килгән киек, җанварларын туктаусыз Варвара кыерсытып тора түгелме? Ә һөнәрегез сезгә явыз Варвара булырга кушмый бит. Укытучы — яхшы тәртипкә, матурлыкка чакыра торган кеше ул.

— Житте, Шәйдуллина! Инде укытучыны өйрәтергә керештеңме? Бүген дәфтәреңне тикшердем, әллә күпме хата. Нечкәлек белән катылык билгесен аера белмисең. Надан! Мин сине грамотага өйрәтәм! — дип нык итеп өстәлгә сукты мөгаллимә.

Сыйныф тәмам тынып калды. Үсмер егетләр, үсмер кызлар кисәк

җитдиләнеп, бер укытучыга, бер укучыга карап, хәтәр бәрелешнең нәтиҗәсен көттеләр.

— Сезнең пычак тотып казлар суйганыгызны күргәч, үзегезне укытучы итеп тоя алмыйм, Зөлфия Хановна, — диде Дания.

— Тоймасаң, класстан чыгып кит! — дип кычкырды ярсыган мөгаллимә.

— Рәхәтләнеп!

Һәм Дания урынына да барып тормады, ашыгып ишеккә юнәлде. Ни гаҗәп! Шулара унберенче сыйныфның барлык унбиш укучысы, егет һәм кызы, кайсы сумкасын эләктереп, кайсы буш кулын селтәп, Дания артыннан томырылды...

— Туктагыз! Кем рөхсәт бирде сезгә, әле дәрес бетмәде, урыннарыгызга кайтыгыз! — дип яшелле-күкле тавыш белән күкрәде Зөлфия Хановна.

Әмма аны берәү дә тыңламый иде инде...

Шагыйрь, язучылар дөньясы, матурлык, гаделлек белән хисләнү — үзенә бер хәят. Ә маллар тотып, казлар асрап, корсак шәрифләре кушканча яшәү — икенче хәят. Билгеле, әлеге ике хәятне уйларда гына булса да бергә тоташтырып уртак нокталар табарга, килештерүләр ясарга тиешле әдәбият мөгаллименә зирәгрәк, шомарак булырга кирәк иде дә бит. Дөм-дөм мәктәбенә каян табып куясың андыйны? Һәм безнең заманда китап кимереп, шигырь белән хисләнеп, чәчкәләр белән бакча тутырып яшәүче зыялылар бармы соң, калдылармы әле? Димәк, хыялый Дания һәм аңа ияргән сыйныф бунты — чебеннең дулап тәрәзә ватарга җыенуы кебек тик көлке бер гамәл.

Гыйсъянчы кызның аттестаты мөһим предметлардан уртачага гына тартты. Иң көлкесе шул: тел-әдәбияттан Шәйдуллинаның аттестат билгеләре «өч»ле булды. Дания шаһәдәтнамәсен әнисенә нәселдән мирас булып килгән агач сандык төбенә атты да, дөньясына төкереп, фермага сыер саварга китте. Чынлап та, үпкәләрлек тә шул, ничә ел укып, мәктәп аның сәләтен, нинди һөнәргә маһирлыгын да ача алмады. Укытучылардан башка да «Айболит» була иде бит ул.

Терлекчелек бинасында төнлә ут чыгып, колхоз рәисе Шәкүр Яушев янып үлгәндә, Дания Шәйдуллинаның савымчы булып эшли башлавына ярты ел гына тулган иде әле...

Ачык йөзле, булдыклы, малларга шәфкатьле кыз тиз арада яхшы хезмәт күрсәткечләре яулады. Аны эшендә яраттылар, дуслары, ахирәтләре артты. Сул бит алмасы утта шактый пешсә дә, үзенә ошаган кияү табудан да өметен өзмәде Дания.

### III

Әмма язмыш очлыгы һәмишә каһәрле кире тарафта тора икән шул. Корылык еллар килеп, ферма сыерлары иткә озатылды. Аңа эшсезлек янады. Җитмәсә, ул бунт күтәргән төркем алдына басып, колхоз рәисе Фердинанд Исхаковка бозлы-тозлы сүзләр ыргыткан иде. Инде тагын гыйсъянлык әҗерен күрде. Эшсез калган савымчыларны колхоздагы башка тармакларга, урыннарга куйганда, аны искәргән кеше дә табылмады Дөм-дөмдә. Әллә бар, әллә юк Дания!

Ямьле җәй башында, халык сабантуйлар үткәргән мәлдә, Себердән авылга кунакка кайткан Данисны күрү Даниядә кинәт яшерен өмет уятты. Исемнәрендә дә янәшәлек, парлашу бар бит: Данис — Дания!

Аны беренче күргәч, эчтән «аһ!» итте. Бу бит Америка киноларындагы мафия, карак-угры өеренә яшен булып ташлана торган Стивен Сигал! Шул, шул — суйган да каплаган. Таза, олпат гәүдәле, йөзе дә җәенке. Йөреше дә нәкъ шуныкы — алпан-тилпән, йодрык төйнәүле, караш үткен... Моны Дания белән янәшә күрсәләр, Шәвәли директор, Фердинанд рәис калтырап төшәр. Ә Зөлфия Хановна хакында әйтәсе дә юк...

«Йәгез, — дияр Данис, тегеләргә усал итеп күз сирпеп. — Сез минем Данияне туктаусыз җәберләгәнсез икән, хәзер үк аның аягына егылып гафу үтенегез. Юкса...» «Ярар, Данис, кичерик инде, кешедәге шеш, кан йөрәккә төшә бит», — дип кыз тегеләрне яклый башлагач, болардан шундук җилләр исәр...

Башта Данис ягы, дөресрәге, аның озын буйлы, какча гәүдәле әнисе Мөзәянә бертуганы Макшия аркылы кызга ым ясады.

Дания һәр иртән кулына капчык, урак тотып туйралыкка үләнгә юнәлә. Печән төнгелеккә, сыерга ашатыр өчен. Беркөнне аңа, бәләкәй арбасын сөйрәп, йорт аша күрше Макшия дә иярде. Аптыраган иде кыз, берәдәк кәҗәсе хакында нишләп көяләнә әле бу? Инде янәшәсенә басып үлән кырка-кырка, Себердән кайткан кунаклары хакында сөйләнә башлагач, аңлады: Макшия аңа кармак сала...

Хәер, хатын сүзчән кимпер булса да, әллә каян урап-сарып тормады, турыдан ярды:

— Хәлләреңне күреп торабыз, Дания. Әлегә әниең Сания исән, Аллага шөкер. Бала чагыңдагы кебек син һаман анаң канаты астындасың. Инде дөньяныкын белеп булмый, китеп барса, абый белән җиңгигә син бит — ашка төшкән таракан. Үзеңә учак тергезергә самай вакыт, сеңлем. Яшең дә хәттин ашкан, инде сазаган кыз хәленә төшүдән курык! Дөнья ямьсезе шул. Әле менә кыюлык итсәң, бик җайлы урын чыгып тора. Әйдә, минем кунак Данис белән бер сөйләшеп карале син, Дания сеңлем!

Кыз башта шактый гарьләнде:

— Макшия түти, син мине кияүгә димлисеңме? Үземә ошаганны үзем тапмам дисеңме?

— И сеңлем, нигә чәпчисең? Борынгыда егет-кызны димче кавыштырган. Бик матур яшәп киткәннәр. Иншалла, Данис бик күркәм егет, дөнья күргән, тормыш итү рәвешен белә, малы бихисап. Мондыйны күпләр эзләп-эзләп тә таба алмыйлар. Ә сиңа Ходай юлыңа чыгарып куйган инде.

Даниянең башына келт итеп уй йөгерде: «Язмышны сынап карарргамы?»

— Макшия апа, иртәгә уннан Чардаклыга җыенам. Вакыты булса, Данис алып барсын соң...

Иртән ул киенеп-ясанып интекте. Үзенә бик килешеп торган җиңел кызыл кофтасы бар иде, көзгегә карагач, аны салып атты. «Эсседә кофта кияләрме?» Аннары күлмәк сайлый алмый иза чикте. Берсе озын, берсе кыска, таман булса, җиңе җәйгә бармый — озын. Инде аягына туфлиләр киеп, чыгарга җыенгач, киредән керде. Үкчәлесендә торна кебек озыная, табанлысында авыл киленнәре кебек бер шыксызга әйләнә... Ахыр чиктә вәсвәсәсенә төшенде, күңелендә тарткалаш бара икән бит аның: «Әйдә, ясан, бизән! Курчак кебек булсаң, бәлки әле кунак егетенә дә ошарсың. Әй, җүләр, базарга сатарга куялар бит сине. Ат сайлаган сыман, авызыңны ачып тешеңне дә санарга онытмасыннар. Югыйсә, азак дәгъва белдерүчеләр табылыр... Әй, Дания, нинди көнгә калгансың бит син, кызыкай!»

Кыскасы, җиңел булмады булачак кәләшкә урамга чыгып, Макшияләр каршында торган ак «иномарка»га утырып юлга кузгалу. Кешенекен күзәтергә генә кызык икән, ә үз башыңа төшсә, әллә нәрсәләр уйландыра хатын-кыз өлешенә төшкән өлеш.

Даниянең Даниска тормышка чыгарга ризалык бирүен белгәч тә, аналы-уллы Сәйфуллиннар эшне бик тиз тотты. Макшия өендә никах укылды. Гореф-гадәт кушу буенча як-яклар бүләк биреште. Туган-тумача мул сый өстәлләре әзерләп ашка йөртте. Өч-дүрт көн үзен Чардаклы Сабан туенда куела торган кәмит утыргычында кебек хис итте Дания. Эчтә, чаршау артында кемнәрдер чабышып чыгырны әйләндерә, ә син утыргычлардагы кешеләр белән бергә җил булып очасың, йөрәккә янә тиле дәрман, шаукым өстәп берничәсе тальян гармун

уйната, дөпелдәтеп барабан суга һәм ритм уңаена туры китереп, кайсыдыр әче итеп сызгырып куя...

Дүртенче көндә Дөм-дөм белән саубуллашып, озын Себер юлына сәфәр чыккач кына кәмит тәгәрмәченнән, шау-шудан, ыгы-зыгыдан араланды һәм, ниһаять, Сургут шәһәрендәге зур ихата эченә үтеп, ике катлы таш пулат эченә кереп утыргач, ул бөтенләй дә әллә нинди шомлы тынлык чолганышында торып калды.

— Әнкәй, килененә йортны күрсәт. Мин эттәй арыдым, бер-ике сәгать бассейнда ятармын, — диде Данис һәм сөлге, тагын нәрсәләрдер күтәренеп өйнең икенче тарафына китеп югалды.

Әмма Мөзәянә малаеның әмеренә карап Даниягә бүлмәләр ишеген ачарга ашыкмады: «Әйдә, килен, без чәйләп алыйк!» — дип кухняга җитәкләде.

— Дөм-дөмне калдырып, күз күрмәгән, колак ишетмәгән тундрага килү әҗәл белән очрашуга тиң булды. Мәгыйшәт авырлыгы өстенә, һай, сагындырды үзебезнең як! Чыдаша алмый елаган чаклар да күп булды инде. Аннары акрынлап күнегелде үзе, — дип чәй эчкәндә кайнә үз тормышын сөйләп алды.

Дания аның тел төбен яхшы аңлый: сиңа да монда яшәп китүләре җиңел булмас, киленкәй...

Дөм-дөм кызы Себердәге катлаулы шартларга, күңел сагышларына түзәргә әзер иде. Сургутта да берәр төрле эшкә керермен дип уйлады. Тик Данис кына кәләшенең ниятен ишетергә дә теләмәде:

— Монда, җаный, сыер саумыйлар. Бәрәңге дә икмиләр. Бу — газ, нефть төбәге. Йә, шуңа яраклы нинди һөнәрең бар? Һич югы исәп-хисап ясый беләсеңме? Документың булса, базар юк, иртәгә үк берәр офиска эшкә кертәм...

Болай булгач, Сәйфуллиннар өчен кем соң ул? Өй хезмәтчесеме, җанлы курчакмы? Бигрәк тә Данис аптыратты кәләшне. Кайткач та алыштырып куйдылармыни? Юньләп сөйләшми дә, «әнкәй, киленең!» дип, аны гел туп кебек күреп, Мөзәянә ягына ыргыта. Әйтерсең, Дөм-дөмнән аны Данис түгел, ә Мөзәянә карчык ярәштереп килгән. Эшкә иртүк чыгып китә, төн урталарында гына кайтып керә. Кайнар ашка, ачык йөзгә дә җавапсыз. Монда әлләни күрәзәлек кирәкми, хатын буларак Данис күңеленә керә алмады инде болай булгач Дания... Сигал кыяфәтен хәтерләтсә дә, ул аңа һич тә яклаучы түгел. Киресенчә, алпан-тилпән, туры караш белән килеп үзеңне таптап китәр бу. Аяк белән таптамаса, теле, сүзе белән таптар хәләлең...

Мөзәянә карчык киленнең боек карашын әллә тоя, әллә юк, һаман колак төбенә килеп гел искәртеп, өйрәтеп кенә тора. Янәсе, Данис таба ашын бик ярата, бигрәк тә кыздырылган сөләйман балыгы, чөгә өчен җан ата. Бәрәңгенең духовкада кургаш кәгазьгә төреп пешерелгәнен өни икән... Янәсе, Данис эчке киемен дә һәркөн яңартырга өйрәнгән. Һәр иртән майка-ыштанын, оекларын йокы бүлмәсенә тезеп куярга онытмасын килен. Тагын менә шундый эчпошыргыч нәрсәләр турында такылдап Даниянең бәгыренә төшә бу:

— Миңа әлләни күп калмагандыр инде. Үзеңә учакка ут элдерер вакыт җитеп килә. Зиһен җыярга кирәк. Ир ничә яшьтә булса да, сабый кебек бит ул. Тәрбияләгәнне, көйләгәнне ярата. Көлдергән дә хатын, бөлдергән дә хатын... Син, килен, безнең халыкның шул әйткәнен дә онытма. Эшкуары да, җилкуары да хатын тәрбиясеннән килә дигән сүз бит инде бу!

Дания шул вәгазьләрне ишетмәс өчен булса да, кибеткә, базарга азык-төлек алырга чыгып китәр иде. Әмма Сәйфуллиннарга ашамлык-эчемлекне машинада яшь бер грузин егете ташый.

Дөнья йөзе, кешеләр чырае күрмичә Дания ярты елдан артык яшәде. Инде Себер ягы булса да, көннәрнең язга авышканы беленә. Һавалар йомшарды,

кояштан көндез җылылык сирпелә. Дөм-дөмдә хәзер әнисенең гөлләре купшы яфрак яргандыр, чәчәккә төймәләнгәндер, мөгаен...

Дания, күпме вакыт ир белән яшәгән хатын, беркөнне ихтыярсыздан уйлап куйды: нишләп авырга калмый әле ул? Һәм бервакыт ир түшәгеннән соңлап кына башын калкыткач, ул, хурласа-хурлар, дип тәвәккәлләп, шиген әйтеп салды. «Әллә соң врачка, табибка күренергәме?» — дип тә өстәде.

Данис карават янында нәүмизләнеп басып торган кәләшенә шактый вакыт сынап карап торды. Башта гадәтенчә уратып көлде:

— Синең белән, җаный, бу хакта договор бармы әле безнең? Яисә килешүдә каядыр берәр пункт ясап әйтелдеме шундый сүз? Юк шикелле. Мин булдыра алганча мал табам. Житеш тормышта яшәр өчен шартлар тудырам. Азып-тузып йөрмим. Сиңа бит миннән нәкъ шулар кирәк иде. Яшә! Ризасындыр бит?

Чынлап та, Дания булачак иргә карата күңеленнән шундыйрак таләпләрне кабартып куйган иде бит. Тегесен әйтү кыз кеше өчен оятсызлык та булып күренер иде әле. Ә хәзер...

— Данис, ир хатыны бала табып үстермәскә тиешмени? Бу бит гайре табигый хәл...

Менә шул сораудан соң Данис, авыртудан бөгелеп төшкән кеше сыман, кисәк сыкрап ыңгырашты:

— Мин кайбер малайлар кебек бакча артында гына хезмәт итмәдем шул, җаный. Океан киңлекләрендә кайбер ирлек функциясеннән колак кагарга да туры килде. Сәбәбен аңлыйсыңдыр? Хәер, рәсми сүзләр әзер: «Атом реакторы... штатта каралмаган ситуация. Исән калуыгыз өчен командованиегә рәхмәтле булыгыз, матрос-радист Сәйфуллин. Су асты көймәсен вакытында күтәрдек!»

Менә шуннан соң кәләш югалып калды:

«Хатын-кыз — тормыш гөле ул. Ул гөл иртәме-соңмы, бөреләнергә, чәчәк атарга тиеш! Аның чәчәге — бәбәй. Бу нәфис зат берчак гавам каршында ак биләүгә төргән чәчәк — бәбәе белән балкымый икән, аның дөньяга килүендә дә бер мәгънә юк».

Җаны өзгәләнгән нәрсәләр хакында эшкуар ирбаш белән дә, акча, мал гаме белән ысланган каенана белән дә сөйләшү урынсыз, хәтта зыянлы ук иде. Ходай сакласын, өй тоткыны ясап, өстеңнән бикләп тә куярлар... Ул эчтән генә ният кылды, әзерләнде. Һәм апрель башында, нәкъ алдар көндә бугай, Данис берничә тәүлеккә Төмән ягына командировкага чыгып киткәч, ныгытып киенде һәм чемоданын тотып өйдән кузгалды ул. Төрмәнеке кебек тимер челтәрле тәрәзәләрнең берсеннән Мөзәянә карчык бәргәләнеп нәрсәдер кычкырып калды. Үз гаебең белән үз-үзеңә ясаган хата өчен кешеләрдән кичерү сорар урын юк... Дания, югалткан нәрсәләре байтак булса да, башын туры тотып, ирек, хак, мәгънәле тормыш юлына юнәлде...

Рәмзил юлдашының Себердә күргәннәрен тыңлап, чынлап торып әсәрләнде: «Карале, безнең Дөм-дөм кызының башыннан да шундый маҗаралы нәрсәләр үтәр икән?» Әмма тагын да гаҗәбрәге Дания Рәмзил кулына калын дәфтәр тоттыргач булды. «Нәрсә бу?» — дип машинаны туктатып сорады ул.

— Сумкамда йөрде. Сиңа бирәсемә ышандым. Кыйсса бу! Укып карале... Син бит үзең дә сәхнәләрдән торып шигырьләр сөйләдең. Икәү уйлашыйк, нишләтергә моны?

Рәмзил, үтә кызыксынып, күн тышлы кульязманы актарды. Кыйсса дигәне исеме белән үк җәлеп итте аны: «Хыялый кыз»...

— Үзеңне тасвирладың мәллә?

— Шулайрак бугай шул...

Рәмзил авылдашын үз йортлары алдында төшереп калдыргач, уйлап куйды. Кулыннан килә торган эш булса, әлбәттә, ярдәм итәчәк ул бу алчак хатынга.

## Келәмгә бастырмакчылар...

### I

Рәмзил берничә көн Дания язган кыйсса тәэсирендә йөрде. Эштән кайткач та, документлар карыйсым бар, дип гаиләсеннән араланып укырга керешкән иде, кулъязма аны биләп алды. Башта Даниянең яза белүенә сөенде. Төзек җөмләләр, шигъри гыйбарәләр, тәэсирле күренешләр аша Вәсилә дигән җанлы герой алга басты. Исеме башка булса да, Рәмзил моны барыбер Дания бу, дип укыды.

Вәсилә бар булмышы, күргән-кичергәннәре белән ачык, прототип кем, дип баш ватасы да юк — Дания! Ә менә Вәсил дигәне кем соң? Вәсил—Вәсилә... Бер-берсен яратышсалар, байтак вакыт чын гашыйклар булып йөрсәләр дә, боларга бергә булырга язмаган шул. Әсәрдән зур сагыш хисләре бәрелә, каләм иясенең йөрәгендә җуелмас сыкрау бар... Чынлап та, кем икән соң бу Вәсил? Хыял белән тудырылган кешеме, әллә чынлап та Дөм-дөмдә бармы шундый егет? Гашыйк җаннарны бер-берсеннән аерган сәбәп тә кыйссада бик тормышчан итеп күрсәтелгән бит. Вәсилә берчакны әдәбият укытучысы Вариса Шәңгәрәевна белән сүзгә килешә. Укучыны класс белән яклап чыгалар. Мәктәптә чынлап торып зур «ЧП» була... Менә шуннан соң Вәсилә белән Вәсил арасы өзелә дә инде. Никме? Чөнки Вәсил — инде мәктәпне тәмамлап, колхозда төзелеш бригадасында эшләп йөргән никрут егет, Вариса Шәңгәрәевнаның бертуган энесе икән. Укытучы низагтан соң үз укучысы Вәсилә хакында аңа ниләр генә сөйләми. Имеш, ул ниндидер бер аңлашылмаслык зат: кыргый, астыртын, җәнҗал куптарырга әвәс... Имеш, өлкән кешеләргә карата аның бер хөрмәт, ихтирамы юк... Син шуның белән тормыш корырга җыенасыңмы, энекәш? Акылыңа кил, Вәсилә белән бәйләнсәң, мәңге иминлек, бәхет дигән нәрсә күрмәссең!..

Вәсил йөргән кызыннан күңеле кайтып, армиягә китеп бара. Хәтта кыз кырына саубуллашырга да килми. Солдатның хәрби хезмәттән кайтуын инде башка бер чәчби көтеп тора...

Рәмзил кинолар, спектакльләр карап, әсәрләр укып, әллә нинди мәхәббәт фаҗигаләрен белә иде. Әмма үзе үскән авылда яшьтәшләре дип әйтерлек гашыйкларның нахак сүз аркасында аймылыш булуын белү аның йөрәген ихлас сыкратты. Кем соң бу Вәсил?

Серне, әлбәттә, Дания генә чишә ала иде. Берара вакыт табып Рәмзил фермага сугылды. Савучы хатын бик бирелеп шешәдән яшь бозауларны имезеп, сөт белән сыйлап тора иде. Рәмзилне күргәч, аның йөзенә шатлык бәреп чыкты:

— Нәрсә, укый алдыңмы?

— Ихластыр, йөрәккә үтәрлек әйбер язгансың!

— Чынлапмы, Рәмзил?

— Моны мин Чардаклыдагы Гардановка бирермен. Өлкә гәзитенең безнең зонадагы собкоры ул. Үзе дә яза, язучы халкы белән әшнәлеге дә зур... Тик син миңа әйт әле, Дания. Вәсил кем ул? Миңа аны чын кеше буларак белү бик мөһим.

— Син, аны әйтсәм, безне ярәштерергә җыенмыйсыңдыр бит?

— Карарбыз!

Хатын үзенең шаярып, көлеп әйткән сүзләренә җитди җавап алгач, кисәк уйланып калды.

— Сер итеп тотарсыңмы соң?

— Вәгъдә!

— Сәүбан, — диде Дания шыпырт кына. Һәм беркадәр кызарынып түбән карап торгач, өстәп куйды. — Батыршин...

— Укытучы Зөлфия Хановна Сәүбанның апасы идемени? Бертуган укмы?

— Әйе, алар туганнар!

Менә, ниһаять, Дания кыйссасындагы һәр персонаж Дөм-дөмдә чын урынын, вакыйгаларда чагылышын тапты... Сәүбан! Караңгы чырайлы, төксе, зарлы Сәүбан фермерны белмиме соң Рәмзил, белә, әлбәттә... Касаткинны урыныннан төшергән җыелышта бу ир үзенең йөрәкле булуы белән күңелгә уелды. Әмма малай чакта да «Бәтрәк» кушаматы, кырку холкы аша Сәүбан яшүсмерләр төркемендә үзен бик еш искәртте. Романтик табигатьле Дания бу чуар йөрәктә нәрсә тапты икән соң? Хәер, хыялый кызларга нәкъ шул баш бирмәс, «бәтрәк» егетләр пар түгелме? Сөйләүләренчә, Батыршалар нәселе Дөм-дөмдә аерым бер кавем булган бит...

## II

...Сәүбан гадәтенчә салкын будкасында уянып китсә дә, бу иртәдә күңелендә җинеллек тойды: Касаткин шайкасын туздырдылар бит! Шөкер, кеше артына посмады, беренче ташны боларга үзе томырды. Юкка «бәтрәк» кушаматы йөртми икән. Инде Ходай кушып, Чардаклыга юньле башлык килсен иде. Бу хуҗалык елында ныклап аякка басарга бик вакыт инде Сәүбан фермерга.

Юрган астыннан чыкмыйча, ир тагын шуны уйлап ятты. Кичә энгер иңгәндә туктаусыз сул кашы тартты аның. Кемдер искә төшерә, күрешүгә инде бу. Тик кайсысы сагына, ашкына икән соң? Чардаклыда әнисе янында яткан хатынымы? Юк, Мәснуганың ике ятып, төшенә дә бер кермәс. Йортны залогка салып, урамда торып калгач, дошманга ук әйләнде ир. Бәлки малае Артурдыр? Буранлы февральнең егерме җидесендә туды ул. Мәхшәр көндә чын бәйрәм булды бу... Бераз иртәрәк булса да, барып, малайны туган көне белән котлау зыян итмәс иде. Хатын белән ачуланыштык дип кенә балаңа кул селтәү егетлек түгел. Сәүбан, шулай уйлагач, бүген үк Чардаклыга барып гаиләсен күрергә карар итте.

Машина дигәнең атна чамасы кар әсирлегендә ята. Сәүбан чит тәгәрмәчләргә исәп тотып, асфальт юлга чыкты. Әле һаман караңгы. Җитмәсә, куе томан да бар. Ниһаfive, шактый вакыт аякны аякка бәреп торгач, юлда автобуска охшаш бер нәрсә күренде. Тик нишләптер уты да юк... Ир кабаланып кулын күтәрде, «зинһар, утырт!» дигәндәй, еш-еш изәргә кереште.

Ходайның рәхмәте, машина шактый зур тизлек белән килсә дә, нәкъ юлчы каршында шыгырдап туктады. Шундук ишек ачылды. Һәм Сәүбан да ашыгып автобус эченә томырылды. Эчтә җылы, урындыкларда кешеләр шәйләнә. Әһә, арткы якта буш урын да бар икән. Сәүбан пассажирларга бәрелмәскә тырышып шунда юнәлде. Бер мизгел утыргычта рәхәтләнеп оеп барды, аякларына җылы төште. Тик сәерсенеп игътибар итте: гадәттә өерелеп сөйләшеп бара торган юлчы халкы монда мәет чыккан өйдәге кебек тынып калган, әнә, һәркайсы үзалдына нәрсәдер чутлап-исәпләп барган кебек...

— Абзый кеше, каян киләсез? — дип сорады Сәүбан янәшәдәге карттан.

— Ерактан.

— Кая барасыз соң?

— Еракка.

Ир әлеге тапкыр сүзләрдән көләргә җыенган иде, абзый дигәне исә алда утырган кешегә җитди итеп кычкырды:

— Хан энекәш, дөрес утырттыгызмы моны, чит-ят кавем заты түгелме соң бу?

Хан — урта буйлы, Дөм-дөмнәрчә әйткәндә, кып итеп торган кышкы, җылы

кием кигән кеше, урыныннан торды да, кочагын җәеп, көлеп, Сәүбан ягына атлады:

— Улым, һаман безне танымыйсыңмы? Мин юри сүз әйтми торам әле. Батыршиннар бит без!

Сәүбан кинәт урыныннан сикереп торды, ис-акылын җыя алмыйча каршыга атлады:

— Әти, чынлап синме бу?

— Мин, Сәүбан улыкаем, мин!

Чынлап та, тавышы шул, күзләре, йөзе шул — әтисенеке! Сәүбанны ничә кат көчле кулларына күтәреп чөйгән, иркәләгән, сөйгән, ягымлы сүзләр әйткән кадерле кеше бит бу! Өстәвенә, борынына таныш ис килеп бәрелде.

— Әти! — дип улы ата кешегә килеп сарылды.

— Таныды нәселне, таныды! — диештеләр төрле яктан. Шуннан автобустагылар уянып киткәндәй булды. Сәүбанны исеме белән төрләндереп шатлыклы, сөенечле сөйләшүләр, Дөм-дөмчә шаяру, үртәшүләр башланды. Ә берәү Сәүбанның бөеренә дә йомшак кына төртте. Себерчә нык итеп киенгән бу. Башында йонлач малахай, өстендә соры аю тиресеннән тегелгән кыска тун... Бу киемдә юлчыга эссе түгелме икән?

— Нихәл, онык? Мине танымассың инде. Галәү бабаң мин... Лашман тартучы зэк.

— Ә, әтинең әтисе! — Онык үзе эчтән уйлап куйды: «Бабай яшьли китеп барган шул. Кырыкны да бирмәссең». Сәүбан хисләнеп бабасының кулларын кысты, яратып, ирләрчә җилкәсенә сукты. — Синең турыда күп сөйләделәр, Галәү бабай, бик уңган-булгансың, булдыклы... Ә кулак дип гайбәтеңә төшүчеләргә мин ышанмадым...

— Дөрес иткәнсең, улым! Башыңны күтәрсәң, тигезләргә теләп кизәнүчеләр күп инде бездә: «Мирныкын ашый, кумәк эшкә таяк тыга... Җинаятьче ясап, кандала кебек сытарга кирәк үзен!» Йә, хәзер ничек соң? Дөньяларны әйтәм. Крәстиангa һаман иркенлек юкмы, худ бирмиләрме?

— И, Галәү бабай, дөньяның асты-өскә килде. Ил тузгый. Кулаклар хаклы булган дип, хәзер сезне сагынучылар бар, Галәү бабай...

Ләкин нәкъ шул чакта каяндыр урта рәтләрдән өлкән яшьтәге, мамык шәлле, нәзакәтле кортка тавыш бирде. Башкалар рәтеннән болар да тынып калдылар.

— Миңнехан, Сәүбаным җиде буын Батырша бабайга бик тарткан, дип мактанган идең. Карыйк әле, расмы шул сүзең? Йә, яндырыгыз әле утны. Батырша, бас әле онык белән янәшә!

Сәүбанның уң ягына шәп камчат бүрек, тун кигән мәһабәт карт килеп басты. Буйлары бертигез, тик карт корсак шәрифләре белән күпкә мулрак, олпатрак күренде... Мәгәр шуңа карамастан, автобустагылар «аһ» итте: «Батырша нәселе үз сөяген саклый белә!» Һәм теге карчык янә бастырып сөйләп китте:

— Чынлап та, күзләр берүк, авыз-ияк тирәсе дә бик охшаш... Борыннар да үрдәкнеке сыман җәенке боларның. Башлар да җилкәгә шыплап утыртылган. Муенга карунлык... Бәрәкалла, суйган да каплаган Батырша икән шул бу олан...

— Батырша сөяген мактыйсыз да мактыйсыз. Сәйфулланың затлы нәсел каныннан башка әллә кайчан төс-килбәт, кот җуйган булыр идегез әле, бәтрәкләр, — дип якыннан аваз салды чәтердәп торган әче тавышлы кимпер. Һәм ул чепи күрән күзләрен елтыратып Сәүбанга текәлеп торды:

— Бигрәк ябыксың, улыкаем. Сакал-мыек та баскан үзеңне. Тәмам

мукшы побына ук охшап калгансың. Мөселман өммәтеннән икәнеңне, шәт, онытмагансың бит, балам? Киемең дә шактый өтек... Хатының бардыр лабаса? Әллә соң авырлымы, карый алмыймы үзеңне? Бала күтәргәндә, күзгә ак-кара күренми, ирдән дә укшыта...

Ир нәсел анасы каршында алдашырга җыенган иде, мәгәр теле тыңламады, башкача әйләнде:

— Хатын белән ачуланыштык әле. Әниләрендә бала белән ята...

— Кит, олан! — дип кычкырды алгы яктан бик кырыс чырайлы мужик. — Синең хатын бер генәме? Икәү түгелме? Син шул көйсез хатын көен көйләп ятасыңмы, кем, Сәүбан. Мәсхәрә! Ялынма, монысына шартлатып «талак» әйт, ишегеңне яп та башкасын алып кайт! Беткәнме ирне санлаган кимпер?

Карчык бу тавыш иясен әллә тыңлый, әллә юк, Сәүбанга үзенекен тукыды:

— Әллә, улым, бик юньсез нәсел белән бәйләнештеңме соң? Анасына карап кызын коч дигәнне искә алмадыңмы? Кәләшне нәселгә карап сайларга кирәк бит аны... Әтрәк-әләмнән Ходай үзе сакласын!

Башкаларны сабыр гына тыңлап торган Батырша, ниһаять, көрәктәй кулын Сәүбанның җилкәсенә салды:

— Син, олан, муеныңа хатын атландырып нәселне хурлама! «Ир — баш, хатын — муен» дигәнне оныттыңмы? Гаиләндә ата-баба кануннарын саклый белергә кирәк! Бәлки мәгыйшәтең үзеңне хуҗа итеп тоярга ирек бирмидер, олан? Әйт әле, җирең ничә десятина? Камыт кидерерлек атларың күпме? Саудыра торган сыерың, башмак, бозауларың бардыр бит? Тавык, чебеш, каз-үрдәк хакында сорап та тормыйм... Амбары тулы ашлык, йорты тулы мал булса гына, ирнең сүзен мир тыңлый, шуны бел! Югыйсә, мин кем дип шыр күкрәккә йодрык каксаң, мәсхәрәгә генә төшәрсең...

— Син, Батырша, гел акыл сатасың, һәркемне өйрәтәсең инде, — дип янәшәдән тагын бер нәсел тарафдары күтәрелде. — Амбар тулы ашлык, йорт тулы мал, имеш. Ә алар әфсен-төфсен белән сиңа күктән төшәме? Хезмәт итәргә, тир түгәргә кирәк! Ә бәлки безнең олан җирдә эшләү тәмен, рәтен җуйгандыр? Зимагур түгелме ул?

Браматлыкка төшмәгәнме? Сорыйк әле без аңардан. Сабан артына төшеп, туфрак исен тоеп, бу байлык минеке бит, дип кинәнә-кинәнә җир күтәргәне бар микән аның? Яз мәлендә кара кырда күгәрчен томшыгы кебек күгелҗем шытымнар дәррәү күтәрелеп үсеп китүенә сөенә беләме икән безнең онык? Яисә тир түгеп өлгерткән ашлыкны җыюдан тәм, ямь табамы ул? Шулардан башка ир-ат крәстиән дигән игелекле кешегә әверелә алмый бит. Әйт, Сәүбан олан, Батыршалар нәселе алдында син үзеңне һәйбәт крәстиән саныйсыңмы, әллә күз генә буявыңмы? Булмышың ялган булса, үзеңә бәхет тәтемәве көн кебек ачык бит... Йә әйт, кем син?

Сәүбан бу сорауга ни дип җавап бирергә дә белмичә аптырап калды. Чынлап та, кем соң ул? Автобустагыларның үзенә текәлгән карашы астында ул тәмам коелып күпме басып торган булыр иде, кисәк «дилбегәче» тавышы барысын да айнытып җибәрде:

— Олан, сиңа төшәргә вакыт!

Баягы әрсез кырыс чырайлы мужик хахылдады:

— Абзыйлар, әллә соң үзебез белән алып китәбезме моны? Ятмасын анда нәсел йөзен каралтып.

— Авызыңнан җил алсын, Әгъләметдин! Нәсел каны барыбер үзенекен итәр әле. Асылына кайтыр безнең онык, — дип аны бүлде басынкы кортка. Ә аннары Сәүбанга карап эндәште. — Бар, улым, төш! Юкса, чынлап та алып

китәр үзеңне исәр Батырша кавеме. Яшьсең әле, безнең янга килергә өлгерерсең. Бар, үз юлыңда бул!..

Сәүбан менгәндәге сыман ашыгып җиргә ыргылды. Юлга аяк басуга, тәне куырылып, калтыранып куйды. Шайтан арбасыннан төштеме соң?.. Ә юл дөрестән дә буш, бары көрпәк кар бураны тузына... Хәер, чынлап та автобуска утырдымы, юлда булдымы соң әле ул? Күргәннәре дә саташу, күз алдану гына түгелдер бит? Сәүбан башын күтәреп тирә-юньгә күз ташланды. Ләхәүлә! Томан аша алдында Чардаклы җәйрәп ята иде. Димәк, ул чынлап та Батыршаның нәсел арбасына утырып сәфәр кылган. Каш-күз тартышына да төшенде: менә кемнәр аны очрашып сөйләшүгә дәшкән икән... Оланны келәмгә бастырмакчылар...

## III

Сәүбан тиз-тиз атлап, хәтта шомлы тойгылардан котылырга теләгәндәй йөгереп, авыл ягына юнәлде. Ләкин ниләр булса да булган, ышанасыңмы-юкмы син, акыл, ә хисләр чын икән бит: «Бетереп, хурлап ташладылар! — дип, нәсел ирләренә рәнҗеде ул. — Аларга рәхәт, анда ирләр, игенчеләр сүзе канун, ә монда?»

Нишләптер шул мизгелдә аның күз алдына кырыс чырайлы Зөлфия апасы килеп басты. Әнә ул балаларга ничә тапкыр үткәреп, инде ятлау хәленә килгән яраткан дәресен бирә: «Бөек күчеш чоры шагыйренең «Җиһан апа» поэмасында бик кызыклы психологик кичереш тасвирланган, укучылар. Шәңгәрәй белән Җиһан колхозга кергәч, яңа тормыш хуҗалары, коллектив, удар эшләвен күреп, хатынны бригадир итеп күтәрәләр. Көнчел, тар күңелле ир кайгыга бата: «Ир рядовой, имеш... Кыр эшендә хатын командир!» Шул уйлары белән Шәңгәрәй иске тормыш кешесе булуын күрсәтә. Ир — баш, хатын — муен булырга тиеш, янәсе. Ә бит аңа хатынының күтәрелүе өчен сөенергә кирәк! Әйе, Бөек Октябрь революциясе, социалистик хезмәт рухы хатын-кызларга ирек бирде, үсү мөмкинлекләрен ачты. Кыр эшендә генә түгел, хатын-кыз хәзер һәр өлкәдә командир, укучылар!»

Элек, яшүсмер чакта, әлеге дәрес туган апасының сабагы булып истә калса, хәзер, Батырша нәселе белән очрашкач, Сәүбанны Зөлфиянең әлеге телмәрне үзләренең шәҗәрәсендәге хатын-кыз заты булып сөйләве сискәндерде. Уйларга да куркыныч бит, кулак дип Себердә һәлак ителгән Галәүнең оныгы Зөлфия, мөгаллимә булып, крәстиән Батыршаның җирдәге эзен суыта. Ул кайдадыр әби патша заманында яшәмичә, укытучы әйткән бәхетле чорга туры килсә, һичшиксез, Шәңгәрәй кебекләр сыман башын иеп бер таякчык хакына колхозга бил бөгәргә тиеш иде. Ә коммуннар әмеренә буйсынып, малыннан ваз кичми икән, аны Галәү кебек кулак ясап Себердә череткән булулары хак. Тегеләйме-болаймы хисап, фараз бер — бетә авылда Батырша кебек крәстиән. Югала салада чын хуҗа. Менә бит ничек! Күчеш елларының мәкерле хакиме ир белән хатынны гына бер-берсенә каршы куймый, ә нәсел җепләрен дә өзеп, оныкны бабасына каршы котырта. Оныкның дигәнең хәтерсез булса, бигрәк тә...

Ә Зөлфия Хановна сөенгәнчә, хатыннар командир булдымы соң Рәсәйдә? Юк, командир — хаким! Коры мәдхияләр белән юмалап, күкрәкләренә медальләр тагып, ул колхозчы хатын-кызлардан хезмәт ударниклары ясады.

Хәтта күмхужлар белән Нәфисәләр, Миңлекамаллар, Наташалар, хатынша ирләр идарә итте. Тик болар нинди хуҗа? Хаким үзенең бар мөридләрен җибәреп, затсыз төстә авылларны талады, иген үстергән, мал үрчеткән кешене хәерче хәленә төшерде. Менә сиңа бу чын командир! Хәер, командир гынамы соң? Юк, генералиссимус! Барлык чорлар һәм бөтен халыкларның бөек

юлбашчысы Иосиф Виссарионович Сталин бу! — дип үзалдына усал итеп көлеп куйды Сәүбан.

Батырша нәселен тыңлады Сәүбан, тик нәселдәшләр колагына үз заманының афәтләрен илтеп җиткерә алмады, томана. Ә бит Батыршалар югалгач, авыллар корый, электәге яхшы гадәтләр бетә... Шулай булмаса, Зөлфия канлы пычак тотып, итеге белән басып каз суяр идеме? Мондый хатын бишек җырларын көйләп сабый тирбәтерме? Ирне гаилә башы итеп берәр таныячакмы бу зат? Көт! Күреп тора бит, апасы күптән инде җизнәсе Хәнәфи муенына менеп атланган... Дөрес, укытучы булгач, урамда халык арасында, укучылар каршында ул рәхим-шәфкать, мәрхәмәт хакында матур сүзләр яудырырга сәләтле. Әмма аның үз гамәлендә боларны көтеп син көтек булырсың. Дания аңа сез укытучы булырга лаеклы түгел, дип бик дөрес әйткән ласа! Хәзер Сәүбанга көн кебек ачык... апасының Даниягә карата яудырган ләгънәтләре нахак бит, нахак! Ә ул, ахмак, туган апасына ышанды. Аннары кәнфит дип агу капты. Һаман да нәсел башы хаклы. Анасына карап кызын кочарга кирәк булган да бит, ашыкты шул, күзләп, исәпләп тормады Сәүбан. Кызлар тирәсендә дә «бәтрәк» булды инде йөгәнсез Мәҗнүн.

Ә арбада иң йөрәкне яралаганы — нәселдәшләрнең «Кем син?» дип каныгулары булды. «Хәерче фермер мин», дип үз-үзенә үчегеп әйтергә теле кычытты кычытуын, ярый, тешләп калды үзен... Нишләргә, ничек аякка басарга соң Сәүбанга? Ничек итеп Батырша бабасына кыяфәте белән генә түгел, ә эше, гамәле белән дә охшаш икәнен дәлилләсен ул? Йә Хода, ярдәм ит син иргә нәсел каршында ниятләгән изге морадына ирешергә!

Сәүбан буран кебек күңел өермәләрен ерып, таныш йортка килеп керде. Ишек ачылуга, керүчегә таба башларын борган хатыны Мәснуга да, аның әнисе Мәгъфирә дә, кыяфәтләренә карап, һич тә сөенеп кочар затлар түгел иде шул. Хәтта Мәснуганың йөзен кисәк кара болыт каплагандай ук тоелды:

— Әйттек бит сиңа, нишләп монда килеп йөрисең, күз көеге?

— Бәй, җаный, мин синең хәләл түгелмени? Чәй куй, өстәл көйлә! Малайны котларга килдем. Туган көне җитеп килә ласа!

Сәүбан Мәснуганың ай-ваена, чырай сытуларына карамастан, итеген салды, курткасын чөйгә элде.

— Йә, әби, ни хәлләр бар? — дип, кияү әби кешегә җылы караш ташлады.

Ул ара эчке яктан тып-тып килеп Артур йөгереп чыкты. Сәүбан аны шундук кочагына алды.

— Йә, мин кем?

Сабый күзләрен зур итеп ачып аңа карап торды:

— Эти! Дырн-дырнда эшлисең.

— Молоток, улым, — дип ихлас сөенде ата. — Йә әле, Артур, күчтәнәч сиңа. Менә алма! Менә түттүт — машина!

Ул алып килгән әйберләрен берәм-берәм Артур алдына тезә башлады. Малай машинаны алгач, идән буйлап тәгәрәтеп куйды:

— Бу машина миндә бар.

— Әниең бирдеме?

— Юк.

— Кем бирде соң, улым?

— Абый!

Боларның сөйләшенә колак салгалап үтеп-сүтеп йөргән Мәснуга туктап калды.

— Нишләп абый булсын... Мин алып кайттым бит!

Малай кисәк җанланып китте. Үз сүзен итәргә теләү галәмәтеме бу, әллә әнисенә үз дәгъвасы бармы, әйтеп салды:

— Абый инде! Ул бездә ашады, аннары әнә шунда йокларга да ятты. Хыр-хыр йоклый... Әти, мин яратмыйм аны.

— Болай булгач, аңлашылды инде, — дип, Сәүбан өздереп хатынына карап алды. — Монда тик ятмыйсың инде, Мәснук, шулаймы? Хет малайны зөфаф кичәңнән аралар идең. Нинди затсызлык соң бу?

Ир әлеге сүзләрдән соң хатыны гадәтенчә корт чаккан сыман бәргәләнер, әллә нинди ямьсез сүзләр кычкырыр дип көткән иде. Ләкин Мәснуга тыныч һәм сабыр калды:

— Ярар, барыбер әйтергә туры килер иде инде. Мин синең белән аерылышырга булдым. Әни дә шуны тели. Өметне өздек без синнән.

Ни гаҗәп! Иргә дә әлеге сүзләр аяз көндә яшен яшьнәү кебек һич тә көтелмәгәнчә булып тоелмады. Ничектер гап-гади хәбәр ишетү сыман... Тик ничә еллар сиңа үз, якын булып тоелган көрән күзләрдән, күпме үбешкән сусыл татлы иреннәрдән читләшүне тою кинәт Сәүбанны сагышка батырды. Бугазына да нәрсәдер килеп тыгылган кебек...

— А-лай!

— Нәрсә алай? — дип сорады хатыны, иргә күзе белән чәнчеп. Күрәмсең, икесенә дә мәгънәле сүзләр эзләүнең кирәге калмаган. Җаннарда йозак...

Сәүбан шуны аңлап дәшмәде. Сүзсез генә малаеның башыннан сыйпап үтте, элгечтән курткасын алып киде, иелмичә генә аякларын итекләренә тыкты да кычкырды:

— Әбекәй, кил монда!

Чаршау артындагы Мәгъфирә шундук аның алдына килеп басты. Ир күреп тора, шулай ук әсәрләнгән бу, күзләре әйле-шәйле йөгерешә...

— Әби, кызыңның сүзләрен ишеттеңме? Инде хәзер мин әйткәнне тыңла, Мәснугага да ирештер. Ир башыннан йөрмәсен кызың. Мин аңа үзем «талак» кычкырам: талак, талак, талак! Булдымы? Эшең бетте, кодагый! Шул минуттан кызыңны аерганмын дип исәплә!

— Тукта, тукта... Кем, Сәүбан! Нинди кыргыйлык бу? Хәзер болай аерылмыйлар... Арагызны судлашып өзегез. Балага алимент кем түли? Бүлешәсе әйберләрегез бар... — Мәгъфирә ярсып акыл чәчә башлаган иде, Сәүбан аны тиз туктатты:

— Болары, Иван әйтмешли, в рабочем порядке эшләнер, тёщакаем. Гуд бай!

Һәм Сәүбан ишекне ябып урамга ташланды. Хет көл, хет ела! Менә ул хатынын да аерып куйды. Әй, дөнья, буялган йонга! Ә бәлки дөрестер дә бу... Яңача яшим дисәң, иң элек үзеңне, җанны ятьмәдән, ышанычсыз җепләрдән араларга кирәк ласа.

Ул кинәт күңелендә иркенлек, ашкынулы омтылышлар елдырамы тоеп, февральнең соңгы бураны эченә кереп китте. «Бәтрәк» ир һич тә ялгыз түгел. Аның артында киләчәк адымнарына көч-куәт биргән Батырша нәселе тора бит. Тик ата-баба каршына кызганыч хәлдә һәм үкенечләр белән түгел, ә «Менә мин, сезнең варис, күрегез!» дип күкрәк киереп басасы иде.

## Соңгы очрашу

### I

Ниһаять, календарьдә 28 февраль, быелгы кышның соңгы көне. Сәгъдиев өчен үтә мөһим сәгатьләр килеп җитте, конкурс комиссиясе аның кандидатурасына карата нинди карар чыгарыр? Дөресен әйткәндә, Чардаклы хакимият бинасына

әйтелгән сәгатьтә килеп, көндәшләрен күргәч, Рәмзилнең кинәт кенә өмете суынды. Район башлыгы булырга өметләнгән дүрт кешенең дүртесе дә коеп куйган түрәләр иде. Чардаклыда милиция начальнигы булып торган майор Геннадий Васюхин, кызгылт чырайлы, чигә чәчләре агарган ир, каешыннан бүртеп чыккан саллы корсагы белән нәкъ менә хаким кәнәфие өчен яратылган кебек. Бу элке-сәлке йөргән ярдәмчеләренә үткен зәңгәр күзләрен бер генә тишеп карар, тегеләр шундук тыз-быз йөгерә башлар. Ә райондагы бар карак-угры моңардан шүрләп, кичекмәстән эз яздырыр...

Чардаклы көллиятенең директор урынбасары Галина Надеждина, киресенчә, ябык, төз гәүдәле, тик моны алтын кысалы, матур күзлеге, сары бөдрә чәчләре бизи. Эшлекле гүзәл затның коеп куйган үрнәге бит бу! Һәм ул, һичшиксез, сүз остасыдыр. Әлбәттә, шулай. Тәрбия эшләрен оештыручы педагог булып эшләгәч, әллә нинди зур-зур чаралар үткәреп, моның тел дә чарланган, кыюлык та хәттин ашкан инде.

Профсоюзлар эшендә peлəше кебек шомарган Әдһәм Нәҗмиевне дә Рәмзил байтактан белә. Бу да сүз эзләп кесәсенә керми. Зур залларда очрашулар ясап, халык белән эшләргә күнеккән. Хакимият башлыгы булып утырса, Әдһәмнең чәчәк атасы алда әле. Кием-салымның инәдән-җептән чыкканын гына кияр, йөреш парадтагы әфисәрнеке сыман булыр, кеше белән мөгамәләсе дә күпләр өчен этикет үрнәгенә әйләнер. Мондый эшем кешесе түрәлек шартын китерә белә инде ул.

Агропром вәкиле Зиннур Акбирдин кыяфәт, нәзакәтлелек ягыннан боларның берсенә дә охшамаган. Буе ике метрга якын, таза, кырыс ирдән дала җиле аңкый. Күк күзләрендә рәшә уйный сыман. Бер карасаң, нурлы иртә кебек, тыныч, ягымлы, ә икенче мизгелдә ул күкрәве, яшеннәре белән барысын тетрәтә. Юлдан чыгып барган Чардаклы идарәчеләренә, азгын ришвәтчеләргә бәлки нәкъ шундый иманнарын укыта торган усал түрә кирәктер дә...

Сәгъдиев әлеге дәгъвачылар рәтендә үз-үзенә читтән карап бәя бирергә тырышса да, искитәрлек әллә нәрсә тапмады. Дөрес, буй-сын бар. Әмма ул зыялылык белән дә балкымый, ихтыярлы чырай иясе булып та күзгә ташланмый. Ә ораторлык сыйфаты ташка үлчим: кырда йөреп, фермаларда көн үткәреп ничек тел шомартсын? Билләһи, боларны алданрак күрсә, ул кастингта катнашам, дип авыз да ачмас иде. Мәрзиягә янә белексез ирдән коләргә җай чыга инде...

Конкурста катнашучыларны кабинетка чакырып алдылар. Комиссия әгъзалары озын өстәлнең бер ягына, дәгъвачылар икенче якка урнашты. Мәҗлестә шулай ук җөмһүрият Президенты аппаратыннан Халиков, үзәкнең өч җаваплы хезмәткәре һәм районның бер төркем җаваплы кешеләре катнаша иде.

— Ягез, әфәнделәр, эшне башлап җибәрик, — дип, какча гәүдәле, ап-ак чәчле карт аякка басты. Кулына кәгазь тоткан конкурс комиссиясе рәисе тантаналы тавыш белән протокол өчен кирәкле сүзләрне сипте. Чардаклы муниципаль район хакимияте башлыгы вазифасына кемнәр гариза биргән, алар каршына нинди таләпләр куелган һәм бу таләпләргә кайсы дәгъвачы ныграк җавап бирә... Шуннан соң сүз конкурсантларга тапшырылды. Үзенең программасына нигезләнеп, һәркайсы дулкынланып, мавыгып төбәкне икътисади яктан күтәрү, халык тормышын яхшырту юлларын күрсәтте. Ниятләре дә, билгеләнгән чаралары да әйбәт, заманча. Тик менә проектның финанс ягына килгәч, чыгышларда да бертөрлелек һәм сүрелү галәмәте сизелде. Районны күтәрү өчен халыкка җиң сызганып эшләргә, чиновникларга кирәкмәгән чыгымнарны кыскартырга, аның каравы урындагы налогларны күбрәк җыярга. Һәм, билгеле,

банктан льготалы кредит алырга. Ә Надеждина хәтта Рәсәй Президентына хат язып, төбәктәге хәлнең мөшкеллеген аңлатырга һәм федераль ярдәм фондыннан акча алырга ниятләвен әйтте. Кемдер арттан «тот капчыгыңны» дип пышылдады.

Сәгъдиев чыгышында бөтен нәрсәне иңләп, колачлап алырга омтылмады. Ул бер генә сорау куйды: «Менә бездә икмәк элеваторы банкротлыкка төшеп ташландык хәлдә тора. Әгәр үз көчебез белән ремонтлап ходка җибәрсәк, ул район икътисадында нинди роль уйнаячак?» Шул мәсьәлә турында уйланган һәр сүзе, китергән саннары ифрат нигезле, ышандыргыч булды. Аның: «Элеваторны тиз арада аякка бастыруга юнәлгән эшчәнлекне башка хуҗалык өлкәләрендә, объектларда да кыю куллансак, аякка басарбыз, Иншалла!» — дигән йомгаклау сүзен залдагылар алкышлап каршылады. «Бу иптәш мәсьәләнең төбенә карый белә... Экономист шул!» дигән сүзләр ишетелде. Ниһаять, мәгълүм утырышта чал рәис иң мөһим, иң дулкынландыргыч карарны укыды: «Конкурс комиссиясе Чардаклы муниципаль район хакимияте постына иң уңышлы кандидат итеп «Таң» крәстиән хуҗалыгы фермеры Сәгъдиев Рәмзил Шаммасовичны тәкъдим итә...» Рәмзил аңышмый торды: һаман төннәрдә була торган хыялыйлык галәмәте генә түгелме? Мәгәр әлеге сүзләрдән соң бүлмәдәгеләр бер булып Рәмзилгә төбәлделәр. Билгеле, бу хәлдә аңа утырып тору килешми иде. Ул торып басты, як-ягына борылып кешеләрне сәламләде, сөенечен тыя алмыйча елмайды. Шулай көтмәгәндә аңа яңа вазифа — районга башлык булу бурычы йөкләнде.

Икенче көнне Чардаклы муниципаль район Советы депутатларының чираттагы сессиясендә аны рәсми рәвештә бу постка раслап та куйдылар. Халиков район хакимият башлыгын беренчеләрдән булып котлап болай диде:

— Сез, Рәмзил Шаммасович, тәҗрибәле икътисадчы буларак, районның үсеш мөмкинлекләрен ифрат дөрес күзаллыйсыз. Бик ачык, конкрет эш программагыз бар. Инде без хәзер сездән аны гамәлгә кертүегезне көтәбез.

Югары җитәкче Сәгъдиевнең гаиләсе, яшәү урыны белән дә җентекләп кызыксынды:

— Рәмзил Шаммасович, сер түгел, безнең дә башлардан кичкән нәрсә, югары постка ияләшү җиңел түгел. Бу җәһәттән асылыбызда аерым психологик киртәләр байтак. Шуңа күрә яңача яшәүгә кыю тотынырга кирәк. Мин сезгә Дөм-дөмдә озак калырга киңәш итмим. Гаиләгез белән тиз ара күченергә тырышыгыз. Фатир мәсьәләсендә проблема юк. Кыскасы, шәхси тормышны көйләү — сезнең беренче номерлы мәсьәлә, Сәгъдиев.

Чынлап та, бик урынлы киңәш булды бу. Югыйсә, Рәмзил үзе Чардаклыда ялгызы гына яшәп торырга исәпләгән иде. Янәсе, эшкә вакытын да күбрәк бирер, ирекләрәк тә булыр... Ә баксаң, район башлыгы вазифасына тотыну иң элек тылны ныгыту икән. Чынлап та, кунак-төшем каршылар өчен өең булмаса, эшеңә озатып, каршыларга хәләл җефетең аяк өсте тормаса, кием-салымыңны карамаса, син нинди хаким инде? Кунакханәдә гомер кичергән гастролёр яисә килешү буенча эш башкарган бизнес, шабаш кешесе син. Халыкта да мондыйга ни хөрмәт, ни ихтирам юк... Шулай уйлап, Рәмзил гаиләсен кичекмәстән Чардаклыга күчерергә кирәк дигән уйга килде.

Бу хәбәрне балалар ура кычкырып каршылады.

Һәдия ана кисәк сагышка батты. Ә хатыны Мәрзия тискәреләнеп аяк терәде, әллә нинди уйламаган катлаулы мәсьәләләр китереп чыгарды. «Бу өйне рәткә китереп күпме акча түктек. Аны кем сатып алыр? Ә ташласак, хаким йорты, дип тормас Дөм-дөм халкы, идәненә, түшәменә кадәр сүтеп үзенә ташыр».

Менә бит ничек! Зур-зур ашкынулар белән янәшә әллә нинди шөкәтсез тормыш ваклыклары тора икән. Аңа Сергеевкадагы фермерлыгы белән дә араны өзәргә кирәк иде. Рәмзил утарга хакимият башлыгы рәвешендә әйләнеп кайткач, Абрам аңа рәнҗү, үпкә белдерер дип көткән иде. Янәсе, шундый зур эшне качып-посып кылгач, син миңа нинди компаньон? Юк! Туганы кебек якын күреп, аның сөенечен уртаклашты. Сөйләнә-сөйләнә чәй кайнатты. Янәсе, Рәмзилнең булдыклы егет икәнен ул әллә кайчан таныган, үзенә хезмәттәш итеп алган. Менә олы нәчәльник булгач, Рәмзил Сәгъдиев та Абрам фермерны онытмас, аңа гел иске дус итеп, ярдәм кулын сузар...

Штельман белән сөйләшеп байтак вакыт узды. Кичен гадәтенчә машинасы белән Дания эшләгән сыерлар фермасына сугылды: «Әй, Дөм-дөм карлыгачы, әйдә, кайтабыз!»

Әмма савучы хатын үзе генә чыкмады. Аның янәшәсендә Сәүбанны күреп, Рәмзил ифрат гаҗәпләнде: «Василә үзенең Василен тапкан бит. Менә бу — бәхетле чишелеш!»

Ә Дания белән Сәүбан исә Рәмзилнең тормышындагы әверелешкә шаккатканнар. Шаккатырсың шул, гап-гади фермер район түрәсенә әйләнсен әле! Боларның гаҗәпләнүләре дә, балаларча сөенүләре дә йөзләренә, күзләренә бәреп чыккан.

Машинада кайтканда, Рәмзил арткы утыргычта бер-берсенә сыенышып утырган парга көзге аша еш-еш күз салды. Һәм уйланды: «Әгәр Дөм-дөмдәге өйне боларга калдырса, бүләк ясап бирсә...»

Сәгъдиевнең киләп сарып торырга вакыты юк иде. Бу хакта анык рәвештә хатыны Мәрзия белән сөйләште. Аның белән Чардаклыга барып яшәячәк йортын карады ир. Үзе канәгать калды, иң мөһиме — аны хатынның ошатуы кирәк иде. Йорт, Ходайга шөкер, Мәрзиядә яхшы тәэсир тудырды. Хәтта күченеп килү көнен дә ачыкладылар.

Һәм менә өч көн үткәч, Чардаклыдан кайтышлый, Сәгъдиев янә Даниянең эш урынына сугылды. Хатынны сөендергән иң беренче хәбәре шул булды: «Гарданов «Хыялый кыз»ны укыган. Тәэсирләре әйбәт. Эшкәртеп, башкала журналына басарга бирәчәк».

Ә Дөм-дөмгә җитеп, Данияне турыларына төшереп калдырганда, Рәмзил аңа тагын бер шатлык өстәде:

— Иртәгә эштән соң, җиделәр тирәсендә Сәүбаның белән безгә кил. Кара аны, онытма, чәй көйләп көтәбез!

Иртәгесен Сәгъдиев үзе эштән беркадәр кичегеп кайтты: «Яңа эштә сәгать теле карап тора торган түгел, гафу итегез, кунаклар», — дип матур итеп киенгән Дания һәм Сәүбан белән күреште.

Гөрләшеп чәй эчтеләр. Һәрвакыттагыча Мәрзиянең коймак, бәлешләре уңган. Сәүбан, бахыр, башта тартыныбрак торган иде. Мәрзиянең: «Аша, Сәүбан, аша, сиңа салкын будканда болар бик тансыктыр», — дип аерым фатиха бирүен ишеткәч, тары коймагын урды гына. Ашка амин тоткач, Дания савыт-саба юышам дип, кухняга китте. Рәмзил шулара кунакның кылларын тартып карады:

— Ничек соң, киләчәккә нинди исәпләр, Сәүбан кордаш? Яланда ялгыз яшәү туйдыргандыр...

— Әй, Рәмзил, Дания белән бүгеннән бергә яшәп китәр идек тә, хуты юк бит. Ни шалаш, ни алачык коралмыйм.

— Ә болай ике арагыз ныкмы соң? Вакытлы мавыгу гына түгелме?..

— Юк, Рәмзил, без икебез дә сират күперен кичеп, янә табыштык. Инде Ходай безгә гаилә корырга язгандыр.

Байтак шулай эчкерсез сөйләшеп торгач, хатыннар кунак залына чыктылар. Мөһим сүз әйткәндә, Рәмзилнең аякка баса торган гадәте бар. Әйтәсе уен да, тыңлыйсы кешене дә зурлау галәмәте инде бу. Менә ул торып басты:

— Дуслар, без Мәрзия белән сөйләштек, киңәшләштек тә бер тәкъдим ясарга булдык. Дания, Сәүбан, кавышу уенда торасыз икән, яшьлектә сезнең яратышканыгыз мәгълүм. Язмыш сынауларын үтеп, менә янә бер-берегезгә тартыласыз. Китапка язарлык кыйсса шул бу. Вәсил-Вәсилә мәхәббәте, иншалла, басылып чыгар. Һәм без Мәрзия белән китап геройларының гына түгел, сезнең дә бик бәхетле булуыгызны телибез, Сәүбан! Шуның өчен киткәндә сезгә менә бу йортның ачкычын тапшырырга булдык. Яшәгез матур итеп, берсеннән-берсе чибәр кызлар, малайлар үстереп. Сезнең нәсел Дөм-дөмнең чын хуҗасы булып күтәрелсен. Килештекме?

Һәм ул Сәүбан каршына барып ирнең иңенә сугып алды. Даниянең кулына кагылды. Тик болар һәр икесе, ни әйтергә дә белми, аптырашып, тынып калдылар. Дөм-дөм кешеләре кайгы-хәсрәткә ифрат тиз ышансалар да, шатлык-сөенечкә, алдар көн хәбәре сыман, шикләнеп карыйлар шул, күнекмәгәннәр...

— Карале, — дип кычкырды Мәрзия. — Минем ирне район башлыгы ясап юкка сайламаганнар икән бит. Май сандугачы диярсең! Ничек килешле сайрый. Маладис, Сәгъдиев! Ә йортны чынлап сезгә калдырабыз, Дания. Тик, Сәүбан, кара аны, тракторыңны ихатага кертеп минем чәчәкләремне, гөлләремне харап итмә! Килеп, җаныңны алырмын, белдеңме?

Менә шуннан соң ни көләргә, ни еларга белмәде бу пар. Тик Дания бу кадерле кичтә бер нәрсәне бик яхшы аңлады. Аның язмыш очлыгы, ниһаять, уңга борылган... Кәмит утыргычыннан исән-имин төште, котылды микәнни ул?

## II

Өйдәге әйберләрнең җәмгысын төйнисен төйнәп, тутырасын тутырып, Сәгъдиевлар мартның ялга каршы төнен Дөм-дөмдә уздырдылар. Ир сәгатьләрен йокылы-уяулы үткәрде, Ильич, мөгаен, күрешүгә килми калмас... Чынлап та, күзләрен йомган гына иде, ул таныш бәрхет тавышны ишетте:

— Сәгъдиев!

— Владимир Ильич, түрдән узыгыз! Күптән күренмәдегез. Безгә сугылырга вакыт тапмадыгызмы?

Хуҗа инде төшенеп килә. Кунак үзен эш, хәрәкәт кешесе итеп күзаллаганны ярата:

— Миңа һәрчак вакыт җитми, Сәгъдиев, янә ике фронтта көрәш алып барырга туры килде. Бер яктан, кабахәт эсерлар туктаусыз яла яга. Имеш, Ульянов-Ленин халык комиссарлары Советы рәисе булып эшләгәндә, Николай патшаны аттырган. Оятсызлык шул дәрәҗәгә җитә ки, янәсе, мин аны гаиләсе белән теге дөньяга озаттырганмын... Яисә болар тагын тузга язмаслык гайбәт уйлап чыгаралар. Мин Герман империалистлары белән яшерен килешү төзегәнмен дә, тегеләрдән миллионлап марка алып, Рәсәйдә революция ясатканмын. Бу — нинди ахмаклык! Революцияне экспорт юлы белән ясарга буламы? Моңа Гоголь персонажы Малиновның фантазиясе дә җитмәс.

Икенче яклап, Сәгъдиев, коммунистик хәрәкәттә уң оппортунизм чәчәк ата. Уйлап кара, гамәлдә шундый төшенчәләр йөри: Рәсәй Федерациясе коммунистлары, Кытай коммунистлары, Куба коммунистлары... Ә кая коммунистик интернационал? «Бөтен дөнья пролетариаты, берләшегез!» лозунгы кая? Бу берлек, әлеге өндәү мондагыларга кирәкми. Чөнки

оппортунистлар күптән эшче-крәстиан мәнфәгатен базарга чыгарып саткан. Аларга тик Дәүләт Думасында урын яуларга да Кремль сыеннан өлеш алырга гына кирәк... Әмма шуңа карамастан, минем исем белән туктаусыз авыз чайкыйлар үзләре.

— Әйе, хөрмәтле Ленин, сезгә һаман тынгылык юк бугай шул...

— Дөресен әйткәндә, үзем дә арыдым...

— Кеше өчен бик табигый тойгы бу, Ильич. Инсан ничаклы даһи булмасын, рухка әверелә алмый ул. Хәер, моңа хаҗәт тә юк. Җиһанда чын рух бар инде. Бу илаһи зат — Аллаһ! Кеше үлгәч, бәдәне җирләнергә, ә җаны гарешкә очарга тиеш... Җиргә тапшырылмаган бәдән җанын исә күк тә алмый, туфрак та кабул итми аны, адашкан, бәргәләнгән һәм имгәтелгән кош хәлендә кала бу бәхетсез җан, Владимир Ильич...

Ильич кисәк сагаеп калды, күзләрен кысып Рәмзилгә текәлде:

— Кем әйтте сиңа моны... Каян белдең?

— Канун бар шундый, Ильич!

Юлбашчының шеше тулган бугай, ачылып китте:

— Мин әллә нинди михнәтләр чигеп, кеше затын бәхетле итәр өчен көрәштем, Сәгъдиев. Ә адәмнәр үзләре кансыз, бәгырьсез икән. Сөягең кипкәнче, тирең корыганчы үзләренә хезмәткә җигәләр. Соңлап кына акыл иреште шул. Эксплуатациянең мондый затсыз төре дә булган, каһәрең. Мавзолейда катырып күргәзмә ясаулары Ленинны мумия хәленә китереп тә эксплуатацияләү түгелмени?

— Сез, хөрмәтле Ленин, тарихта тиңе булмаган патша кыяфәтендә дөнья тарихына кердегез. Азатлык, тигезлек, бәхет идеяләре белән рухландырып, хезмәт халкын гадел көрәшкә күтәрдегез. Аннары эшче-крәстиан мәмләкәте төзеп, уйлаганнарыгызны гамәлгә ашыру юлына керештегез. Мин казый түгел, моңа бәя бирмим. Ләкин башкарган байтак эшләрегез белән кешелек хәтерендә, намуслы йөрәкләрдә мәңгегә урын алдыгыз. Инде сезгә хәзер ял, тынычлык кирәк, Владимир Ильич! Һәм кеше буларак, якты матур хатирәләр белән генә халык хәтерендә калыгыз сез!

— Әйе, Сәгъдиев, гасыр буена пьедесталга басып кул сузып өндәүләр дә мине туйдырды. Талды минем беләк, рәхәтләнеп кулларны кушырасы килә! Кушырырга да сабый кебек изрәп йокыга талырга... Шәп бит!

— Алай булса, Владимир Ильич, мин сезнең белән кешеләрчә хушлашыр идем. Без инде янәдән очрашыр инсаннар түгел бугай. Мин иртәгәдән бу ятакны ташлыйм.

— Кая китәсез, Сәгъдиев?

— Теләгәнемә ирештем, Ильич. Зур юлга чыгам.

— Тәк, тәк... Ә йортың? Аны нишләтәсең?

— Рәнҗетелгәннәргә бирәм. Аларның мәгыйшәте түгәрәкләнсә, сезгә дә борчылыр урын калмас, Ильич! Янәшәндәге кеше бәхетен кайгырту һәрбер инсан өчен төп канун түгелмени, хөрмәтле юлбашчы?

«Кунак» уйланып калды. «Әйе», дип тә җөпләмәде, «юк» дип тә кулы белән гадәтенчә һава кисмәде. Ә шактый көрчектә торып әйткән сүзләре белән ул Рәмзилне тәмам шаккатырды:

— Минем тәгълимат сыйныф, кавемгә юнәлгән, Сәгъдиев. Без, большевиклар, Рәсәйдәге генә түгел, ә дөньядагы эшче-крәстиан бәхете өчен көрәшәбез. Ә аерым индивид, зат мәгыйшәте безне кызыксындырмый. Хәтта кирәксә, инде бер әйткәнемчә, эшче-крәстиан мәнфәгатьләре өчен шәхеснең корбан булуын хуплыйбыз да. Нишлисең? Революцион көрәш таләбе шундый. Кыскасы, бәхетле индивид — безнең көрәш максаты түгел, пардон, Сәгъдиев! Күрәм,

әлегә бу тирәдә миңа эш калмый. Димәк, китүем хәерле. Мин зарлыларга, юксылларга кирәк!

— Кабере булмагач, моның бөкресе тураймый инде, — диде хуҗадагы эчке тавыш.

Төнге кунак әллә ишекне ачып чыкты, әллә әфсен-төфсен хикмәте белән аның аша гына үтте, ул бүлмәдән шым гына югалды. Өрәк-кунакны иң шүрләткән, өркеткән нәрсә шәмаил да түгел, мәче, әтәч тә түгел, ә фикри көрчек икән, дип уйлап кисәк үзе өчен ачыш ясады Рәмзил. Аерым кешене, зарлыны социаль яктан имин-аман итмичә, бөтен бер сыйныфны ничек бәхетле ясамак кирәк?.. Ә ул бөтендөнья пролетариаты хакында кайгырта, боларга коммунизм төзеп бирергә җыена, имеш... Бу бит көрчек! Күкне күккә асып куярга теләү белән бер! Мондый тузга язмаслык глобаль проект белән йөргән юлбашчыга Чардаклыдагы прагмат Рәмзил хаким янәшәсендә урын табылмый, билгеле. Хуш, «Төнге кунак!»

Март азагында бертөркем эшче Чардаклы муниципаль район хакимияте башлыгы Рәмзил Сәгъдиев әмере белән Дөм-дөмдәге В.И.Ленин һәйкәлен пьедесталдан ычкындырып, башкаладагы тарих музейларының берсенә илтеп тапшырды. Сын бик үзенчәлекле итеп коелганга, аны экспонат итеп куячаклар.

...Шигъриятле Ык буйларына чын-чынлап яз килде. Рәмзил Сәгъдиев район хакиме сыйфатында тәүге елын эшли башлаганга, язның мул сулы булып килүен теләгән иде. Булды! Елгалар да ярдан әллә кайларга җәелеп ташыды, ләйсән яңгырлар да чиләкләп койды. Инде берәр атнадан игенчеләр дәррәү кузгалып чәчүгә төшәр. Шулай ашлык өчен зур көрәш башланып китәр. Болын, яланнарны яшеллек каплауга, көтүче чыбыркылары шартлар, терлекләр сусыл үләнгә ябырылыр. Сөт күбәер, артым ишәер... Җир уяну, кошлар җыры, мәрхәмәтле кыйбла җилләре кешеләрне дәртләндерми каламы соң? Мәгәр хезмәт шавы быел көчлерәк яңгырар, эшләр дә яхшырак оештырылыр һәм бу үзгәрешләр хезмәт халкы йөрәгендә киләчәк көннәрнең муллык-иминлек белән туасына зуррак ышаныч уятыр... Шулай булсын, Чардаклы төбәгендәге мәгыйшәт нәкъ аның яшь башлыгы Рәмзил Сәгъдиев теләгәнчә уң барсын! Хәзер бездә, ышангансыздыр шәт, ак теләкле инсаннар заманы башланды бит.

— Хуш, юлбашчы, сау бул, Бакый Әрвах!

## СӘЛАМӘТ ТӘНДӘ... СӘЛӘМӘ РУХ?

Әдәбият елын исән-сау гына озатып җибәрү куанычыннан айнып килəбез сыман инде. Төрле сүзләр ишеттек: бәгъзеләр ялтыравыклы көннәрне учка себереп алып, «менә бит!» дип җиһанга сөрән салудан тәм тапты — сер түгел; шулай да, андый берән-сәрәннәргә диванага карагандай карап, артка бер күз ташлаганнан соң тозлап-борычлап төкеренүчеләр бу юлы да, гадәттәгечә, күбрәк булды, билгеле. Мин исә, яшермим, ел күркәм үтте дигән фикердә. Телевидениедән, матбугаттан, зур мөнбәрләрдән торымнан-торымга «Әдәбият!», «Тукай!» сүзләре ишетелеп торды, җәмәгатьчелек, күлмәге эченә ата кырмыска йөгергәндәй, беркадәр хәрәкәтләнеп-борчылып алгалады... Башкалар... Шуннан да артыгын дәгъва итәргә кирәк идеме икән? Әдәбият кебек гигант тармакны тезенә бастырып терәү куяр өчен генә дә күп вакыт, бик күп вакыт, ә иң мөһиме — бик күп тырышлык кирәк ләбаса.

Әдәбият бүген ни тере, ни үле хәлдә, дисәм, беркемне дә сискәндермәм. Алга таба вакыйгалар үсеш-үзгәрешенең ике гадидән-гади юлы бар. Беренчесе — әдәбиятның исән калуы. Ләкин моның өчен аңа яхшы инвестицияләр кирәк.

Татарстаныбызда Универсиада, Су төрләре буенча чемпионат уздыру өчен күпме спорт корылмалары төзелде. Аларның күпмесе үзен аклады? Үзгәләре кайчан аклап бетерәчәк? Шәхсән миндә, вариант рәвешендә, «һичкайчан» дигән җавап та бар. Өстәвенә, байтакларының яңгыр дими, кар дими төзелгәнен дә күрдек бит. Димәк, хакы каплаганчы ук бу корылмаларның җимерелеп төшүе дә ихтимал? Алла сакласын! Спорт яхшы нәрсә, әлбәттә. Кирәкле, игътибарга лаек нәрсә. Без бит киләчәк буыннарның сәламәтлеге турында борчылабыз! Ә әдәбият? Аның дәвамнарны тәрбияләүдә роле кимрәкме әллә? Юк. Һәрхәлдә, спорттан һич кенә дә ким түгел. Вәләкин, спорт бәдәнне савыктырса, әдәбият рухны савыктыра. Ә рухи яктан без бигүк сау түгел кебек әле. Безнең мәктәп укучылары арасында бер-берсен канга батырып кыйный, ветеран картларны мәсхәрә итә, укытучыларын атып үтерә, әти-әниләрен суя торганнары да бар...

Әдәбият үзен аклаячакмы? Һичшиксез. Бүген үк эшкә керешеп, хәреф танырлык балаларны әдәби әсәрләр үрнәгендә үстерергә-үсендерергә алынсак, унбиш елдан ошбу гамәлнең күркәм җимешләреннән авыз итүебез бәхәссез.

Әдәбиятны җәмгыять өчен гаять файдалы итәр өчен бездә, Татарстанда, бөтен мөмкинлекләр бар югыйсә: бай тарихлы, ныклы нигезле — бренд! — газета-журналларыбыз (кайберләре хәтта Октябрь түнтәрелешенә кадәр ачылырга өлгергән), үзенең иң яхшы традицияләренә тугры калган һәм бүгенгәчә үтә сыйфатлы продукция чыгара торган нәшриятыбыз, өлкәннәр арасында да, яшьләр арасында да осталарча язучы каләм ияләребез... Аларның энергиясен дөрес юлга юнәлтәсе генә ләбаса! Инвестиция генә кирәк! Бусы әдәбият исән булсын дисәк, әлбәттә. Инде җан тәслим кылсын дисәк, моның өчен әллә ни тырышырга кирәк түгел. Шушылай дәвам итик кенә...

**Рүзәл МӨХӘММӘТША**



Илсөяр
Иксанова

# ГОМЕРЕМ ФАСЫЛЛАРЫ

*Февраль*
*(Дөньяга килгән аем)*

***

Чатнама суыклар,
Җәяүле бураннар,
Һәм тәүге тамчылар, —
Яз алда.

Бу — минем халәтем —
Язмышым,
Өметем,
Ышанып яшәвем язларга.

*Март*
*(Әниемнең туган көне)*

## Әни

Йомшак кына елмаюлы йөзең
Күз алдыма килә таңнарда.
Әни, әни, еллар кирәк булды
Синең күңелеңне аңларга.

Әни, әни, кадерлисе килә,
Житмәгәндер кебек җылыбыз.
Бер кайгыга, бер шатлыкка салган
Мең төсмерле гомер җырың без.

Йомшак эндәшүең ишетәм күк
Тынлыгында туган нигезнең.
Әни, әни, ничек өзелә үзәк! —
Үзәгебез идең син безнең.

Әни, әни, кадерлисе килә,
Житмәгәндер кебек җылыбыз.
Бер кайгыга, бер шатлыкка салган
Мең төсмерле гомер җырың без.

Йомшак кына карашларың калган
Тәрәзләрне сөртәм тын өреп.
Синең күзләр төсле тәрәзәләр
Безне көтә һаман тилмереп.

Әни, әни, кадерлисе килә,
Житмәгәндер кебек җылыбыз.
Бәгыреңне гел сызлатып торган
Мең төсмерле гомер җырың без.

---

Илсөяр ИКСАНОВА — *шагыйрә; «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

*Апрель*

## Тукайга

Кичер, диеп гафу сорамыйм мин,
Гөнаһлылар, әнә, сорасын!
Туры Тукай, өстебездә безнең
Намусыбыз төсле торасың.

«Болгар»ыңны синең җимерделәр,
Әле ярый исән Кырлаең.
Белеп ятасыңдыр бу заманда
Сорыкортлар ниләр кылганын.

Синең кебек мин дә яланаяк
Чыгып йөгерердәй буламын,
Күргән саен карагруһларның
Телне, матбугатны буганын.

Ничекләр соң пакьлыйк бу дөньяны! —
Аһ, керләнә бара җан гына...
Кичер, диеп гафу сорый алмыйм,
Гөнаһым юк синең алдыңда.

Шагыйрь булып яшәү газап икән!
Хак яраткач Ходам, ни кылыйм?!
Юккамыни синең әрнүләрең
Бәгыремдә минем сулкылдый...

*Май*

## 9 май

Шау-гөр килеп шәһәр бәйрәм итә.
Салют балкый Казан күгендә.
Йөрәгемне төеп утлы төен,
Авыр төер тора күңелдә.

Кемдер бүген үксеп-үксеп елый,
Кемдер көлә,
Кемдер шатлана.
Йә көләргә иде,
Йә еларга,
Җанымдагы төен, шартла, йә!..

Җиңелрәк булып китәр иде,
Кыса гына төен сулышны.
Шатланырга дисәң, нинди шатлык —
Без бит җиңгән,
Җиңгән сугышны!

Без бит җиңгән,
Дошман юлларына
Киртә итеп кеше салынган.
Миллионлап киткән адәм башы, —
Кем хәбәрсез,
Кемдер табылган...
Без бит җиңгән,
Әй син, Бөек халкым,
Батырлыгың хәттин ашканга
Без бит җиңгән.
Доган — җиңү булган,
Синең Мәккәң булган башкала.
Башкалага дошман керә алмас,
Башкалада Үзе баш кага.

Яу кырында шанлы орыш бара,
Себерләрдә нәсел кырыш бара,
Башкалада Үзе баш кага...

Бүген бәйрәм.
Халкым көлә-көлә,
Елый-елый бәйрәм иткәндә,
Әй кысыла сулыш,
Тын кысыла,
Әй үртәлә күңел,
Үртәлә.

Кичәгедә кичкән газап кала,
Яңа көн туармы иртәгә?!

*Июнь*

## Сабантуй

Җир бәйрәме,
        җыр бәйрәме,
                җан бәйрәме —
Сабантуй.
Дәртләндерә йөрәкләрне
Сабантуйда килгән уй:
Нинди гүзәл минем халкым!
Бизәге, өлгеләре!
Татарымның күңеле күк
Сабантуй сөлгеләре!

*Июль*

## Җәйге этюдлар

**1**

Илаһи күк кыйпылчыгымыни! —
Күкчәчәкләр арыш арасында.
Әйтерсең лә саклап тора алар
Яман күздән, тормыш карасыннан.

Күкчәчәкләр саклап тора безне —
Арыш басуларын,
күңел кырын.
Күңелеңә кунмас дөнья кере,
Ишетә алсаң күкчәчәкләр җырын.

**2**

Башаклар серкә очыра, —
Кыр өсте — яшькелт рәшә.
Тын гына,
Тибрәлеп кенә
Җир белән күк сөйләшә...

**3**

Каен җиләкләре,
кыңгыраулар,
мәтрүшкәләр... —
Июль урманы.
Күрәзәче кәккүк, юмартланып,
Миңа йөз ел гомер юрады.

Каеннарның башын сыйпап үткән
Ак болытка яшел ягыла.
Йөз ел гомергә тиң бер сулышы —
Җәй җәннәте туган ягымда!

**4**

Корама болынның кисәге — шәһәрдә.
Кыендыр болынга
Шәһәрдә яшәргә.

*Август*

***

Күңелемнең моңсу фасылы бу,
Гомеремнең моңсу фасылы.
Ак күбәләк булып җаннар оча —
Җәй азагы,
Август ахыры.

Күтәрелә кошлар төркем-төркем —
Җыеналар ерак юлларга.
Канат очы каглып-каглып киткән
Болытлары әзер еларга.

Юатырга теләп, Кояш карый
Күксел болытларны аралап.
Болыт аша моңсу елмаюы
Йөрәгемне куя яралап.

Бөтерелә ап-ак күбәләкләр —
Җанкаемның җаны кайсыдыр?
...Мине ялгыз иткән август җирдә —
Күңелемнең моңсу фасылы.

*Сентябрь*

***

Сарылы-яшелле фасыл бу.
Бу фасыл яшелле-сарылы.
Җәйләрнең күзләргә атлавы
Нишләптер күңелгә кагылды.

Сап-сары яфрак шикелле
Өзелеп төшәр күк бу йөрәк.
Ямь-яшел тойгылар леперди:
Без җилдән көчлерәк, көчлерәк...

Яшелле-сарылы фасыл бу.
Бу фасыл сарылы-яшелле.
Күзләрнең түренә агылган
Болытка яшердем яшемне.

Кемнедер юатыр,
Кемнедер
Үртәр дә елатыр бу болыт.
Әлегә тойгылар талпына
Яшелле-сарылы моң булып.

*Октябрь*

***

Сары яфрак булып
тәрәзәдән керде — Көз.
Күксел томан булып
күтәрелеп китте — Җәй.
Аксыл офыкларда — кыш шәүләсе.

Һаваларда тибрәп торган
Татлы җәй,
Дымлы көз исенә
Кушыла килә
сыкы —
Кыш исе.

*Ноябрь*

***

Аһ, кар яуган!
Сагындырган аклык!
Ноябрьнең кара таңнарын
Ап-ак итеп
Беренче кар яуган, —
Иркенәеп китте җаннарым.

Аклык җитми икән...
Әйтәм жирле
Кара көздә күңел күшегә.
Беренче кар төсле
сафландыргыч
Якты хисләр кирәк кешегә!

*Декабрь*

***

Бу елның да соңгы ае керде,
Иске елның яуды яңа кары.
«Шатлан!» — диеп, чәчләремә кунды,
Үбеп очты кайнар яңакларны.

Очып китте Яңа елга каршы, —
«Шатлан!» — диеп, тагын кемгә кунар?
Күзләремә тулган моңнарымны
Тоеп өлгерденме, бәгърем кар?!

*Гыйнвар*

## Алдану

Гыйнвар.
Плюс биш, плюс өч.
Бөрегә тулышкан агачлар.
Ак өмет шикелле күкләрдән
Ишелә, ишелә юеш кар.

Бик тиздән ак чәчәк күлмәген
Кияргә җыена алмагач.

(Алдагы зәмһәрир суыклар
Калдырыр бөтенләй ялангач.)

Гыйнвар.
Агачлар бөредә.
Ымсынып саташу бу бары.
...Хәтердә яңарды милләтнең
«Яз!» диеп алданган еллары.

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рәфкать
Шаһиев

# КИТМӘ, ӘТИ!

ХИКӘЯ

Берәүләрнең әтиләре яраланып кулсыз-аяксыз, берәүләрнеке исә тәненә дошманнан бер шырпы да тидерми кайтты. Кемнәрнекедер күз күрмәгән, колак ишетмәгән җирләрдә батырларча һәлак булды, хәбәрсез югалды. Ә Мәүлетнең әтисе... Мәүлетнеке дә югалды. Югалды да табылды. Табылды да тагын югалды...

***

Иртәрәк киленде бугай. Ашлама төялгән баржа күренми иде әле. Мәүлет машинасының рулен ике кулы белән кочаклап, башын шунда салды һәм пристаньда кайнашучыларны тыныч кына күзәтә башлады. Андагы халык ыгы-зыгы килә иде: берәүләр кемнәрнедер каршы ала, икенчеләре озата. Күз күреме җитмәслек булып җәелгән Идел өсте дә буш тормый. Зур-зур теплоходлар, метеорлар, кечкенә катерлар Казан ягыннан да, Ульян ягыннан да килә тора. Кояш нурларында ялтыраган Идел өстенә ак күбек дулкыннар тарала.

Эчке бер рәхәтлек кичереп пристань тормышын күзәтеп утырган Мәүлетне йокы баса башлады. Идел өстендә биегән кояш керфекләрне аска тарта. Колхоз эшеннән соң төне буе Гөлҗиһаны белән печән кайтарып бик нык алҗыган тәне, кояш җылысына эләккән балавыз кебек, эреп бара иде.

— Юк, болай булмый. Бит-кулларны салкын суда чылатып, буыннарны язып менәргә кирәк, — дип, Мәүлет кабинасыннан сикереп төште дә Иделгә юнәлде.

Бая оеп утырганда сизми дә калган: пристаньга зур гына теплоход килеп туктаган икән. Саллы гына агайлар, көяз ханымнар, чибәр кызлар җай гына гәпләшеп, Идел яры өстендә иркенләп, таралып урнашкан Тәтешне күзәтәләр иде. Болгар ханнарының эзен саклаган, язларын ап-ак чия, алмагач чәчәкләренә чумган, ә бүген бөтен Идел өстенә алма исе таратып, яр өстендә горур гына утырган борынгы шәһәр бик матур иде. Тәтеш — кем өчендер Иделдән килгән су, ләм, бака ефәге исләренә кадәр якын туган як, ә кемнәргәдер узып барышлый гына тукталып торган иске бер шәһәр. Шуңа да берәүләре, теплоходтан төшеп, өйгә, туган йортка дип, биек агач баскычтан шәһәргә күтәрелә. Калганнары исә Ульян каласына таба юл ала.

Җиткән ике кызы белән Ульянга юл тотучы шәп гәүдәле, ипләп кенә олыгаеп килүче ирнең, Тәтеш күренүгә, йөрәге күкрәк читлегеннән чыгардай булып тибәргә тотынды. Чәчләренә вакытыннан алда кырау төшкән, алып гәүдәле, шәмдәй таза бу ирнең елыйсы килә иде. Аның җанында дөрләгән утны теплоходтагылар күрсә, янудан куркып, теплоходта бер кеше дә калмас иде, шәт.

---

Рәфкать ШАҺИЕВ (1968) *– язучы, галим, филология фәннәре кандидаты. «Атамалар – тарих ачкычы» (2004), «Ризаэддин Фәхреддин. Тормыш юлы, иҗади мирасы» (2009), «Нефть төбәге микротопонимнары сүзлеге» (2010); «Музей заллары буйлап. Р.Фәхреддин эзләреннән» (2014) кебек китаплар авторы. Әлмәттә яши.*

Мәүлет читкәрәк китте, дулкыннар иркәләп шомарткан ташларга басты. Уч тутырып салкынча су алды, кулларын, битен юды. Башы сафланып, тәне җиңеләеп китте. Керфекләргә ябышкан йокының әсәре дә калмады. Ул тураеп, кояшка чагылган күзләрен кыса төшеп, Идел аръягына карап тора башлады. Шулвакыт нигәдер Мәүлетнең колак яфраклары кызышып куйды. Яннан берәүнең үтәли тишәрдәй булып карап торуын бөтен күзәнәге белән сизде. Ул теплоходка таба борылган иде, палубадан:

— Исәнмесез, егет! Сезне бер генә минутка мөмкинме? Кайсы яклардан, кайсы авылдан буласыз? — диде теге шәп гәүдәле ир.

— Сез миңамы? — диде Мәүлет, башын күтәреп. Армиядә хезмәт итүен санамаганда, Тәтештән ары китмәгән Мәүлет өчен «сез» дип дәшүләре мәзәгрәк тоелды.

— Мондый дәү теплоходта йөзеп йөргән абзый безнең кечкенә авылны белер микән сон?! Берлек дигән авылдан булам мин, абзый кеше, — диде ул, тагын да турая төшеп.

«Берлек» сүзен ишетүгә, әлеге мәһабәт гәүдәле ирнең өстенә салкын су койгандай булды. Бугаз төене бер күтәрелде, бер төште. Маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Йөрәге бугазына җиткән кебек тоелды. Әйе, акыл кайчак ялгышып куйса да, күңел дигәнең ялгышырга тиеш түгел. Бу яшь ирне күрүгә, аның йөрәге юкка гына чәбәләнә башламагандыр. Әкият дигәнең юктан бар булмаган бит инде. Дөньяда могҗиза булмый дип кем әйтер? Юлга кузгалганда ук ниндидер бер могҗизага өметләнеп чыкты бит ул. Бу могҗиза — Иделдә бит-кулларын чылатып, горур гына басып торган Мәүлет. Чыннан да, Идел буендагы ташларда бу агайның яшьлеге — Мәүлет басып тора иде.

Теплоход әкрен генә пристаньнан кузгала башлады.

Сугышларны кичкән ир үзен кулга алырлык көч тапты. Һәм, тыныч булырга тырышып:

— Ә син Берлекнең кем малае буласын? — Ир үзенең «сез»дән «син»гә күчкәнен сизми дә калды.

— Гомә-р малае-е-ы, — дип кычкырды Мәүлет, суза төшеп, нигә алай дип әйткәнен үзе дә аңламыйча. Югыйсә, гаиләсе — бер көтү баласы, хатыны белән ике йорт аша гына яшәп ятучы Гомәрнең аларга бер катнашы да юк иде.

— Ю-ук, син Гомәр малае түге-е-л, син мине-е-м улым! Ишетәсеңме-е, син минем улы-ым. Минем улым — Мәүле-е-т си-и-и-н!

Бая «Берлек» дигәнне ишеткәч, палубада басып торган ир нинди халәттә булса, «улым» дигән сүз хәзер Мәүлетне шул халәткә салды. Ул бермәлгә торараштай катып калды. Ничек инде аның улы? Аның әтисе сугышта хәбәрсез югалды бит. Бары бер хаты килде. Китте дә югалды...

Ир теплоход ерагайганчы тизрәк әйтеп калыйм дип ашыга иде.

— Иртәгә без шушы вакытта яңадан Тәтеш аша узабыз. Әниең белән Сөембикәне дә алып кил. Аларны да алып кил, улым!

Әкрәм Идел ярында басып торган бу яшь ирнең үз малае булуына каян шулкадәр ышангандыр, үзе дә аңламады. Тик шәмдәй төз, горур бу ирнең үз улы Мәүлет булуында аның энә очы кадәр дә шиге юк иде. Шуңа да ул бер шикләнмичә, «син минем улым», диде.

Ашлама төялгән баржа кайчан килде, машинага кемнәр, ничек төяделәр — Мәүлет аңышмый да калды. Колхозга кайтып җиткәнен, складка бушатканын — берсен дә хәтерләми. Барысы да гипнозланган кебек эшләнде.

Кемнән чыккандыр, ник шулай атап йөртә башлаганнардыр, колхозның машина-трактор паркын «әтрәт» дип йөртәләр алар. Мәүлет машинасын әтрәткә түгел, тизрәк өйләренә куды. Аның йөрәге күкрәгеннән чыгардай булып сикерә, күңелендә әйтеп-аңлатып булмый торган хисләр актарыла иде.

Капка төбенә килеп туктагач та Мәүлет тиз генә машинасыннан төшәргә

ашыкмады. Пристаньда урап алган хисләр давылы тынмаган иде әле. Машинасыннан төшеп басса, ул давыл аяктан егар төсле тоелды.

Йөрәге чәбәләнүдән бераз туктагач, машинасыннан төшәргә дип Мәүлет ишеккә тотынды. Аннан янәдан урынына утырды. Утырды гына түгел, бөтенләй сеңеп калды. Өйдәгеләргә бу хәбәрне ничек итеп әйтергә соң? Нәрсә дияргә? «Мин сугышта хәбәрсез югалган әтине күрдем», дияргәме? Әнисе нәрсә әйтер, нишләр? Аларның бит әле кешенеке төсле генә түгел, әтиләре кыңгыраулы булды. Шушы минутка кадәр Мәүлет бу хакта бөтенләй уйламаган икән бит.

***

Озак, бик озак көтте Мәүлет бу көнне. Әтисе сугышка чыгып киткән көннән бирле көтә башлаган иде. Көтмәгән бер көне дә булмады аның. Ничек көтмисең, әти бит ул. Егерме җиде ел буена көтте. Тик әтисе белән очрашуны бер тапкыр да болай итеп күз алдына китермәде Мәүлет.

Малай чакта авылдагы апаларның, яшьтәшләренең сөйләүләреннән, үсә төшкәч, кинолардан күреп, ул әтисен аркасына юл капчыгы аскан, башына кызыл йолдызы янып торган пилотка кигән, күн итекләрдән; яшькелт соры гимнастёркасына медальләр тагып кайтып килер дип хыяллана иде. Өйләренә — алар янына кайтыр дип. Шушы кадәр дә өметләнеп көтүгә ничек кайтмаска мөмкин ди. Инде ике улы үсеп килә. Үзе әтисенең сугышка киткәндәге яшен узды. Тик һаман да шул балачак хыялындагыча итеп көтә иде ул әтисен.

Мәүлетләр бер урамлы Берлек дигән авылның Килдеш очындагы иң беренче йортында яшиләр. Сугышка әтисе, авылдагы башка абзыйлар белән, ат арбасына утырып, шул юлдан китте. Шуңамы, әтисе башка бер яктан да түгел, ә менә нәкъ Килдеш юлыннан кайтып килер кебек. Шул Килдеш юлына каерылып карый-карый муеннары авыртып бетә иде аның. Малай чакта бакча утаганда да, буыннары азрак ныгып, әнисенә ияреп чокыр буенда печән чапканда да шул гадәт калды. Өйдә бердәнбер ир-ат буларак, Мәүлет кечкенәдән төнгелеккә капка бикләргә дә үзе чыга. Биген төшергәнче, башта капканы ачып, Килдеш юлына бер күз сала торганга әйләнде малай. Әтисен көтә-көтә буй җиткерде, егет, ир булды. Әле кичә генә дә капка бикләргә чыккач, Килдеш юлына озак кына карап торган иде... Бүгенге көнгә кадәр шулай булды.

Мәүлет капкадан кергәндә, әнисе Рәйханә абзар ягыннан кочагы белән вак-төяк утын күтәреп килә иде. Әнисен ишегалдында ук күргәч, Мәүлет каушап калды. Өйалды ишеге төбендә кара-каршы очрашкач та, ул ишек ачып, ни әнисен уздырмады, ни кочагындагы утынын алмады. Елау катыш көлгән кебегрәк итеп:

— Әни, мин әтине күрдем, — диде.

Ишегалдын бер мизгелгә тынлык тутырды. Мәүлетнең чигә тамырлары тартышты. Йөрәгенең дөп-дөп типкәне үзенә ишетелде. Рәйханәнең кочагындагы утыннары шапылдап кулыннан төшеп киттеләр дә, чолан тактасына сөяп куйган тагаракка бәрелеп, күк гөлдерәгән тавыш чыгардылар. Үзе исә, чолан ишегенә сөялгән килеш, әкрен генә баскычка чүкте.

— Әй Алла, балам, нәрсә булды монда? Нишлисез? — дип, тавышка өйдән Гөлҗиһан йөгереп чыкты.

— Мин әтине күрдем, — диде Мәүлет, ни көләргә, ни еларга белмичә.

— Кит моннан, хайван. Кем шулай шаяра инде, — диде Гөлҗиһан, иренең сүзләрен чынга алмыйча.

— Чынлап инде. Ниткән шаяру булсын, — дип, Мәүлет баскычта хәле китеп утыручы әнисе янына чүгәләде. — Пристаньда күрдем мин аны.

Мәүлет кечкенә бала кебек дөньясын онытып, әтисен ничек итеп күрүен, нинди сөйләшү булуын бәйнә-бәйнә тезеп биргәч, килен белән каенана аптырап бер-берсенә карашып алдылар.

Алар шулай телсез калып утырганда, өйдән кызган таба, май исе чыга башлады.

— Гөлҗиһан, чукынчык, нәрсә терәлеп каттың. Чәлпәгең янамы әллә? — дип, Рәйханә кычкырып җибәрде. Мәүлет белән Гөлҗиһан икесе дә дерт итеп киттеләр.

— Ай Аллам, учакта табам калган бит, — дип, Гөлҗиһан тиз генә күздән юк булды. Ана белән бала сүзсез генә баскычта утырып калды.

Эссе көн акрын гына сүрәнләнеп килә иде. Кылна буеннан искән талгын җил Юкау чувашлары чапкан печән исен ишегалдына ташый. Көн буе кояш җылысында кызынган кычытканнар, иркен тын алып, башларын күтәргәннәр. Өлгереп килүче алма, чия исләре белән кушылган кипкән печән, кычыткан исләре баскычта утырган Мәүлет һәм Рәйханәнең иләсләнгән җанына куе бер һава дулкыны булып сеңә иде. Алар икесе дә әйтеп аңлата алмастай халәттә иделәр. Мәүлет үзен нәкъ әтисен сугышка озаткандагы кебек хис итте. Ул көнне дә шулай, әнисе Мәүлет белән Сөембикәне ике ягына кысып, дөньясын онытып, шактый вакыт хәле китеп торды. Утыра торгач, аның бөтен эчен калтырау биләп алды. Ул, көзге салкында әнисез калган сарык бәрәне кебек, торып-торып дерелдәп куйды. Әтисен озаткач та нәкъ шулай булган иде.

— Әни, ул бит Сөембикәне дә алып килергә кушты, нишләрбез икән, — диде Мәүлет балалар кебек беркатлылык белән, әнисенә таба башын борып.

— Кызыл Тархан җәһәннәмдә түгел, өч кенә чакрым. Бар, хәзер барып әйтеп кайт. Иртәгә әзерләнеп торсын, барышлый кереп алырбыз, — диде Рәйханә әкрен генә.

— Китегез моннан, юләрме әллә сез? Кем инде шул кешене күрәм дип бара, — диде Гөлҗиһан ачык ишектән.

— Шәкерт кызыннан сораганнар ди нишләргә икәнен, — дип, Рәйханә урыныннан торды.

— Барабыз, өчебез дә барабыз. Күрәсе киләдер, бала бит. Ничек кенә булса да ата бит... Мин дә күрермен, Алла боерса, — дип, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды. Бу сүзләр әллә кайдан, төптән җан газабы белән сузылып, суырылып чыкты. Аларда рәнҗү дә, ачу катыш үртәлү дә, сагыш та бар иде. Суга кушкан сөтне аерып алу мөмкин булмаган кебек, Рәйханә җанында кайнаган кичерешләрне дә аерып тәртипкә салырлык түгел иде.

Тик Рәйханә озак җебеп тормады, үзен тиз кулга алды. Ниндидер бер ачык карар кабул иткәне аның йөзенә чыкты.

— Бар, хәзер Сөембикәләргә барып әйтеп кайт. Син аннан кайткач ашарбыз, — диде дә ишек тоткасына үрелде. Әнисе кузгалуга, Мәүлет урыныннан торып басты. Тагын бер калтыранып куйды да, алыптай олы гәүдәсен төз тотып, машинасына чыгып утырды.

Ишек тоткасына тотынгач, әни кеше борылып улына карады. Шәмдәй төз, нык гәүдәсе белән Мәүлет Әкрәмнең коеп куйган яшь чагы иде.

Икенче көнне, билгеләнгән вакыттан ярты сәгать чамасы иртәрәк барып җитәрлек итеп, Мәүлет, әнисе белән Сөембикәне утыртып, пристаньга китте. Юлда беркем сөйләшмәде. Һәркайсы үз уена чумып барды. Сөйләшер сүзләре юклыктан түгел, ә саксыз сүз чыгып, төне буе өйгән хыял дөньясы җимерелеп төшәр кебек тоелды аларга. Тын гына бару алар өчен үзе бер җәрәхәтле рәхәт иде. Пристаньга килеп җиткәч тә, авыз ачып сүз дәшүче булмады. Хисләре — эчләренә, үзләре кабинага көчкә сыеп килделәр дә, машинаны башкаларга комачауламаслык итеп читкәрәк туктатуга, өчесе дә машинадан чыктылар. Берәү дә авыз ачып сүз катмады. Сөембикә, сүзсез генә килеп, әнисенең таратып япкан яулыгы астыннан чыккан чәчләрен рәтләп, яулык астына тыгып куйды.

Бүген пристаньда халык та әллә ни күп түгел. Халыкның азрак булуы әйбәт әле, кеше-кара үтеп-сүтеп йөргәндә, сөйләшеп тә булмас иде, дип уйлап куйды Рәйханә. Ул җанына урын тапмаса да, кадакланган кебек, күбрәк бер урында

тора, иңнәренә авыр йөк асканнар диярсең. Кисәк килгән хәбәр шулай авыр булды бугай...

Ә Сөембикәнең куанычтан йөзләре балкый. Кешегә сиздерергә кыенсынса да, эчтән бәреп торган куанычны яшереп торырлык түгел. Һич кенә дә бер урында гына тора алмый. Аның һәр очраганга елмаясы килә. Шул ук вакытта күңелдә нинди-дер курку да бар, чөнки Сөембикә әтисенең нинди икәнен дә хәтерләми бит.

Яхшы ат кебек горур башын югары чөеп, Мәүлет кичә әтисе белән сөйләшкән җиргә китте. Дулкыннар ышкып шомарткан, ялтыраткан таш өстенә басса, әтисен алып киткән теге теплоход тизрәк килер төсле тоелды бугай аңа. Акыл утырткан ике бала атасы бит юкса, ә бүген үзен малайлар кебек хис итә. Ул карашын Ульян ягына юнәлтте. Идел өсте үтүкләнгән кебек тип-тигез, чип-чиста. Бүген дулкыннар да, талгын җил дә шадралатмый Идел өстен. Аның яшькелт-зәңгәр төсе ерагая барган саен, аксылланып офыкта күк белән тоташа һәм чиксезлек хасил итә. Чиксезлек — билгесезлек...

***

Теге көнне дә шулай көткән иде Рәйханә, озак итеп, бөтен сабырын эченә җыеп көткән иде Әкрәмнең эштән кайтканын. Ире кайтканда, инде балалар күптән йоклаган. Өйдә тын, җылы. Балаларның мыш-мыш тын алып йоклаганнары ишетелеп тора. Тик Рәйханә генә, лампасын кыса төшеп, каз канатлары, тәпиләре салып пешергән умач ашын бөтенләй суынып бетмәсен дип, учак көлен буталап, утын көйрәтеп торды. Андый чакта бит ул күңелгә бер генә дә яхшы уй килми. Инде әллә ниләр уйлап бетердем генә дигәндә, «дыңк» итеп өй ишеге ачылып китте дә, Әкрәмнән дә ашыгыбрак, башлап өйгә салкын керде. Ноябрь салкыны, «кыенсынып», ишек төбендә таралмыйча бераз торганнан соң, акрынлап түргә узды.

— Ай Аллам, бигрәк озакладың бүген, — диде Рәйханә, иренә аш бүлә-бүлә. — Мәүлет, сине көтеп, әле яңа йоклап китте.

Әкрәм ашыкмый гына чишенде. Рәйханәнең әйткәненә ни җөпләп, ни каршы килеп җавап кайтармады. Хатыны комганнан җылы су салып торганда да дәшмәде. Бит-кулларын сөрткәч, түр якка кереп, балаларына озак кына карап торды. Аннан башларыннан сыйпап, өсләренә юрганнарын яхшылап япты да чыгып ашарга утырды.

— Берәр хәл булмагандыр бит эштә? — диде Рәйханә, Әкрәмнең дәшми утыруына аптырап.

— Рәйханә, мин синнән аерылам. Синнән сыер исе килә, — диде Әкрәм, ашын ашап бетергәч. Һәм ашыкмый гына торып киенде дә, тыныч булырга тырышып, өйдән чыгып китте.

Рәйханә, аякларының хәле китеп, мичкә сөялде, бераздан әкрен генә идәнгә чүкте. Башта еламады. Бераздан күкле-яшелле тавышлар чыгарып ыңгырашты да дөньясын онытып үксеп җибәрде. Елап арыгач, тиле кеше төсле үзен-үзе белештермичә, шашып көләргә тотынды. Тавышка Сөембикә уянып, куркып елап җибәрде.

— Шушы сабыйларым хакына сабырлык бир, Ходай, — дип, Рәйханә көчкә генә торды да, сөйрәлеп, балалары янына кереп ятты.

Әкрәм яшь киленне әтисенең энесе Зөфәр абыйларына төшерде. Төшерде дип, никах укыттылар да кичтән әзрәк мәҗлес кебек нәрсә ясадылар. Урамда чәпәк-чәпәк җепшек кар ява. Әйтерсең, табигать күзнең елак, пычрак көнен әз генә булса да агартырга, яктыртырга тырыша.

Ир бирмәк — җан бирмәк, дип белми әйтмәгәннәр шул. Рәйханә иренең бу хыянәтенә бик әрнеде. Үзен никадәр генә кулга алырга тырышса да, ире дүрт-биш йорт аша гына, яшь хатын алып, туй үткәреп ятканда, түземе бетте. Кечкенә Мәүлетен киендерде дә, йөгерә-атлый, яшь килен төшкән өйгә

китте. Ул барып җиткәндә, ир-атлар ишегалдында тәмәке тартып торалар иде. Шатлыктан авызын җыя алмаган «яшь кияү» бик мавыгып нәрсәдер сөйли. Рәйханә, ирен күргәч, бермәлгә туктап калды:

— Улым, бар, әнә әтиең сине көтеп тора, — дип, әкрен генә аркасыннан этеп җибәрде. Үзе аяк астындагы пычракны да, кара чәчләренә сыланган юеш карны да тоймыйча өенә йөгерде. Бите буйлап тәгәрәгән яшьләре ирен читен көйдереп алды.

Буш өйдә елап утырган кызын күргәч, Рәйханәнең җаны бөтенләй чайпалып түгелде. Баласын кысып-кысып кочаклаган килеш:

— Шушы балаларым хакына телемне каргыштан саклый күр, — диде. Әнисенең җылы куенын сизүгә, бала елаудан туктаса да, җанының өшүенә — җылы, йөрәк әрнүенә дәва таба алмады Рәйханә.

Әнисе этеп җибәргәч, Мәүлет Зөфәр бабаларына йөгерде. Ишегалды тулы җыелып торган ир-атларны күреп, малай куркып калды. Күзенә төшкән бүреген күтәребрәк куйды да, бишмәт җиңенә борынын сөрткәч, җилкапкага асылынып, ирләр арасыннан әтисен эзли башлады. Әнә ич аның әтисе — иң матуры, иң әйбәте.

— Әти, мин монда. Күрәсеңме? — диде Мәүлет, һаман саен күзенә төшеп интектергән бүреген югары этеп.

Ишегалдындагы сөйләшү-көлешү шып тукталды. Әкрәм улын көтмәгән иде, нәрсә дияргә дә белмичә аптырап калды.

— Кер, улым, кер. Нишләп анда гына торасың, — диде Зөфәр бабасы.

Мәүлет, йөгереп килеп, әтисенең аягыннан кочаклап алды. Әкрәм дә, иелә төшеп, көрәктәй зур куллары белән улының ябык иңбашыннан кочып, үзенә таба тартты. Малай үзенең бөтен тәне белән әтисе аягының калтыранып куйганын тойды. Үзе дә дерелдәп:

— Әти, әллә син дә өшисеңме, — диде һәм күтәрелеп әтисенә карады. Әкрәм дә карашын аска, малаена юнәлтте. Малай, гөнаһсыз күзләрен зур итеп ачып, әтисенә карап тора иде. Әкрәм бугазына тыгылган төенне авырлык белән йотып җибәрде дә, «әйе» дигән ишарә ясап, башын селкеп куйды. Үзеннән нindидер әчкелтем ят ис килсә дә, әтисе белән шулай басып тору рәхәт иде малайга.

Ирләр азга гына тукталып алдылар да, берни булмагандай, сүзләрен дәвам иттеләр. Шулвакыт ишек ачылып, өйдән Зәйнәп тавышы ишетелде.

— Тарта-тарта өзеп чыгармагыз инде. Әйдәгез, сезне көтәбез.

Ирләр тәмәкеләрен тиз-тиз генә суыргаладылар да, аяк астына салып таптагач, өйгә кереп киттеләр. Әкрәм, нишләргә белмичә, иелеп, җирдән бер йомарлам кар алды да эреп суы чыкканчы учына кысты. Аннан:

— Улым, — диде. Бераз дәшми торганнан соң, янәдән: — Улым, мә шәкәр, — дип, Мәүлеткә карамый гына, учындагы кар йомарламын сузды.

Зәйнәп, ишектән башын гына тыгып:

— Нәрсә һаман керми торасың? Сине генә көтәбез бит инде, — диде. Әйтерсең, Әкрәм янында Мәүлет бөтенләй юк.

— Бар, кер. Хәзер мин дә керәм, утырыша торыгыз, — диде Әкрәм, Зәйнәпкә борылмый гына.

Мәүлет, күзенә төшеп интектергән бүреген кулына салып тотты да, күзләрен зур ачып, әтисе биргән кар йомарламына гаҗәпләнеп карап торды.

— Әти, шәкәр түгел бит бу, — диде малай, авызын ерып. Әтисен шаярта дип уйлады. — Шәкәр мондый буламыни?

— Шәкәр, шәкәр, улым. Бар, өйгә кайт инде. Әниең югалтыр үзеңне. Шәкәр ул, вакыты белән, шундый да булгалый шул, улым, — диде дә, ашыга-ашыга, кунаклар янына кереп китте.

— Кит, ананңы саткан нәрсә. Хайван икәнсең. Бала бит ул, — дип, Зөфәр ачудан төкереп куйды.

Мәүлетнең «әти, әйдә өйгә кайтыйк инде», дигәнен Әкрәм ишетмәде. Малаеның тавышы шапылдап ябылган ишеккә кысылып калды.

— Бар, улым, әниең янына. Әниеңнән яза күрмә, — дип, Зөфәр Мәүлетнең аркасыннан сыйпады да өйләренә таба йөгергән малайның артыннан озак кына карап торды.

— И-и-и бала, бала. Рәхәт булуын булмас инде дә, Алла ташламасын. Алла ташламаса — бүре ашамас. Дуңгызны коңгыз итеп булмый шул. Ни әйтеп тә тыңламады бит. Менә сиңа мә-ә-ә. Ирләр алдана торган заман килде. Ахырзаман инде бу, — дип авыр көрсенеп, абзарга таба атлады.

Мәүлет мыш-мыш килеп өйләренә кергәндә, әнисе мич төбенә тәгәрәткән бәрәңгеләрне агач коштабакка алып маташа иде.

— Улым, шул гомер нишләп тордың анда? Туңып беттеңме? — диде Рәйханә почмак яктан. — Әтиеңне күрдеңме соң?

— Күрдем. Әйдә өйгә кайтыйк дигән идем дә, ишетмәде, Зөфәр бабайларга кереп китте, — диде Мәүлет, бишмәте белән бүреген сандык өстенә генә ташлап.

Рәйханә кабыклы бәрәңге өстенә су бөркеп, киндер тастымал каплады да өстәлгә китереп куйды. Самавыр инде күптән пар бөркеп, тулы гаиләнең өстәл янына җыелганын көтеп, моңсу гына җырлап утыра иде.

— Әйдә, улым, утыр. Илдә чыпчык үлми, ничек тә түзәрбез, Алла бирсә, — дип, кечкенә Сөембикәне алдына алып, өстәл артына утырды. «Түз, Рәйханә. Синең бит ике балаң бар», диде ул үз-үзенә һәм саркып кан чыкканчы ирennәрен тешләде.

Икенче көнне Әкрәм Зәйнәпне өйләренә алып кайтты. Кичкә инде бер өй икегә бүленгән иде. Рәйханә күршедәге чуваш авылы Юкаудан ике оста чакыртып, түр як өйнең бер тәрәзәсен ишек итте дә язмышы белән килешеп яши башлады. Көндәшкә дә сер бирмәде, иренә дә елап бармады. Үзен кызганучыларга ачуы килсә дә, дәшми сабыр итте. Гайбәтчеләр тәмләп аларны чәйнәгәндә дә, йөрәген учына кысып түзде. «Ил авызын томаларга илле ыштан да җитми», дигән сүзне элеккеләр белми әйтмәгәндер дип, сер бирмәскә тырышты. Шуңа, сүз куып, кеше сүзен дөресләп йөрүне кирәк санамады Рәйханә.

Авыл сөйләде. Рәхәт итеп, тәмләп. Тик озак түгел. Бер урамлы авылда барысы да ап-ачык, уч төбендәге кебек күренеп тора. Бар да күренгәч, кызыгы тиз бетә. Җандагысы гына күренә торган түгел. Авызыңны биктә тота белсәң, әтәч булып кычкырмый. Ә Рәйханә тота белә. Ул бит әни белән түгел, җиңги белән үскән кыз.

— Әни, бер җыр җырлап күрсәтимме? — диде Мәүлет, беркөнне әнисе эштән кайтып капкадан керүгә. Һәм Рәйханәнең, җырла, дигәнен дә көтеп тормыйча, такмаклап та китте.

Кара каз да ап-ак була,
Кылналарда коенгач.
Безнең әти кайтыр әле,
Зәйнәбеннән туенгач.

Рәйханә тиз генә алъяпкыч итәге белән улының авызын каплады. Үзе як-ягына каранып, улына иелде:

— Балам, бүтән җырлый күрмә бу җырны, ярыймы. Әшәке җыр бу, — диде дә, улына күз яшьләрен күрсәтмәс өчен, кысып кочаклаган килеш берара җибәрми торды.

— Кайсысы өйрәтте, улым, бу әшәке җырны? — диде ул, тураеп як-ягына күз салгач.

— Өйрәтмәде, үзем чыгардым. Кислата Сәгыйдә апа, әтиең Зәйнәбеннән туенгач кайтыр әле, ди бит. Шуңа тизрәк кайтсын дип җырладым инде мин. Ә ул кайчан Зәйнәбеннән туена, әни? Кайта бит ул, әйеме? Әни, ә син ник елыйсың?

— Еламыйм, улым, еламыйм. Күзгә чүп эләкте, шуны гына сөрттем. Әйдә, өйгә керик, ашыйсың да килеп беткәндер. Син бүтән җырлама, улым, бу җырны, яме, — диде Рәйханә тагын бер кат. Аннан, Сөембикә кайда соң әле, дип сөйләнә-сөйләнә, малае артыннан өенә кереп китте.

Балалар шул. Сөембикәсе барысын аңлап бетермәсә дә, әтиләренең үзләре белән булмавын Мәүлет бик авыр кичерде. Бигрәк тә кичләрен. Йокларга яткач, әтисе аяклары белән кыстырып ята иде аны. Ә ул әтисенең колак яфрагын тоткан килеш оеп йоклап китә торган иде. Рәйханә әтиләре хакында сөйләмәде, ләкин авылда «яхшы күңелле» кешеләр аз түгел. Аңламаган нәрсәләрен малайга алар әйтеп кайтара тордылар. Андыйларга Мәүлет җавап кайтара алмаса да, Рәйханә сер бирмәде.

Бер тапкыр Нәүбәһар абыстай белән чәчүлек орлык чистартып кайталар иде. Сүз иярә сүз чыгып, Нәүбәһар абыстай:

— И-и-и җәллим дә үзеңне, Рәйханә, — дип сүз башлаган иде, Рәйханә, ике сөйләргә урын калдырмаслык итеп:

— Мине җәлләргә кирәкми, Нәүбәһар абыстай. Дүрт саным сәламәт, балаларым исән-сау, Аллага шөкер. Кеше ирен тартып алмадым. Ходаем шушы көнемнән аермасын. Күңелләргә күрә Ходай көнне бирә ул. Менә Зәйнәпне җәлләсеннәр. Мин аларның икесенең берсен дә каргамыйм, ә менә балаларымның яше тотар. Зәйнәп шуңардан курыксын, — диде, улының теге көнне җырлаган җырын исенә төшереп. Әйтүен генә шулай дип әйтте Рәйханә. Төннәр буе ялгызы мендәр тешләп елаганда, Ходайдан ничек сабырлыклар сораганын үзе генә белә. Вакыт-вакыт көндәшенең чәченә барып ябышудан үзен чак кына тыеп кала иде.

Шулай да беркөнне түзеп кала алмады, сабыр савыты тулып ташыды. Рәйханә эштән кайтып кергәндә, Зәйнәп төз лапас астында җырлый-җырлый сыер савып утыра иде. Чыжылдап чиләккә сузылган сөт тавышы белән Рәйханәнең капкадан кергәнен абайламый калды.

— Иремне алдың, инде балаларымның ризыгына кул сузасыңмы, — диде дә сыер савып утырган Зәйнәпнең артына «лырт» иттереп типте. Сыер, күшәвеннән туктамый гына, читкә тайпылды, сөтле чиләк исә, елак тавыш чыгарып, утынлыкка тәгәрәде. Кипкән сыер «беленнәр»ен ак сөт җәймәсе каплады. Зәйнәп, җәһәт кенә сикереп торды да, бер сүз дә әйтмичә, карак мәче кебек бакча ягына йөгерде. Курыкканы йөзенә чыккан иде аның.

Рәйханә, хәле китеп, аркасы белән абзар капкасына сөялде. Башындагы яулыгын сыпырып төшереп, куллары белән битен каплады. «Тәүбә, тәүбә... әстәгъфирулла», дип пышылдады иреннәре. Ике хатын сугышса, мәңге җәннәт чырае күрмәс, ди торган иде мәрхүмә әбисе. Ходаем, үзең сабырлык бир... Ул Зәйнәпкә карата башка кул да озайтмады, телен дә теш артына кысты. Тизәккә тисәң, исе чыга. Ник кирәк?! Шулай да бәрәңге боламыгы булмады: балаларын да, үзен дә якларга, сакларга көч тапты.

— Әкрәм бит сыер исен яратмый. Син инде бүтән сыер тирәсендә буталма, Зәйнәп, — диде дә, Рәйханә битенә төшкән чәчләрен тыны белән өреп, куллары белән сыпырып җибәрде. Һәм, башын арткарак чөеп, горур гына өенә кереп китте.

Сугышка китәргә повестканы Әкрәмгә авыл советына чакыртып бирделәр. Уч төбе кадәр кәгазь кисәгенә ул озак карап торды. Юк, бу теге көнге бер йомарлам кар гына түгел. Учларны өтсә дә, кысып-изеп, улыңа тоттырып булмый шул. Әйе, болай булырга тиеш түгел иде. Барысы да шулай чәлпәрәмә килер микәнни? Үлә калса, кара кәгазьне кемгә бирерләр икән дә, исән-сау кайту насыйп булса, үзе беренче кем ишеген кагар икән? Баштагы уйлар агышын акыл белән генә куып тотарлык түгел иде. «Ярар, әле бүгенгесен кайгыртырга кирәк», — дип уйлады Әкрәм һәм повесткасын тоткан килеш турыдан Рәйханә янына керергә булды.

Бер өйне ике иткәннән соң, Әкрәмнең бу бусаганы беренче атлап керүе иде. Керде дә, чит кеше кебек, ишек төбендә туктап калды. Чит кеше кебек... Үз идеме, чит идеме бу йорт аның өчен, әллә үзе мондагылар өчен чит идеме? Керүгә, ул үзен ничектер кечерәеп калгандай тойды. Рәйханә, ишеккә арты белән торып, сандыгыннан нидер карый иде, аның кергәнен ишетмәде. Әнисе янында буталган кечкенә Сөембикә ишек тавышына ялт итеп башын борды. Сабый, сүзсез калып, әтисенә төбәлде.

— Кил, кызым, кил. Кочаклыйм әле үзеңне, — дип пышылдады Әкрәм, кипкән иреннәрен көчкә кыймылдатып. Тавышка сискәнеп, Рәйханә башын күтәрде. Бала, йөгереп барып, әтисен муеныннан кочаклап алды. Әкрәм, кызын күтәреп, кытыршы яңагын баласының йомшак битләренә тидерде. Сабыеның татлы исеннән аның башлары әйләнеп китте. Рәйханәнең дә шул киң җилкәләргә барып кагыласы, иренең кочагына сыенасы килсә дә түзде. Бугазында биеп торган төенне йотып җибәрде дә, сандык өстенә япкан паласны тигезләп, җай гына шунда утырды. Калтыранганын күрсәтмәс өчен, кулларын алъяпкычы астына яшерде. Ул арада, тавыкларга бутарга дип ат колагы сыдырырга киткән җиреннән Мәүлет кайтып керде. Ишек төбендәге бу күренешне күреп, бертын аптырап карап торды да, чиләген ташлап,«әти!» дип Әкрәмнең биленнән кочаклап алды. Әкрәм, Сөембикәне кулыннан ычкындырмыйча, икенче кулы белән Мәүлетне күтәрде.

Рәйханә сүзсез генә, сандык өстенә утырган килеш, ике баласын кочаклап торган Әкрәмне күзәтте. «Ирләр аулый белсә дә, ямау ямый белми икән», дип уйлады ул көндәше хакында. Чөнки Әкрәмнең бер тез башындагы ямавы акаеп, күзгә төртелеп тора иде. Ә икенчесе сизелми дә. Анысын Рәйханә ямаган иде... Ул вакытта соң кем белгән.

— Рәйханә, иртәгә мин дә китәм инде... сугышка... — диде Әкрәм, балаларын идәнгә бастыргач. — Мин саубуллашырга дип кергән идем.

Аның тавышы калтырап китте. «Китәм» дигән сүзне ишеткәч, Мәүлет: «Әти, китмә! Әти, китмә!» — дип елап, яңадан Әкрәмгә барыпябышты. Абыйсының елый-елый кычкырганын күргәч, Сөембикә йөгереп килеп әнисенә сыенды. Үзе, каш астыннан сөзеп кенә, әтисенә карап тора башлады. Офыкка кереп бара торган кояшның ян тәрәзәдән якты эз ясап сузылган соңгы нурлары, мунчалалап юган сап-сары идән ярыкларына эләгеп өзелгән булса да, өй эченә сүрән яктылык бирә иде.

— Хәерлегә булсын, — диде Рәйханә, урыныннан кузгалып. — Җае җайсызрак булды дөньяның. Хәерлегә генә була күрсен... Сугыш аера шул кешене. Безнеке кешечә булмады инде. Бәлки сугыш безне кушып куяр... Исән йөреп, сау кайт. Хозыр Ильяс юлдашың булсын.

Әкрәм ничек шыпырт кына кергән булса, шулай тын гына чыгып китте. Тик башы гына тагын да түбән иелә төшкән иде. Мәүлет, олы кешеләр кебек, әтисенә ияреп урамга кадәр озата чыкты. Рәйханә баскан җиреннән кузгалмады. Агасы күз яшьләре күптән беткән, күңеле каткан иде инде. Сөембикә исә, әнисенә күтәрергә кушып, алъяпкыч итәген тарткалады да тарткалады.

Балаларын иртәрәк йокларга салды да, Рәйханә төне буе керфек какмый Әкрәмгә йон оекбаш бәйләде. Офыкта таң яктысы сизелгәндә, оекбашын бетереп, икесен бер пар ясап, бәйләп тә куйды. Ул арада ачык тәрәзәдән ат пошкырган, ирләр сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады. Рәйханә, балаларының башларыннан сыйпап:

— Улым, торасызмы? Әтиеңнәр китә бит. Әйдә, озатырга чыгыйк, — дип, Мәүлетне уятты. Малай, соңга калган кебек, сикереп торды да, «тор инде, тор, әти китә бит», дип, Сөембикәне селеккәли башлады. Сеңлесе тормагач, «и-и-и, сине көтсәң», дип, әнисеннән дә алда урамга чыгып йөгерде. Сөембикә йокыдан торасы килмичә еларга тотынды. Рәйханә кызын күкрәгенә кысып күтәрде дә, төне буе күз нурын түгеп бәйләгән оекбашын алъяпкыч кесәсенә генә тыгып, урамга чыкты.

Халык шактый җыелган. Арада кемдер мәзәк сөйләп шаяртмакчы да булып азаплана. Берәүләре гармунга кушылып җырлый. Рәйханә чыкканда, Мәүлет әтисенә сыенып басып тора, ә Зәйнәп, ай да тулмаган баласын кочаклап, елыйелый, Әкрәмгә нидер сөйли иде. Рәйханәне күргәч, Зәйнәп тә, башкалар да читкәрәк киттеләр.

— Исән-сау әйләнеп кайтырга язсын сиңа, Әкрәм. Җылы аягыңда тузсын, — дип, Рәйханә ап-ак оекбашларны Әкрәмгә бирде дә, әллә үзенең кул җылысы аңа күчсен дип, әллә аныкын үзендә сакларга тырышып, озак кына кулларын иренең учларыннан алмый торды.

— Рәхмәт. Син мине кичерә күр инде, Рәйханә. Булдыра алсаң, кичер, зинһар, — дип пышылдады Әкрәм.

— Мин күптән кичердем инде, сине Ходай кичерсен, — диде Рәйханә, башкалар да ишетелерлек итеп.

— Әйдәгез, су буе сузылмыйк. Вакытына барып җитәргә кирәк, — диде Зиннәтулла һәм атларны кузгатты. Хатын-кызлар мышык-мышык елаша башлады. Балалар әниләренә сырышты. Рәйханә, кызын күтәргән килеш Мәүлетне кочаклап, тынып калды. Яшьләре, кайнар эз ясап, бите буйлап сузылды да сузылды. Атлар кузгалды. Инде шактый җир киткәннәр иде, «Әти, китмә! Әти, китмә!» — дип, Мәүлет атлар артыннан йөгермәкче булып алга омтылды. Тик аяк башы каткан балчыкка эләгеп, йөзе белән юл тузанына егылды. Рәйханә улын торгызды, күлмәк итәге белән битен сөртте дә балаларын тагын да катырак үзенә кыса төште.

— Хәерле булсын, — диде ул. — Хәерлегә була күрсен. Исән йөрсен. Исәннәр кайчан да булса бер кайта ул.

***

Менә чиксез Идел кочагында, кечкенә генә бер нокта шикелле, күптән көтелгән теплоход пәйда булды. Сөембикә сабыррак булырга тырышып, йөгерәатлый абыйсы янына китте. Аларның икесенә дә теплоход бик акрын йөзгәндәй тоелды. Тыннары белән тартып алырдай булып, теплоходка текәлделәр. Рәйханә баскан җиреннән кузгалмады. Теплоходның сузып-сузып кычкырткан тавышы ишетелде. Ул якынайганнан-якыная барды. Тукта, ул бит инде пристаньга таба борыла башларга тиеш... Юк, борылмады да, туктамады да теплоход. Өч пар күз мөлдерәп, ымсынып, теплоходка төбәлгән иде. Теплоход сузып кына бер кычкыртты да юлын дәвам итте.

Әллә ялгызлыктан, әллә явызлыктан Рәйханәнең юка иреннәре кысылып куйды. Болай да какча гәүдәсе тагын да кечерәеп калгандай булды. Ул еламады, елый алмады. Шул гомергә нинди яшь калсын. Йөрәге генә имән чөй белән аркасына кадаклап куйгандай әрнеп авырта иде. «Хәерле булсын, — дип пышылдады чәйни-чәйни каны качкан иреннәр, — хәерлегә генә була күрсен». Сөембикә, гарьләнүен эченә яшереп, яшь элпәсе каплаган күзләрен пристаньдагы кешеләргә күрсәтергә кыенсынып, әнисен кочып алды да, башын аның ябык иңнәренә салып елап җибәрде.

Мәүлет исә бер сүз дә дәшмәде, дөресрәге, дәшә алмады. Бугазына таш булып төер утырды. Күзләре ерагая барган теплоходны озатты, ә иреннәре: «Әти, китмә! Әти, китмә!» — дип пышылдый иде.

Мәүлет көчле куллары белән икесен бергә кочагына алды. Алар теге юлы да шулай өчәү басып калганнар иде. Тик ул вакытта әниләре кочаклаган иде аларны.

Теплоход, «хуш!» дип сузып кына соңгы тапкыр кычкыртты да бөтенләй күздән югалды. Чиксезлектә-билгесезлектә...

# ҖЫРЫ БЕЛӘН ҖИҢГӘН ДОШМАНЫН

**Рашат НИЗАМИ**

## Корыч дивар

Җәлилчеләр аягүрә баскан...
Хәтерлисең булыр, Моабит:
Йөрәкләре, кызыл ромашка булып,
Вулканнардан ныграк яна бит!

Гильотина, канлы балта тотып,
Кизәнгәнсең татар башына.
Кызыл байрак булып, «автограф»
Чәчрәгәндер төрмә ташына...

Бу дөньяда ләкин бар микән соң
Язмышларның гадел бизмәне, —
Балта бит ул... белмичә дә кала
Кемнең башын чабып өзгәнен.

Гильотина! Дистә еллар аша
Нәләт укып дәшәм мин сиңа:
Туган Ил һәм Намус дигән чакта
Җәлилчеләр — корыч стена!

Күкрәгеннән очырган бит алар
Азатлыкның үлмәс кошларын.
Муса Җәлил — пистолеты түгел,
Жыры белән җиңгән дошманын!

Тарих тәгәрмәчен бормак булып
Сөйләнсә дә кайбер кемсәләр,
Аягүрә баскан җәлилчеләр —
Азатлыктан мәгърур илчеләр.

Таралганны жыяр вакыт безгә:
Идел-Урал! Яши хыялда...
Ватанымның байраклары бүген
Өч зөбәрҗәт төскә буялган.

**Мөхәммәт МИРЗА**

## Мәңгелекне хаклап

Чор сораган, дәвер таләп иткән,
Акыннарын — акыл иясен,
Алар фаразлаган, кисәткәннәр
Кайчан, кайда, ниләр киләсен.

Суфилары асылын ачып биргән
Догмалардан аерып хак чынын...
Иманына якынайткан Раббым
Тәүбә иткән һәр иҗатчыны...

Шуннан, очлы сүзне әйткән Сәгъди,
Хәйям «йомарлаган» йомрысын,
Кинаяләп әйткән Мөхәммәдьяр,
Бәреп әйткән Тукай турысын!

Егерменче гасыр — җаһил заман,
Такташ, Туфан, Җәлил калыккан.
Кәрим, Кутуй, Мөҗәй, Алишларның
Каннарына тиран зарыккан...

Егерменче гасыр иттарткычы
Кешеләрнең җанын тартканда,
Күтәрелде татар шагыйрьләре,
Яшәешне җирдә сакларга.

Яшәү хакы тәннәр белән бергә
Рух, бәгырь белән түләнә.
Үлеп үлемсезлек яуладылар:
Милләтеннән төште күләгә...

Үлеп үлемсезлек яулап була,
Калса каның белән язган җыр...
Үзен түгел, халкын хаклар өчен
Шагыйрьләргә шулай язгандыр...

Чор, дәверләр таләп итсә, тагын
Туып торыр яңа Җәлилләр...
Халкым мәңгелеккә хакы барын
Җәлилләре белән дәлилләр!

**Фәйрүзә МӨСЛИМОВА**

## Рухларына – дога...

«Шәһидләрне үлгәннәргә санамагыз,
Алар исән Аллаһ хозурында» –
Зиһеннәрне уеп төшкән Коръән сүзе
Кормаш, Җәлил, Алиш турында да.

Гомеркәйләр кемгә генә газиз түгел,
Газиздерме илең гомердән дә?
Кемнәрнендер ул чак, бәлки, таңы аткан
Берәүләргә шәфәкъ сүрелгәндә?

Исбатларга күпме еллар кирәк булган
Үлемнәре зая түгеллеген.
Һәйкәлләрен чәчәкләргә күмгәндә дә
Рухлары тик дога тели бүген.

Әгәр булса, кичер, Аллаһ, гөнаһларын.
Язма безгә мондый язмышларны...
Оныттырма ләкин, Туган илем, диеп,
Башын салган Җәлил, Алишларны,
Башын салган Җәлил, Алишларны...

**Газинур МОРАТ**

## Соңгы җыр

*Соңгы җырым палач балтасына*
*Башны тоткан килеш языла.*
М.Җәлил

Баш очымда Кояш түгел —
Гильотина!
Ә Вакыт — ташбака шикелле —
сытып үтерәсе килә.

...Чулпан кызым ни хәлләрдә
икән анда?
«Әттә» диеп саташамы
ул һаман да?

...Әминә дә зарыккандыр көтеп,
беләм.
Күренәсем килми
бу кыяфәт белән.

...Илдәшләр ни уйда икән
безнең хакта?
Уйларында юкмы берәр шөбһә,
хата?

...Казан, дуслар, Кашшаф,
Туфан нишләп ята?

...Исән-саумы Андре? —
соңгы ышанычым!
Җырларым бит әле —
читлектәге лачын.

...Соңгы сүзем-әманәтем
сиңа, халкым!
Беркайчан да
сатмадык без
яманатың.

...Ирекле бул мәңге! —
Васыятем сиңа!
...Баш очымда Кояш түгел —
Гильотина...

**Ләбиб ЛЕРОН**

## Җәлилчеләрне уйлап

Еллар башка, чорлар бүтән,
Ә заман — шул ук заман:
Дөньяларда сугыш бара,
Кырылыш бара һаман.

Анда — орыш, монда — вәхшәт,
Һич тынгы юк халыкка:
Ничә ел ул, йодрык төйнәп,
Каршы бара танкка?!

Җәлилчеләр башын салган
Кемнәр бәхете өчен?
Кемнәр көрәш алып бара
Патша тәхете өчен?

Кемнәр ул бәләкәй халык,
Кемнәр ул өстен кавем?
Кем өчен дип башын сала
Бу халык-мескенкәем?

Дөньяларда орыш бара,
Ә максат кайда да бер:
Кемгә — тәхет, кемгә — бәхет...
Тик бәхет кайлардадыр?

...Чорлар башка, еллар бүтән,
Ә заман — шул ук заман:
Баш очында үткен балта
Эленеп тора һаман!

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

## Җәлил кояшы

Кузгалалар эшафотка таба.
Бу — гомернең соңгы «әкбәре».
Сукты сәгать! Һәммәсенең бүген
Легендага күчкән мәлләре.

Палач каршы ала. Элеккечә
Тишек капчык түгел башында.
Юк, башкарып булмый кара эшне
Беркайчан да кояш астында, —
Караңгыга, төрмә төбенәрәк
Ымлый һаман. Көннең яктысы
Бәбәкләрен кисә. Тоткарланса
Исен җуяр адәм актыгы.
«Кеше башы әкияттәге кебек,
Кискән саен кабат үсә лә...» —
Фәлсәфәсе әзер, кереп түнгәч
Фәлән кадәр марка кесәгә.

Кояш кына менә ярсыта бик...
Дивар ышыгына сыенып,
Ул аны да өзеп алыр иде!
Тик
кояшның
юк шул
муены...

**Гөлнур КОРБАНОВА**

***

Керә калсаң әгәр тарих урманына,
барлый калсаң әгәр нәсел шәҗәрәңне,
юлыгасың әкияти аланнарга.
Татарларның шәҗәрәсе дәрәҗәле.

Юлыгасың чишмәләргә. Туктаганнар
башкайларын ия-ия суын эчә.
Ә бер тургай, отып калып чишмә җырын,
ул җырларны җырлый иде әле кичә.

Тукайларга, Җәлилләргә, Туфаннарга,
Сәйдәшләргә, Насыйрига, Такташларга
кайта Татар, ерта-ерта вакытларны,
гасырларны тоташтырган күпер аша.

**Рифат СӘЛАХОВ**

## Шагыйрь йөрәге

ТРИПТИХ

*Тик бер өмит – кара август төне*
*Илтер мине шунда җитәкләп.*
М.Җәлил

**1**

Чәнечкеле тимерчыбык аша
Минем янга килсен берегез!
Таләп итәм: Җаным өчен миңа
Кәгазь-каләм генә бирегез.

Без сугышка киттек мылтык тотып,
Шан җыр булып кайтып керербез.
Исән калмасак та, колач җәеп
Кабул итәр безне илебез.

Палач балтасында киселсәк тә,
Без — шәһитләр, мәңге тере без.
Күңелем тулы шигырь...
Соң теләгем:
Кәгазь-каләм генә бирегез!

**2**

Асып киссәләр дә, кара бәхет
Эзләмәдем тоткын тормыштан.
Мин түгелме
Илгә бәхет теләп
Киләчәге өчен тырышкан?

Соңгы тапкыр кара күккә карыйм —
Җил дә исми безнең яклардан.
Каным белән язган җырларымны
Төрмә диварлары ятлаган.

Төрмә диварлары тынып калган,
Төрмә диварлары дәшмиләр.
Болытлар да бүген ап-ак түгел,
Болытлар да бүген яшьлеләр.

Эх, автомат булса!.. Көрәшергә
Күңелемә шигырь-ут йоттым.
Юк, курыкмыйм хәтта үлемнән дә,
Тик коллыкка юк шул хокукым.

Менә бит ул — кара август төне
Еллар буе көттем бу көнне.
Мин ирекле булсам, каләм өчен
Автоматны ташлар идемме?

Язар идем автоматым белән,
Фашист йөрәгенә ут бәреп.
Ирексезлек сеңгән төрмә исен
Иңнәремдә йөрим күтәреп.

Яраланган бөркет сыман мин дә,
Соңгы тапкыр күккә талпынам.
Безнең җиңү җыры ишетелә
Төрмә диварлары артыннан.

Безнең җиңү җыры ишетелә...
Эх, ник мин дә шунда түгелмен?!
Үлем авыр түгел, әнә шуңа
Соңгы тапкыр әрни күңелем.

Җаны аның ап-ак ромашкадай,
Сүнмәс кояш аның йөрәге!
Соңгы җыры тамды чәчәкләргә,
Тәне үлде, рухы үлмәде.

**3**

Шагыйрь китә... Соңгы яра булып
Офыкларга тулган кызыл кан...
Сезме, кара йөзләр, канга сусап,
Шагыйрь йөрәгенә кызыккан?!

Синме, кара җәллад, күзең тонып,
Каһарманның башын өзәсең?
Белдең микән, каны төшкән төштә
Җаны чәчәк булып үсәсен?!

Соңгы ялкын, соңгы бөртек шигырь
Офыкларга кереп адашты.
Җәсәденә туфрак калкан булыр,
Төрбә булыр аңа ромашка.

Соңгы кан тамчысы ромашкага
Чыклы яра булып сызылган.
Кояш батмый – җырлы гомер балкый:
Офыкларга тулган кызыл таң...

**Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Азатлыкка атлый татар улы

Кирмән каршысында һәйкәл тора,
Мәгърур башын чөеп югарыга.
Тәнен буган тимер богаулардан
Котылырга теләп, арынырга.

Тәнен буган тимер богаулары
Кадалалар тарих төпкеленә.
Яралардан кан саркымый, саркый
Ялкынлы җыр тулы шигырь генә.

Котылырга теләп зынҗырлардан,
Мәгърур башын чөеп югарыга,
Шәһид киткән күпме татар җаны,
Имин көннәр теләп улларына.

Азатлыкка атлап, күпме башлар
Тәгәрәгән җилкәләрдән аска,
Истә әле, истә фида җаннар,
Чал тарихлар басылганнар ташка.

Чал тарихның ишарәсе булып,
Ташта басып тора Җәлил сыны.
Тар коллыктан азат шәһид рухы,
Азатлыкка атлый татар улы!

**Эльвира ҺАДИЕВА**

## Туксаннар Җәлиле

*Бала чакны безнең әйтмә инде,*
*Тау шуганбыз җәфа өстеннән.*
*«Үсмәсләр», дип әти, сабыры бетеп,*
*Чәчебездән тартып үстергән.*
М.Җәлил

Бала чаклар безнең исендәме,
Әни туксаннарда үстерде.
Апалардан калган соңгы күлмәк
Безнең өстә генә искерде.

Таңнан чыгып сыза идек кайчак —
Әби кала иде кисәтеп:
«Буйга җиткән, эшсез чабып йөрмә,
Егет бит син, егет, күсәк!» — дип.

Күсәкнең дә кайчак килә шулай
Балык тотып, эшсез йөрисе.
Без — туксанда үстек, ә ул чорда
Йә акча, йә эштән черисең.

Тырышмасаң, су анасы түгел,
Бандит абый килә, иренчәк!
Әни-әти паен басуларда
Кем утарга тиеш, синеңчә?

Алар таңнан төнгә кадәр эштә
Илнең малын бушка коткарыр...
Гел бер сүзне тукыдылар безгә:
«Акыл сатма, телең кыскарыр!»

Ә шулай да, бабай, вакытын табып,
Илнең, сүзнең кадрен өйрәтте.
Без үскәндә бик бай булмасак та,
Тырыш булып үстек, йөрәкле!

Тукайны да, Җәлилне дә ятлап,
Горурлыкны данлап яшәдек.
«Кем тәрәзне ватты?» — соравының
Чын җавабын белдек, дәшмәдек!

Яшькә тыгылсаң да, түзәсең ул,
Чагу килешми бит егеткә.
Батыр булып чыгалмадык кына,
Җәлил кебек батыр кереп тә!

Сүгелгәнгә еламадык шул без,
Елаганга безне сүктеләр...
Күз яшьләре биткә тимәде дә —
Юрган почмагында кипте лә.

Ә шулай да безнең ул балачак
Кабатланмас уен чыгарды.
Бу көн аналары безнең кебек
Чукмарларга, әйтче, чыдармы?!

Бу көн аталары безнең төсле
Таш-башларны сөя алырмы?!
Бу көн егетләре безнең кебек
Җәлил булып батыр калырмы?

Без алтыда үсеп житкән идек,
Күсәк идек җиде тулганда...
Җиргә туксаннарны керттеләрме,
Без бер буын булып туганга?

Бала чаклар безнең исеңдәме,
Әни туксаннарда үстерде.
Тик кызганыч, без ятлаган җырлар
Онытылды, бетте, искерде...

**Рүзәл МӨХӘММӘТША**

***

Җан бәясе сукыр бер тиенгә
Төшкән саен, дөнья үзгәреп,
Ялтыравык тормыш хакы арта...
Тик сумнарда исәпләнә алмый,
Исәпләнми сумда гүзәллек!

Сәүдәгәрләр хөкем сөргән чакта,
Һәм сатылган чакта изелеп
Бар кыйммәтләр, нидер үтне сыта:
Ә сумнарда исәпләнә алмый,
Исәпләнми сумда изгелек!

Дәлилләмимени Җәлил үзе,
Күз карашын безгә батырып,
Ярдәм итмимени төшенергә? —
Бәй, сумнарда исәпләнә алмый,
Исәпләнми сумда батырлык!

Күпме тора иң беренче кабат
Гашыйк булу, уйнап кар ату,
Һәм озатып кайту өйгә кадәр?..
Юк, сумнарда исәпләнә алмый,
Исәпләнми сумда ярату!

Складлардагы үтмәс тауар булып,
Сораучысыз, тузан, чор иснәп,
Күңелләр дә сөрсеп ята сыман...
Тик сумнарда исәпләнә алмый,
Исәпләнми сумда чын хисләр!

# «ВАКЫТ, ӘФӘНДЕЛӘР, ВАКЫТ!»

XX гасыр башы татар әдәбиятының иң мәшһүр классикларыннан Фатих Әмирханның иҗади мирасы мәктәптә укыган еллардан алып барыбызга да мәгълүм. Аның турында «Әдипләребез» дигән икетомлыкның беренче китабында да (2009, төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани) шактый әтрафлы белешмә бирелгән; иҗаты, элеккеге елларда нәшер ителгән берничә сайланма әсәрләр тупланмасыннан тыш (әлегә соңгысы булган дүрт томлык 1984-1989 елларда чыга), һәртөрле хрестоматия китапларында чагылдырылган. Әсәрләренең чагыштырмача яңа җыелмасы 2002 елда дөнья күргән иде кебек (төзүчеләре: Д.Ф.Заһидуллина һ.б.). Шунысын искәртү кирәк: әле соңгы дип саналган дүрт томлыкта да, һәммәбезгә билгеле сәбәпләр аркасында, Ф.Әмирханның байтак кына әсәрләре, бигрәк тә публицистикасы һәм әдәби тәнкыйте (әйтик, Г.Исхакый иҗатына кагылышлысы) керми калган. Иҗади мирасына замандашларыбыз исеменнән лаеклы бәя биргән М.Гайнуллин, И.Нуруллин, М.Мәһдиев, Н.Вәлиев, Р.Әмирхан, Р.Ганиева, Р.Гайнанов, Т.Галиуллин, Д.Заһидуллина, Т.Гыйләҗев һ.б. галимнәрне рәхмәт хисе белән телгә алырга тиешбездер. Турысын әйткәндә, әдипнең иҗатына багышланган аерым хезмәтләр, мәкаләләр берән-сәрән күзгә чалынгаласа да, соңгы елларда шәхесе, тормыш юлына кагылышлы яңа сүз әйтелгәне юк шикелле әле. Иҗаты уңаеннан да, алда телгә алынган авторларның хезмәтләреннән тыш, төрле чыгышларда өзек-төтек фикерләр генә чагылып китә. Шуңа да, юбилей мөнәсәбәте белән, бу олуг затны хөрмәтләп искә алу фарыз гамәл булса кирәк. Мин, аңлашыла ки, әлеге күпкырлы, киң колачлы иҗатны иңләп, аның танылган галимнәребез күзеннән читтә әлегәчә калган якларын шушы кыска гына мәкаләдә ачып бирүгә дәгъва итмим.

Күренекле язучы, драматург, тәнкыйтьче, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Фатих Әмирхан (Мөхәммәтфатих Әмирханов), билгеле булганча, Казанның Яңа бистәсендә Зариф мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башта шундагы мәхәллә мәктәбендә, аннары заманы өчен алдынгы саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала. Бу елларда ул дөньяви фәннәрне һәм шәрекъ әдәбиятын да өйрәнә, мәдрәсә каршындагы рус классларында укый. Булачак әдип беренче иҗат күнегүләрен дә шунда ала, «Мөхәммәдия»дәге шәкертләр хәрәкәтенә авазлаш кулъязма газета-журналлар чыгаруда ул башлап йөри. Шәкертләр хәрәкәте көтелгән нәтиҗәне бирмәгәч, алар 70ләп шәриктәше белән мәдрәсәне ташлап чыга. Казан университеты студенты С.Гассарның аңа рус теле һәм әдәбияты, математикадан дәресләр бирүе билгеле. Революцион даирәгә тап булып, бер үк вакытта яңа заман сулышын тоя, сәяси сабаклар ала. Листовкалар тәрҗемә итүдә, аларны бастыруда һәм таратуда катнашса да, бәлки, аңардан Тукай шикелле революцион-демократ ясарга кирәк түгелдер?! Әлбәттә, кайбер галимнәребез Ф.Әмирханны Октябрь инкыйлабын хуплап каршы алган, дип язалар, ихтимал, бу хаклыкка якындыр?! Аның иҗтимагый-сәяси карашлары формалашуга бигрәк тә Самарадагы, Петербургтагы һәм Мәскәүдәге махсус курсларда белем эстәү зур йогынты ясый. Шул чорда (мәсәлән, Җаек каласында нәшер ителә торган «Әлгасрел-җәдид» журналында) яшь каләм иясенең беренче басма әсәрләре дә күренә башлый.

XX гасыр башында иҗат мәйданына килеп, халыкта киң танылу алган әдипләребезгә хас булганча, Ф.Әмирхан мәгърифәтчелек, балалар әдәбиятына хезмәт итүгә күп көч куя. Иҗат эшчәнлегенең дә чын мәгънәсендә 1907 елда Мәскәүдә басыла башлаган «Тәрбиятел-этфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле беренче татар

балалар журналында башлануын искә төшерик. Ул анда яшь буынның дөньяга карашын киңәйтә торган берничә фәнни-популяр мәкалә һәм әкиятне әдәби тәрҗемә итеп бастыра. Халык арасында киң танылу алган журналның, кызганыч, нибары биш саны гына чыгып кала.

«Тәрбиятел-әтфаль» басылудан туктагач, Ф.Әмирхан Казанга кайта һәм әдәби-публицистик эшчәнлеген тагын да киңрәк җәелдереп җибәрә. Әмма нәкъ шул чорда аның сәламәтлегенә зур зарар килә – яшь егетне паралич суга, һәм шуннан соң ул үз аягы белән йөри алмас хәлдә кала.

Бу урында, үзенә күрә бер лирик чигенеш ясап, әдипнең әле «Тәрбиятел-әтфаль»дә үк башланган иҗади эшчәнлеген дәвам итүен, Октябрь инкыйлабына кадәр сабыйлар өчен «Ул үксез бала шул», «Нәҗип», «Балалар атавы» һ.б. хикәяләр язуын да әйтергә кирәк. Бу әсәрләрендә ул сабыйлар күңелен аңлап, аларга «канат куючы» каләм иясе буларак таныла. Балалар өчен нәшер ителә торган «Ак юл» журналы белән иҗади хезмәттәшлеге дә шул изге эшнең дәвамы була.

1907 елда Казанда «Әл-ислах» газетасы чыга башлагач, Ф.Әмирхан әлеге басманы да өлешчә милли мәгариф, балаларны заманча тәрбияләү эшләренә хезмәт иттерүгә юнәлтә. Шунысы да бар, Ф.Әмирхан кадими-иске мәдрәсә, белем бирү системасын тәнкыйтьләп кенә калмый, бу хәлдән чыгу юлларын да эзләшә, үзенчә киңәшләр бирә. «Татарның тормышын аслыннан сүтеп төзәтергә кирәк!.. Тәрбия вә гыйлемханәләребезне тамырыннан яңартып корырга кирәк!.. Иске мәдрәсәләрне, милләтебезнең яшь гомерләрен... моннан соң да һәлак итеп тормасыннар өчен..., җир йөзеннән юк итәргә вакыт! Менә газетабызның мәсләге», – дип, алда торган бурычларны бик кискен куя ул.

Фатих Әмирхан «Әл-ислах» газетасының җаваплы секретаре генә дип саналса да, чынлыкта аның рухи-мәгънәви җитәкчесе була, һәм шунда аның беренче оригиналь әсәре – татар тормышындагы феодаль тәртипләрне, артта калуны тәнкыйть утында көйдереп, милли алгарыш, тәрәккыят идеалларын алга сөргән «Гарәфә кич төшемдә» исемле хикәясе дөнья күрә. Бу – әдәбиятыбызга яңача фикерләүче яшь әдип килүнең тәүге хәбәре була. Әлеге чорда ул «Картайдым», «Танымаганлыктан таныштык» кебек мәгълүм хикәяләрен, «Яшьләр» драмасын, «Фәтхулла хәзрәт» дигән атаклы сатирик хикәясен иҗат итә. «Картайдым» хикәясен әдәбият белгечләре, мәсәлән, Г.Исхакыйның «Тормышмы бу?», Г.Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» әсәрләре белән аваздаш дип табалар. Мөгаен, бу фикергә кушылмый да булмыйдыр.

Гомумән, «Әл-ислах» газетасында эшләү Ф.Әмирханның иҗатына зур этәргеч ясый: алда әйтелгәнчә, ул бу дәвердә татар әдәбиятының хәзинәсенә керерлек байтак әсәрләрен иҗат итә, төрле иҗтимагый-сәяси, мәдәни, милли мәгариф мәсьәләләрен күтәргән мәкаләләрен бастыра һәм биредә яшь әдип якын фикердәше, мәсләктәше булырлык Г.Тукай белән якыннан таныша.

«Әл-ислах» газетасы ябылганнан соң, ул Г.Тукай, Г.Камал исеменә бәйле «Ялт-йолт» журналы белән актив хезмәттәшлек итә. 1912 елдан 1918 елга кадәр «Кояш» газетасы идарәсендә җаваплы сәркатип вазифасын башкара. Бу басма турында танылган китап белгече һәм матбугат тарихчысы Исмәгыйль Рәми: «Көндәлек милли-демократик гәзитә. Татар матбугатында күтәрелгән мәсьәләләр буенча, башкаларга иярмәстән, үз карашын әйтә, шуны яклый торган гәзитә булып танылды... Гәзитә, нигездә, Фатих Әмирхан мөхәррирлегендә чыкты... Нашире – китапчы Кәримевләр иде...» – дип яза. Үз вакытында Ф.Әмирхан «урта юлдан баручы, сак» «Йолдыз» (редакторы – Һади Максуди), Әстерханда чыга башлап, берара Сәгыйть Рәмиев секретарьлык иткән «Идел» газеталары, асылда хәзерге «Казан утлары»ның юл башы булган, беренче саны Тукайның мәшһүр «Без бишенче елны уяндык таң белән...» дигән юллары белән ачылган «Ан» журналында да (редакторы – Әхмәтгәрәй Хәсәни) әдәби һәм публицистик әсәрләрен бастыра.

Революциягә кадәр Ф.Әмирхан үзен язучы буларак таныткан, милли тормышыбызны әтрафлы чагылдырган, үзәктә хатын-кыз язмышы торучы «Хәят» повестен, исеме үк тирән мәгънәгә ия булган (кызганыч, тәмамланмый калган) «Урталыкта» романын, «Тигезсезләр» драмасын, иске карашлы дин әһелен сурәтләгән «Хәзрәт үгетләргә килде», шәкерт мохитендә яшәгән хыялый «Габделбасыйр гыйшкы», чәй-шикәр тирәсендә чуалучы «Сәмигулла абзый», риваятьләргә, мифларга нигезләнгән,

романтик рухлы «Сөембикә», «Картада оттырылган Зөлхәбирә», «Ай өстендәге Зөһрә кыз», шулай ук «Кадерле минутлар» һ.б. мәшһүр хикәяләрен яза, көндәлек матбугатта үткен сүзле публицист һәм таләпчән әдәби тәнкыйтьче икәнлеген раслый. Әдипнең «Фәтхулла хәзрәт» кебек хәзерге мәктәп дәреслекләренә кергән әсәрен 1922 елда сәхнә әсәре итеп эшләве һәм әлеге пьесаның шул ук елда тамашачылар хөкеменә чыгарылуы билгеле. Аңлашылганча, бу әсәрләрнең күбесе хәзерге укучыга да яхшы таныш, шуңа күрә алар турында сүз озайтып торуның хаҗәте юктыр.

Октябрь инкыйлабыннан соң да Ф.Әмирхан иҗат эшчәнлеген сүндерми, иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышта актив катнаша, совет чорының газета-журналлары – «Эш», «Кызыл Армия», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» газеталары, «Шәрекъ кызы», «Безнең юл» журналлары белән язышa, төрле җыелышларда чыгыш ясый, яңа хөкүмәтнең карарларын тәрҗемә итү һәм редакцияләүдә хезмәт куя. Иҗтимагый эшчәнлек тә комачаулык иткәндер, – бу чордан аның хәзерге укучыга таныш әсәрләре күп түгел: «Чәчәкләр китерегез миңа» исемле нәсере, «Шәфигулла агай» дигән сатирик хикәясе генә аеруча киң танылган.

Совет хакимияте елларында, «Тәрбиятел-этфаль»ләрдән килүче эшчәнлеген дәвам итеп, Ф.Әмирхан Татарстанның яңа мәгарифен үстерү өлкәсендә үзеннән зур өлеш кертә. Ул милли мәгариф алдында торган бурычлар һәм аларны хәл итү юлларын күрсәтеп тирән эчтәлекле мәкаләләр яза. 20нче елларда үзе дә Казан театр техникумында татар әдәбияты укытып, сәхнә өчен милли белгечләр әзерләүдә турыдан-туры катнаша, «беренче баскыч эш мәктәпләре»нең беренче һәм икенче класслары өчен тәҗрибәле мәгариф хезмәткәре Г.Рафыйков белән уртак «Ана теле» дәреслекләре төзеп бастыра. Аның терминнар төзү комиссиясендәге, сүзлекләр һәм яңа дәвер мәктәпләре өчен укыту программалары төзү өлкәсендәге эшчәнлеге дә билгеле.

Р.Гайнанов һәм Р.Әмирхан хезмәтләрендә Ф.Әмирханның мәгариф системасын яңарту өчен никадәр күп көч салганлыгы ачык күренә. Мәсәлән, «Милләткә хезмәт итүче китапчы һәм педагог» дигән реплика рәвешендәге мәкаләсендә мәктәп дәреслекләрен кумәч урынына әвәләп торучы сәләтсез, принципсыз, тар карашлы кайбер замандашларыннан ул үзенең кабатланмас «Әмирхан көлүе» белән көлә. Гомумән, мәктәп өчен дәреслек төзүгә ул, Тукай кебек үк, гаять мөһим һәм җаваплы бер эш итеп карый. Мәктәп балаларын кечкенәдән җиңел кабул ителешле, иң яхшы кыска әдәби әсәрләр аша тәрбияләү кирәклеген күрсәтеп, Ф.Әмирхан: «Бу мәсьәләнең никадәр әһәмиятле икәнен беләсебез килсә, Толстой шикелле бөтен галәмнең зур әдипләреннән хисап ителгән затларның ... кыска-кыска хикәяләр язуга гомер сарыф иткәнлеген күз алдыбызга китерү җитәдер. Вакыт, әфәнделәр, вакыт! Искеләрне яңалар белән алыштырырга вакыт!» – дип яза. Аның бу сүзләре әле дә әһәмиятен югалтмаган.


Шунысы кызганыч: әдәбият тарихыннан «тукран төкреге» хәтле дә хәбәре булмаган кемсәләргә заманында Г.Тукай, Г.Исхакыйларга бәя бирү генә түгел, үз иҗаты белән гасыр башын яктырткан, яңа чор татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе Фатих Әмирхан исеме һични дә сөйләми, күрәсең. Чөнки юбилейлары килеп житкән саен, ул икенче бөек затыбыз Габдулла Тукай күләгәсендә кала килә. («Казан утлары» журналы гына әлеге олуг шәхесне – Ф.Әмирханны, юбилейлары уңае белән булса да, игътибар үзәгеннән төшерми, рәхмәт яусын.)

Тукай белән Ф.Әмирханның эчкерсез иҗади һәм шәхси дуслыгы турында инде байтак язылды. Гәрчә бу ике зур әдипнең үзара мөнәсәбәтләрен тасвирлауда әдәби әкиятләр күбрәк булуына карамастан (кодачасы – минем якташым, яшь туташ Зәйтүнә белән Тукайны таныштыру һәм кавыштырырга омтылу, аларның бәхетсез мәхәббәт тарихы үзе ни тора!), халкыбызның сөеклесе Тукай шәхесе һәм аның исеме белән тыгыз бәйләнгәнгә күрә генә дә түгел, алда әйтелгәнчә, Ф.Әмирхан үз иҗаты белән әдәбиятыбызның йөзек кашы булганга, берәүнең дә татарның ике бөек улын бер-берсенә каршы куясы килми, әлбәттә. Мин шулай ук, бу эш белән кичә һәм бүген кем шөгыльләнгәнен яки шөгыльләнергә тиешлеген яхшы ук белгәнгә күрә, әлегә ул хакта дәшми торам... Фатих Әмирхан кояшын андый болытлар каплый алмас. Мин шуңа ышанам.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**



*Шагыйрьнең Мәскәүдә яшәгән еллар истәлеге.*
*Сулдан уңга: Фатих Исхаков,*
*Муса Җәлил, Әхмәт Ерикәй.*
*Үткән гасырның 30нчы еллары.*



*Җәлил һәйкәле янында*
*һәрчак халык була.*



*Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу уңаеннан үткәрелгән*
*тантаналы җыелыштан күренеш. Трибунада — Туфан Миңнуллин.*
*Мәскәү. Советлар йортының Колонналы залы. 1986 ел.*



*Казан университетының әдәби берләшмәсе әгъзалары язучыларның Тукай клубында (Бауман, 19) иҗади хисап тота. Сулдан уңга: трибунада Нил Юзиев (җитәкче), Раушания Низамова, Равил Фәйзуллин, Әнвәр Шәрипов, Рәдиф Гатауллин, Булат Сөләйманов, Нурмөхәммәт Хисамов, Тәүфикъ Камалиев. 1964 ел.*




*Санкт-Петербургта бөек галим Лев Гумилёвның музей-фатирында. Сулдан уңга: музей-фатирның мөдире Марина Козырева, шагыйрьләр Газинур Морат һәм Фәйрүзә Мөслимова. 2011 ел.*

# ИКЕ ОЧРАШУ

*Бу көннәрдә мин кулыма Муса Җәлилнең шигырьләрен аламмы яисә аның турындагы истәлекләрне укыйммы, ничек кенә булмасын, һәр юлы мин аның белән бергә үткәргән ике кичәне хәтеремә төшермичә калмыйм.*

Аның берсе 1923 елның көзге айларында булды.

...Казанда татар студентларының чәй һәм сый белән оештырылган бер кичәсендә мине яңа ачылган татар рабфагының бер укучысы белән таныштырдылар. Өстенә кара сатин күлмәк киеп, билен киң ремень белән буган, күрер күзгә яшүсмер малайны хәтерләткән кара чәчле, үткен кара күзле егет, миңа кулын биреп, исемен авыз эченнән генә әйтте. Тирә-якта яшьләр шаулашалар-гөрләшәләр иде — егетнең исемен ишетми калдым, кайтарып сорамадым, дөресе, кызыксынмадым. Чөнки егет үзенең төсе-бите, кием-салымы, барыннан да бигрәк, үзен тотышы белән күзгә ташланырлык түгел иде. Әйләнә-тирәдәге башка егетләрнең күбесе — йә завод-фабрикалардан килгән, йә гражданнар сугышы фронтларын үткән, утны-суны кичкән егетләр. Моны аларның кием-салымнары, кояшта, яңгырда уңган, беренче төсен күптән югалткан, урыны-урыны белән ямалып та өлгергән гимнастёркалары, чалбарлары, күпне күргән хәрби ботинкалары сөйләп тора. Аннан алар игътибарны җәлеп итәрлек шау-шулы, тынгысыз егетләр иде.

Яңа танышым тыйнак, оялчан иде, ахры. Табын янында да, соңыннан залда, уеннар барганда да тавышын чыгармады, үзен күрсәтмәде. Кичәдә бар идеме, юк идеме — аны сизмиләр, күрмиләр иде шикелле. Шулай да, «римский папа» уены башланып, егетләрне, кызларны зал уртасына чыгарып, төрле «җәзалар» бирергә керешкәч, аңа да чират җитте. Уенны алып баручы — аның белән бергә укучы кызларның берсе булса кирәк — кара күзле егетне зал уртасына чакырды да, уйнаучыларга карап, сорады:

— Нинди «җәза» бирәбез моңа?

Берничә кеше беравыздан кычкырды:

— Шигырен укысын, шигырен!

«Шигырен укысын?.. Кем булуы мөмкин моның?..» — дип уйладым мин. Чөнки Казандагы, бигрәк тә студентлар арасындагы яшь шагыйрьләрнең барысын да диярлек күреп белә идем. Әмма бу егетне, дөресрәге, үсмер малайны беркайда күргәнем һәм очратканым булмады. Шуңа күрә бу студентның чыгышын бик кызыксынып көтә башладым.

Егет, бераз уңайсызланып, аска карап, оялгандай басып торды. Мин аны шулай бераз басып торыр да, бер сүз дә әйтмичә, «җәзасын» үтәмичә, кешеләр арасына кереп югалыр һәм иптәшләрчә гомуми көлүгә сәбәпче булыр дип көткән идем. Ләкин алай булып чыкмады. Егет сынын турайтты, ике кулы белән каешын рәтләп, күлмәк итәген тарткалап куйды, башын күтәрде... Минут та үтмәде, кара тутлы яшүсмер егет, билгесез шагыйрь шау-шулы залны үз кулына алды, ихтыярына буйсындырды. Бу минутта хәтта иң шау-шулы егетләр белән чыркылдавык кызлар да тынып калдылар.

Шагыйрь ниндидер бер сылу кызның мәхәббәте турында сөйли иде. Төн уртасы, авыл кырыендагы салам түбәле ярлы йорт. Капка төбендә, караңгыда, кешеләрдән качып, бер яшь кыз белән бер яшь егет басып тора. Кыз күз яшьләрен коя. Чөнки ул сөйгән егете, җанкисәге белән саубуллаша. Егет еракка, халык бәхете өчен, азатлык өчен каты сугышлар барган якка кан эченә китә. Китмичә ярамый. Аны анда ил чакыра, намусы чакыра... Аерылышу авыр, читен, йөрәкләрне телгәли...

Хәзер мин күп еллардан соң, бу шигырьнең эчтәлеген тулысынча хәтерләмим, әмма аның безне, сугышчыларны, фронтларны күргән, аерылышу дигән ачы шәрабның тамчысын да калдырмыйча эчкән егетләрне, уйланырга, тынып калырга мәҗбүр итүен бүгенгедәй хәтерлим. Шигырен укучы егет тә күңеленнән шундый ук хисләрне кичерәдер иде кебек: йөзе алсуланган, кара күзләре чаткыланып яна, ә үзе җаны-тәне белән шигырь рухына бирелгән...

Шигырь укылып бетте. Зал кул чабарга, яшь шагыйрьне алкышларга кереште. Егет, оялып булса кирәк, иптәшләре арасына кереп югалды.

— Кем бу? — дип сорадым мин күршемнән.

— Муса Җәлил, — диде ул.

Мусаның шигырьләрен газеталарда, яңа гына чыга башлаган әдәби журналларда укыганым булса да, моңа чаклы үзен күргәнем юк иде. Мин аны, поэтик талантына, үсеп, күтәрелеп килүенә һәм шигырьләренең киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итә башлавына карап, зур гәүдәле, таза бер егет итеп күз алдына китерә идем. Ә ул менә нинди икән! Тәбәнәк буйлы, җыйнак гәүдәле үсмер егет.

Соңыннан миңа Муса белән күп мәртәбәләр очрашырга, Мәскәүдә бер үк елларны университетның бер үк факультетында укырга, бер үк әдәби оешмада торырга, аннары утызынчы еллар ахырында Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә сайланып, аның белән бергә эшләргә дә туры килде. Шуңа карамастан, Мусаны мин нигәдер күп очракта беренче һәм соңгы тапкыр очрашуларым белән күз алдыма китерәм.

Соңгы тапкыр очрашуым да хәтеремдә яхшы сакланган.

1942 ел. Гыйнвар[1]. Каты салкын көннәр. Муса, Минзәләдәге хәрби политик курсларны тәмамлап, берничә көнгә Казанга, гаиләсе, иптәшләре янына кунакка кайтты. Бераз ябыккан, яңаклары суырылып кергән булса да, шинель киеп, билен каеш белән каты итеп бугач, чыныгып, тазарып киткән, хәтта буйга да үскән шикелле тоелды. Йөзе дә салкын җилләр белән киселгән, янган. Бу да аңа нindидер батырлык төсе бирә иде.

Мусаның кунакка кайту хәбәре язучылар, артистлар, композиторлар арасында бик тиз таралып өлгерде.

Без, Казаннан Мәскәүгә, ГлавПУРККА[2] карамагына, аннан фронтка китәчәген белеп, аның хөрмәтенә үзебезчә озату кичәсе оештырырга булдык. Берникадәр акча җыеп, мәҗлесне авыр сугыш вакыты мөмкинлек биргәнчә, хәлебездән килгәнчә, сый белән, хөрмәт белән үткәрергә җыендык. Мәҗлесебезгә кайбер композиторлар да, артистлар да катнашырга теләкләре барлыгын белдерде.

Шагыйрь иртәгә чыгып китәсе дигән кичне язучыларның Г.Тукай исемендәге клубына җыелдык. Халык көтелгәннән артык килде: язучылар, артистлар, композиторлар һәм нәшрият җитәкчеләре... Кунакларыбыз да җитәрлек. Иң зур кунак, билгеле, Муса. Ул — мәҗлес түрендә. Аның белән янәшә урындыкларда рус язучыларыннан Алексей Сурков, Владимир Бахметьев, Италия язучысы, коммунист Джованни Джерманетто һәм башкалар утыралар.

А.Сурков хәрби киемнән. Ике шпалалы — димәк, батальон комиссары. Яңа гына фронттан килгән. Аның хатыны, балалары Татарстанда, эвакуациядә. Шулар янына кайткан булса кирәк.

В.Бахметьев, Д.Джерманетто һәм башкалар октябрь урталарыннан бирле Казанда яшиләр. Алар да эвакуация белән килгәннәр.

Татар язучыларыннан Нур Баян белән Риза Ишморат та хәрби киемле. Н.Баян Казандагы частьларның берсендә хезмәт итә. Политрук Р.Ишморат әле фронтка китмәгән, элеккеге Каргопольский казармада яши, танк училищесында эшли. Озакламыйча алар да фронтка, ут эченә китәчәкләр.

Клуб салкын. Өске киемнәрне салырлык түгел. Тәрәзәләр бәсле, калын пәрдәләр белән томаланган, караңгылатылган. Түшәмдәге анда-санда калган лампочкалар да тонык булып, саргылт нур сибеп яналар. Әмма аның каравы сугыш еллары өчен табыныбыз шактый мул: һәр кеше саен 200 грамм кара ипи, аның өстендә 30 грамм чамасы ак май, чөгендердән, бәрәңгедән ясалган винегрет, бер кисәк селёдка һәм ике «борынга» бер «кечкенә» эчемлек. Аларны, һәр ике кеше каршына берне утыртып, өстәл буйлап тезеп куйганнар.

Кичәнең ничек ачылуын, ничек дәвам итүен язып тормыйм. Бер караганда, ул гадәттәге дуслар кичәсе иде. Аерылышып, бер-берләрен озак күрми торганнан соң, дуслар очрашканнар, сөйләшәләр, көлешәләр... һәм шундук аерылышырга әзер торалар. Көннәр авыр, ел дәһшәтле. Дусларның моннан соң, кем белә, бәлки, беркайчан да очрашмаулары, болай җыелышып, сөйләшеп утыра алмаулары да мөмкин. Бик мөмкин.

[1] Кичә 1942 елның 7 гыйнварында үткәрелгән. ТР Милли архивы: Р — 7083 фонд. 28 эш. 204 бит.
[2] ГлавПУРККА — Главное Политическое Управление Рабоче-крестьянской Красной Армии.

Икенче караганда, шагыйрьнең отчёт кичәсе дә иде бу. Муса үзенең Кызыл Армиядә үткәргән алты ай эчендә нәрсәләр эшләвен, ничек укуын, нинди хәрби юл үтүен сөйләде һәм безгә яңа шигырьләрен укыды. Хәер, бу кичәдә икмәккә, хәтта майсыз винегретка зур мохтаҗлык булса да, шигырьгә мохтаҗлык сизелмәде. Шигъри сый мул иде. Чөнки монда шагыйрьләрнең атаклылары җыелган: М.Җәлил, Г.Кутуй, Н.Баян, А.Сурков, Д.Джерманетто һ.б. Мондый плеяданы шуннан соң Тукай клубының күргәне булдымы икән?

Шәрабе җитәрлек булмаса да, тостлары күп булды. Ул елларда дуслар буш бокаллар белән дә тост күтәрә беләләр иде. Тостларның иң зурысы, әһәмиятлесе, билгеле, Муса хөрмәтенә багышланды. Аңа мактау сүзләре дә аз яумады.

Мин Шәриф Камал белән Гадел Кутуй арасында утырам. Бокалларыбыз бушамаган иде әле. Без, аларны кулыбызда тотып, кешеләрне, урындыкларны аралап, Муса янына бардык, аның белән чәкешеп, тост күтәрергә уйладык. Муса урыныннан торды, чәкештек, ләкин бокалны иреннәренә тидермәде.

— Бер үтенечем бар, Шәриф абзый, — диде.

— Нинди үтенеч?

— Иптәшләргә әйтегез әле: зинһар, урынсыз мактамасыннар.

Шәриф ага бик аз сүзле кеше иде. Ул аңа тел белән түгел, ә елмаю белән генә җавап бирде: «Нишли алам соң мин? Мактыйлар икән, димәк, мактарлык эшләрең бар», — дип әйтергә теләде шикелле ул үзенең елмаюы белән.

Чыннан да, бу кичәдә мактаулар Мусаны боектырды шикелле. Ул, кайберәүләр сөйләгәндә, күтәрелеп карарга уңайсызланып, башын түбән иеп утыра башлады.

Күп еллар үткәч, мин Мусаның бу кичә турында М.Максудка язган хатын укыдым һәм аның ул кичәдәге мактауларны күтәрә алмавын тагын бер кат күз алдыма китердем. «Мине бераз артыграк мактадылар, — дип яза ул хатында. — Шуңа күрә миңа уңайсыз булды. Ә болай бик яхшы. Мондый игътибар һәм хөрмәткә мин бик дулкынландым».

Без бокалларыбызны явыз дошманны җиңү өчен һәм дусларыбызның сугыштан исән-сау әйләнеп кайтуы өчен күтәрдек.

Урыннарыбызга кайтып утырдык. Ш.Камал тик шунда гына Муса үтенече турында үзенең фикерен әйтте:

— Талантлы егет. Мактарлык.

Бу очрашуыбыз соңгысы булды. Шуннан соң миңа Муса белән дә, Нур Баян белән дә очрашырга насыйп булмады.

...Еллар уза, сулар ага тора, еллар белән бергә син дә киләчәккә барасың, утлар, сулар кичәсең, чәчләрең агара, картаясың, әмма күңел картаймый. Ул, онытылмаслык хатирәләрне бик кадерләп саклап, үзе белән бергә киләчәк елларга алып бара. Минем күңелемдәге бу хатирәләр дә — киләчәккә бара торган хатирәләр.

**Афзал ШАМОВ**
*1966 ел*

# БЕР ФОТОРӘСЕМ ТАРИХЫ

Бу — Муса Җәлилнең Казанга килгәч беренче төшкән рәсеме. Унда — шагыйрьнең татрабфактагы сабакташы, җәмәгать эшләрен бергә башкарган яшьлек дусты Нәгыймә Насыйрова[1]. Язучы Афзал Шамовның[2] архивында шундый рәсемнәр ике данә иде: шагыйрь берсен — А.Шамовка, ә икенчесен Гадилә Насыйровага[3] бүләк иткән. Рәсемнең артында Муса кулы белән болай дип язылган: «Парлы

[1] Нәгыймә Насыйрова (1905-1979) — М.Җәлил белән татрабфакта бер группада укыган. Беренче Мәскәү университетының юридик факультетын Җәлил белән бер чорда тәмамлый. Күп еллар Аралашу юллары министрлыгында инженер-экономист булып эшләде.

[2] Афзал Шамов (1901-1990) — язучы. 1925-1930 елларда Беренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультеты студенты.

[3] Гадилә Насыйрова-Шамова (1902-1982) — А.Шамовның тормыш иптәше.

дуслар. Бәхетле көннәрнең бер хатирәсе. Казан, 1923 ел, декабрьнең 23е». Муса Җәлил имзасы.

Икенче рәсем Афзал Шамов хатынының сеңлесе Нәгыймә Насыйровага бүләк ителгән, аның артында мондый сүзләр бар:

*«Шулай*
*Мәңге ил багында бергә*
*Яшәрбез эш җирендә, ямьле җәйдә,*
*Кара эчле явызлар шунда безгә*
*Карап, тик үртәлеп үлсеннәр, әйдә!!!*
*Муса Җәлил.*
*23 декабрь, 1923 ел, Казан».*



М.Җәлил Нәгыймә Насыйровага бер шигырь *(«Сайланма әсәрләре». I том. 500 бит)* багышлаган:

***Ил чәчәгенә***

*Эшче кызының альбомына*

*Илдә туып үскән бер кыз*
*Син, Нәгыймә!*
*Күктә янып торган йолдыз*
*Син әле дә.*
*Җир йөзенә нурың чәчеп шатланасың,*
*Мактанасың, шаян диңгез,*
*Үз ягыңда.*

*Юләр яшьлек ямен котлап тилерәсең,*
*Шаярасың, көләсең дә көлдерәсең,*
*Ут икәнсең, ут икәнсең, бигрәк инде,*
*Бер карауда сөйдерәсең, көйдерәсең.*

Ә өченче томның 472нче битендә шундый хат басылган:

*Нәгыймә Насыйровага*
*15 февраль, 1928 ел, Мәскәү.*

*Нәгыймә!*

*Сәлам. Сине Мәскәүдә сагыналар. Озак кунак булдың. Кайт инде. Без монда тетеп укып ятабыз. Зачётлар якынлаша. Колак артын кашый башладык. Син ул турыда бер дә кайгырмыйсыңмыни? Укуның иң кызу вакытында әллә кайда кунак булып йөрисең! Килгәндә Казан яңалыкларын, Казандагы дуслардан хатлар, сәламнәр төяп алып кил. Татрабфакка кереп чыксаң, минем Зәйнәп, Хәдичә дигән сеңелләрдән хәбәрләр алып кил. Боларның барысыннан да бигрәк менә бу йомышны үтә. Бер дә уйламаган-көтмәгәннән кинәт кенә сиңа шундый ашыгыч хат язарга мәҗбүр иткән сәбәп тә менә шул йомыш: мин 25 нче елны ук бер шигырьләр дәфтәремне югалткан идем. Өч ел буена эзләп, кайгырып, янып, таба алмый һәм кайдалыгын белә алмый аптырадым. Бүген Шамов миңа шул турыда сөйләде. Һәм шул дәфтәрнең синдә булганлыгын әйтте. Син, зинһар, шуны үзең белән алып кил әле. Онытма, алып кил! Ышанам. Әле хәзергә хуш.*

*Сәлам белән, Муса Җәлил.*

**Әлфия ШАМОВА**

# МУСА ҖӘЛИЛ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ПОЭТИК ЛИНГВИСТИКАСЫ

*Герой-шагыйрь Муса Җәлил иҗаты турында меңнәрчә язмалар, фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр дөнья күргән, кинофильмнар төшерелгән. Шулай булгач, аның иҗаты һәм тормыш юлы җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелгән, әйтәсе сүз әйтелгән, яңалыкка, ачышларга урын калмагандыр дигән нәтиҗә ясарга да була кебек.*

*Әмма шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» шигырьләренең тел-стилен өйрәнеп, кандидатлык диссертациясен яклаган, 35 ел дәвамында тулаем иҗатын тикшереп, докторлык диссертациясен әзерләгән, 50дән артык фәнни-публицистик хезмәт язган, әдәби әсәрләр иҗат иткән җәлилче-галим буларак, шуны әйтә алам: әле безгә Муса Җәлил иҗатын заман белән бәйләп кайта-кайта, кабат-кабат өйрәнергә, энциклопедиясен дә төзергә кирәк.*

*Әлеге әдәби, фәнни-публицистик мәкалә Муса Җәлилнең тууына 110 ел тулуга багышлана һәм анда, моңа кадәр язылган хезмәтләрдән аермалы буларак, шагыйрь иҗатын атаклы «Моабит дәфтәрләре» шигырьләре аша гына түгел, ә бәлки тулаем поэзиясенең тел-стиль үзенчәлекләрендә гәүдәләнеше белән бәйләнештә тасвирлауга игътибар ителә.*

## Данлы юл башы

Муса Җәлил кечкенәдән шигырьләр яза башлый. Әле аларны барлап-табып алып өйрәнәсе бар. Хәзерге вакытта безгә аның кече яшьтә — 1918 елның декабрендә юллы дәфтәр битенә язган «Ятим бала» исемле шигыре генә мәгълүм. Шул шигырендә үк кечкенә Җәлил ятим баланы һәлакәткә дучар иткән байларны, муллаларны фаш итеп, ятим баланы чын күңеленнән кызганып яза.

1919 елның сентябрь аенда аның «Кечкенә Җәлил» имзасы белән Төркестан фронты Сәяси идарәсе органы булган «Кызыл йолдыз» газетасының беренче битендә «Бәхет!» исемле шигыре басылып чыга. Бу — каләм тибрәтә башлаган яшь шагыйрьнең матбугатта дөнья күргән тәүге шигыре. Беренче шигыре булса да, шунысы гаҗәп: ул А.С.Пушкинның «Евгений Онегин» дигән мәшһүр шигъри романындагы, әдәбият теориясендә «Онегин строфасы» дигән атама белән мәгълүм 14 юллык шигъри строфа формасында язылган. Әлегә кадәр татар шигъриятендә моңа охшаш 12 юллык тезем Г.Тукайның рус балалар шагыйре Н.Поздняковтан файдаланып иҗат ителгән, «Йолдыз» гәҗитенең 1909 елның 3 октябрь санында басылган «Китап» шигырендә генә була. Ул мондый юллар белән башлана:

*Һич тә күңлем ачылмаслык эчем пошса,*  
*Үз-үземне күрәлмичә, рухым төшсә,*  
*Җәфа чиксәм, йөдәп бетсәм, бу башымны*  
*Куялмыйча җанга җылы һичбер төшкә;*  
*Хәсрәт соңра хәсрәт килеп алмаш-алмаш,*  
*Күңелсез уй белән тәмам әйләнсә баш,*  
*Күзләремдә кибеп тә җитмәгән булса*  
*Хәзер генә сыглып-сыглып елаган яшь...*

Алдагы өч строфада шарт фигыль формалары кулланылмый. *«Шул вакытта мин кулыма китап алам, / Аның изге сәхифәләрен актарам»,* — дигән юллар белән башланып, соңгы юлларга кадәр нәтиҗә ясау дәвам итә.

Муса Җәлилнең «Бәхет!» шигыренең 10 юлы да үзара рифмалашкан шарт фигыль формаларыннан гына тора:

*Кулыма мин кызыл кылычны алсам,*
*Шулай шуннан кызыл фронтка барсам,*
*Олуг бер дәрт белән сафка атылсам,*
*Кулымны уртага — дошманга салсам,*
*Бөтен куәт белән шунда сугышсам,*
*Җиңелми мин һаман да алга барсам,*
*Менә шунда берәр пуля очса-килсә,*
*Килеп ул күкрәгемне бишкә киссә,*
*Үлем кулы килеп басса — егылсам,*
*Җаным күккә — гарешкә очса-китсә, –*
*Менә шунда бәхетле мин, бәхет — шул,*
*Минемчөн зур олуг шан, зур бәхет ул.*
*Шулай, эшчем, кораллан, бар сугышка,*
*Юлыңнан кайтма син, кирәк егыл — үл!*

Нинди максатчан, реалистик-романтик һәм шул ук вакытта нинди күтәренке революцион-патриотик пафос белән сугарылган шигырь! Бу юлларны 13 яшьлек үсмер язган дип уйларлык та түгел хәтта! Кызыл сәяси патриотик агитацияне үзенең реалистик-романтик дәртле омтылышы аша нинди ялкынлы сүзләр белән тасвирлап биргән! Тикмәгә генә фронт сәяси газетасының беренче битендә урнаштырылмаган инде ул!

Бу — пропаганда-агитация максатыннан язылган «кызыл» шигырь генә дә түгел. Әйтерсең, яшь шагыйрь шушы юллар аша үзенең киләчәк тормышын, иҗат һәм көрәш юлын ныклы итеп алдан билгеләп куйган.

Муса Җәлилнең көрәшче-шагыйрь буларак формалашуын һәм поэтик иҗатын бербөтен итеп күз алдына китерү максатыннан, аның әлеге шигырен анализлауга җитди игътибар бирергә туры килә.

Киләчәктә үзенең иҗат кредосына әйләнәчәк бу шигырьнең хикмәте тирәндәрәк ята икән әле! «Онегин строфалары»н рус әдәбиятында М.Ю.Лермонтовтан башка шагыйрьләр кулланмаган дип әйтерлек. Мондый дүрт юллы строфалар ныклы бер үлчәмдә — икешәр иҗекле *абаб, аабб, абба*, ягъни аралаш, янәшә һәм тулы рифмалы — рус поэзиясендә ямб дип атала торган, ике иҗекле, басымы икенче иҗеккә төшә торган шигъри калыпка салып язылган. (А.С.Пушкинның атаклы: «Пора, пора, роги трубят...» дип башланган шигыре шуның классик үрнәге булып санала.) Алар, гадәттә, дүрт баскычлы сюжет-композициягә корылган була: беренче строфада тема бәян ителә, икенчесендә ул үстерелә, өченче дүртьюллыкта сюжет кульминациягә күтәрелә, соңгы ике юлында исә, лирик-фәлсәфи яисә кинаяле шаян, яки ironияле һ.б. төрле, гомумән, афористик нәтиҗә ясала. («Евгений Онегин»да шаян, ironияле нәтиҗә төре күп.)

«Евгений Онегин»дагы 500 шигъри строфа нәкъ менә шул кыса-калып үлчәмендә язылган да инде. 13 яшьлек шагыйрь бәхет төшенчәсен азатлык көрәшенә бәйләп, халык бәхете өчен көрәштә корбан булуны зур, данлы эш дип, ышанычлы рәвештә, сәнгатьле һәм үтемле итеп тасвирлап бирә алган. Шигырь, беренче чиратта, шуның белән игътибарны җәлеп итә: анда фикер дә, шул теләк-максатны гәүдәләндерүче сүзләр дә, ачык, аңлаешлы рәвештә, нык инанып, укучыны да шуңа ышандырырлык итеп, шул чорга хас пафосны тагын да көчәйтеп, кискенләштереп әйтелгән. Эпитет-сыйфатлаулар, сынландырулар тезем рәвешендә, нигездә, шул «Онегин строфасы»на охшаш, әмма рифмалары бөтенләй башкача: шигырьнең 10 юлы да шарт фигыльләрдән генә торган *а1... а10* формалы *(алсам, барсам, атылсам, салсам, сугышсам, барсам, очса-килсә, бишкә киссә, егылсам, очса-китсә).*

Соңгы строфасы да ааба формалы, үзенчәлекле рифмага корылган. Күренгәнчә, ул фигыль формалары вакыйгаларны киеренкеләндереп, сугышчыларның канын кыздырырлык, дәрт-гайрәт, көрәш ялкыны кабызырлык итеп сайлап алынган.

Шигырьнең сюжет-композициясе «Онегин строфасы»н төгәл кабатламаса да, аның фабуласы шулай ук дүрт баскычлы: беренче дүртьюллыкта тема ачыла, икенчесендә — тагын да үстерелә, өченчесендә — кульминациягә күтәрелә, шул мәгълүм строфадан аермалы буларак, ул ике юлдан гына гыйбарәт, ләкин аның каравы, нәтиҗә өлеше дүрт юлдан тора: баштагы ике юлда нәтиҗә ясала, соңгы ике юлда исә шигарь буларак кабул итәрдәй сугышчан өндәү — чакыру *(«Шулай, эшчем, кораллан, бар сугышка, / Юлыңнан кайтма син, кирәк егыл — үл!»)* белән тәмамлана.

Шигырьнең лексикасы да сугышчан рухны күтәрерлек, максатчан кулланылган: *«кылыч», «фронт», «саф», «дәрт», «дошман», «пуля», «күкрәк», «гареш», «бәхет», «эшче», «юл»* һ.б. шигырьнең гомуми эчтәлеген, эмоциональлеген күзалларга мөмкинлек бирә, мотивлашкан поэтик лексикасы исә эчтәлекнең доминанта-үзәк идеясен хасил итә. Шушы лексик катлам тирәсендәге гомумкулланыштагы нейтраль-битараф сүзләр дә шигырьдәге идея-эстетик максатка хезмәт итә башлый һәм алар битараф лексик берәмлектән яңа төсмерләр белән баетылган эмоциональ-тәэсирле сүзләргә әйләнә.

Үз чиратында, мотивлашкан сүзләр нигезендә метафоралар һ.б. төрле троплар — тасвирлау-сынландыру чаралары барлыкка килә: *кызыл кылыч, кызыл фронт, олуг дәрт, бөтен куәт белән, олуг шан* һ.б.

Алдагы юлларда күрсәтелгән теләк формасында рифмалашкан шарт фигыль формалары шигырьнең эчке динамикасын, яңгырашын, киеренке эчке хәрәкәтен, уй-фикерне, хис-тойгыны көчәйтә һәм аларның үзара тыгыз бәйләнешен барлыкка китерә.

Әлбәттә, Җәлилнең «Бәхет!» шигырен тышкы яктан «Онегин строфасы»на тиңләү белән генә чикләнеп калу берьяклырак караш булып тоелыр иде. Чөнки бу очракта татар халык авыз иҗатында һәм язма әдәбиятта мәгълүм урын тоткан синтаксик фигураны — теземне яки, икенче төрле әйткәндә, периодны да искә алырга кирәк була. Теземнең классик үрнәге итеп, гадәттә, Г.Тукайның бая искә алган «Китап» шигырен мисалга китерәләр. Дөрес, шагыйрь аны рус балалар шагыйре Н.Поздняковның «Книга» исемле шигыреннән файдаланып язган һәм шигырьнең астына «аз гына русчадан» дип, искәртеп тә куйган һәм ул, күренгәнчә, тоташ теземнән тормый, аның беренче ике строфасы гына теземгә нигезләнгән.

Гадәттә, әдәбият галимнәре тезем-периодны көттерү паузасы белән аерылган ике интонацияле (күтәрелү һәм төшү) бер җөмлә дип тә күрсәтәләр. Периодның икенче өлеше эчтәлеге белән йомгаклау, нәтиҗә, вакыт, максат, шартлылык һ.б. белдерү рәвешендә — төрлечә булырга мөмкин.

Г.Тукайның шул 12 юллык «Китап» шигыре — теземнең шушы билгеләренә өлешчә туры килгән мисал. Әлеге уңайдан шунысын да әйтергә кирәк: «Онегин строфасы»ндагы шигырь юллары 9ар иҗекле, «Китап» шигыре — 12шәр иҗекле, «Бәхет!» шигыре исә 11 иҗекле.

Ихтимал, «Кечкенә Җәлил» әлеге шигырь үрнәкләре белән таныш булгандыр, әмма, ничек кенә булмасын, ул аларның берсен дә кабатламаган. Җәлилнең тезем белән язылган башка шигырьләре дә бар. Мәсәлән, 12 юллык «Үземә» шигыре шулай ук теземгә нигезләнгән, ләкин ул 6 строфалы, тоташ *а...а* рифмалы, аның сюжет-композициясе, фабуласы, ритм-рифмасы, иҗекләр саны да бөтенләй башкача. Анда ачыктан-ачык көрәшкә өндәү булмаса да, ул аның шул тормыш эчендә тынгы белми янып яшәвен күрсәтә.

Әлбәттә, Җәлилнең беренче шигырьләренең теле әле шактый кытыршы. Аларда шул чорның эчке каршылыклары, тирән шәхси һәм социаль кичерешләрдән бигрәк, башлыча, вакыйгалар һәм аларның тышкы ягы сурәтләнә һәм әлеге шигырьләрдә шул чорның идол-символына әйләнгән «кызыл» эпитет-сыйфатлауның кирәгеннән артык кулланылуы күзгә бәрелеп тора. Ул эчтәлектә генә түгел, әсәрләренең

исемнәрендә дә киң кулланыла башлый. Һәрхәлдә, аның 13 шигыре шул төсне белдерүче сүз белән ясалган: 1918-1921 еллардагы башлангыч иҗатында: *«Кызыл әләмгә», «Кызыл таң нурлары», «Кызыл каһарман», «Кызыл гаскәр», «Кызыл юл», «Кызыл бәйрәм», «Кызыл юл белән»;* 1921-1923 елларда — «*Кызыл көч»;* 1930-1932дә — «*Кызыл галстуклы Урал*»; 1933-1935тә: «*Кызыл очкыч җыры*», «*Мәңге сүнмәс кызыл байрак»;* 1936-1937дә — «*Кызыл йолдыз*».

Күренә ки, шагыйрь алдагы иҗатында, тормышның асылын тирәнрәк аңлый башлап булса кирәк, ул символ-төс куллануын әкренләп киметә барган. Ниһаять, «кызыл» эпитеты, «соңгы могикан» кебек, «Кызыл ромашка» шигырендә, хәтта «Моабит дәфтәрләре»нә кадәр килеп җитә.

Иҗатында кызыл төс куллану турында сүз кузгатылгач, хронологияне бераз үзгәртеп, бу үзенчәлеге хакында әйтеп үтәргә туры килә: соңга таба аның 526 тезмә әсәре исемендә ал, күк, зәңгәр, җирән төсләр килеп керә: «Ал чәчәкләр» (1938-1941), «Зәңгәр күл» (язылу вакыты билгесез; 30нчы еллар булуы ихтимал), «Күк юрга» (1934), «Җирән кашка» (1938). Фронт лирикасында һәм «Моабит дәфтәрләре»ндәге «Кызыл ромашка»дан башка «төсле» шигырь исемнәре башкача очрамый. Әмма шигырьләрендә бу төсләрдән башкалары да шактый киң кулланылган.

Шагыйрь иҗатында төсләрнең табигатен, аларның үсеш-үзгәреш эволюциясен бөтен иҗаты буенча үтәли анализлап чыкканда, шактый кызыклы күзәтүләр ясарга була. Хәер, гомумән, язучы, шагыйрь иҗатында сүз куллану үзенчәлеген, аның лингвистик поэтикасын нәкъ менә шушы алым белән эш иткәндә генә дөрес һәм тулы итеп күз алдына китерергә мөмкин.

М.Җәлилнең шигырь эчтәлегендә төсләр куллануы — еш очрый торган күренеш. Хәзер шуларга игътибар итик. Бу үзенчәлекне беренче шигыреннән алып соңгысына кадәр күзәтү шагыйрьнең төсләр куллану эволюциясен дә, поэтик фикерләвенең үсеш-үзгәрешен дә күзалларга мөмкинлек бирә.

Мәсәлән, 1918-1920 елларда «кызыл», көчәйткеч кисәкчәле «кып-кызыл» эпитетлары аеруча актив кулланылган, кайберләре төрле шигырьләрдә берничәшәр тапкыр кабатлана (аларның саны җәяләр эчендә күрсәтелә). *Кызыл кан, кызыл әләм* (2) — «Хакыйкать»; *кып-кызыл күк, кып-кызыл байрак* (2) — «Тартыш»; *кызыл кылыч, кызыл фронт* (2) — «Бәхет!»; *кызыл әләм, кызыл бәйрәм* (2) — «Ирек бәйрәмендә»; *кызыл кылыч, кызыл әләм, кызыл яу* (3) — «Ирек шәме нурын сачкәндә»; *кызыл ялкын, кып-кызыл байрак, кызыл нур* (3) — «Октябрь бәйрәме»; *кызыл саф, кызыл таң* (2) — «Ил тәбриге»; *кызыл кан, кызыл таң нурлары, кызыл әләм* (3) — «Халык идеалы»; *кызыл кылыч* (1) — «Ил батыры авызыннан» һ.б.

Шул рәвешчә, ул елларда язылган 33 әсәрнең 18ендә «кызыл» сүзе белән ясалган 50гә якын эпитет һәм метафора кулланылган, ягъни һәр шигырьдә уртача өчәр тапкыр «кызыл» сүзе очрый. Нигездә, алар 19 исемне ачыклап килә: *әләм (8), байрак (4), кылыч (5), яу (6), юл (4), гаскәр (4), таң (4), бәйрәм (3), саф (2), каһарман (2); болары берәр тапкыр очрый: кан, фронт, күк, ялкын, нур, болын, йөрәк, тасма, мәйдан.* Нәкъ менә шулар, нигездә, ул әсәрләрнең идея-эстетик юнәлешен билгеләүче төп лейтмотив сүзләр булып тора. Игътибар итсәк, аларда хәтта табигать күренешләре дә кызыл төстә.

Шунысы кызыклы: М.Җәлилнең алдагы елларда иҗат ителгән әсәрләрендә кызыл төс кими бара. Мәсәлән, 1921-1923 елларда язылган 55 әсәрнең 10сында — бер дистә чамасы; 1924-1926 елларда — 20 шигырьнең нибары өчесендә берничә тапкыр гына очрый; 1927-1929 елларда — 34 шигырьнең икесендә генә фәкать ике тапкыр «кызыл» сүзе кулланылган.

Әмма 1930-1942 елларда иҗат ителгән 114 әсәрнең 21ендә тагын шул төс активлашып китә (40тан артык). Әлбәттә, бу күрнеш шул чорда илдә барган чамасыз хәтәр сәясәт белән үрелгәндер дигән фикер тудыра.

«Моабит дәфтәрләре»ндә исә 94 шигырьнең бары тик бишесендә генә бер дистә чамасы шул сүз очрый: куе кызыл төстә — «Яулык»; *кан шикелле кып-кызыл, кызыл чук, кызыл ромашка, кызыл күлмәк* — «Кызыл ромашка»; *кызыл күзле* — «Хөкем

алдыннан»; *кызыл гөл* — «Соңгы үпкә»; *кызыл тасма* — «Вәхшәт»; *кызыл кәбестә* — «Күршеләр».

Нәтиҗә ясасак, Муса Җәлил иҗат иткән 530 поэтик әсәрнең һәр җиденчесендә, ягъни 75ләп шигырендә 125 чамасы «кызыл» эпитеты кулланылган. Бераз алга китеп әйткәндә, партия хакимлек иткән совет чорында патриот-шагыйрь Муса Җәлилне, беренче чиратта, кызыл символга, интернационалистка әйләндерүнең реаль җирлеге, нигезе, чыннан да, бик нык булган икән шул.

Төсләр генә түгел, ачыкланучы исемнәрнең нинди булуы да шигырьләрнең төп эчтәлеген билгеләүче чара булып хезмәт итә. Кызыл төс белән ачыкланучы 50гә якын исем сүз берничә тапкыр кабатланып килә. Алар арасында, билгеле, күпчелекне хәрби темага караган сүзләр алып тора. Мәсәлән, *«байрак», «әләм», «флаг», «комач»* кебек синоним исемнәр әлеге «ачкыч» сүзләрнең «байрагы» формасында 20гә якын әсәрендә кабатлана. Шулай ук бер дистә чамасы әсәрендә кулланылган мәгънәдәш *«яу», «гаскәр», «ялкын», «армия», «очкын», «шәүлә», «нур»* кебек сүзләр дә шул чор идеологиясен, вакыйгаларны, күренешләрне тасвирлауда, лингвистик поэтиканың үтемле чарасы буларак, зур роль уйный.

Шунысы да игътибарны җәлеп итә: «кызыл» сүзе белән ясалган 70ләп сүзтезмәнең барысы да дип әйтерлек революцион-патриотик стильдәге әсәрләрдә, ягъни уңай эмоциональ төсмер белән кулланылган. Фәкать «Хөкем алдыннан» дигән шигырьдәге *«кызыл күзле»* эпитеты фашистларга карата әйтелгән, ә *«кызыл кәбестә»* дигәне «Күршеләр» шигырендә юмор чарасы булып хезмәт итә.

Шагыйрьнең алдагы иҗатында кызыл төс, бер яктан, кими барса, икенче яктан, анда башка төсләр дә килеп кушыла. Мәсәлән, 20нче еллардагы иҗатында ук кызыл төс белән бергә якты, ак, ап-ак, ал, алсу төсләр дә еш очрый, ягъни ул дөньяны, әйләнә-тирә тормышны кызыл төс аша гына түгел, башка төрле төсләр ярдәмендә дә сурәтләп гәүдәләндергән.

Муса Җәлил, зур, талантлы шагыйрь буларак, тормышны, дөньяны оста рәссамнар кебек, бөтен тулылыгы, матурлыгы белән тасвирлап бирә алган. Аның иҗатында ак-кара йә булмаса ак-кызыл кебек капма-каршы төсләр генә түгел, бәлки калейдоскоптагы кебек, бик күп төрле төсләр һәм аларның төрле төсмерләре дә киң кулланылган. Мәсәлән, акбүз, җирән, зөбәрҗәт, энҗе, җәүһәр, яхуд, алтын, көмеш кебек төсләрне белдерүче сүзләр халык авыз иҗатында да киң файдаланыла. Болар шагыйрьнең алдагы иҗатында торган саен ешрак кулланыла башлый. Дөрес, кайбер төсләр соңрак килеп керә. Мәсәлән, зәңгәр төс «Студент көндәлегеннән» исемле шигырендә — 1927 елда, яшел төс исә тагын да соңрак — «Зәйтүнәгә» дигән шигырендә 1935 елда гына очрый.

1918-1921 еллардагы иҗатында, кызыл төстән башка төсләргә күчүне тоташтырган сыман, «якты» эпитеты киң кулланыла башлый һәм ул да, кими барса да, «Моабит дәфтәрләре»нә кадәр килеп җитә. Шуларның кайберләрен мисал итеп китерергә мөмкин. *Якты нур* — «Ирек шәме нурын сачкәндә!!!»; *якты таң* — «Кызыл әләмгә», «Ил тәбриге», «Халык идеалы»; *якты йолдыз* — «Ил тәбриге»; *якты юл* — «Алданма»; якты күк — «Кызыл гаскәр». 1921-1923 елларда: *якты илдә* — «Күк йөзендә»; *якты җәй* — «Боз ага»; *якты юл* — «Үземә»; 1924-1926 елларда: *якты сер* — «Эш карты»; *якты кояш* — «Көн дә кояш»; 1936-1937дә: *якты, алсу йөзле* — «Арыш кырында»; *якты күзләр* — «Ул үскәндә»; 1941-1942дә: *якты бәхет, якты нур* — «Чулпанга»; «Моабит дәфтәрләре»ндә: *җир йөзе якты* — «Соңгы җыр»; *якты өмит, якты гомер* — «Яңа ел теләкләре».

Шагыйрьнең буяу кунасы төсләргә бай. Якты төс белән бергә ак, ап-ак, ал, алсу төсләр дә иҗатының буеннан-буена кулланыла. Күзаллау өчен аларның кайберләрен санап күрсәтергә була: *ак теләк, ак йөрәк, ак юл, ак көч, ак бәхет, ак бәйрәм, ак каен, ап-ак кар, ап-ак кәгазь, ак болытлар, ак мамык мендәр* һ.б.

Ал, алсу төсләр дә ак төс кебек, бер яктан, романтик рухтагы күтәренке пафос, халыкчан, милли традицияләр белән үрелгән метафорик, символик образлар тудыру чарасы булса, икенче яктан, еш кына идеологик ярлыкка әйләнгән кызыл төсне алмаштырып, тормышны табигый, халыкчан йә булмаса романтик рухта тасвирлау чарасына әвереләләр. Бу аеруча «Моабит дәфтәрләре»нә кергән әсәрләрдә ачык чагыла.

## Җәлил патриотизмы

Әлбәттә, без Муса Җәлилне хаклы рәвештә патриот-шагыйрь, герой-шагыйрь, каһарман-шагыйрь дип искә алабыз, «патриот» сүзен исә аеруча еш кулланабыз.

Шагыйрьнең патриотлыгы, геройларча һәлак булуы һәркайсыбызга да яхшы мәгълүм. Ә менә патриотизм аның иҗатында ни рәвешле чагыла соң, дигән сорауның әлегә кадәр анык кына итеп куелганы юк иде. Әлеге язмада шул сорауга җавап бирү дә күздә тотыла.

Иң элек «патриот» сүзенең мәгънәсен ачыклаудан башлау максатка ярашлы булыр дип уйлыйбыз.

«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (11 т. — 506 б.) бу сүзгә мондый аңлатма бирелә. «Патриот — үзенең туган җирен, халкын, илен, ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше». «Патриотизм — патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз иленә, халкына мәхәббәт».

Муса Җәлил патриотизмы турында сөйләгәндә, гадәттә, аны «Моабит дәфтәрләре» белән бәйләп кенә кулланалар. Әлбәттә, «Моабит дәфтәрләре» шагыйрь патриотизмының иң югары күтәрелеше, ягъни аның кульминацион ноктасы булып торуы бәхәссез.

Әмма Муса Җәлилнең туган иленә, халкына, туган җиренә карата ялкынлы патриотик хисләре, әгәр аның җирлеге, нигезе булмаса, кинәт кенә «Моабит дәфтәрләре»ндә шул дәрәҗәдә дөрләп кабынып китә алмас иде. Шуңа күрә моны тулырак итеп күзаллау өчен, шагыйрьнең Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗатына, хәтта ки иң беренче шигырьләренә мөрәҗәгать итәргә кирәк була, чөнки аның тулаем иҗаты туган ил, туган җир, халык бәхете, аның азатлыгы өчен көрәш темасы белән аерылгысыз бербөтенне хасил итә.

«Бәхет!» шигыреннән күренгәнчә, Җәлилнең патриотик хис-тойгылары кече яшьтән үк һәм ышанычлы рәвештә формалаша башлый. Шунысы да игътибарны җәлеп итә: матбугатта басылмаган, әмма «Бәхет!» шигыреннән алдарак, 1918 елда язылган «Хакыйкать» исемле шигырендә «ил» сүзе, 1919 елның февралендә язылган «Тартыш» шигырендә «җир», «ил», «халык», шул ук елның маенда язылган «Тилгән» шигырендә «җир» сүзләре бар. 12-13 яшьлек үсмер бала бу сүзләрне аңлап, урынлы кулланган.

Шуннан соң — 1919-1920 елларда «ил», «җир», «халык» сүзләре шигырьләренең исемнәрендә үк кулланыла башлый: *«Ил халкына!»* (1919, октябрь), *«Ил тәбриге»* (1919, ноябрь), *«Ил корбаннары»* (1919, ноябрь), *«Ил батыры авызыннан»* (1920, гыйнвар), *«Ил ирке өчен»* (1920, җәй). Билгеле, болар буш сүз генә булмый, аларның эчтәлеге шул шигырьләрендә бик яхшы аңлашыла.

Алдагы иҗатында бу сүзләр даими рәвештә кулланыла башлый, ә инде *«Ил тәбриге»* шигырендә беренче тапкыр «халкым» дип мөрәҗәгать итә.

М.Җәлил иҗатында патриотик лексика 20нче еллардан соң да шактый актив рәвештә кулланыла һәм ул илдә барган үзгәрешләрне чагылдырып, яңа мәгънәләр, яңа төсмерләр, эпитет-сыйфатлаулар, сынландырулар, чагыштырулар, метафоралар белән үрелеп бирелә башлый. Бу бигрәк тә ил сүзенең кулланылышында аеруча ачык чагыла: *ил көне — «Хатирә»* (1922); *ил бәхете, эш иле — «Пар күгәрчен* (1922, июнь); *ил тажы — «Яңа никах белән»* (1922, июнь); *күтәрел ил — «Бер парча»* (1922); *ил шатлыгы — «Йөрәктән»* (1923); *ил бәхете — «Дусларым»* (1937, ноябрь).

1923 елның 17 мартында Кызыл һава флоты мөнәсәбәте белән язылган «Күк йөзендә» шигырендә шагыйрь беренче тапкыр «туган ил» сүзтезмәсен куллана: *«Тагын бергә туган илгә очарбыз, / Көләч йөзле туганнарны күрергә».*

Шуннан соң ул аның «Дусларым» (1937, ноябрь) һәм «Гөлләрем» (1938, гыйнвар) шигырьләрендә кулланыла.

«Ил» сүзе белән бергә шагыйрь иҗатында «җир» сүзе һәм аны тагын да ачыклабрак «урман», «болын», «кыр», «басу» һ.б. да киң кулланыла. «Туган җирем» сүзтезмәсе исә аның иҗатында беренче тапкыр «Парашютчы җыры» (1938, гыйнвар) шигырендә очрый.

Патриотик лексиканың аеруча тәэсирлесе — «Ватаным» сүзе Муса Җәлил иҗатына 1938 елда язган «Ана» шигырендә беренче тапкыр килеп керә: *«Мин ант*

*итәм: дошман кулын сузса / Безнең илгә, безнең иреккә, / Туган анам — сөйгән Ватаныма / Тырнагын да аның тидертмәм».*

Шул рәвешчә, Муса Җәлилнең патриотизмы турында сөйләгәндә, иң элек аның Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗатына күз салу кирәк.

Шагыйрьнең патриотк хисләре фронт лирикасында яңа көч белән, яңача яңгыраш ала: андагы 38 шигырьнең 35ендә патриотик хисләрне белдерүче «ил», «туган ил», «туган җир», «Ватан», «халык» кебек сүзләр төрле формаларда 90 тапкырдан артык кулланыла, ягъни һәр шигырьдә уртача икешәр-өчәр тапкыр очрый дигән сүз. Үз чиратында, алар шагыйрь иҗатының туган иленә, Ватанына, туган җиренә һәм халкына карата булган мәхәббәт хисенең ни дәрәҗәдә көчле булуын ачык күрсәтә. Бу сүзләр һәр шигырьнең үзеген хасил итә һәм әсәрләренең тел-стилен, лексикасын, сөйләм төзелешен, идея-эстетик юнәлешен билгели. Шагыйрьнең патриотик тойгылары әлеге сүзләрне ачыклап, көчәйтеп яңгырата торган һәм һәркемнең күңеленә балачактан таныш, якын «урман», «болын», «басу», «инеш», «чишмә», «тау» кебек сүзләр белән үрелә.

Шул уңайдан фронт лирикасына караган әлеге шигырьләрдә (1941-1942) патриотик лексик берәмлекләрнең, бер өлешен генә булса да, ничек итеп кулланылуын күрсәтү урынлы булыр, чөнки фәнни әйләнешкә бу беренче тапкыр кертелә. Шигырьләр китаптагы тәртиптә китерелә һәм ул лексик катламга караган сүзләр тексттан аерып алып түгел, аңлаешлы булсын өчен, башка сүзләр белән контекстта бирелә.

«Дошманга каршы» шигырендә: *күп илләрне, азат халкым, җиребезне* көл итәргә, кол итәргә *азат халыкны, ил чигеннән, без илебездә, халкыбызның ачы нәфрәте, безнең илдә»*; «Соңгы көрәшкә»: *ил чигенә, күтәрел, ил;* тезел сафка, *халык; илне сакларга;* «Тупчы анты»: *совет халкының, халыктан* утлы төкерек; «Очрашу»: *илебезне* яндырмакчы; «Әйдә, җырым»: *илне* сөйгән йөрәк тибешем, *туган ил* өчен, *шат илемдә, илем капкасын,* багышларга *Ватан сугышына, илнең* данлы хезмәт тавышын; «Чулпанга»: бүләк иткән иде *илебез*, дошман вата *илебезне*, саклармын йөрәк каным белән *илемне*, үз *илемдә*; «Хуш, акыллым»: *илемне* һәм сине сөюемне, тормышымны бирсәм *ил өчен*; «Дуска истәлек»: *бөек Ватан өчен, илнең күзе* бездә, без ант иттек *илдән* киткән чакта һ.б.

Муса Җәлилнең фронт лирикасында туган иленә, җиренә, халкына карата булган мәхәббәте, патриотик хисләре әлеге сүзләрнең кулланылышында аеруча калку булып гәүдәләнә: «ил» сүзенең — 60, «туган илем» — 6, «халкым» — 12, «җир» сүзенең 16 тапкыр кабатлануы шуның ачык мисалы булып тора. Бу сүзләрне патриотик лексик катлам дип исәпләсәк, аларның гомуми саны 94кә җитә. Димәк, шагыйрь фронт лирикасына караган 38 шигырьнең 35ендә, ягъни һәр шигырендә ике яки өч шундый сүз кулланган. Бу, әлбәттә, очраклы хәл түгел, ә бәлки фронт лирикасына кадәрге иҗатындагы патриотик теманың дәвамы, аның тагын да көчлерәк булып яңгыравын күрсәтә. Тик аерма шунда: әгәр башлангыч иҗатында әлеге сүзләр нигездә инкыйлаб казанышына, большевиклар хакимиятенә мәдхия җырлауга багышланган саф патриотик хисләрне чагылдырса, фронт лирикасында алар бер үк вакытта фашизмга капма-каршы куелып, фашистларга карата нәфрәт хисләре белән үрелеп гәүдәләндерелә. Шуның белән бергә, патриотизм хисләре, шул төп лексик берәмлекләрдән тыш, «урман», «болын», «кыр», «басу», «тау», «инеш», «чишмә» кебек сүзләргә кушылып, шагыйрьнең туган илгә, туган җиргә булган мәхәббәт хисләрен дә, шул ук вакытта фашистларга карата нәфрәт хисләрен, җирәнү, чиркану тойгыларын тасвирлау чарасы да булып хезмәт итәләр.

Шул рәвешчә, Муса Җәлилнең туган иленә, Ватанына, үз халкына, туган җиренә карата кайнар мәхәббәте белән сугарылган патриотик хисләре «Моабит дәфтәрләре»нә кадәр — башлангыч иҗатыннан, нигездә 20нче еллардан башлап, фронт лирикасында, ягъни Бөек Ватан сугышында яраланып, фашистлар кулына әсирлеккә эләккәнче, җитәрлек дәрәҗәдә көчле формалашкан була.

Билгеле, «Моабит дәфтәрләре»ндә тоткынлыкта булган шагыйрьнең мәхәббәт һәм нәфрәт хисләре, иҗтимагый-сәяси, гомумкешелек югарылыгыннан торып, яңа

көч белән, яңа дулкында — әрнү-газапларга, сагыну-юксынуларга һәм күз яшьләре аша елмаюларга үрелеп тасвирлана.

Муса Җәлилнең патриотик хисләре, алда әйтелгән төп патриотик лексик катлам сүзләреннән тыш, югары патетик шигъри һәм язма сөйләм стиленә хас югары стиль, китап сүзләре аша да көчәйтелә. Мәсәлән, *хәят* — тормыш («Имән»), *гали* — бөек («Сандугач һәм чишмә»), *хозур* — матур («Яңа ел теләкләре»), *өмит* — өмет, теләк; *бәгырь* («Ышанма», «Ана бәйрәме»), *дәрья* («Тик булса иде ирек»), *мәгърур* («Каска», «Сандугач һәм чишмә», «Урман»), *баглану* («Аерылу») һ.б.

Шагыйрьнең башлангыч иҗаты һәм фронт лирикасындагы кебек турыдан-туры патриотик лексикага караган сүзләрен шулай ук «Моабит дәфтәрләре» шигырьләренең бер өлешендә генә булса да күрсәтеп бирү кызыклы, дәлилле җитди нәтиҗәләр ясарга да мөмкинлек тудырыр.

«Хат»: дошманны илдән куып; «Кичер, илем!»: кичер мине, илем; илемне сөюемне, ышан, илем, илгә керсез мәхәббәт; «Ирек»: якын илемне, илсез — мин үксез; «Тик булса иде ирек»: *туган илем, туган җирем*; «Сандугач һәм чишмә»: *ил дошманы, ил батыры, илгә* саф мәхәббәт, ул *сөя Ватанын*, ул улы *хөр илнең* һ.б.

Билгеле, Муса Җәлилнең туган иленә, туган җиренә, халкына карата ялкынлы патриотик хисләре, тирән кичерешләре фәкать шушы лексик катлам белән генә чикләнми; ул туган илнең, туган җирнең җанга кадерле кешеләре, урман-болыннары, инеш-чишмәләре, таулары, ай-кояшлары, йолдызлары, таңнары, кошлары, акбүз атлары һ.б. бик күп сүз-образлар, символлар, сурәтләү-тасвирлау чаралары белән көчәйтелә.

Муса Җәлилнең Бөек Ватан сугышы чоры иҗаты өчен сөйләм һәм язма телебезнең бөтен байлыгын, нечкәлеген тоеп, сүзләрне, тәгъбирләрне, канатлы әйтемнәрне, сурәтләү-тасвирлау чараларын, җөмләләрне, ритм-рифманы һ.б. бик төгәл, урынлы куллану хас. Шагыйрьнең шигъри куәте телебезнең сүзлек хәзинәсеннән уңышлы, максатчан файдалану да, сәнгатьчә сурәтләү чараларын, поэтик алымнарны стильләргә бәйләп оста һәм иҗади куллануда да чагыла.

Гадәттән тыш шартларда иҗат ителгән «Моабит дәфтәрләре»нең югары идея-эстетик эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше, образлы сөйләм теле шагыйрьнең алдагы иҗаты җирлегендә үсеп чыккан. Без моны аның патриотик лексик катламны, шулар белән үрелгән сүзлек хәзинәбезне зур осталык белән файдалануында күрдек.

Шуның белән бергә шагыйрьнең патриотик хисләре туган ил төшенчәсен белдерүче «өй», «йорт» сүзләре белән дә бирелгән. *«Кайталмады өйгә зур улым, / Сугышып үлде, бәгърем, күз нурым»*. («Ана бәйрәме»). *«Кызы өчен, туган йорты өчен / Ул алдында булды көрәшнең»*. («Сөю»).

Фашистларга карата нәфрәтләнеп сөйләгәндә, шагыйрь шул ук сүзне икенче төрле мәгънәдә куллана: *«Сүз җитәрме сөйләп аңлатырга / Бу йорттагы вәхшәт, коллыкны»*. («Серле йомгак»).

Аларның иле турында сөйләгәндә, «оя» сүзен файдалана: *«Без дошманны илдән куып, / Оясын көл итми торып, / Өйгә кайтачак түгел»*. («Хат»).

Муса Җәлилнең патриотик хисләрен чагылдыручы югары патетик шигъри сөйләм аһәңе язма һәм сөйләм стиленә хас *ай, кояш, таң, чишмә, гөлчәчәк, сандугач, карлыгач, яулык, күлмәк* кебек дөнья поэзиясе өчен традицион символлар, романтик рухын саклаган хәлдә, аның әсәрләрендә тугрылык, батырлык, кыюлык төшенчәләре белән яңартыла: *«Яулык шаһит: сине һәм илемне / Йөрәк каным белән сакладым»*. («Яулык»)

## Үлемсез җырлар каһарманы

Билгеле, әгәр без Муса Җәлилне үлемсез җырлар каһарманы буларак бәяләмәсәк, күрсәтмәсәк, язмабыз тулы булмас иде.

Иҗаты җыр белән үрелмәгән шагыйрь сирәктер. Ә менә иң киң танылган җыр шагыйре кем дигәндә, һичшиксез, без Муса Җәлил исемен әйтер идек. Чыннан да: *«Җырларым, сез шытып йөрәгемдә, / Ил кырында чәчәк атыгыз! / Күпме булса сездә көч һәм ялкын, / Шулкадәрле җирдә хаккыгыз!»* — дигән саф, кайнар

хисләргә уралган мондый илаһи юлларны үлемсез җырлары, тиңдәшсез көрәше белән дөнья халкын таң калдырган татар халкының бөек шагыйре Муса Җәлил генә яза алган.

Ошбу юлларны иҗат иткән шагыйрь үзе дә, гүя җырдан яралгандай, бар яшәве дә җыр дулкынына уралып узгандай тоела.

Муса Җәлил иҗатының җыр-музыка сәнгатебез белән үрелеп үсүе очраклы хәл түгел, әлбәттә. Замандашларының искә алуына караганда, Җәлил кече яшьтән үк такмак әйтергә, шигырь язарга гына түгел, рәсем ясарга да, җырларга да яраткан, мандолинада уйный белгән, балалар белән спектакльләр оештырып, шунда үзе дә катнашкан, сәхнәдә уйнау өчен «Бибкәй кыз», «Каз канаты» исемле пьсалар да язган. Шунысын да искә алып әйтергә кирәк: Җәлил дә, Тукай кебек, шигырьләрен җыр көйләп язарга яраткан. Бу — халкыбызның элек-электән көйләп уку традицияләре белән дә бәйләнгән. Аның үзе уйлап чыгарган: *«Көш-көш, тилгән, / Йөрмә гел түбән, / Үрдәк аулаудан / Өмет өз, тилгән!»* («Тилгән») дигән такмакларыннан берсе халык авыз иҗатына нигезләнгән. Әмма гап-гади генә булып күренгән шул такмакны да ул ритм, рифма, ритмикага туры китереп, фольклор нигезендә иҗади эшкәртеп язган. Такмакларының җыр белән үрелүе алдагы иҗатына да йогынты ясый: шул нигездә ул авыл көйләренә туры китереп, яңа эчтәлекле җыр текстлары язган. Җыр сәнгатендәге мондый үзгәрешләр XX гасырның 20нче еллары өчен, гомумән, типик күренеш була.

Муса Җәлил иҗатының җыр сәнгате белән бик тыгыз үрелгәнлеге «җыр» сүзенең иҗатында бик күп тапкырлар кулланылуында да ачык чагыла: шушы сүз 43 шигыренең исемендә (14е — җәяләр эчендә), 130 шигырендә 200 мәртәбә файдаланылган. Шуның белән бергә «көй», «моң», «марш» сүзләре дә байтак санда очрый. Шунысы да игътибарны җәлеп итә: бу сүзләр, башка сүзләр белән янәшә килеп, шул чорга туры килгән бик күп яңа мәгънәләр белән баетылган. Шуларның беркадәр өлешен мисал итеп китерик: *безнең җыр, көрәш җыры, иркен җыр, икмәк җыры, сөю җыры, җиңү җыры, яңа җыр, яшьлек җыры, дәртле җыр, котлау җыры, үлмәс җыр, ил җыры, изге Ватан җыры, бәхетле шат җыр, машиналар җыры, күмәк җыр, шат җырлар, онытылмас җыр, көчле җыр, батыр көрәш җыры, ялкынлы җыр, нәни батырлар җыры,* «Моабит дәфтәрләре»ндә: *нәфрәт һәм мәхәббәт җыры, соңгы көрәш җыры* һ.б.

Күренә ки, *«җыр»* сүзенең шушындый яңа төшенчәләрен уйлап табу үзе генә дә Муса Җәлилнең әдәби телебезне, тормышны бик яхшы белүен, зур талант иясе, новатор шагыйрь булуын күрсәтә; аларның күбесе аның тарафыннан беренче тапкыр кулланылган. Җырның мондый мәгънәләре бүгенге көндә кулланырга да бик кулай. Моның өстенә ул аны уннарча тапкыр *«җырлый-җырлый»* дип, парлы сүз итеп тә файдаланган. Бу үзе генә дә шагыйрьнең әдәби телебезнең эчке мөмкинлекләрен тулы көченә куллана белү осталыгы үрнәге булып тора. Бер генә шагыйрь иҗатында да бу сүз шул дәрәҗәдә актив кулланылмаган. Шуның белән бергә бу сүз җыр текстын гына түгел, көй-моң, шатлык, яшьлек, мәхәббәт, хезмәтне; фронт лирикасында һәм «Моабит дәфтәрләре»ндә исә көрәш, батырлык, кыюлык, җиңү, Ватанга тугрылык символын да гәүдәләндергән.

Муса Җәлил шигырьләренә беренчеләрдән булып композитор Латыйп Хәмиди көй яза башлый һәм шул нигездә аларның ныклы иҗади дуслыгы барлыкка килә. Соңрак М.Җәлилнең балалар өчен язган шигырьләренә Җәүдәт Фәйзи бер дистә тирәсе көй иҗат итә һәм алар шул елларда еш яңгырый. Шундыйлардан аның «Маэмай», «Күке», «Әтәч», «Чишмә», «Карак песи», «Беренче вальс», «Шмидт бабай», «Кызыма», «Сәгать», «Парашютсыз курчак» исемле җырларын күрсәтергә була.

Муса Җәлил сүзләренә Ф.Яруллин («Маэмай»), З.Хәбибуллин («Бишек җыры»), М.Мозаффаров («Чишмә»), А.Вәлиуллин («Октябрь җырлары»), И.Якупов («Карак песи») һ.б. да балалар өчен җырлар яза.

Муса Җәлилнең аерым шигырьләренә хәтта берничә композитор көй иҗат иткән. Мәсәлән, «Октябрь җырлары»на — Л.Хәмиди, А.Вәлиуллин; «Сәгать» шигыренә — Ж.Фәйзи, Ф.Әхмәтов, «Маэмай» шигыренә — Ф.Яруллин, Җ.Фәйзи; «Карак песи»гә — Ж.Фәйзи, И.Якупов һ.б. Бу мисаллар М.Җәлилнең ул елларда бик популяр шагыйрь булуын күрсәтә.

М.Җәлилнең балаларга гына түгел, өлкәннәргә атап язган шигырьләренә дә Ф.Яруллин («Колхоз кызына»), Н.Җиһанов («Колхоз иртәсе», «Җырым булсын бүләгем»), Җ.Фәйзи («Дулкыннар», «Кырларда, суларда», «Күк юрга», «Диңгезче җыры»), М.Мозаффаров («Җиләк җыйганда», «Хат ташучы җыры», «Парашютчы җыры», «Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?»), З.Хәбибуллин («Күк юрга»), Р.Яхин («Күк юрга», «Дулкыннар»), Ф.Әхмәтов («Чишмә җыры», «Карашларың»), Ә.Бакиров («Чишмә җыры»), И.Шәмсетдинов («Килсәнә»), Х.Вәлиуллин («Комсомолларга», «Урман»), Л.Хәмиди («Син дулкыннар тавышын тыңладыңмы?»), Э.Бичурин («Карашларың») һ.б. композиторлар ике дистәдән артык (кайберләре берничәшәр) көй иҗат итә.

Герой-шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» шигырьләренә шулай ук байтак композиторлар көйләр, музыкаль әсәрләр иҗат итә. Мәсәлән: С.Сәйдәшев («Җырларым»), Н.Җиһанов («Ышанма!», «Кичер, илем!», «Батырлык турында», «Төрмәдә төш», «Хат», «Юллар», «Алман иләндә»), М.Яруллин («Сандугач һәм чишмә», «Бөрлегән»), М.Мозаффаров («Карлыгач булса идем», «Тик булса иде ирек»), Р.Яхин («Тик булса иде ирек», «Соңгы җыр», «Үткәндә кичергән», «Яулык», «Тау елгасы»), И.Шәмсетдинов («Ана җыры»), Р.Еникеев («Яулык»), Х.Вәлиуллин («Урман»), М.Латыйпов («Урман»), Ю.Виноградов («Кыз җыры»), И.Якупов («Күршеләр», «Кыз теләге») һ.б.

«Җырларым» — ул шагыйрьнең бөтен иҗат һәм көрәш юлында якты маяк. Аның үлемсез җырларының — көчле һәм ялкынлы кайнар сүзләренең җирдә яшәү хакы бик зур булуын тормыш үзе раслады: шигырьләре дистәләрчә телләргә тәрҗемә ителеп, бөтен дөньяга таралды.

Әйе, каһарман шагыйрьнең «Җырларым» кебек бөек, үлемсез әсәр иҗат итүе очраклы хәл түгел. Аның чишмә башы тирәндә ята. Ул Җәлилнең халкыбызның җыр сәнгатен үстерү өлкәсендәге гаять нәтиҗәле эшчәнлеге белән дә бәйле. Шагыйрь иҗатының җыр сәнгате белән бәйләнешы турында байтак язылды һәм бу хакта махсус хезмәтләр дә бар. Мәсәлән, Йолдыз Исәнбәтнең «Муса Джалиль и татарская музыка» (Казан, 1977) исемле китабын, Ким Миңнуллинның шул хакта байтак мәгълүмат бирелгән «Һәр чорның үз җыры» (Казан, 2003) дигән зур хезмәтен һ.б. күрсәтергә була.

Әйткәнебезчә, М.Җәлилнең иҗаты, бер яктан, җыр иҗаты белән бик тыгыз бәйләнсә, икенче яктан, шигырьләрендә «җыр» сүзенең яңа символикага — мәхәббәт, батырлык, көрәш, Туган илгә тугрылык, җиңү, үлемсезлек символына әверелү эволюциясе дә гаять үзенчәлекле булып гәүдәләнә.

Шагыйрь иҗатында җыр, җиңүгә әйдәүче конкрет образ буларак, Бөек Ватан сугышы башлангач язылган «Әйдә, җырым» шигырендә бик ачык булып гәүдәләнә: *«Әйдә, җырым, / батыр җиңү дәртен / Алып керик ялкын эченә. / Мин калмасам җирдә, / син калырсың / Һәйкәл булып үлмәс эшемә».*

«Ышанма» шигырендә җыр үлемсезлек символына әверелә: *«Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас, / Ялкынлы җыр тулы күңелне. / «Үлем» диеп әйтеп буламы соң / Җиңеп үлгән мондый үлемне?»*

Ә инде: *«Җыр өйрәтте мине хөр яшәргә / Һәм үләргә кыю ир булып. / Гомрем минем моңлы бер җыр иде, / Үлемем дә яңгырар җыр булып»*, — дигән юллары үзләре үк каһарман шагыйрь иҗатының үлемсез һәйкәле булып тора.

Шул рәвешчә, Муса Җәлилнең патриот-шагыйрьлеге иҗатының буеннан-буена туган иленә, туган җиренә, үзенең халкына карата булган ялкынлы мәхәббәт хисләрен чагылдырган сүзләрне, төрле сурәтләү чаралары белән тыгыз итеп үреп, бик еш куллануында шулай ук аеруча ачык һәм калку гәүдәләнә.

## Муса Җәлил иҗатында юмор

Шагыйрьнең сугышка кадәрге иҗатында юмор күзгә бәрелеп тормый. Әмма фронт лирикасына караган «Минзәлә истәлеге» (Дусларча шаяру) дигән шигырендә исә ул үзен юмор хисенә гаять бай шагыйрь итеп таныта: *«Хуш, Минзәлә, / синдә кунак булдым / Бик аз гына, үтеп барышлый; / Шуңар күрә нәни шаярулы*

*/ Бу җырымны сиңа багышлыйм. / Исән калсын миннән урамнарың, / Урам баскан карың, бозларың. / Бер лейтенант күрсә, акылыннан / Шаша торган иркә кызларың»*, — дигән юллар белән башланган бу шигырьдә төрле юмор алымнары мул, иркен кулланылган.

Ихтимал, зур, җитди эшләр башкарганга, үз иҗатына карата бик таләпчән булганга, алдагы елларда юмор-сатира әсәрләре язарга вакыты да, җае да туры килмәгәндер дип уйларга мөмкин. Әмма үткен телле юмор остасы буларак, ул «Моабит дәфтәрләре»ндә генә тулысынча ачыла. Әлеге шигырьләр арасында, санап чыксак, шаян, юмористик шигырьләр шактый күп. «Ишек төбендә», «Хәдичә», «Томаулы гыйшык», «Гашыйк һәм сыер», «Сәгать», «Иркәм», «Бәла», «Бөрлегән», «Тозлы балык», «Борча», «Күршеләр», «Табут», «Бала йокысы» — әнә шундыйлар. Идея-эстетик эчтәлеге, сюжет-композициясе ягыннан аларның һәркайсы үзенчәлекле. Анда шаян миниатюралар да («Тозлы балык», «Бәла»), баллада характерындагы сюжетлы шигырьләр («Хәдичә», «Гашыйк һәм сыер», «Томаулы гыйшык», «Табут») дә бар.

Баш өстендә палач балтасы торган хәлдә, шаян шигырьләр иҗат итә алуы шагыйрьнең искиткеч рухи ныклыгын, зур батырлыгын күрсәтә. Тоткынлыкта, гадәттән тыш авыр шартларда юмор хисенең калкып чыгуы укучыда һәм аның иҗатын өйрәнүчеләрдә хаклы рәвештә зур кызыксыну уята.

З.Мәҗитов, мәсәлән, шагыйрьнең бу халәтен, «беренчедән, кайгы-хәсрәтне җиңүе, тоткынлыкта да фашизмга каршы көрәшеп була икән, дигән фикергә килүе, икенчедән, үзенең язганнарын бербөтен итеп туплау ышанычы һәм дәрте рухландырган», дип күрсәтә *(З.Мәҗитов. — Сугышчан поэзия. — Казан: Татар.кит. нәшр. — 1975. — 273-274 б.).*

Ә.Мәхмүдов сүзләре белән әйтсәк, «шагыйрьнең юморы, иң беренче чиратта, тормыш тантанасын раслый, совет кешесе рухының җиңелмәслегенә ода булып яңгырый» *(А.Махмудов. Эстетический идеал в творчестве Мусы Джалиля. — Казань: Татар.кн.изд-во. — 1980. — 58 б.).*

Шунысы үзенчәлекле: Моабит шигырьләренең күпчелегендә, юмористик әсәрләренең барысында да тыныч тормыш вакыйгалары сурәтләнә.

Сүз әдәби әсәрнең беренчел һәм төп элементы булганга, М.Җәлилнең юмористик шигырьләре турында сөйләгәндә дә, игътибар тел-стиль, образлы тасвирлау чараларын анализлауга юнәлдерелә. Бу чаралар төрле көлкеле вакыйгаларны, герой һәм образларның мәзәк хәлләрен сәнгатьчә сурәтләргә ярдәм итә.

Шул уңайдан, нәрсә ул көлке, юмор, мәзәк һәм алар бер-берсеннән аерыламы дигән урынлы сорау да туа. Мәгълүм булганча, көлке — беркатлы, дусларча шелтә; юмор исә соклангыч, теләктәшле, кызыклы (мәзәк) һәм шул ук вакытта тупас, зәвыксыз да булырга мөмкин.

М.Җәлилдә юмор (һәм көлке) шаян, беркатлы, теләктәшле, кызыклы, дусларча ягымлы һәм эчкерсез җылы булуы белән характерлы. Юмор аша аның интеллектуаль яктан югары дәрәҗәдә зыялы, тәрбияле, белемле, укымышлы шәхес булуы аңлашыла. Ул үзенең шигырьләрендә тормыштагы мәзәк хәлләрдән, үзенә таныш кешеләрнең һәм лирик геройның аерым кимчелекләреннән, аларны төзәтү максатыннан чыгып, дусларча елмаеп көлә.

Ә беркатлы көлү кешеләрнең эшнең асылын аңламыйча, һәрнәрсәгә беркатлы карашларыннан килеп чыга.

Билгеле, тапкыр, үткен һәм көлкеле сүзләрдән башка юмористик әсәр була алмый. М.Җәлил иҗатында андый сүзләр күбесенчә әдәби тел нормасында булмаган лексик катламнар (гади һәм җирле-диалекталь сөйләм, искергән, китап, шаярту сүзләре, төрле алынмалар һ.б.) куллану, сүз уйнату, сүзләрнең эчтәлеге белән форма арасында бәйләнеш бозылу нәтиҗәсендә барлыкка килә, ягъни юмористик шигырь язу өчен, зиһен, тапкырлык кына түгел, телне, аның мөкинлекләрен бик яхшы белергә кирәк. Шуңа күрә юмор-сатира әсәре язу теләсә кемгә җиңел генә бирелми.

М.Җәлилнең юмористик шигырьләрендә гади һәм җирле сөйләм, китап, күчерелмә мәгънәле, алынма сүзләр күп һәм алар еш кына үзгәртеп, ягъни иҗади

эшкәртеп кулланыла. Мәсәлән, «Минзәлә истәлеге» шигырендә *«чарка»* (савыт), *«апара»* (камыр башы), *«мәл»* (вакыт), *«мут»* (хәйләкәр), *«чуалу»* (ярамаган эшкә алыну), *«эленке-салынкы»* кебек гади сөйләм сүзләре; *«тәмаман»* (тәмам), *«мәгъшука»* (сөйгән яр) — искергән сүзләр; *«ипле»* (уңайлы), *«бутка»* (ботка — буталчыклану), *«тузыну»* (дуамаллану), *«сырыша»* (сыена), *«посу»* (яшеренү) — көчерелмә мәгънәле сүзләр; *«кубарь»* (бөтерчек), *«клуб»*, *«мода»*, *«танг»о*, *«конюшнә»*, *«барышня»*, *«процент»*, *«артист»*, *«кассир»* кебек алынма сүзләр; *«ләктем»* (эләктем), *«тин»* (тиен), *«сырлы-мырлы», «симәнкә», «эләүкә», «сувсыз-парсыз»* кебек сүзлекләргә теркәлмәгән сүзләр дә бар. Мәсәлән: *«Исән калсын «клуб» дип аталган / Ягылмаган «конюшнәләрен». / Зиләйлүккә «танго» бии торган / Сырлы-мырлы барышняларың».*

Сүз уйнату ярдәмендә гомумкулланыштагы гадәти сүзләргә дә шагыйрь көтелмәгән үткен, шаян мәгънә сала: *«Ник елмайдың, каш сикертеп, / Яратмагач, йөрмәгәч? / Ник ашаттың тозлы балык, / Соңыннан су бирмәгәч?»* («Тозлы балык»)

*«Томаулы гыйшык»* шигырендәге «чир» сүзенең кулланылышы да үзенчәлекле. Гади сөйләмгә караган бу сүзнең туры һәм күчерелмә мәгънәсе бар: 1) авыру яки кешедәге берәр кире сыйфат, начар гадәт һәм 2) ярату, гашыйк булу. Биредә шагыйрь аның ике мәгънәсен дә янәшә куя. Шулай итеп, «чир» сүзенең юмористик хасияте барлыкка килә: *«Мин күрмәдем артык мәгъшукамны, / Томау бетте, гыйшкым онтылды. / Көчле булды дару егет күңеле / Ике чирдән бергә котылды».*

Юмор тонын көчәйтү максатында шагыйрь мәгънәдәш сүзләрдән дә файдалана. Мәсәлән: *«Иркәм белән икебез, / Пар алмадай битебез. / Чөкердәшеп, гөрләшеп, / Утырабыз серләшеп».* («Сәгать»)

Уңай мәгънәле сүзләрне берәр тискәре сүзгә каршы кую да юмор рухын бирә: *«Киткән чакта кайсын озатасың / Назлап, сыйпап, мактап, иркәләп. / Ә кайберсен куып чыгарасың, / Якасыннан тотып типкәләп».* («Сыра залында»)

Монда «назлап», «сыйпап», «мактап», «иркәләп» дигән сүзләр «типкәләп» сүзенә кискен каршы куела. Синоним сүзләрне градация рәвешендә куллану да юмористик максатка хезмәт итә.

*«Бетте бакчам, кырылды, / Һич чара юк каһәргә. / Охшап калды түтәлләр / Бомбаланган шәһәргә».* («Күршеләр»). Биредә «бетте», «кырылды» сүзләре — әнә шундыйлар.

М.Җәлил иҗатында «кыза», «тузына», «яратмагач-йөрмәгәч», «әйбәт», «акыллы», «юклыгы», «кытлыгы» кебек синоним сүзләр дә шундый функция үти.

Билгеле, аерым сүзләр генә әсәрнең тулаем юмористик рухта булуын тәэмин итә алмый; аны әсәрнең төрле стилистик чараларының бердәмлеге генә билгели. Мәсәлән: *«Беләм, кызлар, сезне куркытмыйдыр/ Ирен өчен буяу юклыгы. / Беләм, беләм, сезне куркытадыр / Минзәләдә кияү кытлыгы».* («Минзәлә истәлеге»). Бу юлларның шаян тоны синонимнар (юклыгы, кытлыгы), антонимик мәгънәле сүзләр (куркыта — куркытмый), кабатлаулар (беләм, беләм), антитеза кебек чараларның үзара тыгыз бердәмлегенә нигезләнгән.

Шагыйрьнең юмористик шигырьләрендә кулланылган «зәңгәр күз», «яшь матур», «мәгъшукам», «иркәм», «бер генәм», «җаным», «матурым», «акыллым», «җанкай» кебек синоним сүзләрнең үзәге — «сөйгән кыз» белән мәгънәдәш.

«Мәхәббәт» сүзе дә зур гына синонимик оя төзи (гыйшкым, мескен гыйшкым, минем гыйшкым, томаулы гыйшык, чир, су һ.б.). Биредәге «томаулы гыйшык», «чир», «су» сүзләре, шулай ук «дару — агу», «ләззәт — михнәт», «елау — көлү» кебек капма-каршы мәгънәле сүзләр дә аның әсәрләрендә юмор чарасы функциясен үти. *«Икенче көн ни күрәм? — / Бер елыйм да, бер көләм. / Урам тулы хатын-кыз, / Бар да ертык юбкадан.* («Хәдичә»)

Рәвеш сүзләрнең кабатлануы да сөйләмгә юмористик тон бирә. Мәсәлән: *чак-чак килеп өлгердем, учлап-учлап май сөрттем, үрле-кырлы сикертә* («Иркәм»), *ярсый-ярсый бардым* («Томаулы гыйшык») һ.б.

Кабатлаулы һәм парлы сыйфатлар ярдәмендә шагыйрь көнкүрештәге гади генә әйберләрне дә юмор объектына әвереләдерүгә ирешә: *сусыз-парсыз мунчада, баскыч-баскыч коры эләүкә, эленеп-салынып торган пәрәвез* («Минзәлә истәлеге») һ.б.

Аның әсәрләрендә, юмористик тасвирлау чаралары буларак, чагыштырулар да зур роль уйный. Алар көтелмәгәнлеге һәм эш-хәлне, процессны көлкеле итеп сурәтләү белән үзенчәлекле. Мәсәлән: *кубарь* (бөтерчек) *төсле башың биеп торгач* («Сыра залында»), мескен гыйшкым кызган куык төсле шартлады, гашыйкларча авыр сулыйм дисәм («Томаулы гыйшык»), *болан төсле чабып кайттым* («Иркәм»), *абау ямьсез сугуы, чирәү кага диярсең, утырган күк сәнәккә* («Сәгать») һ.б.

Юмор тонын бирүдә шагыйрь эпитетлардан да киң файдалана: *өметсез кәҗә, мамык кул* («Күршеләр»), *ипле урын, калын мичкә, яшел күзле мәшһүр шадра шагыйрь* («Сыра залында») һ.б.

М.Җәлил шигырьләрендә төрле образлар да көлке чарасы булып хезмәт итә: *томау, гыйшык* (абстракт образлар), *сыер, кәҗә, бүре, борча, болан* (аллегорик образлар), *сәгать, кызыл кәбестә* (предмет-образлар).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, халыкның тапкыр, шаян рухын чагылдыручы, үткен, җор телдә язылган шигырьләре М.Җәлилнең чын мәгънәсендә юмор остасы булуы турында сөйли.

## Данлы юл дәвамы

Бөек Ватан сугышына кадәр үк шагыйрь, журналист, җәмәгать эшлеклесе буларак халык арасында һәм ил күләмендә киң танылган Муса Җәлилнең таланты «Моабит дәфтәрләре»ндә бөтен тулылыгы белән ачылды. Йөрәк кайнарлыгын кушып иҗат ителгән ул шигырьләргә җитмеш елдан артык вакыт узып барса да, алар бүген дә безне тирәнтен дулкынландыра, рухыбызны ныгыта, туган җиребезгә, халкыбызга, туган телебезгә карата булган хисләребезгә кайнарлык өсти, кешеләр, халыклар арасында дуслыкка, бердәмлеккә, татулыкка өнди һәм шул ук вакытта кешелекнең иң явыз дошманы булган фашизмга, ул нинди генә битлек кисә дә, тирән нәфрәт, җирәнү хисләрен уята һәм һәрвакыт уяу булырга кирәклеген искәртеп тора.

Бөек Ватан сугышына кадәрге иҗатына нигезләнеп үскән фронт лирикасында һәм атаклы «Моабит дәфтәрләре» әсәрләрендәге шигъри сөйләм стиле нәкъ менә Муса Җәлил иҗаты өчен генә хас. Мәсәлән, аның туган җиребезгә, халкыбызга карата булган кайнар мәхәббәт хисләре белән сугарылган югары патетик аһәндә иҗат ителгән әсәрләре һәм үзара шактый якын торган мәхәббәт лирикасы татар әдәби телебезнең матурлыкны, нәфислекне, нечкә хис-тойгыларны зәвыклы, затлы рәвештә белдерә алырдай гомумкулланыштагы һәм егәрле китап сүзләребезне, эпитет, метафора, чагыштыру, антитеза, эндәш сүзләр кебек тасвирлау-сурәтләү чараларын үзара ятышлы, килешле итеп, максатчан куллана белү югарылыгы белән аерылып тора. Иҗатындагы мондый шигырьләре сыйфаты белән генә түгел, сан ягыннан да өстенлекне алып тора.

Дошманга, фашизмга карата нәфрәт белдергән патетик фаш итү стиле исә шул хисләрне бөтен барлыгы белән ачып салырдай әдәби тел һәм гади сөйләм сүзләре, образлы тасвирлау чаралары, ритм, рифма, җөмлә һәм сөйләм төзелеше белән үзенчәлекле.

Герой-шагыйрь Муса Җәлил һәм аның тугрылыклы көрәштәшләре узган юлдан, аларның эзләре буенча йөреп, эзләп табасы документлар бик күп әле. Боларга шагыйрьнең тагын ике дәфтәре, Оренбург чоры шигырьләре, 825нче батальон документлары, «Курмашев һәм башка 10» эше, Гиббельс карамагындагы «Винета» радио-студиясе, Розенбергның «Идел-татар легионы» архивы материаллары, «Идел-Урал» гәҗитенең һәм «Татар әдәбияты» альманахының табылмаган саннары һәм башкалар кирә. Бу эзләр буенча йөреп, яңа мәгълүматлар табу — бүгенге һәм киләчәк буыннар эше.

**Хәнәфи БӘДИГЫЙ,**
*җәлилче-галим, шагыйрь*

# КҮҢЕЛЕНДӘ ГАЛӘМ ЧИКСЕЗЛЕГЕ...

СОЛТАН ШӘМСИГӘ 70 ЯШЬ

Галәм дип авыз ачуга, күз алдына әллә нинди космос киңлекләре, шул киңлекләрне гизүче каһарманнар — космонавтлар килгәндәй була. Тик бу урында сүзебез галәм геройлары хакында түгел, ә үзебезнең яныбызда яшәүче гап-гади адәм баласы, җир кешесе — татар язучысы Солтан Шәмси һәм аның иҗат дөньясы турында барыр. Гап-гади дисәк тә, ул, күпләребездән аермалы буларак, җирдәге, әйләнә-тирәбездәге көндәлек көнкүреш мәшәкатьләреннән тыш олы хыяллар, бай омтылышлар белән яши, һәркайсыбызны кеше иткән Табигатьнең бөеклеге, безне бар итеп, яшәеш могҗизасын танып белергә өйрәткән илаһи Рухның яшерен серләрен тоеп, ныклап уйланып яшәргә чакыра.

Бер әңгәмә вакытында үзе ихлас кына итеп, «гомерем буе гел сибелеп яшәдем мин», дигәч, гаҗәпкә калган идем — ничек алай була инде ул? Без аны үтә дә җыйнак, максатчан, төгәллекне яратучан, һәр эшен җиренә җиткермичә туктый белми торган зат дип белә идек... Баксаң, «сибелү» дигәне дә болары белән яраша икән ләбаса!.. Соңрак «сибелү»нең хикмәте аңлашыла төште: аны тормышның күптөрле, кызыклы, гыйбрәтле, яшертен яклары, Ходай бүләк иткән кеше гомеренең асыл мәгънәсе, җаныбызның серлелеге, яшәешнең мәңгелеге, Галәм чиксезлеге кебек нәрсәләрнең һәркайсы кызыксындыра, бердәй мавыктыра икән — бу кызыксыну, мавыгулар әледән-әле берсе-берсен алмаштырып тора — һәм болар эзсез-нәтиҗәсез калмый: яңадан-яңа мәкаләләр, эсселар, хикәя-новеллалар, китаплар туа. Шулай бер иҗатчы әсәрләрен укып, күп мәгълүмат алырга, сорауларга җавап эзләшергә, ә кайберләренә этрафлы җавапларны табарга да була. Берәүләргә Солтан Шәмси — заман прозаигы, икенчеләргә балаларның яраткан язучысы булып күренер, өченчеләре аның төп шөгыле — милли тарих сәхифәләрен актару икән дип уйлар, кайберәүләрнең игътибарын әдипнең дини, фәлсәфи карашлар белән бәйләнешле эзотерик язмалары җәлеп итәр. Иң әһәмиятлесе: һәр очракта да, бер-берсеннән читтәрәк торучы бу өлкәләрнең һәркайсында автор тиешле югарылыкта кала — профессионалларча эш итүче мәгърифәтче булып кала.

Әдипнең халкыбызның ерак тарихына булган мөнәсәбәтенә генә игътибар итик: «Низаглы йортта» (1984) исемле китабын язганда — Алтын Урда тарихына кагылышлы фактларны ул күп төрле чыганаклардан (тарихчы-галимнәрдән С.Соловьёв, Н.Карамзин, В.Ключевский, В.Бартольд, Н.Рерих, Л.Гумилёв, Р.Фәхретдин һ.б.) мәсьәләнең тәмам төбенә төшеп өйрәнә, анда кызыклы һәм маҗаралы хәлләр шулкадәр күп — авторның романнар язарга яратучы каләмдәшләренең берсе бу муллыкка сокланып: «Мин бу материалдан кимендә дүрт-биш роман иҗат иткән булыр идем», — дигән, имеш. Солтан Шәмсинең әлеге өлкәдәге эзләнүләре, билгеле бер дәрәҗәдә, атаклы тарихчы Лев Гумилёв эшчәнлеген хәтерләткәндәй була. Ул да бит матур әдәбият, тарихи бәяннар авторы түгел иде, әмма аның күзәтүләре, эзләнү нәтиҗәләре, тапканнары, әллә кем әйтмешли, дөнья бәһасенә тиң.

Солтан Шәмси әдәбиятның төрле өлкәләрендә бердәй осталык белән эшли алучы буларак танылса да, күбрәк тарих катламнарын актарырга ярата, кирәк очракта, ул хәзерге тарихчыларыбызның теләсә кайсысы белән аяк терәп сөйләшә ала — аны үзе өйрәнгән өлкәләрнең энциклопедик белгече дип тә санап булыр иде. Алтын Урда дәүләтенең XIII-XIV гасырлардагы тарихын эченә алган «Низаглы йортта» китабында драматик хәлләр, вакыйгалар бөтен борылышлары, нечкәлекләре, фаҗигаләре белән тасвирланган. Аксак Тимер, Туктамыш, Үзбәк ханнар, Мамай,

Идегәй мирзалар тормышы, алар чапкан яулар, кырылышлар, җиңүләр, җиңелүләр турындагы язмаларны мавыгып, кызыксынып укыйсың. «Алтын Урда дәүләтенең таркалу чорыннан сәхифәләр» рәвешендә тыйнак кына тәкъдим ителгән бу әсәрне тарихилык һәм әдәбилек җәһәтеннән бик уңышлы тәҗрибә дип санарга кирәк. Тарих фәннәре докторы Равил Әмирхан: «Солтан Шәмси эшчәнлегенең төп кыйбласы — милли тарихыбызның чуалып каткан төеннәрен сәнгать ысулы белән реаль чынбарлык, документаль җирлектә чишүдән гыйбарәт, — дип язды. — «Низаглы йортта» китабы — С.Шәмсинең соңгы еллардагы иҗат эзләнүләренең җитлеккән җимеше сыйфатында кабул ителә». Соңгы вакытта Солтан Шәмси Казан ханлыгы чорын җентекләп өйрәнүгә кереште — бу очракта да хикмәтле бер әсәр тудырачагы шик уятмый.

Тарих өлкәсендәге эшчәнлеген генә дә әдәбиятыбызның зур казанышы дип билгеләргә булыр иде — тик тарихи тема белән генә аның кызыксынганнары чикләнми: моннан тыш ул әлегә күпләргә мәгълүм булмаган Галәм, Галактика серләренә кагыла, үзебезнең әйләнә-тирәбездәге тормыш вакыйгалары, замандашларыбыз турында да матур-матур бәяннар, балаларга махсус багышлап язылган әсәрләр дә иҗат итә. Кайлардан, нинди юллардан, нинди каршылыкларны җиңеп килгән соң бүген хөрмәт казанган бу әдип? Шуларга күз салып үтик әле.

Солтан Шәмси (Шәмсетдинов Солтан Сәлах улы) 1946 елның 10 февралендә Татарстан Республикасының Биектау (элекке Дөбъяз) районы Суыксу авылында туа, әмма ул анда өч кенә ел яши. Балачак еллары һәм үсмер чагы шул төбәкнең Юртыш авылында уза. Анда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казандагы һөнәр училищесында укый, токарь һөнәрен үзләштерә. 1962 елда тормыш юллары аны Мәскәү каласына китерә, башкала заводларында токарь, слесарь-инструментчы булып эшли, хезмәтеннән аерылмыйча укып, кичке урта мәктәпне тәмамлый. Соңыннан, гаскәри хезмәтен (1967-1969) тутырып кайткач, Мәскәү басмаханәләренең берсендә полиграфист һөнәрен үзләштерә. 1971 елда С.Шәмси Казан университетына укырга керү нияте белән Казанга күчеп кайта, берникадәр вакыт Казанның Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинатында — китап басучы, аннан «Урак-чүкеч» заводында слесарь булып эшли. Бер үк вакытта университетның татар филологиясе факультетына керү өчен әзерлек курсларында укый. Әмма аңа Казан университетында укырга насыйп булмый. Әле Мәскәүдә кичке мәктәптә укыган чакта ук әдәбият белән мавыгып китеп, беренче хикәяләрен язган С.Шәмси 1972-1977 елларда Мәскәүдә М.Горький исемендәге Әдәбият институтында югары белем ала, институтны тәмамлап кайткач, 1977-1985 елларда «Казан утлары» журналының проза бүлегендә мөхәррир булып эшли. Соңрак ул «Идел», «Татарстан» журналларында, Татарстан китап нәшриятында җаваплы вазифалар башкара. 2000-2005 елларда — Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институтында татарча текст мөхәррирләре төркемен җитәкли, беркадәр вакыт әлеге эшеннән читләшеп торса да, тиз арада аны яңадан институтка чакырып алалар — биредәге актив иҗат эшчәнлеге 2012 ел уртасына кадәр дәвам итә.

Әдәби иҗат юлын ул тәрҗемәләрдән башлый, иҗат эшен ике юнәлештә алып бара — татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итә. 1986-1987 елларда С.Шәмси атаклы классик язучы Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» повестен һәм дистәдән артык хикәясен рус теленә тәрҗемә итә. Шулай ук аның тәрҗемәсендә С.Антонов, С.Воронин, Н.Думбадзе, С.Данилов, Г.Матевосян, А.Мифтахетдинов, Р.Мирхәйдәров кебек әдипләрнең әсәрләре татар укучысына үз ана телебездә барып ирешә.

Солтан Шәмсинең матур әдәбияттагы мөстәкыйль эшчәнлеге 1984 елда башлана: беренче хикәяләре тупланган «Көмеш чылбыр» исемле җыентыгы Татарстан китап нәшриятында басылып чыга. Андагы әсәрләр үзләренең матур теле, геройларның эчке халәтләрен тасвирлаганда, авторның нечкә психологик бизәкләр таба белүе белән каләмдәшләренең игътибарын җәлеп итте һәм С.Шәмси 1985 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителде. Аннан соң да язучы проза өлкәсендә актив эшләде: озакламый аның «Җәяүле буран» (1988),

«Ут хәйләсе» (1994), «Еллар эзе» (1996) исемле хикәя, повесть, әкият жанрларын үз эченә алган китаплары дөнья күрде. Композиция ягыннан җыйнак, матур әдәби телдә язылган, тыгыз фикерле бу китапларны укучылар бик җылы кабул иттеләр, ә «Еллар эзе» дигәне — Татарстан Язучылар берлегенең Фатих Хөсни исемендәге, ә «Сөт калыр, Ватан китәр» (2011) китабы Абдулла Алиш исемендәге бүләкләргә лаек булды. Матур әдәбият өлкәсе — әдип иҗатының бик әһәмиятле тармагы, һәм, әйтергә кирәк, әлегә әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан бик аз яисә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән, тиешле бәя бирелмәгән килеш кала. Гәрчә бу әсәрләр бүгенге татар прозасы өлкәсендә эшләүчеләрнекеннән һич тә ким түгел дип беләбез. Алга табарак, әдипнең шушы юнәлештәге эшчәнлегенә мәкаләбездә ныграк игътибар белән күз салырбыз.

Күпләр бу авторны тарихи темалар буенча эзләнүче, популяр китаплар ярдәмендә бай милли тарихыбызның әһәмиятле дәверләрен ачып салып, халыкка җиткерүче мөхтәрәм зат дип беләләр. Россия гуманитар фәннәр академиясе академигы Мәхмүт Әхмәтҗанов, С.Шәмсинең тарихи эзләнүләрен югары бәяләп, болай дип язды: «...милли тарихыбызны тирәнтен белгән язучының игътибарын Идел Болгарстанында Ислам дине кабул ителү вакыйгасы үзенә тарта һәм ул, Әхмәд ибне-Фазланның мәгълүм язмаларын яңабаштан хикәяләп чыгып, аның әдәбиләштерелгән вариантын әзерли («Путешествие Ибн-Фадлана на реку Итиль и принятие в Булгарии ислама» (1992)). Нәтиҗәдә, моңарчы тар даирәдә генә билгеле булган кыйммәтле чыганак 50 мең тираж белән басылып чыгып, милләттәшләребезнең яратып укыла торган китабына әверелә. 1999 елда аның татарча һәм русча эшләнгән, зур форматлы, сурәтле басмасы да дөнья күрә («Ибне Фазлан сәяхәте. — Путешествие Ибн-Фадлана»).

1996 елны Солтан Шәмси Ризаэддин Фәхреддиннең «Алтын Урда ханнары» исемле мәгълүм хезмәтен рус теленә тәрҗемә итә һәм, бер тышлык эченә татарча һәм русча текстларны урнаштырып, аларны тарихи рәсемнәр белән бизәп, икетелле китап рәвешендә бастырып чыгара. «Язучы С.Шәмсинең иҗат юлына тулаем караш ташласаң, — дип язды арабыздан киткән язучы М.Әхмәтҗанов, — аның гомер буе халкыбыз тарихы белән тирән кызыксынып, даими рәвештә шул хакта сүз әйтергә омтылып яшәвенә игътибар итмичә калу мөмкин түгел. Аның әдәбият өлкәсендә башкарган һәр эше милли тарих белән бәйләнгән — Кубрат ханның Бөек Болгар дәүләтен төзүеме («Кубрат» пьесасы), Идел Болгарстанында Ислам дине кабул ителүме («Ибне Фазлан сәяхәте»), Казан ханлыгына багышланган язмалармы, Алтын Урда дәүләтендә барган ватандашлар сугышымы («Низаглы йортта»), «Болгармы?», «Татармы?» бәхәсенә катнашып, җитди сүз әйтүеме — әдипнең һәр язган әсәре халкыбызның тарихи язмышы турында җитди уйлануга әверелә».

2006 елда Солтан Шәмси, үзенең моңа кадәр иҗат иткәннәренә йомгак ясагандай, укучыларга исеме дә, эчтәлеге дә сәеррәк тоелган «Күк капусы ачылса...» дигән фәлсәфи китап бастырып чыгарды. Икенче карашка, бәлки бик сәер дә түгелдер — чөнки халкыбызда «күк капусы ачылганда, изге теләкләр телә, бар теләгәнең дә кабул булыр» дигән гыйбарә бар. Әлеге әйтем үзе генә дә гавамның игътибарын бу әсәргә тартырга тиеш иде, һәм ул шулай булды да: укучылардан килгән җылы хатлар шул турыда сөйли. Әмма әдәби җәмәгатьчелек китапны күрмәмешкә салышты — хәзер тәгаен генә әйтүе кыен: әллә диннәр белән бәйләнешле фикерләрнең артык кыю куелышы куркытты, әллә инде бу каты чикләвеккә бөтенләй теше үтмәде. Ничек кенә булмасын, инде менә ничә еллар олы матбугатта бу турыда сүз әйтелгәне юк диярлек — аңлаешсыз бер сәер тынлык хөкем сөрә. Ә бит, ныклабрак уйлап карасаң, бу китап әдәбиятыбызда моңарчы булмаган өр-яңа теманы ача. Анда тупланган материалларда сүз Коръән һәм Библиядәге серләр, Кыямәт көне, Планетабызның яшәеш цикллары турында бара. Өченче меңьеллыкка аяк баскан адәми зат алдына куелган рухи үсеш мәсьәләләре хакында бәян ителә. Бәлки бу китапны күрмәмешкә салышуның сәбәбе шуңа бәйледер. Тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият белгечләренең бу хакта сүз әйтергә әзерлеге җитмидер? Кыскасы, әлеге басманы әдипнең дөньяга карашларының квинтэссенциясе, ягъни иҗат йөзен шактый тулы ача торган тупланмасы дип кабул итәргә мөмкин.

Әлеге китапка урнаштырылган материаллар жанр һәм язылышлары, төзелешләре, хәтта эчтәлекләре ягыннан да бер-берсенә бигүк охшамаган кебек тоелсалар да, дөресендә аларны авторның дөньяга карашлары системасы, тәмам калыплашып өлгергән фәлсәфәсе, яшәешкә, кеше җанының үлемсезлегенә карата нык утырып җиткән мөнәсәбәтен үзенә бәйләп тора. Иксез-чиксез Галәмдә, Галактикадагы җисемнәр, йолдызлар, планеталарның нииндидер яшерен, әмма кодрәтле кануннарга буйсындырылган хәрәкәте, Табигать-анабызның бөек рухына табынып, шуларны аңларга тырышып яшәргә чакыру, Күктәге Иерархиянең Планетабызны, кешелек дөньясын даими күзәтеп, аны кайгыртып яшәве турындагы язмаларның «Күк капусы ачылса...» әсәрендәгечәләре татар әдәбиятында моңарчы күренгәне юк иде шикелле. Кайбер бүлекләрнең исемнәренә генә күз төшереп үтик: «Үзгәрешләр һәм Бөек күчеш», «Диннәр ни сөйли?», «Хисап көне», «Адәмне кем коткарыр?», «Раббыбыз сәяхәте», «Коръән хикмәтләре: бер аятьнең сере» ...һәм тагын бик күп кызыклы материаллар. Алар арасында тәрҗемә ителгәннәре дә бар. Мәсәлән, Елена Рерихның «Өч ачкыч»ы һәм Эльза Баркерның «Мәрхүмнән иңгән хатлар» исемле язмалары... Боларның һәркайсы озак еллар буена фәкать бер яссылыкта, бер юнәлештә генә уйларга күндерелгән туң миләребезне уятып яисә кузгатып җибәрә.

Кешелек дөньясының яралтылуы, аның төрле этаплар аша үтеп үзгәрүе, иске һәм яңа Гаһед, кешелеккә Хисап көне якынлашуы турындагы фикерләр төрле мифлар, риваятьләр, борынгы Майя язмалары, дини китаплар — Библия һәм Коръәндә язылганнар белән янәшә куеп, җентекләп анализлана. Бу эзотерик язмаларда замандашларыбыз өчен гаять кыйммәтле һәм кызыклы мәгълүматлар тулып ята. Галактикадагы 26 мең еллык цикл хикмәтләре, кешелек дөньясының бишенчесе тәмамланып, алтынчысына керүе, адәми затларның тәннәренә урнаштырылган, галәмдәге төрле дөньялардан мәгълүмат алуны тәэмин итә торган чакралар турындагы фикерләр затлы, зыялы укучыларның берсен дә битараф калдырмас, дип ышанабыз. Гомумән, «Күк капусы ачылса...» әсәрен хәзерге мәдәниятебез даирәсендә тиңе булмаган күренеш дип бәяләсәк тә ялгышмабыз.

Китаптагы күп кенә тезислар укучыларыбыз өчен зур ачышлар тезмәсе булып тоелыр, бәлки кайберәүләр үзләрен күптәннән борчып, уйландырып торган сорауларына дәлилле һәм өметләндерерлек җаваплар да таба алыр. Әлбәттә, китаптагы беренче юллар ук укучының галәм серләре белән кызыксынуын көчәйтеп җибәрәчәк. Мәсәлән: «Әйе, кешелек дөньясы беркайчан да берьялгызы яшәмәгән, үзенең барлыкка килү көненнән үк аның Олуг Остазлары, Илаһи Тәрбиячеләре булган һәм Алар бүгенге көндә дә шушы изге вазифаны башкару белән мәшгуль. Бу затлар хәзер дә кешенең һәм планетабызның эволюциясен күзәтеп торалар... Галәмдәге дустанә цивилизацияләр күптән инде безнең ниһаять уянуыбызны, алар белән бер сафка басуыбызны түземсезлек белән көтә. Әмма һәрнәрсәнең бер чиге була. Шуңа күрә без, кешеләр, язмышыбызны куркыныч астына куеп яшәгәнче, мөмкин кадәр тизрәк рухи үсеш юлына басарга тиешбез. Күкләрдән иңгән кисәтүләргә колак салырга теләмәгән, һаман элеккечә яши биргән, киләчәктә дә тормыш шулай барыр дип уйлаган кешеләр үзләренә нинди аяныч язмыш әзерләүләрен аңлыйлар микән?»

Шул рәвешчә, автор кешелек дөньясының дөрес юлдан читләшүе зур һәлакәтләргә китерергә мөмкин, дип кисәтә. Галимнәрнең күзәтүләре раслаганча, бүген кешелек дөньясы галәм, галактика хәрәкәтенең үсеш цикллары тәмамланып кисешкән, кискен үзгәрешләр баскычына алып менүче мизгелне кичерә икән. Хәзер Җир-Кояш системасы үзе шунда кергән Плеядалар йолдызлыгы эчендәге 26 мең еллык эволюция циклын тәмамларга тора. Ә бу циклның үзен 12 дәвергә бүлеп карыйлар. Бу икешәр мең ел дәвам итә торган дәвер дә бүгенге көннәрдә тәмамланды — безнең планетабыз Балык йолдызлыгыннан Сукояр йолдызлыгына килеп чыкты — ә без өченче меңьеллыгыбызга килеп кердек.

Башланып киткән Сукояр йолдызлыгы дәверендә планетабызга килә торган нурланышлар шартлы рәвештә Церемониаль Тәртип энергияләре дип атала. Алар җирдәге цивилизациянең йөзен тамырдан үзгәртеп корачак һәм аның яңа

формаларын барлыкка китерәчәк икән. Тормышыбызның зур тизлек белән үзгәрә баруы нәкъ шул хакта сөйли, һәм иң мөһиме — Сукояр йолдызлыгы дәверендә кешелек дөньясына Йокыдан уяну һәм Берләшү мөмкинлеге ачылачак, адәми затның киңәйгән аңы галәм киңлекләренә чыгачак.

Әнә шулай, күпләребезгә әлегә бигүк аңлашылып җитми торган эзотерик күренеш-хәрәкәтләр һәммәбезгә һәм дә бездән соң бу якты дөньяга килүчеләргә турыдан-туры кагылышлы икән бит!.. Рухи үсеш кануннарын белмәү, барысын да матди як хәл итә дип уйлау аянычлы нәтиҗәләргә китерә. Коммунистик идеология нигезендә «Материя — беренчел, аң-рух — икенчел» дигән принцип ятты, моның тискәре нәтиҗәләре — күз алдыбызда. Ә Җиһанда бит барысы да киресенчә, — ди китапның авторы. — Анда аң-рух һәрвакыт беренчел, материя исә икенчел. Раббыбыз аңында Галәм идеясе барлыкка килмичә, ул төзелә алмый.

«Күк капусы ачылса...» китабында нык дәлилләп, әнә шул караш үткәрелә. Көнкүрештә дә шулай бит. Кешенең илаһи зат булып яралтылып та, бүгенге көнне күп асыл сыйфатларын югалтуы, бозыклыкка батуы байлыкка табынуыннан килә түгелме соң?

Солтан Шәмсинең китабында турыдан-туры күчереп урнаштырылган язмалар да бар. Алар бу хезмәтнең идеясе-рухына аваздаш һәм кыйммәтен тагын да арттыра төшә. «Мәрхүмнән иңгән хатлар», «Парацельс китабы», Елена Рерихның «Өч ачкыч» исемле язмалары — шундыйлардан. Күпләребезгә адәм ышанмаслык булып тоелып та, кайберәүләргә, бигрәк тә «күктә ни булмас, дисең — очсыз-кырыйсыз күк бит ул» кебек шигъри юллар белән рухланып гомер итүчеләргә кеше җанының мәңгелеге яисә бер тәннән икенчесенә күчеп урнашу сәләте (реинкарнация), теге дөньядан әледән-әле иңә торган хәбәрләр турындагы язмалар өметләнеп яшәүче күңелләргә өстәмә җим, оптимистик җан азыгы булып хезмәт итәр.

Болардан тыш китапка «Алтын Урдада ватандашлар көрәше» исемле зур тарихи хезмәт, бүгенге тормыш хәлләрен бөтен үткенлегендә чагылдырган, кыю рухлы публицистик мәкаләләр («Яшәү даирәң киңме, ана телем?», «Исемең мәгърур, кемнәр кушкан?») һәм нәкъ бүгенге заман рухында язылган дүрт хикәя-новелла («Каты чикләвек», «Табигатьнең газиз баласы», «Синеке булыр», «Соңгы юаныч») урнаштырылган. Тулаем алганда, «Күк капусы ачылса...» китабы битләрен ачса, зирәк һәм кызыксынучан, эзләнүчән рухлы укучы аннан үзенә, зиһененә күп нәрсә алыр иде. Ә гомумән, әлеге хезмәтне бүгенге әдәбиятыбызның олы казанышы, күңелләргә рух һәм җан азыгы бирердәй, аңнарыбызны киңәйтердәй кыйммәтле китап дип санап була.

«Күк капусы ачылса» китабына тупланган язмалар аша әдип иҗатының нигезен тәшкил итүче принципларны билгеләргә була. Иң башта яшәешнең бары тик үзара аңлашу, татулык, мәрхәмәтлелек шартларында гына мөмкин икәнлеге ассызыклана. Бөек рухи көчләр, кешелек дөньясы тәрбиячеләре, табигать-ана, галәмгә, кешелеккә иң уңайлы шартлар тудырган Затлар турында сүз алып бара автор, һәм менә без — адәм балалары шул могҗизаның бөеклеген күреп, аңлап, кадерен белеп яши беләбезме, әллә һәрдаим үзебезнең кылган гамәлләребез, гөнаһлы кыланышларыбыз белән шул изгелекләрдән читләшә барабызмы? Әдип шул сорауларга җавап эзли — ә ул җавап тик уңай гына булырга тиеш. Бу очракта сүз югарыда исеме телгә алынган китап турында гына бармый. Әдипнең бөтен тормышы, яшәеше, көн итүе һәм, әлбәттә, күпкырлы иҗаты әнә шул турыда сөйли. Биредә А.П.Чеховның «...кешедә һәрнәрсә гүзәл булырга тиеш...» дигән мәгълүм гыйбарәсе дә искә төшә. Солтан Шәмси белән очрашкан һәр зыялы бу шәхеснең әңгәмәдәшенә карата үтә дә игътибарлы булуын, аеруча тактлы теләктәш мөнәсәбәтен, карашы, сүзе белән, сине рәнҗетмичә генә, үз фикерләрен куя, яклый, үткәрә белүе кебек характер сыйфатларына битараф калмагандыр.

Әлбәттә, барысының да төбендә яшәешнең матур, тигез, гармонияле мөнәсәбәтләргә нигезләнгән булуы һәм шуны аңлау, саклауның зарурилыгы ята. Боларны югалту зур, хәтта төзәтә алмаслык фаҗигаләргә алып килә. Бөек Алтын Урда дәүләтенең XIII-XIV гасырлардагы котылгысыз һәлакәтенең төп сәбәбе — хакимлек, власть өчен ызгыш-талаш, элеккеге акыллырак хакимдәрләр урнаштырган

гармонияле мөнәсәбәтләрнең күрәләтә бозылуында, юкка чыгуында. Моның шулай икәнлеге «Низаглы йортта» әсәрендә җитди тарихи фактлар ярдәмендә исбат ителә. Һәм иң гаҗәбе — бөтенләй башка жанрдагы — балаларга атап язылган «Ут хәйләсе» исемле әкияттә дә матурлыкны, дуслыкны, тату мөнәсәбәтләрне саклый белмәгәндә, бөтен җир шарын ут ялмап алып, бар табигатьне юк итәчәге турындагы кисәтү нәниләрнең үз телләрендә аңлаешлы итеп бик әйбәт ачып салынган.

Ә хәзер әдипнең иҗат эшчәнлегенең тагын бер ягына — заман прозасы юнәлешендәге эшчәнлегенә күз салыйк. Узган гасырның сиксәненче елларында әдипнең бер-бер артлы өч проза китабы («Көмеш чылбыр», «Җәяүле буран», «Ут хәйләсе») дөнья күрүе хакында инде алдарак әйткән идек. Аннан соң да шушы юнәлештәге эшләр уңышлы дәвам иттерелде: «Еллар эзе» (1996) һәм «Күк капусы ачылса...» (2006) җыентыкларында С.Шәмси безне яңа хикәяләре һәм язмалары белән таныштырды. Әмма әдәбият белгече Равил Рахмани бик дөрес билгеләп үткәнчә, «авторның бу китаплары күпсанлы һәм берникадәр чуар сыйфатлы әдәби продукция ташкыны эчендә укучы күзенә бик үк ташланмый калды, алар киң җәмәгатьчелек тарафыннан тиешле бәяләрен алып җиткермәде кебек. Хәлбуки, язучының байтак кына хикәяләре өлгергән, югары сәнгать әсәре буларак, бүгенге әдәбиятыбызның уңышы итеп каралырга тиешләр иде сыман. Һәрхәлдә, автор үзен нечкә психологик хикәя остасы итеп күрсәтә алды, ...без аларда соң чиккәчә җитеп тартылган киеренке халәт үсешен, тетрәндерә дә, уйландыра да торган күп төрле характер-образлар белән очрашабыз».

Әйтелгәннәр белән килешеп, әдипнең чәчмә әсәрләренең битләрен ачып карыйк. Нинди жанрда булуларына карап, авторның язу стиле даими үзгәрә тора. Прозасының матур үрнәкләре белән таныша башлаганда, «боларны бит күренекле әдип-тарихчы язган» дигән уй бөтенләй башка да керми. Тик беренче карашка гына шулай тоела. Эш шунда ки — әдип бу юлы башка, кечкенәрәк модельләргә күчә: бүгенге чор, заман чынбарлыгын чагылдырган хикәяләренең бик күбесендә олы, катлаулы тормыш юлы узган, аның ачысын-төчесен татыган мөхтәрәм затлар, шәхесләр гәүдәләнә — «Балконда» хикәясендәге фронтовик Кадыйр, «Соңгы юаныч»тагы бакчачы карт, «Табигатьнең газиз баласы» хикәясендәге Гаффә карчык — әнә шундыйлардан. Җентекләбрәк карасаң, аларның башларыннан узган тормыш вакыйгаларының һәркайсы — үзе тарихның бер нәни кыйпылчыгы, һәм болар турында сөйләгәндә дә автор җитди һәм аңлаешлы аналитик иҗат принцибыннан читләшмәскә тырыша.

Солтан Шәмсинең күпчелек герой-персонажлары — тәрбияле, итагатьле, тәртипле кешеләр — заманыбызның ихтирамга лаеклы мөхтәбәр затлары — аларның күбесендә авторның үзенә хас характер сыйфатлары, карашлары, омтылышлары аермачык гәүдәләнә. Әдип үзе дә аны яхшы аңлардай теләктәш укучысына йөз тота сыман. Хикәяләр һәм бәяннарда без әнә шундыйлар арасында яшибез — бер сүз белән әйткәндә, бу — позитив дөнья. Шулай да тәрбиянең һәм тормышка карашларның төрлечәрәк булуы сәбәпле, тигез җирдә дә кыенлыклар, каршылыклар аяк астыннан килеп чыгучан була. Бу хәл бигрәк тә гаилә оешу һәм гаилә эчендәге мөнәсәбәтләргә карый. Әмма болытлар баш өстендә никадәр генә куермасын, автор аларның вакытлыча гына булуына өметләнә, ә инде юллар котылгысыз рәвештә бер-берсеннән аерылганда, әле башка сукмакларның да барлыгы, әле яңа шанслар, мөмкинлекләр булачагы турында да искәртелә («Якты утрау», «Нихәл, дустым?», «Сагыну» һ.б. хикәяләрдә).

Әдипнең төп иҗат кредоларының берсе — яшәешкә, тормышка, матурлыкка — шуларны һәркайсыбызга мулдан бүләк иткән Табигать-анабызга һәм аның әйләнә-тирәбездәге һәртөрле чагылышларына тирән рәхмәт һәм ихтирам хисләре белән сокланып гомер итү. Адәм баласының гомере, тормышы, гаиләсендәге мөнәсәбәтләр турында фикер йөрткәндә дә, автор процесс яки күренешкә фәлсәфи планда якынлаша, һәрнәрсәнең төбенә төшеп тикшерүче буларак бәя бирә. «Якты утрау» хикәясендә әлеге вазифа әсәрнең баш герое Гомәргә йөкләтелә. Менә аның табигать һәм кеше тормышының янәшәлеген чагылдырган кайбер уйлары:

«Гаилә тормышы кызык икән ул, — дип уйлый иде Гомәр. — Ул нәкъ һава

торышы, ел фасыллары, табигатьтәге үзгәрешләр кебек алышынып тора, болытлы көннәрдән соң кояш чыга, ул, ниндидер законнарга буйсынып, гел тирбәлә: бер өскә күтәрелә, бер аска төшә. Кайвакытларны ул: «Безнең гаилә генә шулаймы, әллә кеше психикасы кебек сизгер системалар өчен гомуми закончалыкмы бу?» дип тә куя». Әнә шул рәвешчә, хикәядә гаилә тигезлеге, гармониясе мәсьәләләре кузгатыла. Геолог Гомәр белән хатыны Сания арасындагы аңлашылмаучылыкны озакламый туачак бәбиләре алып ташлый: аның туачагын көткән Гомәр «хәзер үзен яшел оазиска, якты утрауга юлыккандай хис итте. Тату яшәгән гаилә дә — шул ук коткаручы утрау — яшел оазис кебек бит, дип уйлады ул. Кеше анда хәл алырга, яраларын дәваларга, яңа эшләр һәм көрәшләр өчен көч тупларга әйләнеп кайта».

Менә шулай гаилә татулыгын, кеше бәхетен табигать байлыгы белән янәшә куеп чагыштыру һич тә очраклы түгел — бу янәшәлек С.Шәмси прозасында гел дәвам итәчәк, әле тагын күп тапкырлар безгә очраячак. Тик кайбер шикләр дә туарга мөмкин: иң куркынычы — бу төштә авторны фикерне образга «төреп җиткермәү» яисә фикернең «ялангач» калып, образга әйләнеп, «эреп бетмәве» сагалап тора. Әмма автор үзе моны яхшы аңлый һәм андый очраклылыктан да читләшергә тырыша. «Соңгы юаныч» исемле хикәясе — шуның бик матур мисалы. Бакчачы карт күңелендәге сафлану халәте кечкенә генә тормыш детальләре, штрихлары аша шактый матур гәүдәләнә — күзгә моңсу табигать фонындагы авыр уйлар башкалары — өметлерәкләре белән алмашына. Бу карт, хатыны авырып, үлеп киткәч, үзен кая куярга белми — хәзер аның бердәнбер сыену ноктасы — юанычы булып бакчасы — дачасы кала. Бердәнберенең шушы бакча дия-дия казынып, үлемен тизләткәнен дә аңлый ул. Төпле бер карарга килеп, олы кызының ай-ваена карамастан, карт, бакчада вак-төяк яшелчә үстерүдән ваз кичәргә була — суыктан корыган алмагачларын кисеп, мул итеп үлән чәчеп, бакчаны да, үз-үзен дә тынычлыкта калдыра. Чапкан үләннән шалаш ясап куя да шунда яши башлый. Хикәянең финалында көтелмәгән сюжет борылышы бар: «печәнне кемгә, күпмегә сатар икән бу карт», дип көтеп торган бакча күршеләре һәм, әлбәттә, укучылар, бераз гаҗәпкә дә кала: «үзең, кирәксә, кереп алырсың», дип, бер танышына калдырып китә. Сюжетның үзәгендәге печән характердагы кискен үзгәрешне күрсәтер өчен файдаланылган әдәби деталь икәнлегенә укучы тиз төшенә.

Бу әсәрдә дөнья артыннан куып, вак-төяк мал тупларга азапланып, борчылып яшәүнең үтә мәгънәсезлеге, болардан арынганда гына җан тынычлыгына ирешеп була дигән фикер ярылып ята. Әсәрләре нинди генә жанрда булып, кайсы гына темага карамасын, һәр очракта авторның ныклы позициясе, утырып җиткән карашлары, мәсьәләгә конкрет мөнәсәбәте ачык сизелеп тора. Хикәяләрдәге һәртөрле сюжет, сурәтләү алымнары әдипнең укучысына әйтергә теләгән уй-фикер һәм тойгыларын җиткерүнең чаралары булып хезмәт итә. Төп фикер һәм аның образлы сурәте әсәрнең нигезен һәм, шуннан чыгып, уңышын тәэмин иткәнлеген яхшы беләбез. Ә вакыйгалар, аерым сурәтләү чаралары — тышкы билгеләр, калып булып кына тоела. Тик менә шул тышкы билгеләр, вакыйгалар, сурәтләр тезмәсенә фикер-идеяне салганда, сүз художнигына аеруча сак эш итү, укучы белән автор арасындагы элемтә җепләренең ныклыгы, чәбәләнмәве һәм һәркайсыннан үзара теләктәшлек сорала. Бер караганда, Солтан Шәмси үз әсәрләрендә, бигрәк тә хикәяләрендә, персонажлар яисә геройлар тормышының тик бер читен генә ачып күрсәтү, күзгә бәрелеп тормаган вакыйгаларны сурәтләү белән чикләнә кебек. Әсәрдән маҗаралы хәлләр, кискен борылышлар өмет итүчеләр әлеге алымнан бигүк канәгать тә булмастыр. Аның каравы, тормышның асыл мәгънәсе турында уйланырга, нечкә күңел халәтләрен, тирән чоңгылларын сабыр гына күзәтергә, аларны үз хәлләре, яшәешләре белән чагыштырып, кайбер нәтиҗәләр ясарга күнеккән укучылар өчен бу типтагы әсәрләр кыйммәтле хәзинә булып тоелыр.

Кеше күңеленең байлыгы, аның нечкәлеге, аз гына тупас кагылганда да, тиз яраланучан булуы, үзара мөнәсәбәтләрдә аеруча сак эш итә белү зарурлыгы кебек мәсьәләләр һәм фикерләр татар прозасында күптәннән үткәрелеп килә. Шуның матур һәм гыйбрәтле мисалларын без үз вакытында Фатих Әмирхан, Шәриф

Камал, Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники кебек бөек әдипләр әсәрләрендә байтак очраттык. Солтан Шәмси прозасында шушы бәрәкәтле психологизм юнәлеше бик уңышлы дәвам иттерелә. Бу психологик сызык үзеннән-үзе мөнәсәбәтләр гармониясе, күңел җылылыгының табигыйлеген аңлау, бүтәннәргә, бигрәк тә язмыш җилләре тарафыннан кагылган-сугылганнарга, вакытында ярдәм кулы суза белү сәләте кебек нәрсәләргә килеп тоташа. Хикәяләрендәге күпчелек геройларга мондый сыйфатлар тумыштан салынган. Боларның барчасы автор шәхесенең үзеннән килә дип әйтергә тулы нигез бар. Жанр кануннары буенча, әлбәттә, мондый кешелекле мөнәсәбәтләр укучыга күп очракларда персонажларның эш-хәрәкәтләре, гамәлләре һәм сүзләре аша җиткерелә.

Табигатьнең мәрхәмәтле кочагында сау-сәламәт килеш әйләнә-тирәлекнең матурлыгын тоеп яшәү — үзе генә дә зур бәхет. Ә инде гүзәл сөйгәне белән тиз арада очрашуның кадерле минутларын көтеп торган ир-ат заты моны аеруча ләззәтләнеп тоя («Сагыну»): «Болын өстендә яткырып куелган кувшинга охшаш болыт асылынган. Аннан тамчылар тамар да Әлфияне чылатыр сыман. Хафиз шул бердәнбер ак болыттан күзен алмый утырды. Тәненең бөтен күзәнәкләренә кояшның шифалы, тансык нурын сеңдереп, бу мәлне күңелен камап алган тынлыкка һәм шул ук вакытта минут саен ныгый барган ышанычка гаҗәпләнеп куйды: бу тынлык, әлеге күңелгә иңгән ышаныч — бәхет үзе түгел микән?.. Утыра торгач, ул бире таба килүче Әлфияне күреп алды. Шул вакытта артта рельслар гүли башлады. Электричка якынлашып килә иде... Болын өстеннән, үләннәрне җиңел тибрәтеп, җил узды. Хафиз аның йомшак канатын тоя, күзләрен йомар-йоммас утыра бирде. Бераздан ул үзендә әйтеп бетермәслек җиңеллек сизде. Бу минутта инде ул салмак адымнар белән аңа таба килүче Әлфиянең гомерлек, алыштыргысыз дус булачагына ышанган иде...»

Күренеп тора: бу кечкенә, әмма герой өчен бик тә әһәмиятле тормыш мизгеле нәкъ үз төсләрендә җемелди. Мондый күренешләрнең авторын, бәлки тәнкыйтьчеләребез тарафыннан еш кына урынлы-урынсыз кулланыла торган термин — «импрессионизм вәкиле» яисә «импрессионист» дип тә атап була торгандыр. Чөнки мондый агымга хас, нечкәләп сурәтләнгән хисси сурәтле күренешләрне С.Шәмси әсәрләреннән бик күп табып була. Бу җәһәттән авторны югары хәзерлекле эстет дисәң дә ярыйдыр. Ул үзенең иҗатында һәрдаим нәфислек, нәзакәтлелек, гүзәллек тарафдары булып кала. Менә тагын бер мисал: «Хафиз, китаптан аерылып, өстәлдәге розага борылды. Кара өстәл, кара сызыклар төшкән ак ваза, аңа утыртылган ялгыз роза — зәвык белән берләштерелгән бу өч әйбер берсе-берсен тулыландырып, бүлмәгә ямь өстиләр иде... Хафизның күңеле күтәрелеп китте...» («Сагыну»).

Геройлары белән бергәләп, автор укучыны да тормыш мизгелләренең кадерен белеп, табигатьнең сулышын тоеп, андагы тереклекнең бихисап рәвешләрдәге чагылышларын, үсемлек, кош-корт, бөҗәкләре дөньясын күреп, аңлап яшәргә чакыра сыман. Әдип карашларын һәм иҗатын иңләп алган төп тема — тормышны, тереклекне, гомумән, яшәешне сөю, олылау мотивлары аның язганнарының барчасын сугарып тора. Моңа авторның гаять тирән, хәтта энциклопедик гыйлемгә ия булуы, дөньяны, аның тарихи хәрәкәтен фәлсәфи киңлегендә һәм бөтенлегендә күзаллый белүе дә ярдәм итә шикелле. Икенчедән, авторның бай мәгълүматны кызыклы, аңлаешлы һәм тәэсирле әдәби калыпларга салып, беренче җөмләләре белән үк укучыны кызыксындырып, үз артыннан ияртергә сәләтле шәхес икәнлеген дә истән чыгармыйк. Игътибарлы укучысы алдына ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең нечкәлекләрен генә түгел, хәтта Галәмдәге хәрәкәтнең акыл җитмәстәй булып тоелган яшерен серләренең кайбер якларын да ачып сала. Боларның барысы да Табигать-анага хас кодрәт һәм материаль дөньяның камиллеген тәэмин итүче Илаһи көчләрдән килә — алар мәхәббәтле, гармонияле тормышның чыганагы дигән фикерне аңлауга һәм олылауга кайтып кала. Әлбәттә, мондый фикерләр һәм дөньяга карашларның тирәнлеге үзләреннән-үзләре тумаган — игътибарлы укучы аларның күбесенең ислам тәгълиматыннан килгәнен, Коръәни Кәримнең үзендәге аятьләр белән аваздаш икәнлеген тиз шәйли аладыр. Шул

тәгълимат белән сугарылган тарихыбызның бай классик әдәбиятыбызда чагылган рәвеше, сурәтләре булып тагын бер чыганак күңелгә килеп ирешә. Моның матур мисалы — атаклы Дәрдемәнднең шигъри юллары: «Ни газизрәк — бу Ватанмы? Аһ, туган каумем газиз! Ул мөкатдәс кан белән ул изге сөткә ни җитәр!.. Сөт калыр, Ватан китәр! Сөт калыр, Ватан китәр!»

«Бу сүзләрдә нинди тирән мәгънәләр ята, — ди Солтан Шәмси. — Чыннан да, тарих барышында бик күп кавемнәр, халыклар төрле сәбәпләр аркасында төрле тарафларга күченеп, туган җирләрен, ватаннарын ташлап китәргә мәҗбүр булганнар, шул исәптән татар халкы да. Шуңа да карамастан, алар яңа җирләрдә дә үзләре булып кала белгәннәр. Ягъни туган телне, гореф-гадәтне, ата-бабадан калган йолаларны — кыскасы, халыкның йөзен тәшкил итә торган күп сыйфатларны саклап калуга ирешкәннәр. Бу үзенчәлек төрки бабаларыбызга да хас, бихисап гасырлар, меңнәрчә еллар үтсә дә, алар төрки кавем булып калганнар. Шагыйрь бу сыйфатны иң изге һәм газиз әйбергә — Ана сөтенә тиңли, Ватан китсә дә, сөт калыр, халык үз йөзен югалтмас, чит йогынтыларга бирелеп, башка халыклар арасында эреп югалмас, йотылмас, ди. Бабаларыбыз үткән юлны күздән кичергәндә, мин дә безнең өчен төп нәтиҗә, иң зур гыйбрәт әлеге «сөт»не саклап калудыр дип уйлыйм».

Кешелек язмышы өчен борчылып яшәү, башкалар хәсрәтен үз күңеленә якын итеп кичерә белү хаҗәтеннән караганда, С.Шәмси иҗаты рус әдипләреннән А.П.Чехов иҗатына якынрак тора дип уйлыйбыз. Бу хәл әйләнә-тирәдәгеләргә үтә дә игътибарлы, итагатьле мөнәсәбәттә, экономияле, бәрәкәтле язу стилендә дә сизелә. Ә инде кешенең кемлеген, чын кешелек сыйфатларын ача торган гаделлек, намуслылык, мәхәббәт һәм бәхет кебек олы категорияләр яссылыгына куеп карасаң, бу ике иҗатчы язганнардан байтак кына уртаклыклар табып булыр иде. Әлбәттә, әлеге урында сүз ниндидер иярү яисә кабатлау турында бармый. Шулай да татар әдәбиятчысының әдәбият белемендә кабул ителгән «Чехов мәктәбе» дигән төшенчәгә тартым яисә аваздаш икәнлеген исбат итү артык кыен булмастыр. Тик әлегә без бу хезмәтебездә алдыбызга ул күзәтүебезне исбатлауны максат итеп куймадык.

Солтан Шәмсинең иң матур хикәяләренең берсе — «Әбиләр чуагы» (2013). Аның жанрын ул «тәэссорат» дип билгеләгән. Әдәбият фәнендә мондый язмаларны «эссе» дип атау гадәткә кергән. Дөресендә исә бу атамалар үзара каршылыкка керми. Иң әһәмиятлесе: «Әбиләр чуагы»нда авторның кеше, гражданин, замандаш һәм художник буларак тормыш агышына, яшәешкә мөнәсәбәте бик ачык итеп әсәрнең зур булмаган мәйданына туплап бирелгән. Эчтәлеге бик гади һәм һәркайсыбызга аңлаешлы: шәһәр ыгы-зыгысыннан, чирләреннән алҗыган герой (аның автор үзе икәнлеге бик җиңел аңлашыла) көзнең матур көннәрендә авылга кайта — тормыш мәшәкатьләреннән вакытлыча арынып, җан рәхәте кичерә: «Монда бернәрсә дә сиңа басым ясамый, мәҗбүрият юк, син табигый яшәү кочагында, үз-үзеңә хуҗа, әбиләр чуагының гаҗәеп манзарасы күзләрен, һәр күзәнәгең аша җаныңа үтеп керә, күңелең ниндидер тантана, аңлатып булмый торган илаһи хис белән тула. Үзең дә сизмәстән, шагыйрьгә әйләнәсең, табигатьнең көзге матурлыгы җанында нечкә көй булып сузыла».

Хикәянең төп өлешен геройның, көндез авыл читенә чыгып, җәяүләп Шүрәле яры дип аталган үзәнлек буенда йөргәндә һәм кичен авыл өстендәге йолдызларга карап торганда, күңелендә туган уйлар тәшкил итә. Менә ул кайчандыр гөрләп эшләп торган һәм бүген инде хәрабәләре һәм коесы гына калган иске шырпы заводы калдыклары яныннан үтә, халык өчен эшләнгән һәм аңа хезмәт итәрдәй әйберләрнең вакытсыз югалуына уфтана. Ләззәтле һәм хәсрәтле уйлар-истәлекләр гел аралашып бара. Якында гына урнашкан мари авыллары һәм андагы эш сөючән дустанә халыклар искә төшкәндә дә, инде ул элемтәләр, элеккеге дуслык җепләре ерак тарихта өзелеп калганлыгы искәртелә. Бүгенге яшәешнең дә күңелне тырнап торган яклары байтак: авыл читләре пычранган, үзәннәргә чүп өемнәре тулган, авылдашлар моңа битараф — берни булмагандай яныннан үтеп йөриләр...

Солтан Шәмси — контрастлар әдибе. Бер яктан, ул Кеше дигән Гали затның илаһи күкләр, табигать бөеклеге белән кушылып, бербөтен булып яшәвен олылый. Икенче якта — булганны, кешелек тапканны әрәм-шәрәм итеп, өстеннән таптап йөрү, чүп өемнәренә әверелдереп, табигатебезне, яшәешебезне агулау... Моның белән ул ничек килешсен?.. Ирексездән, автор кайчандыр тереклек, тормыш гөрләп торган һәм инде сүнгән Фобос, Марс кебек планеталарны искә төшерә. Әмма барыбер авылның көзге кичләрендә күктәге йолдызларга карап торсаң, күңелләр сафлана, рухи көчләрең арткандай була икән — тормыш ыгы-зыгыларына да җиңелрәк карый башлыйсың, йөрәгеңә дәва була... «Галактика кебек могҗизаны озаклап күзәтергә яратам, — ди автор. — Сизгәнегез бардыр, күкләрне күзәтүнең ниндидер аңлашылмаган тылсымы бар. Җаның күкләргә тартыла, шул тылсымлы күккә ашасың килә башлый. Моның хикмәте нәрсәдә соң? Хикмәте гади дә, катлаулы да — җаныбыз бит шуннан иңгән, аны Туган йорты тарта...»

Шул рәвешчә, Солтан Шәмси җир кешесе тормышының олы Илаһият белән бәйләнешен эзли, шуны күрергә, расларга тырыша. Һәм ул аның җавабын һәркайсыбызга бүләк ителгән яшәү бәхетендә таба. Әбиләр чуагын истә тотып, бик гади һәм һәркайсыбыз аңлардай җавап та бирелә. «Нәрсә ул бәхет?.. Бәлки шушы татлы халәттер, бушап калган кырлар, үзәннәр тынлыгында, аның илаһи музыка булып яңгыраган авазларын тыңлап ләззәтләнүдер... Әйе, шулайдыр».

Ни өчендер — әллә күпкырлы булгангамы, Солтан Шәмси иҗатын киң диапазонлы, күп ешлыклы, саф яңгырашлы, сыйфатлы радиоалгыч, хәтта үзе дә нурлар таратучы ниндидер аппарат белән тиңлисе килә. Әлеге нурларны ул Галәмнең иң ерак почмакларыннан да ала. Ул нурлар гаять тә серле, әлегә күбебезнең зиһененә барып җитмәгән яклардан, Мәхәббәт, Бәхет, Гыйлем кебек төшенчәләрне үзара кристаллаштырып, бер монолит сафлык берәмлеге дип аңлатучы Рерих кебек галимнәрдән, Җиһанның бүтән үлчәмнәрен үзләштергән башка затлардан, хәтта яшәүнең үлгәннән соң да башка формалары, катламнары бар дип ышанучылардан индерелүе рәвешендә безгә дә килеп ирешә.

Хәзер инде сүзебезне тәмамларга, нәтиҗә ясарга да вакыт җитте бугай. Хезмәтебез башында «Кем соң ул Солтан Шәмси?» дигән сорауны куйган идек һәм бу сорауга аның иҗатын анализлап, беркадәр ачыклык керттек шикелле. Ә кыскарак итеп әйтсәк, ул болай булыр: Галәмнең чиксезлеген, яшәүнең бөеклеген фәлсәфи төшенчәләргә бәйләп, аларның катлаулы якларына күз салырга чакыручы да, халыклар тарихындагы текә борылышларны, һәлакәтләрне, торгызылу-яңаруларны бер чылбыр итеп күрә белүче дә һәм «Ут хәйләсе» исемле повесть-әкиятендә табигать балалары — Кояш-ата, Җир-ана, Урман, Агымсу, Ут кебек геройларын образ-символларга әверелдереп, сурәтләрен сабыйлар күңеленә күчерүче дә ул — дустыбыз, фикердәшебез, замандашыбыз — Солтан Шәмси!

Олы юбилее көннәрендә без аңа һаман да шулай югары биеклекләрдән карап, тормышка сокланып, үзе сайлаган дулкыннарда һәм ешлыкларда укучыларына нур өләшеп яшәвен теләп калабыз.

**Рифат СВЕРИГИН**

# КҮЗЕН АЧКАЧ, ЗӨЛӘЙХА НӘРСӘ КҮРДЕ ИКӘН?

## ГҮЗӘЛ ЯХИНАНЫҢ «ЗУЛЕЙХА ОТКРЫТВАЕТ ГЛАЗА» РОМАНЫ ТУРЫНДА

Романның атамасы ук укучының игътибарын җәлеп итә.

Чыннан да, күзен ачкач, Зөләйха ни-нәрсә күрде икән соң?

Ул игенчеләрнең хәләл көче белән үстергән икмәген талаучы совет инквизиторларын күрде. Ул изге мәчетләрне мыскыл итүче, гаепсез кешеләр белән рәхимсез кыланучы «кызылурдачыларны» күрде.

Зөләйха ире белән зиратка барып, кызларының каберен ачып, табутына чәчүлек икмәкне яшереп кайтып килгәндә, кемнендер урысча җырлаганын ишетә. Бу җырны икмәк талаучылар отряды җырлап килә икән. Зөләйха җырның сүзләренә колак сала:

*Вздуйте горн и куйте смело,*
*Пока железо горячо...*

Зөләйха җырны тимерче урыс җырлый дип уйлый. Юкса, автор Зөләйханың урысча бер авыз сүз дә белмәгәне турында яза. Бер сүз дә урысча белмәгән Зөләйха җыр турында фәлсәфә куерта. Шушы мантыйксызлыкны укыганнан соң, романның беренче битләреннән үк авторга ышанмый башлыйсың.

Ни өчен халыктан рәхимсез рәвештә икмәк талаучы кызылармеецлар автор тарафыннан «кызылурдачылар» дип аталган? Автор үзенең борынгы ата-бабаларын җене белән сөйми һәм гаделсез «кызылармеецларны» «кызылурдачылар» дип атый.

Әлеге дә баягы «Татар игосы» заманасындагы урдачылар коммунист-кызылареецлар кебек рәхимсез булмаган. Алтын Урда баскагы буйсындырылган илләрдән елга бер тапкыр ясак җыйган да китеп барган.

1254 елда бөек солтанат — Алтын Урдада халык санын алу башлана. Шуның нәтиҗәсенә күрә, карар чыгарыла: җирбиләүчеләр Алтын Урдага «мал» дип аталган ясак (налог) түләргә тиеш була. Терлекчеләр йөз баш тере малдан бер баш малны баскакларга бирү мәҗбүрендә булган. Сәүдә өчен ясак «тамга» дип аталган. Бу ясак сатылган малның өч процентын тәшкил иткән (*История Грузии, 1967, стр. 98).*

Шул да булдымы «иго»?

Чын иго совет власте вакытында килде халык өстенә. Халыкның җиде кат тиресен тунадылар коммунистлар. Сүз иярә сүз чыккач, әйтим: бөек тарихчы Лев Николавевич Гумилёв «иго» булмаганын исбатлады. Тарихчылар «иго» уйдырмасы татарларны кысарга-кимсетергә шовинистлар уйлап чыгарган сылтау гына дип карый.

Бичара, гаепсез бәрәнгә бүре әйтә: «Син гаепле минем ашыйсым килгәнгә!»

Мескен крәстиән совет власте өчен бушка эшләде, паспорты булмады, кол иде игенче, калхуз рәисенең рөхсәтеннән башка игенче беркая да китә алмый иде. Крәстиәннең соңгы кыерчык ипиен, урта хәллеләрнең имана җирен, малларын, йортларын, җиһазларын тартып алдылар. Коммунистлар-кызылареецлар мәчетләрне җимерделәр яки клуб ясадылар. Советлар Берлеге халыклары түли алмаслык налоглар, заемнар түләргә дучар ителделәр. Хәтта күт налугы салдылар. Хатын-кызлар кияүгә чыккач, бала табалмаса, аңа күт налугы салалар иде. Ир кеше өйләнсә, хатыны бала тапмаса, ирләргә дә күт налугы йөклиләр иде. Имәнгеч налуг иде ул. Әгәр ир импотент яки кыз-тәкә булса? Әгәр дә хатын бала табалмый торган булса?

Гәрчә 1861 елда ук крепостное право бетерелсә дә, СССРда крепостное право XX гасырга чаклы дәвам итте. Бу хәл, автор язганча, «кызылармеецлар» заманасында булды. Гаҗәпләнергә генә кала, урта гасырлардагы «урдачыларнын» «коммунист кызылурдачыларга» ни катнашы бар? Гүзәл Яхинаның борынгы бабалары — «урдачылар» «кызылармеецларга» караганда йөз мәртәбә миһербанлырак булган.

Октябрь революциясеннән соң СССРда котчыккыч кызыл террор чоры башланды.

Коммунистлар халыкның соңгы ямаулыгына кадәр алып бетерделәр. Кызыл бандитлар белән чагыштырганда, «ордынчылар» фәрештәләр кебек миһербанлы булган. Урта гасырдагы «урдачылар» буйсынган чит халыклардан өлешчә генә ясак алганнар. Кызыл бандитлар исә халыкны соңгы тавыгына кадәр талаганнар, атканнар, үтергәннәр, ач үлемгә дучар иткәннәр. Идел буендагы, Украинадагы ачлык йөзмеңнәрчә кешеләрне кабер якасына кертте.

Язучы Гүзәл Яхина бу өлкәдә, йомшак кына әйткәндә, бихәбәр икәнен күрсәтте. Ул татар тарихына өстән генә, җиңелчә генә карый икән. Димәк, романның беренче битләреннән үк авторга ышанмый башлыйсың.

Романда калкытылган тема яңалык түгел, халыктан икмәк талау, кулакларны каторгага сөрү, гулаглар инде күптән тапталган темалар. Романның аерым үзенчәлеге нәрсәдә соң? Юк анда аерым үзенчәлек. Мескенлеккә төшерелгән татар хатыны «яхшы ирен» атып үтергән коммунистка — гыпыушникка кияүгә чыга. Бәлки шушы канлы вакыйга аерым үзенчәлеккә дәгъва кыладыр? Бу да әдәбиятта яңалык түгел. Эсхилның «Орест»ында да, Шекспирның «Гамлет»ында да, Пушкинның «Ташһәйкәл кунаг»ында да хатыннар ирләрен үтергән кешегә гашыйк була яки кияүгә чыгалар. Бу темага күп авторлар әсәрләр язды бит инде.

Бәлки автор романында моңарчы әдәбиятта булмаган уңай образлар, зиһенле, каһарман татарларны һәм татар милләтенең башкаларга күрсәтерлек гүзәл йолаларын сурәтлидер? Милли холыкларга килгәндә, әсәрдә метаморфоза калкып чыга. Кайда татарларда мең еллар буена шомарган, тәртипкә салынган матур гаилә институты? Романдагы кебек татарлар мескен, кыргый, примитив тормышта яшәгәннәрме икәнни?

Булган алар рәхимсез-кансыз каенаналар, алпавыт хатыннары, алар үз крепостнойларын эт урынына кыйнаганнар, хәтта үтергәннәр дә, урыс алпавытихасы Салтыкова Дарья Ивановна крәстияннәрен юкка-барга да каты җәзалап үтергән. Ләкин бу гамәл татарлар арасында типик түгел. Гаилә башлыгы булмаган очракта аның вазифаларын каенана башкарган, бу гадәт төрк-татарларда борынгыдан булган, ләкин каенаналар киленнәрен үз урынына калырлык итеп, кырыс тәрбияләгәннәр. Татар гаиләсендә каенана йола-гадәт сакчысы булган. Татар гаиләсендә каенана кырыс булган, ләкин ул кырыслык һич тә кансызлыкка, садистлыкка әверелмәгән. Романда «Убырлы карчык» патологик рәвештә явыз, гипетрофический әшәке, артыгы белән гаделсез һәм кансыз. Уйлап куясың, каенананың рухы сәламәт түгел бит. Ни өчен каенана артыгы белән каты күңелле? Бу турыда автор сүзсез кала. «Кабахәт кеше ролен уйнаганда син аның кайчан-кайда миһербанлы булуын эзлә». Юк шул, каенана Убырлы карчык һәрвакыт гаделсез усал. Ул гомергә гаделсезлек битлеге кигән. Чөнки авторга шулай кирәк булган.

Әсәрнең каһарманнары Яхина тарафыннан шулай уйлап чыгарылган, алар авторның теләге буенча хәрәкәт итә, шуңа күрә алар ышандырмый. Каенана холкында бөтен кабахәт кешеләрнең үзенчәлеге тупланган: ул килененә нахак яла яга, ул рәхимсез, ул гаделсез, ул сәбәпсезгә киленен кимсетә, җәберли, ул Зөләйханың фаҗигасен (аның туган бер баласы үлеп бара) мыскыл чыганагы итә. Каенана — патологик садистка.

Әсәрнең каһарманнары җепкә тагылган курчаклар кебек хәрәкәт итә, җеп автор кулында.

Михаил Шолохов турында риваять йөри. Имеш, ул бик кайгылы рәвештә редакциягә килеп керә.

— Ни булды, Михаил Александрович? — дип сорыйлар моннан.

— Давыдовны үтерделәр! — дип Шолохов үксеп елый башлый.

— Кайсы Давыдовны? — диләр редакторлар.

Баксаң, Шолохов «Күтәрелгән чирәм» әсәрен тәмамлап килгән икән. Әсәрнең азагында дошманнары Давыдовны үтерәләр.

— Михаил Александрович, ә сез Давыдовны үтертмичә тәмамлагыз әсәрегезне! — дип киңәш итәләр редакциядәгеләр.

— Юк! — ди автор. — Бу миннән тормый. Ул шулай һәлак булырга тиеш иде.

Димәк, әсәрнең каһарманы Давыдов үз тормышы белән яши, автор курчакның җебен кая тартса, шунда йөрми Давыдов, чөнки Шолохов курчаклы уйнамый.

Әйтәләр, Лев Толстой белән дә шундый ук хәл булган, диләр. Яңа әсәр башлар алдыннан озын-озак уйлап йөргәннән соң, Толстой булачак әсәренең булачак каһарманнарының тавышларын ишетә башлый, кыяфәтләрен күрә һәм Толстой аларның артыннан яза барган, шулай язылган бөек романнар. Толстой үзен персонажлар арасында яшәгән кебек хис иткән.

Роман азагында Зөләйха чыннан да уяна, күзен ача, Зөләйханың күзенә ни күренсә, китапны укучы да шул вакыйганы күрә. Ә Зөләйха ачык күзе белән үзенең улы, Мортаза Вәлиевнең улы атасын атып үтергән кеше тәрбиясендә үскән, ана Юзуфның урыслашканын күрә. Зөләйханы шатлык урап ала, ул бәхетле.

Кол Галинең (1212) «Йосыф белән Зөләйха» әсәре 800 ел буена татар халкын гүзәллекне аңларга, миһербан тәрбияләргә, гадел булырга, бөек мәхәббәткә тугры калырга өйрәтте. Яхинаның романында да Юзуф белән Зулейха исемнәре бар. Ләкин алар татар милләтеннән тамырлары белән аерылган, алар татар йолаларын, гадәтләрен дәвам итүче түгел.

Роман тәмам. Без Зөләйха күзләре белән Мортаза Вәлиевнең шәҗәрәсе өзелгәнен күрдек.

Интернетта Яхинаны классик язучылар рәтенә кертә яздылар. Романның тел төбендә татар халкының бетәргә дучар булганлыгы турында киная бар. Мин бу киная белән килешер дә идем, татар әдәбияты классигы Гаяз Исхакый 1904 елда әсәрендә («Ике йөз елдан соң инкыйраз») татар халкының бетәренә 200 ел гына калды дип яза. Әүлия сүзләренә күрә, татарларның юкка чыгарына тагын 111 ел калып бара. Әмма Исхакый татарларга кисәтү буларак язган бу әсәрен. Татар халкының милли сәламәтлеге турында кайгырта әдип. Ачыктан-ачык һәм яшертен ассимиляция турында кисәтә язучы. Чынлыкта Исхакый татарларга котылу юлын күрсәтә. Ә Яхина гамьсез рәвештә татарларның урыслар тарафыннан йотылганын раслый. Хәтта ул бу сөрешне хуплый да кебек. Яхина татар халкының йолаларын, гадәтләрен, тарихын белеп бетерми, автор белмәсә, Зөләйха белергә тиеш иде, юкса, аларның гамәлләрен ничек аңларга: Зөләйха ире Мортаза белән зиратка барып, уртак кызлары Шәмсиянең каберен казып, аның табутын ачып, потлап-потлап икмәк тутыралар. Матур күренеш түгел. Әйттем исә кайттым, мөселман-татарлар мәетне табутка салып җирләмиләр, ә бәлки аерым казылган ләхеткә (кечкенә мавзолейга) салып, имән такталар белән каплап куялар. Кайбер очракларда татарлар, изге китаплар кяферләр кулына төшмәсен дип, каберне ачмыйча гына кабер туфрагына качырып куя торган булганнар. Гомумән, революциягә чаклы, революциядән соң да мөселман хатыннарына зиратка керү тыелган була. Саба төбәгендә, Яхина туып үскән якта, мәетне табут белән җирләү гадәте бармы әллә? Юктыр, булмас! Зөләйханың балалары бер-бер артлы сабый чакта ук үлә барган. Димәк, сабый гәүдәләрен кечкенә табутчыкларга салып гүргә иңдергәннәр. Бу табутчыкларга потлап-потлап орлыкны ничек сыйдыра алганнардыр? Автор язуынча, Зөләйха белән Мортаза ике көрәкне лачинкә итеп, шул лачинкәгә салынган чәчүлек орлыкны көчкә-көчкә күтәреп, кабер якасына илтәләр. Кабердәге сөякләр янына салгач, бодай-арышка мәет исе сеңмәсме, язын каберне яңадан ачып орлыкны алгач, ни булыр?

Кабер казыганда да, табутны каерып ачканда да, ата-ананың рухи халәте автор тарафыннан тасвирланмый. Алар үз баласының сөякләренә ничек бакты икән! Мондый халәттә некрофиллар гына тыныч кала алыр иде. Аннан соң, кышкы туңда каткан каберне ике агач көрәк (хәтта тимер көрәк) белән ачу — каторга хезмәте, күп сәгатьләргә сузылган хезмәт, чынлыкта башкарыла алмый торган хезмәт.

Зөләйха йөкле килеш толып киеп йөри. Толып — ул бик авыр йөк. Хәтта ирләр дә толып кигәч, җиңел генә йөри алмый, ә Зөләйха этап буенча сөрелгәндә, тун яки кыска тун киеп йөри ала, ләкин толып түгел. Толып алты-сигез сарык (бүре яки төлке) тиресеннән тегелә торган иде. Күтәреп йөреп кара син шул авыр тунны йөкле килеш.

Китапның азагында аңлатма сүзлек бирелгән. Сүзлек өйрәнчек каләме белән язылган. Мәсәлән, «кота» сүзен хәтта татар кешесе дә аңламый. Нәрсә ул «кота»? Күрәсең, сүз «къата», «киез къата», ягъни кыска итек турындадыр. «Мокрая курица» «җебегән тавык» дип түгел, «шәбәргән тавык» буларак тәрҗемә ителә (7 б.). «Конская колбаса» «казылык» дип түгел, «казы» дип атала.

Зөләйха Гүзәл Яхина уйлап чыгарган гыйбарәләр белән сөйләшә. «Басу капка

иясе» (18 б.), «зират иясе» (32 б.), авторның күзаллавына күрә, шүрәле зиратта яши (гәрчә, шүрәле урманда яши, ул бит урман сарыгы), Зөләйха каенанасының җилкәсенә «яга» сала (14 б.). Нәрсә ул яга? Бер генә сүзлектә дә «яга» сүзе юк. Бәлки ул җирле сөйләм телендә бардыр? Ләкин «Татар теленең диалектологик сүзлеге»ндә дә «яга» сүзе табылмады. Бәлки автор татар телендәге «утыртма якалы тун» турында язадыр, бәс, автор ул сүзгә җентекле аңлатма бирергә тиеш иде.

Романда гаиләнең мунчада юынуы турында язылган. Татарларда мунча ул — культ. «Бәби мунчасы», «кияү мунчасы», «кара мунча», «ак мунча», «болгар мунчасы»... Татар мунчасы турында бик кызыклы, матур риваятьләр бар. Татарларда мунча ничек барлыкка килгән? Мунча ничек төзелә, мунча ничек ягыла, мунчага ничек баралар, мунчада ничек юыналар, мунча яккан кешегә кунаклар нинди бүләкләр бирә? Бу йола романнар язарлык, кинолар төшерерлек, чөнки татарлардагы мунча йоласы бер халыкта да юк. Мунча турында сүз чыккач, автор бу риваятьләрне файдаланырга, башка халыкларга җиткезергә тиеш иде.

Бер каһарман романның 106 битендә Денисов булып килеп керә дә 146 биттә Давыдовка әверелә. Денис Давыдов барлыкка килә. Денис Давыдов — ул 1812 елны рус-француз сугышы каһарманы.

Тәҗрибәле красноармеец, гыпыучы Игнатовка кулга алынган кулакларны түкмичәчми ерак-еракларга алып барырга әмер бирелә. Кулга алынганнарны баржага тутыралар, давылда баржа бата башлый. Игнатов, тәҗрибәле сугышчы–командир ачкычны табалмыйча, үзе дә суга сикереп котылып кала, баржа төрмәсенә ябылган каторжниклар баржа белән бергә батып үлә. Әгәр дә Яхина боевиклар караган булса, күрер иде, анда гамәл кылучы каһарманнар йозакларны пистолет, револьвердан атып ваталар да тоткыннарны иреккә чыгаралар. Игнатовның янбашында патроннар белән тулы револьверы була. Нишләп ул револьверыннан атып, тоткыннарны азат итми? Юкса, һәр югалган әсир өчен Игнатов башы белән җавап бирәчәк. Бәлки Игнатов «контра кулакларның» котылуын теләмәгәндер?

Берлинга җитеп, орденнар тагып, исән кайткан кырым-татар язучысы Шамил Әлветдиновның хатирәсе:

– Кырым татарларын Кырымнан куганда, солдатлар бер татар авылын онытып калдыралар. Кырым татарлары белән шыплап тутырылган поездлар инде күптән Себергә киткән. Бу ялгышны Кремль ишеткәнче дип, солдатлар бала-чаганы, картларны, сугыштан яраланып кайткан солдатларны баржага төйиләр дә ачык диңгезгә алып чыгалар. Баржаның төбен тишәләр, аннан соң баржага бензин сибеп, ут төртәләр, солдатлар үзләре шлюпкаларга төялеп, котылып калалар, чыдый алмыйча, баржадан суга сикергән татарларны мылтыктан атып үтерә баралар.

Нинди «миһербанлы» коммунистлар!

Бу ике баржадагы коточкыч фаҗига өчен беркем дә җавап тотмады. «Титаник» фаҗигасенә караганда да бу ике баржадагы коточкыч рәхимсезлек гасырлар буена да онытылырлык түгел.

Романның теле турында сүз. Кемдер интернетта Яхинаны, татар язучысы буларак, классик язучылар рәтенә кертә язды. Әлбәттә, тел — язучының кайсы милләткә мөнәсәбәтле икәнен билгели торган фактор. Автор рус телендә яза икән, ул урыс язучысы дигән сүз. Әмма бу кагыйдәдән искәрмә бар: Чыңгыз Айтматов, Фазыл Искәндәр, Рытхэу, Михаил Львов (Рәфкат Маликов), Рөстәм Валиев (Тукай турынла һәйбәт роман язган кеше), Олжас Сөләйманов — барысы да русча яза, ләкин алар үз милләте турында, үз халкының фаҗигасе, шатлыгы, тәкъдире, йолалары, тарихы турында яза. Алар иң беренче үз милләтенә хезмәт итә, аннан соң гына — башкаларга.

Роман тирәсендә нигезсез алкыш куптардылар. Кызганыч ки, әдәби зәвык яхшы якка түгел, начар якка үзгәрде, ләкин мин ышанам: әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр авторның беренче романы турында үзләренең абруйлы сүзен әйтер, иншалла. Филология фәннәре кандидаты Миләүшә Хәбетдинова роман турында үзенең тәфсилле тәнкыйтен язып чыкты инде. Сәләтле язучы Гүзәл Яхина иҗади ярдәмгә бик мохтаҗ. Артык мактап, без башлап язучыга ярдәмгә караганда зыянны күбрәк кылган булырбыз.

Зыян түгел, ярдәм итәсе килә!

**Рабит БАТУЛЛА**

# ЕРАК КӨНЧЫГЫШТА ТАТАРЛАР

Мин дә Уссурийскига сәфәремне шул Арча татарлары өендә башладым, милләттәшләрем Әхтәм һәм Роза Хәсбиуллиннарда берничә көн мосафир-кунак булдым. Аларда барысы да үзебезчә-милли — бакчасы, мунчасы, ризыгы, киемнәре, дөнья читендә дә татарча яшәп яталар! Уссурийск шәһәрендәге сәфәрем өчен ирле-хатынлы Хәсбиуллиннарга, аларның ярдәмчеләре Флёра, Зилә, Василә, Зөлфирә сеңелләремә иксез-чиксез рәхмәтләремне әйтәм, Аллаһ алар белән тагы очрашырга насыйп итсен иде! Шәһәрдә татарлар күп түгел, әмма бар, хәтта үзләренең милли оешмалары да бар, аңа инде 20 ел. Биредә татар хәрәкәтенә нигез салучылар — Әхтәм һәм Роза Хәсбиуллиннар. Әхтәм әфәнде — Арча районының Яңа Мәңгәр авылы кешесе, ул башта Казан дәүләт ветеринария институтында укый, аннан Камчаткага китә, Уссурийск авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый, Камчаткада төньяк боланнарын өйрәнү буенча фәнни-тикшеренү институтында эшли, аспирантурада укый, шактый еллар авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтында директор булып эшли. 1990 елда аны Камчаткадан Уссурийскига, Тимирязев авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институтына җитәкчелек эшенә күчерәләр, шуннан бирле ул гаиләсе белән биредә яши. Аның хатыны Роза ханым да — фән кешесе, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты. Роза ханым Хәсбиуллина Приморье краенда, Смолянино бистәсендә татар гаиләсендә туып-үскән, Владивосток дәүләт университетының биология факультетын тәмамлаган, юллама белән Камчаткага эшкә киткән, анда булачак тормыш иптәше Әхтәм әфәнде белән танышкан һәм алар 1968 елда гаилә корып җибәргәннәр. Роза ханым Камчаткада һәм Уссурийскида озак еллар фәнни-тикшеренү институтында эшли, гыйльми секретарь дәрәҗәсенә ирешә, хәзер инде алар икесе дә лаеклы ялда. Хәсбиуллиннар өч ул тәрбияләп үстергәннәр, ялга чыккач, бизнес белән дә шөгыльләнеп алганнар, хәзер исә җигелеп, парлашып милләт эшләрен тарталар. Аларның милли оешма исемлегендә йөздән артык татар тора, оешма төбәктә һәм шәһәрдә узган барлык милли-мәдәни чараларда катнаша, үзләре милли киемнәр тегеп, концертлар бирәләр. Һәр елның 8 мартында алар Приморье краеның бөтен татар-башкорт лидерларын, активистларын Уссурийск шәһәренә, яхшы залларга кунакка чакырып, бер табын артына утырталар, халыкка бәйрәм ясыйлар.

Мин дә Уссурийск шәһәренең хакимият бинасында татарлар белән очрашу уздырдым, аларга бу төбәкнең тарихын сөйләдем, шигырьләремне укыдым, китапларымны бүләк иттем. Икенче көнне бу очрашуны җирле телевидениедән дә күрсәттеләр. Уссурийск шәһәрендә бик зур мәчет төзелеп ята, мин анда да булдым, эшләп килә торган гыйбадәт йортына кереп, намазларымны да укыдым. Мәчет төзелеше бик зур, кызыл кирпечтән берничә биек бина инде төгәлләнеп килә иде. «Инде хакимият берәр сәбәп табып, мәчет төзелешен туктата гына күрмәсен», дип уйлаган идем, нәкъ шулайрак булып чыккан да. Интернетта күренгән хәбәрләр буенча, инде төзелеп беткән мәчетне законсыз дип тапканнар, җимерергә кушканнар... Мин барганда мөселманнар намазны бер йортта укыйлар иде, алар аны сатып алып, гыйбадәтханә итеп тоталар. Югыйсә, Уссурийскида адым саен чиркәү дә монастырь бит, ә мөселманнарга шушы бер мәчетне дә күпсенгәннәр...

Тагы Уссурийскиның элеккеге чорларына әйләнеп кайтыйк әле, чөнки монда патша заманында да мөселман-татарлар яшәгән бит! Менә минем кулымда 1897 елгы беренче халык исәбе алу мәгълүматлары, аннан күренгәнчә, ул вакытта Уссурий округында 109 мөселман яшәгән, 54 кеше үзенең ана телен татар, дип, 22 кеше

---

*Дәвамы. Башы узган санда.*

— мишәр, дип, 22 кеше башкорт, дип яздырган, 2 кыргыз-кайсак та булган. Монда сүз Владивосток турында бармый, ул Көньяк-Уссурий округына кергән, анда тагы 514 мөселман яшәгән, шуларның 497се үзен татар телле, дип яздырган, 82 мишәр, 13 башкорт та бар. *(Первая всеобщая перепись населения Российской империи, 1897 г. Приморская область. — Санкт-Петербург, 1905, стр.61, 64.)*

Бу мөселман-татарларның биредә мәчетләре дә булган булырга тиеш, чөнки хәрби мулла нәкъ менә Уссурийски шәһәрендә яшәгән. Мөселман-татарларның бирегә патша заманында ук, хәрбиләр арасында килүе турында хәбәрләр фәнни чыганакларда еш очрый. Әйтик, Уссурийски янындагы Казачий полкларда дистәләгән мөселманның хезмәт итүе, татар сәүдәгәрләренең биредә эш алып баруы билгеле. Шулай ук күршедәге Кытайдан уйгурлар Уссурийски тирәсенә күчеп, җир эшкәртәләр, сәүдә белән шөгыльләнәләр. *(Мусульманская община Уссурийска. Рукопись.)*

Башка бер чыганакта Ерак Көнчыгышка хәрби мулла билгеләнүе, аның даими рәвештә Уссурийскида яшәве дә язылган. ***«Появление мусульман на территории Приморского края непосредственно связано с истории освоения региона,*** — дип яза тарихчылар. — ***Последователи ислама переселялись на дальневосточные земли в числе других народов Российской империи. Мусульмане были среди военнослужащих российской императорской армии. Для обеспечения их религиозных нужд на Дальний Восток был назначен военный мулла, с постоянным проживанием в г.Никольск-Уссурийский. В первые годы XX века мусульмане составляли около 1 % населения Приморской области, по этническому составу в основном были татарами и башкирами».*** *(Религиозные организации Приморского края. Словарь-справочник. — Владивосток, 2009, стр.137.)*

Димәк, бу төбәк татарсыз тормаган, татарсыз булмаган, алар хәзер дә биредә бар һәм үз милли йөзләрен, үз диннәрен саклап калу өчен тырышалар. Безгә исә дөнья читендә яшәп яткан бу милләттәшләребезгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә кирәк булачак, дөрес тарихын язу да шушы юлда бер адым булып тора...

Биредә дин башында күпчелек таҗиклар һәм үзбәкләр, араларында Казанда, Әлмәттә укыганнары да бар, татарларга яхшы карыйлар, әмма аларның намазга аз йөрүләрен, мәчет төзелешенә аз булышуларын әйтәләр. Югыйсә, шәһәрдә мәчет төзетергә хәленнән килерлек татарлар да бар икән – картон фабрикасының директор урынбасары татар, диделәр, әмма милли оешма белән элемтәдә тормый. Шулай ук ремонт заводы директоры урынбасары да татар кешесе икән. Моннан тыш шәһәр хакименең урынбасары Саченкова Рәхимә Миннәхмәт кызы да татар, ул татар-башкорт оешмасы белән элемтәдә тора, диделәр. Шәһәр уртасында «Риф» дип аталган ике катлы дәвалау-матурлык үзәге тоткан милләттәшләребез Риф һәм Рида Фәткиевлар белән мин үзем дә очраштым, татарларның кайда да юкка чыкмауларын күреп, сөендем... Бу милләттәшләребез Башкортстаннан булып чыктылар, Риф хәрби офицер булган, биредә хезмәт иткән һәм яшәп тә калганнар, ике ир бала үстергәннәр, алар да биредә әти-әниләренә ярдәм итәләр. Дәвалау-матурлык үзәгендә 30 кеше эшли, алар сөлек белән дәвалыйлар, халык медицинасын, бигрәк тә җирле үләннәрне киң файдаланалар, ә Уссури урманнарында аларның нindиләре генә юк!

Мин аралашкан татарлар, нигездә, бирегә узган гасырда төрле сәбәпләр белән килеп урнашкан милләттәшләребез. Менә апалы-сеңелле Вәсилә һәм Зөлфирә Хөснуллиналар. Алар Башкортстанның Иглин районында туып-үскәннәр, бу якларга башта Вәсилә юллама буенча килеп чыга, аннан аның янына сеңлесе Зөлфирә дә килә. Вәсилә украин кешесенә кияүгә чыга, хәзер аның фамилиясе Давиденко, ә Зөлфирә үзенең тормышын рус кешесе белән бәйли, ул Губанова фамилиясе йөртә, икесенең дә балалары бар. Вәсилә дә, Зөлфирә дә белемле, әзерлекле белгечләр, Вәсилә – Госнадзорда, ә Зөлфирә мәгариф системасында эшли, алар – Уссурийскида татар-башкорт милли хәрәкәтенең иң актив әгъзалары. Бөтен милли чаралар, сабантуйлар, фестивальләр апалы-сеңелле Хөснуллиналар катнашында үтә, алар җырлый да, чәкчәк, кыстыбыен, өчпочмагын да әзерли, кунакларны милли киемнәрдә матур итеп каршылый да белә.

Менә тагы катлаулы язмышлы бер милләттәшебез – Флюра Галиуллина-Кан, ул

Казакъстанның Талдыкурган шәһәрендә туып-үскән. Аның әби-бабалары – патша заманында ук бу якларга сөрелгән татарлар була, әмма нәселләрендә төрекләр, нугайлар да бар икән. Бу нәсел Казакъстанның Андреевский районы Лежинск – Берег Татарка авылында яшәгәннәр, моннан тыш тагы бу тирәдә Чубар дип аталган татар авылы да булган. Флюра үзенең татар әби-бабаларын зур хөрмәт белән искә ала: ***«Алар үзләрен аксөякләр дип йөртәләр иде, ягъни, затлы татарлар, – дип сөйләде ул. – Бик чисталар иде, тәрбия бик кырыс булды. Мин зур нәселдә, агалар һәм түтиләр тәрбиясендә үстем, алар һәр ике яктан да дистәләгән иде... Алар бик тырыш иде, бакча да тоттылар, күпләп мал да асрадылар, кырда җир дә эшкәрттеләр, каникуллар вакытында без дә ярдәм итә идек. Минем туганнарым, агай-түтиләрем матур итеп күңел дә ача беләләр иде, гармуннарда уйнап, җырлашып ял иткәннәрен хәтерлим. Шул ук вакытта әби-бабайларым намазны да калдырмадылар, безгә дә ислам буенча төп нигезләрне өйрәттеләр. Алар һәрвакыт сабыр, тыныч һәм ачык күңелле иде, бу сыйфатлар эти-әни аша безгә дә күчкән».***

Әйе, Флюра да бик ачык күңелле, кеше өчен җанын ярып бирергә әзер булып тора. Ул үзе Казакъстанга сөргенгә сөрелгән кореецка кияүгә чыккан, шуңа күрә дә фамилиясе Кан. Аларның өч уллары бар, барысы да университетларда укыйлар, Флюра белән ире дә югары белемле. Ә Уссурийскийга алар 1998 елда, сөргенгә сөрелгән кореялыларны аклагач күчеп кайталар, хәзер дә Казакъстан белән ике арада яшиләр. Флюра татарларның бөтен милли чараларында актив катнаша, кореялыларныкында да аларны татар ризыклары белән сыйлый икән. Аның ире Уссурийск янында корея авылына нигез салган, ә Флюра анда Көньяк Кореядан килгән кунакларны чәкчәк, өчмочмак, азу кебек татар ризыклары белән каршы ала. ***«Кореецларның күп гадәтләре безгә охшаган,*** – ди Флюра. – ***Алар да бик тырыш, чиста, олыларны хөрмәт итәләр... Мин исә һаман үземнең әби-бабаларыма, эти-әниемә рәхмәтләремне әйтәм, алар өчен белгән догаларымны укыйм... Барыбер үземнекеләргә – татарларга тартылам...»***

Менә шундый язмышлар, шундый тормышлар бу җирләрдә... Барысы бергә буталган – урысы-татары-украины-кореецы, һәм бу безнең милләттәшләр язмышы аша да үтә... Бу инде котылгысыз процесс, кеше нәсел калдыру өчен барысына да бара икән... Мин аларны хуплый да алмыйм, гаепләргә дә телем бармый, чөнки үз тормышын, үз язмышын һәркем үзе хәл итә... Әмма бу урыс-кореецлардан туган балаларның татар булулары икеле инде, һәрхәлдә, әниләре милли җанлы татарлар булсалар да... Тик барыбер балаларыңа, нәселеңә **кемлегеңне**, бөек тарихыңны тапшырып китәргә кирәктер дип уйлыйм, **алар рухлары белән татар булырга теш**.

Татарлар белән бергә милли эшләрдә башлап йөргән башкорт кардәшебез Зилә Гафурова турында да яхшы сүзләр язып калдырасым килә. Ул 1954 елда Башкортстанның Мәләвез районы Апас авылында туган, Мәләвездә сөтчелек техникумын тәмамлаган. Яратып йөргән егете Миңнулла бу төбәктә армиядә хезмәт иткән, ул Зиләне дә кайтып алган, яшь гаилә бирегә 1978 елда күчеп килгән. Зилә Уссурийскида гомер буе сөт заводында эшләгән, пенсиядә булса да, һаман шунда эшли, өч балалары югары белем һәм һөнәр алган. Зилә менә ун ел инде шушы татар-башкорт оешмасында иң актив әгъза, ул китапханә оештырган, милли чараларда башкорт киемнәреннән чыгышлар ясый, гаиләсен дә шуңа тарткан. Шулай ук хакимияттә очрашу барышында Ләлә Мәҗитовна Попова исемле өлкәнрәк яшьтәге бер татар апасы да хәтеремдә нык уелып калды. «Мин мулла кызы», – дип ул хәтта безнең белән фотога да төшмәде, ә үзенең сөйләр сүзләре, уртаклашыр хатирәләре күп иде кебек...

Уссурий төбәген иң күп гизүче, өйрәнүче һәм бу хакта фәнни-популяр хезмәтләр язучы кеше – ул географ, этнограф Владимир Клавдиевич Арсеньев (1872-1930). Әлбәттә, ул Уссурийски шәһәрендә дә еш булган, биредә тукталган, берара яшәп тә алган. Шәһәрдә бүген дә Арсеньев яшәгән йорт саклана, анда хәзер аптека, йортның диварына «В ЭТОМ ЗДАНИИ В 1928 ГОДУ РАБОТАЛ НАД КНИГОЙ «СКВОЗЬ ТАЙГУ» ВЛАДИМИР КЛАВДИЕВИЧ АРСЕНЬЕВ» дип язылган. Мин анда да булдым, шулай ук китап кибетендә бу бөек шәхеснең хезмәтләрен дә сатып алдык. Арсеньев хезмәтләрен кулга каләм тотып, махсус өйрәнергә кирәк, чөнки

аларда моннан йөз ел элек бу төбәктә булган җир-су атамалары төгәл күрсәтелгән, алар арасында төрки-татарчалары да шактый.

Әмма узган гасырның 70нче елларында, кытайларның басып алуларыннан һәм бу җирләргә дәгъвасыннан куркып, Приморье төбәгендәге җир-су атамаларының 80-90 процентын, хөкүмәт карары белән, русчага әйләндереп чыкканнар. Шулай итеп, Татан-шан таулары – Пржевальскига, Дәүбик елгасы – Арсеньевкага, Сучан – Партизанскаяга, Суйфун – Раздольнаяга, Бичә – Стеклянухага, Сандуган – Снегуровкага, Таз тавы – Половинкинога, Янтун кыясы – Горелая тавына, Иман елгасы – Большая Уссуркага, Сибича – Голубицага, Туганча – Нижняя Лимонихага, Самур сырты – Стрельниковога, Силан – Сахалинкага, Табынды Верхний Перевалга әйләнә. Бу исемлекне әле озак дәвам итәргә булыр иде, аны «Дерсу Узала» китабына комментарийлар язучы Григорий Левкин төзегән, моның өчен ул Арсеньев булган урыннар буенча айлар-еллар буе эзләнеп йөргән. *(В.К.Арсеньев. Дерсу Узала. По Уссурийскому краю. – Хабаровск, 2011, стр.548-570.)*

Үзенең **«Быт и характер народностей Дальневосточного края» китабында *(В.К.Арсеньев, Е.И.Титов. – Хабаровск-Владивосток: Кн. дело, 1928. – 82 с.)*** Арсеньев җирле халыклар исәбенә төрки-татарларны да кертә. ***«Книга написана в соавторстве с писателем и этнографом Е.И.Титовым, и включает материал по этнографическим группам Дальнего Востока: русские (великороссы, украинцы, белоруссы, молдаване), культурные народы Восточной Азии (китайцы, корейцы, японцы), аборигены (тунгусо-маньчжуры, тюрко-татары и палеазиаты), метисы (камчадалы)»***, – дип язылган китапның аннотациясендә. Бу китапны да галимнәребез яхшылап өйрәнергә тиеш.

Әйткәнемчә, Уссурийски тирәсеннән бик күп борынгы ядкәрләр табылган, алар арасында төрки-татарларныкы да бар. Бу хакта алдагы бүлекләрдә бәян итәрбез.

## Владивосток – диңгезчеләр шәһәре

Картага карасагыз, Владивосток шәһәре ярымутрауга урнашкан, ул бөтен яктан да диярлек сулар белән уратып алынган. Амур һәм Уссури сулык-заливлары арасына урнашкан әлеге шәһәр алар аша бөек Тын океанга тоташа... Бу урынның кытайча һәм японча атамалары да «култык-бухта» дигәнне аңлата. Бирелән Кытае, Кореясы, Япониясе кул сузымында гына, хәтта Америка да Мәскәүгә караганда якынрак. Хәер, әлеге төбәк 1860 елга хәтле Кытай җирләре дип исәпләнә иде бит, ул бары тик шул елда Пекинда төзелгән Россия-Кытай килешүе нәтиҗәсендә генә Россиягә бирелә. Владивостокка хәрби пост буларак 1860 елда нигез салына, 1880 елда аңа шәһәр статусы бирелә.

Ә инде борынгы тарихка килгәндә, биредә дә һаман шул Бохай дәүләте, киданнар һәм чжурчжэннар хакимлеге тасвирлана, татар-монголлар турында басып алучы итеп кенә күрсәтелә. ***«В древности территория современного Владивостока входила в состав государства Бохай (698-926 гг.), начиная с X века она принадлежала киданям, а затем чжурчжэням. В начале XIII века на территории современного Приморья существовало несколько городов чжурчжэньского государства Восточное Ся. Все они были разрушены монголами в результате нападения 1233 года, после чего территория пришла в запустение. Позднее из-за споров между маньчжурами и ханьцами южное Приморье обезлюдело и практически не упоминалось в источниках вплоть до XIX века»,*** – дип язылган бу хакта Википедия сайтында.

Кызганыч, төбәкнең 1234 елдан соңгы зур татар-монгол-кытай-манчжур тарихы бөтенләй өйрәнелмәгән диярлек, биредә рус тарихы 1860 елдан гына башлана. Ерак Көнчыгышка татарлар яңадан руслар белән бер чорда – XIX гасырның икенче яртысында килеп урнаша башлыйлар. Владивостокның үзенә дә нибары 1860 елларда гына нигез салынуын онытмаска кирәк, архивлар да шул чордан гына туплана башлый. Татарлар бирегә төрле юллар белән килгәннәр – ихтыяри-мәҗбүри дә, ягъни үзләре теләп тә, сөргенгә сөрелеп тә, эзәрлекләүләрдән, хөкемнән качып та дөнья читенә киткәннәр. Мин Владивосток шәһәренең Приморье край китапханәсендә соңгы йөз ел эчендә уздырылган халык саны алу нәтиҗәләрен

өйрәндем. Әйтик, 1897 елгы беренче халык саны алу нәтиҗәләре буенча, Приморье өлкәсендә (ул чагында бик зур төбәк шулай дип аталган) 1185 ир-ат мөселман, 85 хатын-кыз мөслимә яшәгән. Бу әле болар барысы да татар дигән сүз түгел, шулай ук хатын-кызлар да хисапка алып бетерелмәгәнгә охшый. Көньяк Уссурий округында бу сан – 510 ир-ат, 4 хатын-кыз, шуларның 148е Владивосток шәһәрендә яшәгән. Аерым саналган Уссурий округында исә 109 мөселман ир-ат яшәгән. Бу халык санын алуда милләтләрнең кайсы телдә сөйләшүе дә исәпкә алынган. Әйтик, Приморье өлкәсендә 1897 елда татар телендә сөйләшүче 979 ир-ат, 55 хатын-кыз теркәлгән, мишәрләр аерым язылган, алардан 23 ир-ат исәпкә алынган. Шул исәптән 495 татар ире, 2 хатын-кыз – Көньяк Уссурий округында, 54 татар Уссурий округында яшәгән. Владивосток шәһәрендә исә ул вакытта 139 татар ире, 2 хатын-кыз яшәгәнлеге теркәлгән, хатын-кызларның күпчелеге хисапка кермәгәнгә охшый. Ул вакытта зур бер өлкәдә нибары йөз меңләп кенә кеше яшәгәнен, Владивостокта урыслар саны ун мең тирәсе генә булганны истә тотсак, татарлар саны алай аз күренми – өлкәдә ике меңгә якын, шәһәрдә – ике йөз тирәсе. 1923 елда өлкәдә татарлар саны инде 6532 кешегә җитә, бу революцияләр нәтиҗәсендә, ачлыктан качып килеп егылган татарлар булырга тиеш.

Владивосток татарчага «Шәрыкка хуҗа бул!» дип тәрҗемә ителсә дә, ул озак еллар хәрбиләр һәм төрмәләр шәһәре булып калган. 1869 елда Сахалин утравы Россия империясенең каторга зонасы, дип игълан ителгәч, анда бөтен тоткыннар Владивосток аша озатыла. Башта бу мескеннәр, аяк-куллары богауланган килеш, бөтен Себер буйлап еллар буе җәяүләп Владивостокка килгәннәр, аннан аларны пароходларга төяп, Сахалинга озатканнар. Совет чорында да Владивосток төрмәләр үзәге булуын дәвам итә, Ерак Көнчыгышка сөрелгән барлык тоткыннар да юлны аның аша үтә.

***«В 1930-1940-х годах Владивосток служил транзитным пунктом на пути доставки заключённых и грузов для Севвостлага советского супертреста «Дальстрой». В городе располагался известный Владивостокский пересыльный лагерь, куда со всей страны свозились заключённые. Здесь из них формировались этапы для дальнейшей отправки в дальневосточные ИТЛ. Время содержания заключённого во Владивостокском пересыльном пункте, как правило, длилось от нескольких недель до нескольких месяцев. Здесь умер поэт Осип Мандельштам, через этот лагерь прошёл будущий актёр Георгий Жжёнов, писатели Варлам Шаламов и Евгения Гинзбург, «космический» академик Сергей Королёв и ещё сотни тысяч других политзаключённых. Этот лагерь располагался в районе Моргородка»,*** – дип яза бу хакта интернет сайтлары.

Галимнәрнең әйтүе буенча, Ерак Көнчыгышка диңгез юлы белән генә дә 1 миллионнан артык кеше сөргенгә сөрелгән, төрмәләргә озатылган, алар арасында 7 меңнән артык татар да булган. Владивостокның үзендә дә төрмәләр эшләп торган, «Владлаг» дип аталганында алтмыш меңгә якын тоткын шәһәр сала, юллар төзи, урман кисә, балык тота, алар арасында татарлар да шактый була. Сугыштан соң исә бирегә немецларда әсирлектә булган тоткыннарны, власовчыларны, легионерларны да китерә башлыйлар, алар арасында 427 татар да була. *(Е.Н.Чернолуцкая. Принудительные миграции на Советском Дальнем Востоке в 1920-1950-е гг. – Владивосток, 2011, стр.373.)*

Владивосток янәшәсендәге Артём шәһәрендә генә дә ГУЛАГның 7 төрмәлагере булган, Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң бирегә хәтта «Идел-Урал» легионы татарларын да китергәннәр, халык аларны «Америка татарлары» дип атап йөрткән, чөнки аларны СССРга Америка тапшырган. Сөрген сроклары беткәч тә, бу татарларның бер өлеше биредә яшәп калган, шахтада эшләгән, татар кызларына өйләнеп, тормыш корып җибәргәннәр, аларның балалары бүген дә биредә яши. Шунысын да әйтергә кирәк: 1991 елга кадәр Владивосток ябык шәһәр була, анда чит ил кешеләрен кертмиләр.

Ә бүгенге Владивосток – ул инде бөтенләй башка шәһәр, гөрләп торган диңгезчеләр, интеллектуаллар каласы! Мин биредә дә милләттәшләрем белән очраштым, музейларда, китапханәләрдә, тарихи урыннарда булдым, җирле тарихчылар белән аралаштым, хәтта катер белән диңгезгә дә чыгып кердем! Владивосток миңа

ошады, ул заманча шәһәр, якындагы Азия илләренең дә йогынтысы сизелә, ерактагы Европаның да мәдәнияте, мәгърифәте белән бәйләнешләре күренә. Биредә музейлар күп, югары уку йортлары шактый, бик күп Азия һәм Европа илләренең консуллыклары эшләп тора. Инде күрше Корея, Кытай, Япония кебек илләр белән элемтәләр турында әйтеп тә тормыйм, алар монда үз өйләрендә кебек йөриләр, төбәк халкы да әллә кайдагы Мәскәүгә караганда, алга киткән азиат күршеләре белән эш итүне артыграк күрә сыман.

Бүгенге көндә Владивостокта 600 мең кеше яши, шуның 5-6 меңе – татарлар. Әлбәттә, татарлар күбрәк булырга тиеш, әмма катнаш гаиләләр йөз процентка якын, ә алар барысы да рус дип язылган. Владивосток, нигездә, диңгезчеләр шәһәре, ул Ерак Көнчыгыштагы иң зур порт-кала санала, безнең милләттәшләрнең дә күпчелеге диңгез эшендә. Шәһәрдә шулай ук балык промышленносте, машина төзелеше, җиңел промышленность та бөтен көченә эшли. Шәһәр сопкалар арасында таралып ятканлыктан, транспортка йөрергә шактый кыен, бөкеләр зур, юл һәлакәтләре күп. Җәен яңгырлар күп һәм көчле, тоташ муссон яңгырлары булып тора, шуңа күрә су басулар да булгалый. Шуларның барысына карамастан, халык начар яшәми, ераклык, дөньядан аерылу сизелми, мескенлек күренми, диңгезнең, урман-тауларның кадерен белеп һәм рәхәтен күреп яшиләр кебек тоелды...

Приморье өлкәсенең төбәк тарихын өйрәнү музеенда шактый кызыклы табылдыклар белән очрашырга туры килде. Биредәге күп кенә борынгы экспонатлар Уссурийскидан китертелгән булып чыкты, аларны 1889 елда тарихчы Лопаткин тапкан, галим Буссе музейга тапшырган. Менә XII-XIII гасыр ядкәрләре дип саналган таш сыннар, аждаһа, юлбарыслар, борынгы балбаллар. Боларның барысы да халыкка Бохай дәүләте, чжурчжэннар мирасы буларак тәкъдим ителә, төрки-татарлар турында сүз бөтенләй юк. Алай да мин бу борынгы ядкәрләрнең барысы да төрки-татарлар мирасына хас икәнлеген әйттем: канатлы аждаһа бүген дә Казан шәһәренең символы булып тора, барс – Татарстан гербында рәсми тамга, ә таш балбаллар бөтен төрки далалар буйлап сибелгән... Әмма музей хезмәткәрләре тарихны үзләре шәрехләми, аларга галимнәр ничек язып бирсә, шулай күрсәтәләр, шулай сөйлиләр. Шуңа күрә алдагы очрашуыбызны төбәкнең төп тарихчылары белән уздырырга, бу мәсьәләләрне күтәрергә булдык.

Әйе, минем биредә иң мөһим эшем Владивосток шәһәрендәге Тарих, археология һәм этнография институтында тарихчылар белән махсус очрашу булды. Бу очрашуда Приморье краеның «Туган ил» татар һәм башкорт оешмасы җитәкчесе Рамил әфәнде Килмөхәммәтов һәм Владивосток шәһәре татар-башкорт оешмасы рәисе Әлфия ханым Сафуганова да катнашты. Җирле галимнәр, фән докторлары – Вадим Тураев, Людмила Гәлләмова, Юлия Аргудяева, Александр Ивлиев, Галина Ермак һәм башкалар Приморье крае тарихына җентекле анализ ясадылар, татарлар белән бәйле тарихи фактлар турында да әйттеләр. Әйе, бар биредә татар эзләре, бар, аны беркая куеп булмый, әмма төбәктәге татар тарихын беркем дә махсус өйрәнмәгән, эзләнмәгән, хезмәтләр язмаган. Бер өлкән галимнең әйтүенчә, «татарлар темасы алар өчен перспективасыз» икән, ягъни төбәк тарихын кытайлар белән бәйләп өйрәнү алар өчен күпкә файдалырак. Әмма мин әлеге тарихчыларның үзләре өчен яңарак юнәлештә эшләп карыйсы килүләрен дә тойдым, бу – борынгы төрки-татар темасы, төрки-татар тарихы. Әмма аларның Казан белән элемтәләре бөтенләй юк икән, мин дә татар эзләрен барлап Татарстаннан бу якларга килгән беренче язучы-тарихчы булып чыктым... Приморье крае тарихчыларын Казанда үткән фәнни-гамәли конференцияләргә чакырдым, борынгы тарихка яңа күз – төрки күзлек аша да карау өчен бу бик мөһим, чөнки төрки-татар факторы булмаса, бөек тарихка чин-мачин хуҗа булачак, ул процесс инде бара...

Владивостоктагы рус-украин тарихчылары белән әңгәмәбез ихлас һәм ачыктан-ачык барды. Күренеп тора, алар татарларга хөрмәт белән, үз тиңнәре итеп карыйлар. Шулай ук аларны соңгы елларда Приморье краеннан бик күп урысларның һәм татарларның туган якларына күчеп кайтып китүләре, алар урынын кытай-вьетнам-кореялы-үзбәк-таҗикларның алуы да борчый икән. «Этник кыр үзгәрә, алар белән бөтенләй башка мәдәният килә», – диделәр алар, кайбер күрше халыкларның

борынгы тарихка дәгъва кылуларын да сиздерделәр. Әйе, чин-мачиннар башта тарихка дәгъва белдерәләр, аннан иленә-җиренә дә хуҗа булалар. Төрки-татарларга бирмәс өчен, борынгы тарихны боза-боза, алар белән бәйләп язуның да ачы нәтиҗәсе инде бу...

Тагы борынгы тарихка кайттык. Әңгәмәбез барышында җирле галимнәрнең әйтүенчә, биредә *төрки телле кешеләр яшәгән*, алар бохайлар кулы астында булганнар. Төрки каганатларның мохэ кабиләләре белән бәйләнешләре булган, бу турыда Билге каганның хәбәре бар, алар VII гасырда мохэләр өстенә яу белән барганнар. VIII гасырда мохэлар бик көчәеп китә һәм төркиләрдән дә, кытайлардан да баш тарта. Галимнәрнең әйтүенчә, 1215 елда инде төбәккә татар-монголлар үтеп керә, алар илне тәртипкә салу өчен күп эш башкара: юллар салдыра, Амур тамагына хәтле ям (ямщик) элемтәләре булдыра, шәһәрләр төзи. Татар-монголлардан калган XIII-XIV гасыр шәһәр хәрабәләрен бүген дә Амур тамагында, Партизанск (Сучан) шәһәре тирәләрендә очратырга мөмкин икән, әмма, галимнәрнең әйтүенчә, аларны махсус өйрәнүчеләр юк. Шулай, безнең мирас, дип әйтергә Казан ерак, мондагыларга ул кирәкми, ә кытай килгәч, инде соң булачак...

Сөйләшүебез борынгы тарихтан бүгенге көннәргә, татарларның бүгенге хәленә күчте. Галимнәрнең әйтүенчә, узган гасырның 60-70нче елларында бирегә миграция белән күп татарлар килгән. Аларның бик мобильный, бердәм икәнлекләрен дә әйттеләр, Приморьеда татарлар күбрәк шәһәрләрдә яши икән, авылларда да бар, диделәр. «Татарлар Россия культурасына бик тирән керде, аларда этник озабоченность юк, татарлык гаилә кысаларында гына саклана», — диде җирле галимнәр, ягъни татарлар үз милләтем, дип бик борчылмыйлар икән. «Төбәктәге татарларның абсолют күпчелеге руслар белән катнаш никахларда, төп җирле халыклар белән дә кушылган гаиләләр бар, — дип дәвам итте галимнәр. — Авылларда яшәүче татарлар анда нинди милләт күпчелекне тәшкил итсә, шулар булып языла». Алар шулай ук татар тарихын, татар проблемасын өйрәнүне үзләре өчен перспективасыз, дип әйттеләр, моның өчен Татарстан бар, диделәр. Алай да, бер аспирантның төбәктә татар темасын өйрәнә башлавын хәбәр иттеләр.

Бу — алар күзлегеннән караганда шулай — татар темасы перспективасыз, үзенең язмышы өметсез... Әмма мин алай ук дип әйтмәс идем, Ерак Көнчыгышта, шул исәптән Приморье краенда да татар тарихы бар, анда татарлар бүген дә яшәп ята, алар берләшә, милли оешмалар төзи, мәчетләр салалар (болар хакында алга таба язармын әле). Мин галимнәргә дә үз теләкләремне белдердем, төбәк тарихын төрки-татар күзлегеннән өйрәнә башларга кирәклеген әйттем. Бу очрашуны оештырган татар милли хәрәкәт лидерлары Рамил Килмөхәммәтов һәм Әлфия Сафуганова да алга таба аралашып яшәргә, уртак проектлар өстендә эшләргә кирәклеген әйттеләр.

Соңыннан безгә Тарих институтының искиткеч бай музеен күрсәттеләр, ул, нигездә, төбәкнең иң борынгы чорын чагылдырган археологик табылдыклардан тора. Монда да төрки-татар эзләре бар, әмма аларга «татар» дип язылмаган... Ә менә бронза көзгеләр күргәзмәсе яныннан мин тыныч кына үтеп китә алмадым, чөнки алар рәвешләре белән дә, артларына төшерелгән бизәкләре белән дә безнең Болгардан табылган көзгеләрне хәтерләтә иде... Ә инде свастика тамгалары белән уратып алынган бронза көзге һун бабаларыбыздан калган рун язулы истәлек булып тора, кояш хәрәкәтен аңлата. Мин моны музей хезмәткәренә дә әйттем, ул моңа бик гаҗәпләнде, бу тамгага беренче тапкыр игътибар итүен һәм мондый версияне беренче тапкыр ишетүен әйтте.

Алга таба сәяхәтебез крайның үзәк китапханәсенә. Ул Максим Горький исемен йөртә һәм төбәк тарихы буенча материалга шактый бай булып чыкты. Алдан ук сөйләшеп куйганга, безгә Приморье краенда татар тарихы һәм ислам дине белән бәйле хезмәтләрне китереп кенә тордылар, эшләп, укып, күчереп кенә өлгер! Дәүләт китапханәсенең төбәк тарихын өйрәнү бүлеге мөдире Иванцева Нина Семёновна татар темасын да яхшы белә булып чыкты, кайбер хезмәтләрне ул үзе дә тәкъдим итте. Без биредә үзебез өчен шактый күп яңа нәрсәләр белдек, бигрәк тә татарларның соңгы йөз елдагы тарихлары буенча материал туплый алдык. Биредә

1897, 1926, 1939 елгы халык саны алу нәтиҗәләре дә саклана, без аларны да яхшылап өйрәндек, әмма 1926 елгы хезмәтләрдә милләтләр күрсәтелмәгән булып чыкты. Моннан тыш «Религиозные организации Приморского края» белешмәсе, «Восьмая Дальневосточная конференция молодых историков» җыентыгы *(Владивосток, 2004)*, М.Б.Сердюк һәм С.М.Дударенокның «Религиозная жизнь Советского Дальнего Востока (1941-1954) китабы *(Владивосток, 2009)*, шул ук М.Б.Сердюкның «История религии на Дальнем Востоке в исследованиях и библиографиях» монографиясе (Владивосток, 2006), Е.Л.Мотричның «Население Дальнего Востока России» *(Владивосток-Хабаровск, 2006)*, «Населения и жилые места Приморского района. Крестьяне. Инородцы. Жёлтые. Перепись населения 1-20 июня 1915 года» *(Владивосток, 1915)* белешмәсе һәм башка фәнни хезмәтләр миңа бу тарихи очеркны язарга нык ярдәм итте. Ә төбәкнең борынгы тарихы буенча хезмәтләрне мин Россия Фәннәр академиясенең Владивостоктагы Ерак Көнчыгыш филиалыннан һәм башка китапханә, кибетләрдән таптым.

Бу хезмәтләрдән күренгәнчә, Ерак Көнчыгышка, шул исәптән Приморье төбәгенә татарлар урыслар белән бергә XIX гасырның икенче яртысында килә башлаган. Алар хәрбиләр арасында да булган, сәүдә белән дә бу якларга килеп чыкканнар, биредә һөнәрче татарлар да яшәгән. ***«Первые официальные данные о татарах на Дальнем Востоке относятся к XIX – началу XX в., когда в гарнизон Владивостока прибыл Уфимский пехотный полк, в котором служили преимущественно татары и башкиры, – дип яза тарихчылар. – В состав полка входил военный мулла Багаутдинов, впоследствии он стал во главе Владивостокского татарского мусульманского общества, которое размещалось по адресу: 1-я Морская, 17»*** *(Е.А.Чечель. Татары в Приморском крае: к постановке проблемы // Восьмая Дальневосточная конференция молодых историков. – Владивосток, 2004, стр.280.).*

XX гасыр башында Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә, шул исәптән Владивостокта да мәчетләр була, бу турыда төбәк тарихчылары яза: ***«...в первые годы двадцатого столетия в Хабаровске, Благовещенске и Владивостоке на законных основаниях действовали религиозные общины и были открыты мечети. В 1930-е годы все имевшие в Дальновосточном крае мусульманские общины и культовые здания, как и организации, и храмы других конфессий, были закрыты»*** *(М.Б.Сердюк, С.М.Дударенок. Религиозная жизнь Советского Дальнего Востока (1941-1954). – Владивосток, 2009, стр.157.).*

Шунысын да онытмаска кирәк: гражданнар сугышы елларында Ерак Көнчыгыш, шул исәптән Приморье төбәге дә Антанта илләре кулында була, 1918 елда Владивостокта Америка гаскәрләре тора, ә диңгез портын Япония хәрби корабльләре саклый. Әйе, бу төбәк халкы большевизмны кабул итми һәм аңа каршы озак көрәшә, хәтта үзенең Дальневосточная Республика дип аталган мөстәкыйль дәүләтен дә төзеп карый. Бу чорда Владивосток шәһәрендә татарларның үз оешмалары һәм мөселман мәктәпләре дә булганлыгы билгеле, шулай ук татар яшьләренең аерым оешмалары да була. Әмма әлеге милли-дини мәктәпләр һәм оешмалар төбәктә совет власте урнашу белән, ягъни, 1922 елда ябыла.

***«С 1919 г. во Владивостоке существовала татарская мусульманская школа, – дип яза тарихчылар. – Первые два года она содержалась на средства татарского общества, с 1921 г. – на средства города и получила название 14-го городского начального мусульманского училища. В первый год в школе было 12 учащихся, во второй – 22, в третий – 31, в 1921-1922 гг. она имела уже 49 учеников. В школе обучались и мальчики, и девочки. Программа обучения была рассчитана на четыре года. Школа прекратила своё существование предположительно после установления советской власти. В феврале 1920 г. во Владивостоке был зарегистрирован Устав кружка Владивостокской татарской молодежи»*** *(Е.А.Чечель. Татары в Приморском крае..., стр.280-281.).*

Әйткәнебезчә, төбәктә советлар хакимияте урнашу белән, боларның барысы да юк ителә, ә милли хәрәкәт җитәкчеләрен, активистларны, дин әһелләрен төрмәләр һәм сөрген көтә... Галимнәр утызынчы елларда Приморье төбәгендә татарларның артуын язалар, 1939 елгы халык саны алу нәтиҗәләре буенча, аларның саны хәтта

11 меңгә җитә. Бу — сөргеннәргә сөрелгән, ихтыяри-мәҗбүри бу якларга күчерелгән һәм шунда урнашып калган татарларның да язмышы инде... Инде 60-70 нче елларда Ерак Көнчыгышка татарлар эш эзләп тә, юлламалар буенча да шактый киләләр һәм шушында калалар, әйтик, 1989 елда аларның саны инде 20 меңгә җитә. Хәзер исә шуның яртысы гына калган, кайберәүләр кире туган якларына кайтып киткән, кайберәүләр үзләрен урыс дип яздырган, кайберәүләр инде бакыйлыкка күчкән... Әмма Приморье краенда татарлар бүген дә бар, милли һәм дини тормыш дәвам итә...

Әлбәттә, Владивосток шәһәре — милли тормышның үзәге. Биредә 1992 елда ук «Туган тел» дип аталган татар мәдәният үзәге оеша, аның беренче җитәкчесе Җәүдәт Гыйззәтуллин була. Шул елны ук Вольно-Надежденски бистәсендә Сабан туе уздырыла башлый, бу күркәм традиция менә инде 20 ел буе дәвам итә, 2012 елда федераль Сабантуй да Владивостокта үтте. Татар-башкорт милли оешмасында төрле елларда Җәүдәт Гыйззәтуллин, Ринат Якуб, Любовь Сермягина, Марс Миннәхмәтов, Урал Сафуганов, Риф Харисов җитәкчелек итә, 2009 елның апрелендә эшмәкәр Рамил Килмөхәммәтов бу җаваплы урынга сайлап куела.

Владивосток — интеллектуаллар шәһәре, биредә татарның каймагы җыйналган, дисәң дә ярый. Татарлар арасыннан ректор һәм проректорлар да, капитаннар һәм штурманнар да, зур җитәкчеләр һәм эшмәкәрләр дә бар, миңа аларның кайберләре белән очрашырга туры килде. Әйтик, Ерак Көнчыгыш федераль университеты проректоры (элек ректор булган) милләттәшебез Әнвир Әмрулла улы Фәткуллин, без Әлфия Сафуганова белән аның эш урынына бардык. Ул 1955 елда Магадан өлкәсендә туган, әтисе тау инженеры булган, аннан Әнвир әтисенең туган якларына — Амур өлкәсенең Зея шәһәренә килгән.

***«Анда бик зур татар диаспорасы бар иде,*** *— дип искә ала Әнвир әфәнде.* ***— Урта мәктәпне Зеядә тәмамладым. Аннан Владивостокта политехник институтны, Мәскәүдә аспирантура тәмамладым, 1994 елда докторлык диссертациясе якладым. Хәзер үземнең дә күп кенә шәкертләрем галим булды. Әти-әнием татар, әнием Казан ягыннан, Мөхәммәтшина Равия Сабир кызы, аның Казанга кайтканы бар, минем — юк. Кызганычка каршы, татарча белмим, инглиз, алман телләрендә яхшы аралашам. Татарлар үзләренең тырышлыклары, гаделлекләре сәбәпле, биредә яхшы исәптә йөри. Шуңа күрә мин, узган тарихка караганда, бүгенгене өйрәнергә тәкъдим итәр идем, әйтик, бүгенге икътисади һәм фәнни мохитнең формалашуында татарларның тоткан урыны һәм роле...»***

Әйе, бу юнәлештә дә, һичшиксез, эш алып барырга кирәк, чөнки Приморье краенда, шул исәптән Владивостокта да татар фамилияле яки татарлар белән катнаш шактый гына галимнәр, фән эшлекләре булуын әйттеләр. Аларны милли оешмаларның эшенә тартырга, акыл көчләрен, интеллектларын татар файдасына да эшләтергә кирәк, моннан без отачакбыз гына. Бигрәк тә тарих өлкәсендә зур бушлык сизелә, биредә борынгы тарих та, йөз еллык тарих та, бүгенге тормыш та татар күзлегеннән өйрәнелмәгән, милли кадрлар әзерләнмәгән. Русча язсалар да, татар турында, татар файдасына язсыннар иде!

Владивосток татарлары белән танышуыбызны дәвам итәбез. Менә ирле-хатынлы Сафугановлар, алар төбәктәге бөтен татар-башкорт хәрәкәтенең үзәгендә тора, Владивостокта гына түгел, бөтен Приморье краенда милли тормышны җитәкләп бара. Алар икесе дә Башкортстанда туып-үскән, Урал — Стәрлетамак районының Кырмыскалы авылында, Әлфия Гафури районының Яңа Карамалы авылында дөньяга килгән. Уралның әтисе — башкорт, әнисе — татар, шуңа күрә ул ике якка да тигез карый, Татарстанга да, Башкортстанга да милли җыеннарга кайтып йөри. Ә Ерак Көнчыгышка килеп эләккәнче, Урал 1983 елда Бакуда хәрби уку йортын тәмамлый, аннан соң — Камчатка, лейтенант-инженер, ВВС штурманы буларак, ул 8 ел су асты көймәсендә хезмәт итә, аннан тагы уку — Тын океан югары хәрби диңгез училищесы, академия... Ул хәзер икенче ранг капитаны, отставкада, әмма диңгезгә һәм милләткә хезмәтен дәвам итә. Урал Сафуганов — «Росморпорт»ның Владивосток филиалы директоры урынбасары, «Туган ил» татар һәм башкорт оешмасы рәисе урынбасары, кояш чыгышы төбәгендә беренче татар театры директоры. Әйе, 2009

елда Владивосток шәһәрендә милләттәшләребез татар театры оештырып җибәрә, Гаяз Исхакыйның «Жан Баевич» әсәрен сәхнәгә куеп, аны Владивосток, Артём, Уссурийск, Находка шәһәрләрендә күрсәтә. Бүгенге көндә әлеге үзешчән театрга татар оешмасының беренче җитәкчесе Җәүдәт Гыйззәтуллин исеме бирелгән. Шунысын да әйтергә кирәк: бу халык театры – Ерак Көнчыгышта гына түгел, бөтен Себерендә бердәнбер татар театры.

Ә Әлфия Сафуганова – Уралның тормышта да, милли эшләрдә дә уң кулы, төп таянычы. Ул – ире белән бергә 1992 елдан бирле Приморье краенда татар-башкорт хәрәкәтендә иң актив катнашучы, күзгә күренмәгән бөтен эшләрне алып баручы, оешманың архивын туплаучы, Владивосток татар-башкорт оешмасы җитәкчесе, югары белемле педагог-психолог. Сафугановлар гаиләсендә ике кыз бала үскән, хәзер алар үзләре әти-әниләренә бөтен милли эшләрдә ярдәм итә. «Туган ил» оешмасы төбәктә оештырылган бөтен милли-мәдәни чараларда катнашып бара, биредә татарның йөзен алар билгели, әйтик, хакимият уздырган шәһәр көннәрендә, төрле фестивальләрдә, музейларда уздырылган күргәзмәләрдә шушы оешма вәкилләре чыгыш ясый. «Туган ил» оешмасы татарын, башкортын, мөселманнарны, яшен-картын берләштереп, бергә тупларга тырыша. Әмма биредә дә милли һәм дини хәрәкәт берничәгә бүленгән, теркәлгән һәм теркәлмәгән оешмалар да шактый, әмма Казан менә шушы Сафугановлар, Килмөхәммәтовлар белән эш йөртә. Монда дин, мәчет мәсьәләсендә дә бүлгәләнүләр сизелде. Чыннан да, мәчет мәсьәләсе монда бераз катлаулырак тора. Хакимият мәчет салырга дип дүрт тапкыр җир бирә, дүрт тапкыр кире ала, җитәкчеләр алышынган саен, карарлар да алышына... Хәзер уңай якка бераз хәрәкәт китте инде, үзара тату булсак, Владивостокта мәчет салыныр, иншаллаһ!

Татар хәрәкәтенә төрлечә ярдәм итеп торган тагы берничә милләттәшебез турында язып үтәсем килә. Менә якташыбыз, Әлмәттә туып-үскән Газинур Мингали улы Фәрәхиев. Ул – отставкадагы икенче ранг капитаны, корабль командиры, ирекле көрәш буенча СССРның спорт мастеры, менә инде 19 ел буе биредә сабантуйларда спорт өчен җаваплы милләттәшебез. Газинур да Бакуда югары хәрби диңгез училищесын тәмамлый, ерак араларга йөзә торган штурман белгечлеген ала, Санкт-Петербургта офицерларның югары курсларында укый, корабль капитаны дәрәҗәсенә ирешә. Хатыны – Мәдинә ханым, бер балалары бар, бергәләп милли эшләрне алып баралар. ВВС капитаны, бөтен гаиләсе белән милли эшләрдә катнашкан Венер Гарифуллин Уфада туып-үскән, тамырлары – Бүздәк районыннан. Ул Уфада авиация институтын тәмамлый, аннан юллама буенча Хабаровскига җибәрелә, ВВС составында инженер-техник булып хезмәт итә. 1988 елда аны Приморьега күчергәннәр, хатыны татар, уллары биредә хәрби хезмәттә. Менә бу татарлар «Туган ил» оешмасының төп таянычы инде, алар артык шауламыйча, ирләрчә киңәшеп, бер-берләренә таянып, дөнья читендә дә милли эшләрне алып баралар.

Бу игелекле татарлар исемлегенә тагы зур эшмәкәр, сабантуйларның химаячысы, Башкортстанда туган Лилия ханым Цептнерны, үз сәхифәләрендә татарлар тормышын даими яктыртып килгән «Утро России» газетасы редакторы Дамир Гайнетдиновны, 20 ел буе сабантуйларны алып барган Фәнисә Искәндәрованы һәм дистәләгән татарларны кертергә мөмкин. Фәнисә ханымга аерым тукталасым килә, чөнки ул да биредә милли тормышны башлап җибәрүчеләр рәтендә тора. Ул үзе Башкортстанның Гафури районы Бурлы авылыннан, 8 класс тәмамлагач, 1972 елда Владивостокка апасы янына килә һәм шушында кала. Фәнисә урта мәктәпне урыслар арасында тәмамлый, тегүчелеккә дә укый, паспортистка, мастер булып та эшли. Әмма аны бар халык татар сабантуйларын матур итеп алып баручы, оста оештыручы буларак белә һәм таный. 1992 елдан бирле ул Владивосток татарларын өй буенча йөреп җыйган, утырырга биналары булмагач, күп вакыт үз фатирларында очрашканнар.

***«Хәзер инде 40 ел мин туган яктан киткәнгә, әмма шуңа карамастан, татармын, дип сөенеп йөрим, үз телемдә җырлыйм, үз телемдә сөйлим,*** *– диде ул. –* ***Мин апамнарда яшәгән чакта, аларга бик күп татарлар, якташлар килеп йөри иде. Шуңа***

***күрә мин Владивосток шәһәрендә генә түгел, хәтта районнарда яшәүче бик күп татарларны беләм... Үземнең фатирда татарларны җыеп, бәйрәм ашлары уздырдым, кешеләрне шулай тупладык. 1992 елда беренче Сабантуй бәйрәмен үткәрдек һәм тәүге мәртәбә Владивостокта «Дружба народов Приморья» фестивалендә катнаштык, бөтен халык алдында Тукайның «Туган тел» җырын җырладык... Мин беренче булып үземә татар халык костюмын тегеп кидем. Шуннан концертларда кияргә барыбызга да милли киемнәр тектек. Приморьеның Артём, Уссурийск, Находка шәһәрләренә концерт белән барып, татарларны берләштереп йөрдек. Өч мәртәбә Хабаровскига һәм Комсомольск-на-Амуре шәһәрләренә барып, татарча Сабануй бәйрәмен үткәрергә ярдәм иттек».***

Әйе, Ерак Көнчыгышта татар күтәрелеше менә шулай башланган, әлеге милли күтәрелешкә һәркем үзеннән өлеш керткән. Бу урында беренче Сабантуйларны уздыруда башлап йөргән Халисә ханым Әмирханованы, үзенең моңлы җырлары, дини ирадәләре белән халыкны әсир иткән Фәрит Фәйзуллинны да рәхмәт сүзләре белән искә аласы килә. Бирегә шулай ук дин юлында йөргән милләттәшләребез дә бар. Әмма, әйткәнемчә, милли һәм дини хәрәкәт бүлгәләнгән, ә хакимият моннан бик оста файдаланырга мөмкин, ягъни, үзебезнең таркаулыкны гаепләп, тагы мәчетсез калдырулары бар, Аллам сакласын! Владивосток шәһәрендә мөселманнарның намаз укый торган гыйбадәт йортлары (молильный дом) бар, муллалары – Үзбәкстаннан кайткан татар кешесе, Абдулла хәзрәт. Бирегә мәчеткә йөрүчеләрнең күпчелеге – үзбәкләр, таҗиклар һәм Кавказ халкы. Татарлар да үзләренчә дин тотарга тырыша, бигрәк тә өлкән як, апа-әбиләребез шушы изге юлда йөри. Шәһәрдә Коръән ашлары, дини мәҗлесләр еш уздырыла, миңа да Урал һәм Әлфия Сафугановлар оештырган Коръән мәҗлесендә булырга туры килде, анда милли киемнәрдән бик күп татар апалары килгән иде... Болар – яшьтән үк ирләре, гаиләләре белән Владивостокка килеп, төрле авыр эшләрдә эшләп, инде лаеклы ялга чыккан, балалары, оныклары белән җир читендә яшәп калган калфаклы, ак яулыклы, милли җанлы татар апалары... Балалары инде урыслар белән гаилә корган, оныклары шул милләтнекенә әйләнгән үзәк өзгеч язмышлар... Күзләре тулы моң, алар, кагылмасаң да, дәрья булып түгелергә тора... «Үзебезнең телебездә сөйләшеп, иман белән үләргә язсын», диде алар, соңгы сүзләре итеп...

Әйткәнемчә, бу якларда татарларның күтәрелеше моннан егерме еллар элек башланса да, милләтнең чын мәгънәсендә рухланып, көчәеп китүе соңрак булды. Моның беренче сәбәпчесе 2005 елның ахырында Камил Исхаковның Ерак Көнчыгышка тулы вәкаләтле вәкил итеп билгеләнүе булса, 2011 елда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Приморье краена килүе, анда татарлар белән очрашуы күтәрелеп китүгә икенче сәбәпче булды. Татарның бу якларда диңгез кебек кайный башлавына өченче сәбәп – бирегә федераль Сабантуй уздыруга карар бирү. Шушы бер ел вакыт эчендә ике як хөкүмәт тә зур әзерлек эшләре башкарды, гел очрашулар булып торды. Бу эшләрдә Бөтендөнья татар конгрессы да читтә калмады – 2011 елда конгрессның башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров җитәкчелегендә делегация Приморье краенда булды, милләттәшләребез белән очрашты, «Татарстан – Яңа Гасыр» каналының «Халкым минем» тапшыруы бирегә яшәүче татарлар турында махсус тапшыру эшләде. 2012 елда исә Татарстанның халык артисткасы Гөлзадә ханым Сафиуллина Приморье краенда ай буе яшәп, андагы дүрт шәһәрдә милли ансамбльләр оештырып кайтты, илкүләм Сабантуйда алар махсус чыгыш ясады. Минем бу якларга килүем исә татар тарихын, татарларның бүгенге тормышын өйрәнү белән бәйле иде, беренче баруымда бирегә ун көн булдым. Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Ерак Көнчыгышта татарлар уянды, әмма алар яңадан йокыга китмәсен, милли һәм дини рух сүнмәсен өчен, безнең дә ярдәм кирәк – ешрак аралашу, галимнәрнең, язучыларның, сәнгатькәрләрнең анда барып, чыгышлар ясап торуы, андагыларның безгә ешрак килүе кирәк. Приморьеда, нәкъ менә Владивостокта, Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиллеген ачыр вакыт та җитте, бу анда яшәүче татарларга зур ярдәм, арка таянычы булыр иде.

Ниһаять, 2012 елның 30 июнендә Владивостокта мәчет нигезенә таш салынды һәм федераль Сабантуй гөрләп узды. Татарстаннан һәм бөтен Россиядән зур делегация составында анда мин дә катнаштым, милләттәшләрем белән тагы очраштым һәм кайткач, матбугат битләрендә бу хакта хәбәрләр бирдем. «Владивостокта татар бәйрәме» дип аталган хәбәрне бу язмамда да файдаланырга булдым.

## Владивостокта татар бәйрәме

Приморье краеның башкаласы Владивосток шәһәре бу көннәрдә чын мәгънәсендә татар каласына әйләнде – биредә берсеннән-берсе әһәмиятле милли һәм дини чаралар булып үтте. Казаннан 8 мең чакрым ераклыкта, Тын океан ярларына урнашкан Владивосток шәһәрендә XII федераль Сабантуй уздырылды, яңа төзеләчәк мәчет нигезенә таш салынды, филармония бинасында Татарстан сәнгать әһелләренең зур концерты булды, Приморье крае белән Татарстан Республикасы арасында төрле килешүләр төзелде, Ерак Көнчыгышта яшәүче татарлар белән очрашулар уздырылды... Әмма шушы вакыйгалар арасында иң зуры, иң әһәмиятлесе Владивосток шәһәрендә мәчет нигезенә таш салу булгандыр, мөгаен.

Халыкның сөйләве буенча, революциягә хәтле Владивосток шәһәрендә татарларның гыйбадәт йортлары булган, әмма ул большевиклар тарафыннан юк ителгән. Соңгы елларда татарлар күпме генә мәчет салырга тырышып йөрсәләр дә, аларга рөхсәт ителмәгән – мәчет өчен дүрт тапкыр җир биреп, дүрт тапкыр яңадан тартып алганнар. Ягъни, һәр шәһәр башлыгы алмашынган саен, карарлар да алмашынган... Дөрес, биредә яшәүче мөселманнарның гыйбадәт йортлары (молильный дом) бар барын, әмма ул берничек тә дистә меңләп кешене сыйдыра алмый, халык гает намазларын урамда яки аерым биналарда укырга мәҗбүр була. Һәм, ниһаять, Аллаһы Тәгалә мөселманнарның догаларын ишетте, 2012 елның 30 июнь иртәсендә Владивосток шәһәрендә, Тын океанның Улисс култыгы буендагы биек тау башында, булачак мәчет нигезенә таш салынды.

Бу тарихи вакыйгада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Россиянең Үзәк Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгать Таҗетдин, Приморье краеның вице-губернаторы Ирина Василькова, илнең бөтен төбәкләреннән килгән милләттәшләребез катнашты. Коръән уку белән башланып киткән әлеге тантана Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның Владивосток шәһәре имам-хатыйбы Габдулла хәзрәт Ишмөхәммәтовка изге Коръән бүләк итүе белән дәвам итте. «Бер ел элек без биредә мәчеткә нигез салу турында хыяллана гына ала идек, ә бүген бу тормышка ашты», – диде Рөстәм Миңнеханов үзенең чыгышында. Шунысын да әйтергә кирәк: мәчет Казан исемен йөртәчәк, ягъни «Казанская» дип аталачак. Рөстәм Миңнехановның чыгышыннан аңлашылганча, Владивостоктагы Казан мәчете Татарстан ярдәме белән төзеләчәк, аның җиренә дә безнекеләр хуҗа булачак, иншаллаһ! Мондый тотрыксыз заманда, татарлар шундый авырлык белән төзегән мәчетләргә төрле көчләр хуҗа булырга ыргылып торганда, булачак мәчет нигезенә башта ук «татар казыгы» кагып калдыру – бик дөрес гамәл.

Приморье крае җитәкчелегенең, ниһаять, татарларга йөз белән борыла башлауларын да әйтеп үтәргә кирәк. Төбәктәге геополитик вазгыять тә аларны шуңа этәрә, чөнки күршедәге кытай басымына бары тик берләшеп, бергәләп кенә каршы торырга мөмкин. Моны вице-премьер Ирина Василькова да ассызыклады, мәчет ачылуның Приморье краенда яшәүче татарлар һәм башкортлар өчен бик әһәмиятле икәнлеген әйтте: «Мин бу көннең безнең өчен һәрвакыт үзара тирән ихтирам, толерантлык, бөек ватаныбызда яшәүче халыкларның үзара аңлашу символы булуын телим, – диде ул. – Мин бу көннең һәрвакытта да мәдәният һәм традицияләрнең төрлелеге, Россиянең барлык халыкларының рухи берлеге символы булып калуын телим». Шундый ук изге теләкләр булачак мәчетнең нигез ташына да уеп язылган иде: **«Бу урында Татарстан Республикасыннан Приморье халкына бүләк итеп, иманны, дуслыкны һәм татулыкны ныгыту символы – мәчет төзеләчәк. 2012 елның 30 июне».**

Мөфти Тәлгать Таҗетдин исә үзенең чыгышында: «Бу мәчеттән яңгыраган азан тавышы, Тын океанны урап узып, Япония, Америкаларга хәтле барып ирешсен иде!» – дигән теләк белдерде. Әйе, Россиядә беренче азан нәкъ менә биредә – Ерак Көнчыгышта яңгырый, чөнки Казан-Мәскәү белән вакыт аермасы җиде сәгать, бездә караңгы төн булганда, аларда инде таң ата... Хәзергә Приморье краенда бары тик Находка шәһәрендә генә мәчет бар, Уссурийск шәһәрендә төзелеп ята, Артёмда бары тик гыйбадәт йорты гына эшләп килә. Владивостокта мәчет өчен урын бик матур җирдә, диңгез култыгында, данлыклы яңа күпернең бер башындагы сопка-тауда бирелгән. Инде аны бергәләп, исән-имин төзеп чыгарга һәм шунда җыелып намазлар да укырга насыйп итсен иде!

Бу көн тарихи вакыйгаларга бай булды – Владивостокта Татарстан Республикасы белән Приморье крае, Казан (Идел буе) һәм Ерак Көнчыгыш федераль университетлары арасында хезмәттәшлек турында килешүгә кул куелды, Рөстәм Миңнеханов су асты көймәсендә хезмәт итүче Татарстан егетләре белән күреште, ике яктан да зур эшмәкәрләрнең очрашулары узды.

Шул ук көнне Владивосток шәһәрендә тагын бер мөһим вакыйга булды – биредә XII федераль Сабантуй үтте. Дөрес, Приморье татарлары үзләрендә инде егерменче тапкыр Сабантуй уздыралар, әмма мондый илкүләм бәйрәмне алар әле беренче тапкыр күрәдер, мөгаен... Федераль Сабантуй Владивостокта үтә дигәч, башта күпләр борчылып та куйды, чөнки ара бик ерак, анда татарлар аз яши, ә илкүләм Сабантуй бик нык әзерлек, оешканлык сорый. Шуңа күрә ел буе Татарстан һәм Приморье крае хөкүмәтләре арасында зур эшләр алып барылды, татар бәйрәме дәүләт дәрәҗәсендә узсын өчен, барысы да эшләнде. Федераль Сабантуйны уздыруда төп җаваплылык Түбән Кама шәһәренә төште, алар моны намус белән, иң югары дәрәҗәдә башкарып чыктылар. Шулай ук Татарстанның Мәдәният министрлыгы да, бәйрәм оешкан төстә, милли рухта, югары зәвык белән үтсен өчен, барысын да эшләде – ике көн рәттән Владивосток сәхнәләрендә Татарстаннан 400 сәнгать остасы, күренекле җырчылар, милли ансамбльләр чыгыш ясады. Әле Сабантуй алдыннан, 29 июнь көнне, Владивосток шәһәренең филармония залында Татарстанның сәнгать осталары катнашында зур концерт булды, аны карарга Ерак Көнчыгышның бөтен төбәкләреннән татарлар килде, тамашачылар арасында шулай ук Приморье крае җитәкчеләре, танылган галимнәр, диңгезче-хәрбиләр дә бар иде.

«Бу чара федераль Сабантуй кысаларында бара, – дип белдерде Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин. – Безнең танылган артистларыбыз монда килеп, татар халкына, башка халыкларга сәнгатебезне һәм мәдәниятебезне күрсәтте. Мин тамашачыларның ничек утырганнарын, артистларны ничек алкышлаганнарын, һәрберсенең безнең халык өчен горурлык хисе кичерүен күрдем. Чөнки халкыбыз эшли дә, ял итә дә белә. Сабантуй бит ул – безнең гореф-гадәтләрне саклый торган зур чара. Сабантуй бездә алдагы елларда да, алдагы гасырларда да сакланачак .»

Владивостокта узган федераль Сабантуйга Россиянең төрле төбәкләреннән җиде йөзгә якын вәкил килгән, алар арасында милли оешма җитәкчеләре, җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре, күренекле эшмәкәрләр, галимнәр, язучылар, сәнгать осталары да бар иде. Ерак Көнчыгышта яшәүче милләттәшләребез бигрәк тә актив булып чыкты – Сахалиннан, Якутиядән, Магаданнан, Еврей автономиясеннән, Бурятиядән, Хабаровск, Амур, Иркутск өлкәләреннән, Приморье краеның Находка, Артём, Уссурийск, Партизанск шәһәрләреннән бәйрәмдә катнашырга йөзләгән татар килгән иде. Әлбәттә, федераль Сабантуйның хөрмәтле кунаклары – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Приморье краеның губернаторы Владимир Миклушевский булды, алар икесе дә халык алдында чыгыш ясады, алга таба да аралашып, дус-тату яшәргә халык алдында сүз бирде. Татарстан Президенты Приморье губернаторына чиккән татар түбәтәе һәм милли чапан бүләк итте.

Бу көнне Татарстан Президенты кулыннан бүләк алучылар тагы да булды – Владивостокта милли хәрәкәткә нигез салган, Ерак Көнчыгышта беренче татар

театрын оештырып җибәргән диңгезче ир-егет, Приморье краеның «Туган ил» татар һәм башкорт оешмасы рәисе урынбасары Урал Сафугановка «Татарстанның атказанга мәдәният хезмәткәре» дип аталган мактаулы исем бирелде. Ә «Туган ил» оешмасы рәисе Рамил Килмөхәммәтов исә Татарстан Президенты кулыннан өр-яңа машина ачкычын кабул итеп алды, димәк, милли театрга Ерак Көнчыгыш буйлап гастрольләргә йөрергә транспорт булды дигән сүз.

Федераль Сабантуй Владивосток шәһәренең иң матур урынында – Тын океан ярындагы «Динамо» стадионында үтте, шулай ук стадион каршындагы урамга да икенче сәхнә куелган иде, анда Түбән Камалылар һәм Владивосток, Артём, Находка, Уссурийск үзешчәннәре чыгыш ясады. Әлбәттә, ике сәхнәдә һәм стадионның яшел чирәме өстендә ясалган чыгышлар таң калдырырлык иде, ул үзенә күрә милли олимпиаданы, татар олимпиадасын хәтерләтте. Казан Сабантуйга дип Приморье үзешчәннәренә өр-яңа костюмнар тектергән. Инде Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле киемнәре һәм чыгышлары турында әйтеп тә торырлык түгел – алар Ерак Көнчыгышка иң югары зәвык дәрәҗәсен күрсәтте.

Сабантуй булгач, анда бөтен милли уеннар, көч сынашулар да тәртибе белән алып барылды. Өйләдән соң коеп яңгыр явуга карамастан, чүлмәк тә ваттылар, баганага да менделәр, капчык киеп тә йөгерделәр, көрәштеләр тә. Яңгыр астында келәмдә көрәшү авырлашкач, алыптай ирләр яшел чирәм өстендә бил алыша башлады. Көрәштә җирле батырлар да, читтән килгәннәр дә катнашты, спорт мастерлары да, урысы да, татары да бил алышты, әмма абсолют батыр булып үзебезнең керәшен татары, Түбән Кама егете Ленар Иванов калды, ул Сабантуй тәкәсенә һәм җиңел машинага ия булды.

Федераль Сабантуйның символы – канатлы ат сыны Төмән өлкәсе вәкилләренә тапшырылды, чөнки киләсе елда федераль Сабантуй Төмән шәһәрендә булачак.

«Владивостокта федераль Сабантуй уздыру – үзе зур батырлык, – диде соңыннан Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров. – Федераль Сабантуй – матур традиция һәм, әйтергә кирәк, халкыбызның үзаңын тәрбияләүдә, гореф-гадәтләрен яңадан тормышка кайтаруда Сабантуйның роле бәяләп бетергесез зур. Кайберәүләр сабантуйлар уздырып кына милләтне саклап булмый дигән сүзләр дә әйткәли. Ләкин бу кешеләр бик нык ялгыша. Сабантуй – мең еллар дәвамында уздырылган, татарның рухын, гореф-гадәтләрен саклаган иң зур бәйрәмнәрнең берсе. Ул булмаса, халкыбызның рухын торгызу күпкә авыр булыр иде. Хәзер исә Сабантуй тулы бер хәрәкәткә әйләнде, ә башында, югары ноктасында федераль сабантуйлар тора. Аларга төрле төбәкләрдә яшәүче татарларның делегация-делегация булып катнашуы зур вакыйгага әйләнә. Әлбәттә, Владивосток шәһәрендә узган Сабантуй калганнарыннан аерылып тора. Масштабы ягыннан дип әйтмим. Бу яктан ул бераз оттыра. Ләкин Ерак Көнчыгышта уза бит ул, Казаннан сигез мең ярым чакрым ераклыкта урнашкан төбәктә. 15 меңгә якын гына татар булган җирдә федераль Сабантуй үткәрү – үзе бер зур батырлык, тәвәккәллек, анда яшәгән татарларның зур уңышы. Алар бу Сабантуйны оештыру хокукын Татарстан Президентыннан сорап алып, республика, барыбызның да зур ярдәме белән башкарып чыктылар. Ләкин үзләрендә көч һәм рух булмаган кешегә берничек тә ярдәм итеп булмый, рухы нык булган кешегә генә ярдәм кулы сузып була. Андагы халыкның рухы турында сөйли торган бер әйбер әйтәм: Сабантуй буе яңгыр яуды, әле моңарчы болай булганы юк иде. Әмма бәйрәмнең рухы бетмәде, Сабантуй гореф-гадәт буенча узды. Әлбәттә инде, Сабантуй көрәшсез үтмәде. Татар батырлары Ерак Көнчыгышта да бар. Бу татар халкының рухы сау булуын исбатлый».

Әйе, әлеге Сабантуй Ерак Көнчыгышта яшәүче татарларның рухын күтәрде, аларга көч-дәрт өстәде. Бу турыда сөйләшү төбәкнең милли хәрәкәт җитәкчеләре белән уздырылган «түгәрәк өстәл»дә дә булды. Шунысын да әйтергә кирәк: бу федераль Сабантуй милли рухта үтсен өчен, Бөтендөнья татар конгрессы да күп эшләр башкарды. Конгресс җитәкчесе Ринат Закиров берничә тапкыр Владивостокта булып, урындагы милли оешма җитәкчеләренә алда торган максатларны аңлатты, аларга Казан тарафыннан бөтен ярдәмне күрсәтеп,

киңәшләрен биреп торды. Бөтендөнья татар конгрессы Приморье краена халык белән эшләү өчен аерым шәхесләрне дә җибәрде, әйтик, Татарстанның халык артисткасы Гөлзадә Сафиуллина биредә берничә тапкыр булып, айлар буе яшәп, Владивосток, Находка, Артём, Уссурийск шәһәрләрендә милли ансамбльләр төзеде, алар Сабантуйда бик матур чыгыш ясады. Ә Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты әгъзасы, язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова бирегә Сабантуйга хәтле үк килеп, Владивосток, Находка, Артём, Уссурийск, Партизанск шәһәрләрендә халык белән очрашып, архивларда, музейларда, китапханәләрдә эшләп, җирле тарихчылар белән аралашып, татар тарихына кагылышлы бай материал туплап кайтты һәм аларның бер өлешен Сабантуйга хәтле инде матбугатта да бастырып чыгарды.

Милли лидерлар белән булган «түгәрәк өстәл» утырышында да Фәүзия Бәйрәмова татарларның Ерак Көнчыгышта төп халык булуын, биредә татар тамырларының бик еракларга – Төрки каганат, Алтын Урда чорларына барып тоташуын ассызыклады. Ул үзенең «Ерак Көнчыгышта татарлар» дип аталган китап язуын әйтте, тарихи материал туплауда ярдәм сорар милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итте. «Тиздән Россиянең язмышы Ерак Көнчыгышта хәл ителәчәк, – диде ул. – Үзегез күрәсез, бер яктан – Кытай, икенче яктан – Корея, өченче яктан Япония инде бу җирләргә үтеп кергән. Алга таба безгә дә дөнья алдында бу җирләрдә төп халык, иң борынгы халык, биредә дәүләтләр тоткан милләт икәнлегебезне исбат итәргә туры киләчәк. Милләтебез алга таба да бу җирләрдә яши алсын өчен, безгә союзникларны дөрес сайларга кирәк булачак. Шуңа күрә, нәрсә генә булса да, киңәшләшеп эшләү шарт, алга таба акыллы планнар белән яшәргә кирәк».

Әйе, Владивостокта федераль Сабантуй уздыру татарның алдан күрүчәнлеген, киләчәккә әзерләнеп килүен күрсәтте, Сабантуй байрагы артында милләтнең бөек тарихы да, алдагы тормышы да җәйрәп ята иде... Әйе, Владивостокта федераль Сабантуй уздырып, татар үзенең кемлеген дөньяга күрсәтте, матурлыгын, батырлыгын, булганлыгын дөньяга танытты. Владивостокта үткән милли һәм дини чаралар Тын океан буйларына татарның алтын казыгын какты, төрки каганнардан, Атиллалардан, Чыңгыз ханнардан калган юл буйлап, милләт яңадан үз җиренә, асыл тамырларына әйләнеп кайтты... Бу кайту инде мәңгелек булсын иде...

*«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге*

...Бу вакыйгаларга да инде өч ел вакыт үтеп киткән икән... Владивостокта мәчет төзелеше ни хәлдә соң? Бүгенге көндә Татарстан ярдәме белән «Казан» мәчетенең проекты эшләнгән, җир сатып алынган, документлар белән эшләр беткән, әмма мәчет үзе юк әле... Ахрысы, астан гына ниндидер каршылыклар да бара кебек... Чөнки сабантуйлар үткән, җитәкчеләр киткән, ә урында вак түрәләр ни теләсәләр, шуны эшлиләр... Алай да, Владивостокта, Тын океан буенда барыбер мәчет булыр, Ерак Көнчыгышта, борынгы төрки-татар җирләрендә тагын азан яңгырар, дигән өметтә калабыз...

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА**

*Ахыры киләсе санда*

# КОЛ ГАЛИ ҺӘМ ТУКАЙ

*«Йосыф-Ягъкуб китабы»ның көен көйлим…*

Насыйп булып, бу елда Тукай юбилеена басыласы энциклопедиягә хәзерләнгән материаллар арасында хөрмәтле галимебез Нурмөхәммәт Хисамов каләменнән чыккан «Кол Гали» исемле әтрафлы мәкалә бар. Ул аны: «Татар шигъриятендә генә түгел, бөтен төрки шигърият тарихында аның үлемсез әсәре «Кыйссаи Йосыф» гаять зур роль уйнаган», дип башлый һәм алга таба дастанның төрки әдәбият, татар шигърияте күләмнәрендәге кыйммәтләрен билгели, Тукай иҗатына да йогынтысын яза һәм әлеге йогынтыны аерым әсәрләр мисалында ышандырырлык дәлилли.

Зур галимнән соң Тукай һәм Кол Гали мөнәсәбәтләре темасына керү, бәлки, бераз әдәпсезлектер дә. Шул ук вакытта, энциклопедиягә урнаштырылган язмаларга бик аз урын бирелүен, аларның регламентлануын һәм бик җыйнак язылганнарының да редакторлар тарафыннан кыскартылуын күздә тотып, Бөек Остазыбызны мин шагыйрегезгә читләп үтүне җинаять санап, үз карашларымны да язып үтәргә җөрьәт иттем. Әлбәттә, алар, тасвирлау объекты бер булганлыктан, күпмедер күләмдә Нурмөхәммәт абый фикерләре белән дә кисешер.

Гомер буе белем эстәгән Тукай иҗатында Борынгыдан һәм Урта гасырлардан килгән традициячелек гаять тә көчле, бу, билгеле, эчтәлектә дә, сайлаган калып-үлчәмнәрдә дә, образлар системасында да чагылыш таба. Әлеге дә баягы традициячелекне шагыйрьнең укыган китаплары, шул исәптән бу көнгәчә әдәбиятыбызның чишмә башы саналган Кол Гали мирасы да формалаштыра. Тукайның тәүге шигырьләренең берсендә моны түбәндәгечә билгеләве гаҗәп түгел:

*Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,*
*«Йосыф-Ягъкуб китабы»ның көен көйлим.*

(«Дусларга бер сүз»)

Без галимнәр эчтәлек һәм форма берлеге, берсендәге үзгәрешләрнең икенчесен үзгәртүе турында күп язабыз, әмма моның озын-озак барыш икәнлеген онытып җибәрәбез. Тукайның мисалга китерелгән әсәрендә идея эчтәлеге үтә яңа, образлар системасында борынгыдан килгәннәре күзгә ачык бәрелерлек түгел, лексик катламда шигъриятә моңарчы ишетелмәгән чиновниклар, Петербург, манифест, государь, абразауный кебек төшенчәләр урын алган. Яңа фикер, күренешләрнең иске структурада, җөмлә калыпларында, Кол Гали атаклы поэмасына сайлаган үлчәмдә яңгыраш табачагы инде беренче строфадан ук күренә. «Йосыф-Ягъкуб» китабының көен көйлим, дип белдергән автор алга таба болай дип яза:

*Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим, –*
*Җебем – кара, инәм каләм булсын имди.*

Иҗтимагый-сәяси эчтәлектәге әсәрдә шунысы игътибарга лаек: Тукай борынгы поэманы, мәхәббәт тарихы икәнлегенә ишарәләп – «Йосыф-Зөләйха», үзәк геройны ассызыклап – «Йосыф кыйссасы» дип тә атамый. Ул аңа дәүләт башында торган гадел патшалар исемнәре йә булмаса ата һәм бала мөнәсәбәтләрен чагылдыручы дип билгеләргә дә мөмкин атама куя. Тукайның дастанны киң таралган вариантта исемләмәвен үлчәм-яңгыраш камиллеге таләбе белән генә бәйләргә ярамый. Форма шомалыгына ирешү талантлар өчен берни тормый. Шагыйрь кыйсса атамасын Йосыф сәүче, гашыйк Йосыф тарихы кебек гыйбарәләргә алмаштыра яисә бөтенләй башкача да яза алыр иде.

Укучыга шуны аңлатырга теләгән шикелле, Тукай шунда ук бу әсәрендә халык (милләт) язмышын кайгыртуын әйтә. Моның белән дә, Кол Гали кебек, әсәр башында ук тема, шуны җиткерү юлларын билгеләве белән дә, ул ике талантны янәшә бастыра.

Тукай сайлаган дастан исеменә мөнәсәбәттә Н.Хисамов фикерләрен дә язып үтик: «Шагыйрь болай дигәндә, әсәрнең тематик нигезен бик төгәл билгели. Поэма үзәгендә, чыннан да, ата белән угыл мөнәсәбәтләре яктыртыла. «Исемдә калганнар» язмасында да шагыйрь «Йосыф китабы»н телгә ала. Анда поэманың исемен әнә шулай халыктагыча китерә».

Тукай кайбер әсәрләренең ахырына Кол Гали рухында нәтиҗәләр чыгара. Шагыйрьнең «Кечкенә генә бер көйле хикәя» текстындагы төп өлешнекеннән аермалы – «Йосыф кыйссасы»ныкына тәңгәл үлчәмдәге һәм робагый калыбындагы «Бәхре сани»ны эпилог дип карарга мөмкин. Тукай анда Сафи хатыны Фатыйманың бозыклыгы аркасында ирсез калганнан соң кичергән һәм теләсә кемне кызгандыртырлык хәлләрен сөйли, укучыга үз эшенең тормышта булган эш-күренешләрне язу икәнлеген җиткерә. «Кыйссаи Йосыф»та, мәсәлән, авторның әсәр язу максатын тасвирлаган һәм сюжетның гарәп-фарсы телләрендәгечәлегенә ишарәләгән «Хәтимә» бар. Әлеге Соң сүздә Кол Гали болай дип яза:

*Бу зәгыйфьнең шушы назмы аз булмады,*
*Робагые үлчәмендә торсын инде.*

Тукайда да уникe иҗекле юллардан торган робагыйлар җитәрлек. Үз иҗат тәҗрибәмнән чыгып әйткәндә, җыр кебек укылышлылыгына карамастан, бу үлчәмдә заман темаларын ачу, иҗтимагый күренешләрне җиткерү шактый авыр. Шагыйрьнең «Дөньяда торыйммы? – дип киңәшләшкән дустыма», «Бер татар шагыйренең сүзләре», «Утырышу» һәм башка әсәрләре шул калыпта язылган, әмма аларда строфадан строфага кабатланып килгән һәм составында “имди” (инде) сүзе булган гыйбарәле соңгы юл очрамый. Әнә шунлыктан гади укучы «Кыйссаи Йосыф»лардан килгән үлчәмне тотып алмаска да мөмкин, ә менә «Кәҗә тугрысында» урын алган һәм Кол Гали каләменнән төшкән кебек үк калыптагы бәет хәтта анда да әдәби бәйләнешләр хакында уй тудырачак. Бу әсәр фольклор белән матур әдәбият традицияләренең Тукай иҗатында ничек тыгыз үрелүен бик ачык күрсәтә һәм икесенең дә озын тарихлы икәнлеге хакында сөйли.

Тукайның Кол Гали сайлаган үлчәмнән тәнкыйди характердагы яисә юмор-сатира рухындагы әсәрләрендә файдалануы әдәбиятта үзенчәлекле бер күренеш булып тора. Сүзебезгә мисал рәвешендә «Гыйбрәт һәм нәсихәт» шигыренең бер строфасын китереп узыйк:

*Номерың матур булса, күсе булгай,*
*Һәр матурда начар якның берсе булгай,*
*Ансы булып җитмәсә дә, монсы булгай, –*
*Андин җыртык, мондин җыртык туннарым бар.*

Әдәбият ул, нигездә, бер үк мотивларны үстерә, кайчандыр бер яңгыраткан фикерләрне һәр чорның үз материалы аша укучыга җиткерә. Әйтик, Кол Галинең үзәк герое, беренче чиратта, сабырлык сыйфаты белән истә кала, Йосыф үзе дә Зөләйханы сабыр итәргә чакыра, поэмада халыкның ачлыкка түзү хәлләрен тасвирлаган урыннар да бар, чөнки сабырлыкка өндәү – Коръәннән үк килгән мотив. Көрәшче рухлы Тукай моның белән килешергә теләми, еш кына ризасызлык белдерә. Хәтта Изге китапка каршы килеп, «Бәет» текстында болай ди:

*Бу сәнә ачлык җыланы чын халык бәгърен ашый!*
*Кит, китап! Сабрит, дип әйтмә, ул халык көчен ашый.*

Тукай иҗатын Кол Галинекенә фәлсәфи уйланулар бик нык якынайта. XX гасыр шагыйре, үзеннән элгәре талант иясе кебек үк, Тәңрегә сынган күңел, саф инсан, гадел җитәкчеләр, ана-бала мәхәббәте һәм башкалар турында фикер йөртә;

бу вакытта ул электән килгән төшенчәләр белән эш йөртә, борынгыдан калган бай образлар системасына мөрәҗәгать итә.

Тукайда Кол Галидәге кебек чагыштырулар, охшатулар, хәтта арттырып әйтүләр очрый. «Күңел» әсәрендә шагыйрь: *«Шундый гали матлабың — мең җан бирергә урын бар, / И югарылык белән типкән вә селкенгән күңел!»* — дип белдерсә, «Кыйссаи Йосыф»та шундый гипербола кулланылган:

*«Минем әгәр йөз мең җаным булыр исә,*
*Барчасын да сезгә фида кылам инде».*

«Күңел»дән: *«фәләкнең төрле-төрле золменә күнгән күңел!», «бул чыдауда таш кеби», «Күп сөекледер бөтеннән — Тәңрегә сынган күңел»*, — дигән юлларны укыганда, күз алдыбызга язмышына ризалашкан, сабыр, чыдам һәм Аллага буйсынуны матди байлыклардан, ягъни тормыш бөтенлегеннән өстен куйган Йосыф образы торып баса.

Тукайда, Кол Гали заманнарыннан ук трансформацияләнә барып, бүгенгәчә килеп җиткән башка образлар да очрый, күренеш тудыру алымнары да җитәрлек. Мәсәлән, Йосыф пәйгамбәр, урамга чыгып, йөз нуры белән кешеләрдәге ачлык хисенә кадәр оныттырса, Тукай «Ике кояш»та тамашачы күңелен кояш кебек нурландырган, тулаем биләгән Гыйззәтуллинаны тасвирлый.

Кол Гали дастанының унынчы фасылында халык арасына сарайда хезмәт итәрлек кешеләр эзләргә чыккан Йосыф патша, туны искергән, пычранган бер кешене күреп, үзенә тиң түгеллеге, вәзирлеккә яраксызлыгы турында фикер йөртә. Тәңредән сәлам белән килгән Җәбраил аңа мондый фикерне башыннан чыгарып ташларга куша, әлеге фәкыйрьнең Йосыфка авыр чагында игелек кылганлыгын, моны онытырга ярамаганны әйтә. Йосыф сәүче әлеге юлчыны затлы киемнәргә киендерә һәм үзенең вәзире итә. Димәк, бүген түбәндә булган кешенең иртәгә югары күтәрелүе дә мөмкин. Тукайның «Нәсихәт» шигырен искә төшерик. Анда һәркемнең, теләнчеләрнең дә Алла колы икәнлеге ассызыклана, тормыш көпчәгенең әйләнүе, байны — ярлы, ярлыны бай итәргә мөмкинлеге турында сүз бара.

Тукай русчага ияреп язылган әсәрләрендә дә Кол Галидән килгән образлар, мотивлар белән эш итә, чөнки аларның эчтәлеге үк шуңа этәрә. «Кыйссаи Йосыф»та дәрәҗә-байлыкка кызыкмаган, кешедән көнләшмәгән яшь каһарман ир хатынына гашыйк була, аның матурлыгына тиңнәр тапмый, әмма пәйгамбәрләрчә сабырлык кыла, шунлыктан бәхеткә, тиң мәхәббәткә ирешә. «Тәүбә вә истигъфар»ның лирик герое бу уңайдан менә нәрсәләр ди:

*Йа Ходай! Нишлим, әгәр күрсәм кешенең зәүҗәсен?*
*Торса ул яд иттереп (искә төшереп. – Р.Р.) җәннәт сарае раузасын?*

*Ул Зөләйхалар вә Ләйләләр кеби булса матур?*
*/…/*
*Ибне адәмме түзәр, җирдә әгәр күрсә мәләк?!*

Каты, усал теллерәк, фикерне аерым бер ситуациягә бәйле куллanучанрак Тукай «Халык әдәбияты»нда, үзенә хас булган кискенлек белән, Кол Гали телен «җен теле» дип атый. Бу, билгеле — әдәби тел нормаларын гади халыкныкына якынайту һәм кору омтылышыннан, мәктәп программаларын дөньяви китаплар белән баету теләгеннән чыгып кына әйтелгән сүз. Шул ук вакытта Тукай «Васыятем» шигырендә: *«Күр, нә рәсмә тулган иман берлә Коръән садремә»*, — дип белдерә. Димәк, Изге китаптан ук килгән Йосыф тарихы шагыйрь җанында мәңге яшәячәк.

«Словарьдан фал ачу» язмасында Тукай «Йосыф китабы»н бераз гына мәгърифәтле кызларның фалнамә рәвешендә куллануларын әйтә, хәтта шагыйрь көлеп телгә алган бу гореф-гадәт тә бүгенге көннәргәчә яши. Ә инде Кол Гали иҗаты күңелләребездә Тукай мирасы аркылы да гел яңарып тора.

**Рифә РАХМАН**

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ ДӘВАМ ИТӘ

*2014 елның 9 нчы санында башлаган идек без бу өмәне. Халкыбыз үзе үк чыгарып, гасырлар буена таянып яшәгән бай мәкаль мирасыбызга XXI гасыр мәкальләрен дә ялгар өчен. Болай ярыйсы гына бара кебек бу эш. Ун санда 39 авторның 349 мәкале басылды инде. Ләкин сыйфат ягын көчәйтә төшәсе иде бит. Яңа мәкальләребез бу четерекле заманның маякчыклары булсыннар иде. Һәм хәтергә бер кергәч, чыкмаслык итеп эшләнсеннәр иде.*

*Сезнең иҗатны чыгасы мәкаль китабыбыз да көтә, кадерле авторларыбыз һәм укучыларыбыз!*

- Туган тел — бушлай бирелгән хәзинә.
- Тапкыр кеше тел белән таш яра.
- Башлы хатынга баш булуы кыен.
- Бай ярлыдан саранрак.
- Баланы акыл ашатып та үстер.
- Үгез белән сөзешмә, юртак белән ярышма.
- Ташны — кәйлә, көчне хәйлә белән җиңәләр.
- Жирафны буй басар, акыллыны уй басар.

**Рашат НИЗАМИ**

***

- Юләрне — төп башына, акыллыны түр башына утырталар.
- Мәхәббәт — давыл сыман, көтмәгәндә килә.
- Бурычлы үлмәс, әмма рәхәт тә күрмәс.

**Фәнәвис ДӘҮЛӘТБАЕВ.**
*Актаныш районының*
*Татар Суыксуы авылы*

***

- Иң олы бәхетсезлек — бәхетсезлеккә түзә алмау.
- Дуслар күп, дуслык кына җитми.
- Дәүләтнең какшамас нигезе — гаделлек.
- Өендә — арыслан, өйдән чыккач — төлке.
- Явыз кеше бәхетле була алмый.

**Әсгать СӘЛАХ.**
*Әлмәт*

***

- Эштә кием керләнер, җан керләнмәс.
- Нияте түмгәкленең күңеле имгәк.
- Тоташ көлгән — аңыннан бөлгән.
- Яшьлегендә яшьнәгән картлыгында күк күкрәтер.
- Сукыр кояшсыз тормас.
- Күктән йолдыз санаганчы, аяк астындагы түмгәкләрне сана.

**Әхәт ГАФФАР**

# АНЫҢ ТӘНЕ ДӘ КӨЧЛЕ БУЛГАН

***(Муса Җәлил тормышында спорт һәм физик тәрбия)***

Халык хыялында һәрвакыт батыр, көчле, кыю, баһадир гәүдәле ир-егет образы яши. Ул Ватанын һәм сөйгәнен, карт ата-анасын һәм олыны-кечене дошманнардан яклап калучы каһарман, ил өстенә килгән яуны кире борырдай гайрәт иясе итеп сурәтләнә. Сезнең игътибарыгызга тәкъдим итәчәк язмамда мин халкыбызның әнә шундый каһарманы герой-шагыйрь Муса Җәлилнең спортка һәм физик тәрбиягә мөнәсәбәте белән таныштырырмын. Ни өчен мине бу җәлеп итте соң? Беренчедән, үлемгә хөкем ителгәннән соң да көн саен иртәнге гимнастика ясарга каян көч алган, кебек сорауга җавап табасым килде. Икенчедән, мин үзем дә спортка һәвәс.

Сәламәт кеше тормышны ярата, сәламәт кеше бик сирәк бәхетсез була. Бәхет исә безнең үз тәнебезгә күрсәткән кайгыртучанлыкка да бәйле. Тән гармониясе булганда, җан тантана итә. Акылның зирәклеге дә ныклы физик нигезсез була алмый.

Әнвәр Хуҗиәхмәтов болай дип язды: «Кеше үзенең тәнен көчле, сәламәт итеп тәрбияли алса, ул тормыш авырлыкларына да каршы тора ала. Сәламәтлек, чыдамлык, яшәү өчен көч һәм энергия запасы стрессларга һәм тормыштагы кыенлыкларга каршы көрәшү өчен төп корал булып тора».

1924 елга кадәр язган хатларында Муса Җәлил еш кына сәламәтлегеннән зарлана. Авыр балачак еллары, ачлы-туклы яшәү, 1921 елгы ачлык, күрәсең, үзенекен иткән инде. 1923 елның җәендә Җәлил бизгәк авыруыннан интегә. Рабфакта укыганда, ул физик тәрбиянең файдасы турында брошюрага тап була. Шуны укыганнан соң, үз сәламәтлеген ныгытуны максат итеп куя: салкын су белән коена, гер күтәрә, бик яратып волейбол уйный, Кабан күлендә көймәдә йөзә. Күп тә үтми, Җәлилнең сәламәтлеге чыннан да ныгый. Муса Җәлил, оптимист кеше буларак, чын күңеленнән ышанган: сәламәт тәндә — сәламәт акыл.

1924 елдан башлап Муса бер көн дә иртәнге зарядкасын калдырмый. Андре Тиммерманс сөйләвенчә, хәтта Моабит төрмәсендә утырганда да!

Утызынчы еллар уртасында ул Кырымда, Севастопольдә ял итә. Баштагы көннәрдә Муса санаторий тәртипләрен төгәл үти: комда кызына, төшке аштан соң ятып йоклап ала. Ләкин түземлеге озакка җитми, Севастопольдән Ялтага чаклы булган 80 чакрым араны җәяүләп үтә. Кырым белән әнә шул рәвешле таныша ул. Ялтада яраткан язучысы Галимҗан Ибраһимов янына керә. Кайтканда да җәяү кайта.

«Физик яктан Муса кебек сәламәт кешеләрне миңа сирәк очратырга туры килде, — дип яза Гази Кашшаф. — Ул сәгатьләр буе ишкәк ишеп көймәдә йөри ала, кичке ял вакытларында бертуктамый волейбол уйный, көнозын урманда

йөри һәм ару-талуның нәрсә икәнен дә белми иде». Гази Кашшафка Җәлил, ярым шаяртып, ярым җитди итеп: «Мин 100 яшькә кадәр яшәргә җыенам, бер дә шуннан ким түгел», — дип әйтә торган булган.

Муса үзенең сәламәтлеге, физик көче белән мактанырга яратмый. Шуңа күрә бу турыда хәтта аның белән аралашкан кешеләрнең дә күбесе белмәгән.

«Төне буе «Алтынчәч» операсын язып утырганнан соң, әсәрнең бер өзеге турында фикер алышу нияте белән, Муса янына кердем, — дип искә ала Нәҗип Җиһанов. — Вакыт бик иртә булуга да карамастан, Муса инде торган, гимнастик күнегүләр ясый иде». Шагыйрьнең мускулларын, тыгыз тәнен күреп, ул чын-чынлап хәйран кала. Үз күзенә үзе ышанмыйча, композитор Мусаның күпереп-калкып торган мускулларын капшап карый һәм, соклануын яшермичә, тел шартлатып куя. Аннан, кызыксынып:

— Шагыйрьгә мондый мускулатура нәрсәгә? — дип сорый.

— Кирәге чыгып куюы бар, — ди Муса, тәнен юеш сөлге белән сөртә-сөртә.

1941 елның февраль аенда шагыйрь Васильево санаториенда ял итә. Аның шул чакта төшкән бер рәсеме сакланган. Тирә-юнь ап-ак кар белән капланган. Җәлил яланбаш, майкадан гына чаңгы шуарга чыккан. Аның өчен бу — бер дә гаҗәп эш түгел. Бил тиңентен чишенеп яки майкачан килеш чаңгы шуу, иртә яздан башлап, кара көзгә кадәр су коену Муса өчен гадәти хәл саналган. «Чаңгы шуарга вакыт-вакыт майкадан гына чыгуы таза булудан гына түгел, ул, кышкы салкыннан курыкмыйча, шуңа юри үч иткән кебек чыга иде. Кышкы кояш яктысында аның таза беләкләре җәйге кояшта янган сыман каралып күренә, хәтта бераз кызынып та алган кебек була», — диелә хатыны Әминә Җәлилова истәлекләрендә.

Муса Җәлил көненең күп вакытын язып үткәргән, шуңа да ул саф һавада йөрергә, физик хезмәт белән шөгыльләнергә яраткан. Ял көннәрендә Муса еш кына хатынының әти-әниләренә кайта торган булган. Монда ул үзенә төрле шөгыльләр тапкан: утын ярган, су ташыган, бакча казыган. Бер кайтканында исә эш тапмый ул.

— Атна буена ялыккансың, бераз ял итеп ал, — диләр аңа.

— Эш — минем өчен иң яхшы ял, — ди Муса.

Армас-талмас таза, көчле кеше булса да, Җәлилне тимер-бетоннан коелган пәһлеван итеп күз алдына китерергә ярамый. Башкалар өлешенә тигән авыруларның кайберләре аны да читләтеп узмаган. Әминә ханымның язуына караганда, Муса «авырырга бик яраткан». «Әгәр чак кына салкын тидерсә, Муса пижамасын кия дә тиз генә караватка менеп ята. Аның өчен кура җиләге кайнатабыз, куе итеп чәй ясап бирәбез, температурасын үлчибез, аптекага барып, тиз генә дару алып кайтабыз. Безгә карап, ул шуларга бик тә канәгать булып ята. Гомумән, ул ничектер иркәләп торганны ярата иде кебек», — ди Әминә ханым.

Хәдичә апасы үзенең истәлекләрендә аның авырып больницада яисә урын өстендә ятканын хәтерләмим, дип яза. Яшьтән чыныгып үскәнгә, Муса авыруга тиз бирешмәгән. Җитдирәк авыруларны ишетеп кенә белә. «Аз гына сырхаулый башласа да пошаманга төшә, бераз температурасы да күтәрелсә, ах-ух килә башлый иде. Андый чакта аны карарга кеше кирәк. Бармагын әз генә киссә, зур иттереп урап куя, әйтерсең зур җәрәхәте бар. Үзе кечкенәдән иркә үсмәгәч, йомшак күңелле, ягымлы булгач, бүтәннәрнең дә игътибарлы булуын ярата. Иптәшләре, туганнары килеп хәлен белешсәләр, маңгаена кулларын куеп карасалар, тәмле әйберләр алып килсәләр, ул бөтенләй эреп китә, — дип язган апасы. — Ә даруны сирәк эчә. Барлык авыруга каршы бердәнбер даруы бар, ул да булса — мигрень карандашы. Эче авыртса, шуның белән эчен ышкый, башы авыртса, чигәсен ышкый. Хәтта киселгән

җирен дә шул карандаш белән дәвалый иде. Шулай да без аның турында авырудан бигрәк иркәләнергә ярата дип уйлап, гаделсез булганбыз. Җиңел генә авырса да, ул ябыгып, хәлсезләнеп кала иде. Авыртуга бер дә түзми иде ул. Төрмәдә ерткычларча җәзалауга ничек түзде икән, шуны күз алдыма китерәм дә йөрәгем сыкрый. Ватанына мәхәббәте чиксез, дошманына нәфрәте көчле иде шул…»

Шулай ук туганнары, якыннары Җәлилнең бик мавыгып шахмат уйнавы хакында язалар. Муса шахмат уйнарга яраткан. Җиңсә, сөенеп бетә алмый, җиңелсә, нык үртәлә торган булган. Андый чакларда үзен «грошмейстр» яки «гробмейстр» дип атаган. Янә Хәдичә Җәлилова истәлекләренә күз салыйк: «...Бу вакытта Муса «Алтынчәч» либреттосын яза иде. Эше күп, бик бирелеп утыра. Мин аларга килсәм, өстәл артыннан торып, киерелеп, бераз тәнен язып ала да мине берәр партия шахмат уйнап алырга кыстый. Безнең уенны берәр шахматчы карап торса, исе китәр иде. Беренчедән, мин уйный белмим, икенчедән, озаклап уйлап торырга түземлегем җитми. Муса йөргәч, тактага күз дә салмыйча:

— Хәзер ничек йөрим? — дип сорыйм.

Муса уйланып утыра да минем өчен йөри. Аннары, үзе йөрер өчен, озаклап уйга чума, әйтерсең, Ботвинник белән уйный».

Җәлилләрнең Столешников урамындагы фатирында чыгарылган «Шахмат бюллетене»нең өченче саны сакланып калган. Бюллетень Муса язган төрле мәзәкләр һәм эпиграммалар, үзе ясаган юмористик рәсемнәр белән бизәлгән.

Ул тормышны ярата, һәм кайда яңалык өчен киеренке көрәш барса, шунда ашкынып яши. Муса комсомолларга хас ашкыну һәм кайнарлык белән көрәшкә ыргыла, үзенең көчле, эмоциональ шигырьләрендә зур ләззәт белән шул көрәш турында сөйли.

Мусаның спортка һәвәслеге иҗатында да чагыла. Мәсәлән, аның «Чаңгы шуганда», «Кавказда» кебек шигырьләре шуңа багышланган. Күпме оптимизм, тормышка мәхәббәт хисе ул шигырьләрдә! Күңел төшенкелеге, эч пошу, елау-сыкрау — Җәлил иҗаты өчен ят нәрсә. Аның шигырьләре нык ихтыяр көче, ашкынулы дәрт белән сугарылган, аларда бәхеткә омтылу, яшәүгә мәхәббәт ярылып ята:

*Ашкынулы йөрәк җырын җырлап,*
*Гөрләвекләр акты урамда.*
*Сагыну моңын сузып, күк юлыннан*
*Сайрар кошлар кайтты урманга.*
*Зифа каен яшел яфрак ярды,*
*Яфраклары шаулый җил белән.*
*Ул каршылый язны күтәренке*
*Һәм шатлыклы яңа җыр белән...*

«Яз җыры», 1936.

Шагыйрьнең Мәскәүдәге иң якын дусларыннан берсе Әхмәт Фәйзи була. Мусаның өйләнгәнче яшәгән фатирын ул болай тасвирлый: «Бүлмәдә китаплар өелгән, өстәлдән һәм урындыктан башка берни дә юк. Муса иске газеталар өстендә йоклый... Ул күп укый, спорт белән шөгыльләнә, кояшны бик ярата. Кояш белән дуслыгы аның күп кенә шигырьләрендә дә күренә. Ул аңа «Исәнме, Кояш» яки «Кояш дус» дип дәшә иде. Иң яраткан спорт төрләреннән берсе, шиксез, мылтыктан ату иде».

Муса еш кына Ә.Фәйзине тирга чакыра торган булган. Үзе бик төз ата, ә дустының мишеньга тидерә алмавыннан рәхәтләнеп көлә икән. Бервакыт

Әхмәт Фәйзи, ачуы килеп, Мусаны иҗади ярышка чакыра. «Әйдә, оборона спорты турында шигырь язып карыйк. Кем җиңәр икән?» — ди. Ә.Фәйзи «Оптимистлар җыры» дигән шигырь яза. Бу шигырендә ул шагыйрь өчен, мылтык ата белүгә караганда, әйбәт шигырь язу мөһимрәк, дип исбатларга тели. Аңа җавап рәвешендә Муса «Тирга» дигән шигырь яза.

*Әхмәт туган, ташла каләмеңне,*
*Әйдә киттек тирга, булмаса.*
*Төз атучы булдык җырда да,*
*Төз атарбыз, шиксез, тирда да.*

Моабит төрмәсендә сорау алулар иртәнге 9дан башланып, 5-6 сәгатьләп барган. Тикшерүче сорау алу барышында көненә өчәр тапкыр ашый. Гаепләнүчегә дә ашап алырга тәкъдим итә. Ләкин Җәлил бу тәкъдимне кире кага. Ач килеш ризыктан баш тартыр өчен никадәр ихтыяр көченә ия булырга кирәк. Җәлил ашауның җәзалауның бер төре икәнен аңлаган. Үзеңнең бер генә теләгеңә ирек бир, шунда ук башкалары да баш күтәрәчәк. Каршына китергән ризыктан баш тартып, ул дошманы алдында баш имәс, буйсынмас горур зат булуын күрсәткән. Яшьлектән үзендә тәрбияләгән ихтыяр көче, физик һәм рухи ныклык Җәлилгә шундый кырыс шартларда да җиңүче булып калырга ярдәм иткән.

Муса Җәлил үтә пөхтә, җыйнак, максатчан һәм зур ихтыярлы кеше була. Үзенең бөтен гомерен ул бер олы максатка багышлый, зур тырышлык һәм ныклык белән шул максатына ирешү өчен көрәшә. «Мин тормышта тирән һәм ялкынлы сөя беләм. Мин табигатьне дә, кошны да, чәчәкне дә, музыканы да, намуслы хезмәтне дә, ялкынлы иҗатны да, тиңдәшсез илемне дә янып, кайнарланып сөям», — дип яза ул. Шагыйрьнең шулай ярата, хөр күңелле булып яши белүе рухи һәм физик ныклыгыннан киләдер дип уйлыйм. Балкар шагыйре Кайсын Кулиевның:

*«Соңгы җырым палач балтасына*
*Башны тоткан килеш языла, —*

дип әйтә алган кеше — шәхес, һәм фаҗигале шәхес. Баш очында палач балтасы күтәрелгән хәлдә дә җыр яза алу — бу инде батырлык. Моның өчен кыю кеше булу гына җитми, моның өчен инде яшәешкә, тормыштагы бөтен яктылыкларның һәм яхшылыкларның җиңә алу мөмкинлегенә ышана белү кирәк», — дигән сүзләре Җәлилне бигрәк тә тулы бәяли.

**Элина ЗӘКИЕВА.**
*Сарман*

# КӨТЕЛМӘГӘН ОЧРАШУ

Без студент чакта тыелган фәннәр бар иде. «Фәнне тыеп буламыни?» — дип гаҗәпләнүчеләр дә табылыр, мөгаен. Булды шул, шундый заманада да яшәргә туры килде. Без вузда укый башлаганда, радиотапшыруларда (телевидение юк иде әле), газета-журналлардагы язмаларда берничә фәннең «измәсен изү» һәм аларны өйрәнүче, гамәли эшләрендә файдаланучы «буржуаз, реакцион» галим затларны «утлы табада биетү»дә остарган каләм ияләре күп иде. Безнең өчен шунысы бигрәк тә сәер иде: кыйнала торган фәннәрне шәрехләп тасвирлаучы китаплар яисә мәкаләләрне без студентлардан беребезнең дә күргәне булмады, әмма, аларны «пыр туздырган» язмалар-мәкаләләрне генә укып, семинарларда чыгыш ясар өчен әзер булу зарур иде. Шундый фәннәр арасында безне бигрәк тә кызыксындырганы *кибернетика* дип атала иде. Аны ялган фән (псевдонаука) дип шул чактагы мәсхәрәүләрне әдәпле (башыннан сыйпап кына, иркәләп кенә) шелтәләү дип бәяләргә була. Чынлап та кызыксынып һәм төп чыганакларын табып өйрәнгән галимнәргә исә төрмә дә яный иде ул кырыс елларда. «Акыл эшенә баш мие урынына металлдан эшләнгән роботларны җигүме? Җәмгыять тормышын автомат җиһазлар ярдәмендә көйләүме?» Бу турыда уйлаган галимнәргә карата ил җитәкчеләренең (бигрәк тә Н.С.Хрущёвның, кибернетиканы ул империализмның сатлык фахишәсе дип атый иде) мөнәсәбәте миһербансыз булды. Моны күзаллау, аңлыйм, укучыларга кыендыр.

Ни гаҗәп, берзаман университетның 24 колонналы төп бинасында төрле рангтагы капитаннар — хәрби диңгезчеләр күренгәләп алды. Алар, чыгарылыш курстагы бишлегә генә укыган, «иң-иң башлы» егетләр белән очрашып, әңгәмә кордылар. Безгә шул әңгәмәләрнең эчтәлеге хакында өлкән иптәшләребез берни сөйләмәде.

Дүрт ел узгач, аларның кайберләре белән очрашу да насыйп булды. Погоннары капитан-лейтенантлар икәнен күрсәтә иде. Безне иң шаккатырганы — аларның, һич яшермичә, хәрби флотта кибернетика казанышларын гамәлгә кертү өстендә эшләүләре турындагы сүзләре иде. Кибернетика фәнен гамәли, хәрби эшләрдә куллана башлаган әйдаманнарның җитәкчесе адмирал А.И.Берг турында беренче тапкыр шулардан ишеттем. Тәвәккәл, батыр шәхес булган, репрессияләрдән дә куркып тормаган галим-адмирал бу (һич гаепсезгә төрмәдә дә утырып чыккан сәясәт корбаны да әле). «Бөек юлбашчы» белән аның кабинетында фән һәм техниканың ул замандагы иң мөһим бер проблемасы турында икәүдән-икәү генә гәпләшкәндә, хуҗаның бертуктаусыз ачулануыннан да каушамаган, үз карашларына Сталинны ышандыра алган.

Хәрби кибернетиклар белән очрашулардан соң университеттагы остазларыбызның берничәсенә, сабакташларымның һәм бездән соң укыганнарның шактыена бу яңа фән юнәлешендә актив эшләү насыйп булды. Үзем (ике ел математика бүлегендә укыганнан соң) өченче курста сайлаган астрономия өлкәсендә эшләсәм дә, яңа фәннәр белән кызыксына идем (остазым, вакыт әрәм итәсең, дип моның өчен мине шелтәли иде). Ә искиткеч темплар белән үскән кибернетика, әлбәттә, фәнни хезмәткәрләрнең игътибарын һәрдаим җәлеп итә иде.

Вакыт тиз уза. Унике ел агымында аспирантурада уку да, дәрәҗәлерәк дипломнарга ирешү дә, күп галимнәр белән бергә эшләү дә насыйп булды.

Ике ай командировкада эшләгәндә, ифрат катлаулы билиниәл дифференциаль тигезләмәләр системасына юлыктым. Андый системалар буенча белгечне Ленинградта таба алмагач, кайтканда Мәскәүдә тукталдым. Университет математиклары да ярдәм итә алмады, әмма, рәхмәт аларга, кирәкле белгеч эшләгән фәнни-тикшеренү институтына юлладылар.

СССР Фәннәр академиясенең В.А.Стеклов исемендәге математика институтының эңгер-меңгер яктылы вестибюлендә, чалт аяз көнне урамнан килеп кергәч, кая барырга белми каранып торган, еректан килгән вуз укытучысын хәрбиләрдәге шикелле төз гәүдәле бер абзый күреп алып, яныма килде. Ул кайдан һәм нинди йомыш белән килүемне төпченде. КГБ хезмәткәрләре белән эшем буенча аралаша идем, шуңа күрә, дилбегәне кыска тотып, проблемамны тасвирладым һәм кемне күрергә теләгәнемне әйттем. Ә аны, ни хикмәт, минем документларым бөтенләй кызыксындырмады, ул тиешле кабинетка ничек барасын шәрехләп сөйли башлады. Минем (аптыраган чыраемнандыр, мөгаен) юлны һич аңламаганымны тоеп, әңгәмәдәшем кулын селтәде һәм, «Әй, барыбер адашырсыз, озата барыйм әле!» — дип, мине сул терсәгемнән «җитәкләп» алды. Институтның лабиринт сыман коридорларында кирәкле кабинетка «сәяхәтебез» вакытында юлдашым сорауларын яудыра барды. Хәтта мин эшләгән институтта нинди биналар, нинди спортзал, күпме укытучы һәм студент булганы да кызыксындыра иде аны. Шулай итеп, «КГБ хезмәткәре» (үзем фаразлавымча) мин фәкыйрегездән шактый күп «дәүләт серләре»н белә алды. Хәер, аның мине кызыксындырган математик проблеманы да яхшы аңлавы бераз гаҗәпләндерде үзе. Тиешле кабинетка җиткәч, ул, ишекне ачып:

– Александр Дмитриевич, менә сезгә кунак алып килдем, каршы алыгыз, — диде. Кабинет хуҗасы:

– Аааксель Иваааанович! Керегез, керегез, рәхим итегез! — дигәч кенә, «гид»ымның академик-адмирал, совет кибернетикасының «атасы» А.И.Берг икәненә төшендем. Ә ул:

– Башка чакта керермен әле, менә кунагыбыз еректан килгән, сезгә йомышы бар аның, — дип, аркамнан җиңелчә генә этәреп, мине А.Д.Брюно янына уздырды. Аңарчы журналларда Бергның адмирал формасында төшкән күптәнге портретларын гына күргәнем бар иде. Шуңа күрә шактый олыгайган галимне танымаганмын.

Хатирәләрем бик еракка алып киткән. Кибернетика фәне турында шәрехләп сөйли башласаң, озакка сузылыр иде. Атамасы грек телендәге «кибернесий» сүзеннән алынган: борынгы карабларның койрыгына куелган бик озын ишкәк белән карабны идарә итүчене шулай дип атаганнар. Кибернетиканың нигез ташларын салган галим — америкалы математик Норберт Винер. Аның кибернетика буенча 1948 елда дөнья күргән беренче китабын, туган телебезгә тәрҗемә итсәк, «Кибернетика, тереклектә һәм машинадагы идарә һәм элемтә» дип атарга була. Чираттагы китабын галим «Кибернетика һәм җәмгыять» дип атаган иде. Бу фәндә, кыскача әйткәндә, теләсә нинди системаларда була торган идарә итү, элемтә һәм информация эшкәртү проблемалары тикшерелә. Кибернетика өйрәнә торган системаларның табигате һәм «тумышы» буенча теләсә нинди булуы мөмкин: техникадагы автоматик көйләгеч-регуляторлар, электрон хисаплау машиналары, башыбыздагы «ми» атамалы акыл «аппараты», тере организмнардан оешкан берлекләр, җәмгыять. Бу фән хәзер, үзе берничә тармакка бүленеп, көндәлек тормышыбызда искиткеч зур роль уйный. Сабакташларым һәм остазларыбызның шактые бу фәнне үстерүдә һәм аның казанышлары белән сәнәгатьне автоматлаштыру эшендә актив

катнашты. Кыскасы, без вузда укый башлаганда, хакимият басымы аркасында тыелган, җәберләнгән кибернетика укуыбыз тәмамланганда ук иң абруйлы белем тармагы буларак танылды. Аны төрле курслар һәм семинарларда яисә үзлегебездән өйрәнергә туры килде. Шулай итеп, бу яңа фән кыска гына вакыт эчендә тиешле урынын яулады. Әмма кибернетика үзе дә яңа фәннәрнең туып үсүе өчен этәргеч булды. Чөнки аның казанышлары *система* дигән күренешләргә яңача карарга мәҗбүр итте. Кибернетиканы «үз канаты астына алган» *информатика* да — шундый үзгәрешләрнең бер мисалы. Хәер, болары үзе аерым бер язма темасы.

Очрашкан чакта мәшһүр галим 78 яшен тутырган булган икән, ә мин, үз каланчамнан карап, иллене узган «бик олы яшьтәге ир-ат» дип фаразлаган идем. Баксаң, Беренче Бөтендөнья сугышында булачак галим — су асты көймәсенең штурманы, ә революциядән соң Гражданнар сугышында шундый көймәнең командиры сыйфатында катнашкан. Соңыннан, ике вузда белем туплап, 1925 елдан хәрби вузларда һәм Ленинградтагы электротехника институтында укыту белән бергә, фәнни-тикшеренүләр дә алып бара ул. Биографиясе искиткеч бай, фәнни эшләренең күп тармаклылыгы шаккатыра. Фән һәм техниканың өр-яңа өлкәләрендә киң колачлы тикшеренүләр оештырган галим 1943 елда — СССР Фәннәр академиясенең мөхбире, ә 1946 елда хакыйкый әгъзасы булып сайлана, радиотехника һәм электрлы элемтә өлкәләрендәге казанышлары өчен Академиянең А.С.Попов исемендәге Алтын медале белән бүләкләнә, 1963 елда «Социалистик Хезмәт Герое» исеменә лаек була. Шунысы гаҗәп: галим, фәнни тикшеренүләрне оештырудан тыш, дәүләт хезмәткәре буларак та искиткеч күп эшләр башкарган шәхес, хәтта оборона министры урынбасары булып та хезмәт итә әле. Кибернетика казанышларын укыту эшендә файдалану шикелле проблемалар өстендә эшләргә дә өлгерә инженер, адмирал-академик Аксель Иванович Берг.

Аның тәрҗемәи хәле белән кызыксынучылар интернетта шактый күп язмалар таба ала. Ә мин фәкыйрегезнең күңелен, кырык дүрт елга якын вакыт узса да, кайчагында бер сорау борчый: ул чакта фән даирәләрендә барысына да билгеле мәшһүр шәхес үзен танымаган өчен ерактан килгән вуз укытучысына үпкәләмәде микән? Үпкәләмәгәндер, шәт. Андый фәһемле, искиткеч бай белем ияләрен популярлык мәсьәләсе борчымыйдыр. Үз-үземне шулай дип тынычландырам.

**Ким ШАКИРОВ**

---

## Халык әйтсә, хак әйтә

- Акыл азмый, белем тузмый.
- Дөнья — йозак, ачкычы — белем.
- Җир күрке — иген, ил күрке — гыйлем.
- Тән зиннәте — кием, акыл зиннәте — гыйлем.
- Уку каты булса да, җимеше татлы.

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

*Инде игълан ителгәнчә, ошбу конкурсның 2016 елгы өлешен башлап җибәрәбез. Бу юлы алты җиңүче (бер — беренче, ике — икенче һәм өч өченче урыннар) билгеләнәчәк.*

*Башламнар 12нче санда басылган иде. Күләм бер журнал битеннән артмаска тиеш.*

*Былтыргы бәйгене Казандагы 4нче гимназия остазлары һәм укучылары башлап җибәргән иде. Алар быел да өлгерлек күрсәтте. Биредә гимназиядән килгән хикәяләрнең беренче өлеше бирелә.*

## Камәрия әби хатирәсе

**Әлеге вакыйга инде онытыла да башлаган иде. Тик менә бүгенге хәл аңа барысын да яңадан исенә төшерде.**

Мине классташларым шаяртып кына «китап корты» дип йөртәләр. Алай дип әйтүләренә үпкәләмим. Чыннан да, китап укырга бик яратам мин. Менә кулымда Вакыйф Нуруллинның «Ике урам арасы» повесте. Йотлыгып укый торган әсәр. Бигрәк тә мәктәптә укучы Вакыйфның классташлары Мәхмүт һәм Гәрәй белән кышкы буранлы көндә урманга утынга бару вакыйгасы минем күңелемдә хатирәләр уятты. Малайлар колхозның «Баһадир» кушаматлы үгезен җигеп 13 чакрым ераклыктагы «Корноухово» урманына утынга китәләр. Көне буе эшләп, кайтырга соңга калалар. Аларны юл буе өч бүре озата бара. Бүреләрне бик явыз дисәләр дә, тимиләр алар малайларга...

Ирексездән әбием сөйләгән вакыйга күз алдына килә.Чуашстанның Шыгырдан авылында әбием Камәрия һәм бабам Абзалетдин яши. Аларның тормышы күпләр өчен үрнәк булды. Кызганыч, бабам инде күптән гүр иясе.

Бабаем Абзалетдин Себердә Артёмовск шахтасында эшләгән. Бер елга гына киткән бабаем 25 ел гомерен шушы эшкә багышлый. Ел саен гаиләсе янына кайтып йөри. Әбием дә аның янына еш бара. Шулай бервакыт әбием бабай янына Иркутскидан самолёт белән оча. Аннан аны каршы алырга тиеш булалар. Ләкин бу көнне шахтёрларны башка объектка алып киткән булалар. Камәрия әбине каршы алучы булмый.

— Хәзер шахтага шалтыратабыз, бераз гына көтегез, килеп алырлар, — дип әбиемне төшереп калдыралар. Самолётны күздән югалганчы карап тора әбием. «Инде сумкаларым өстенә булса да утырып торыйм әле, — дип талпынуы була, ни күзе белән күрсен, каршысында бүре утыра. Нишләргә дә белми Камәрия әби. «Тукта әле, бүреләр курыкканны белә диләр бит, курыкмаска кирәк», — дип, бөтен көчен җыеп, бүренең күзенә карап тора башлый ул. Менә шулай, кыр уртасына бүре белән бергә күзгә-күз карашып ярты сәгать чамасы торалар алар. Бу вакыт эчендә әбиемнең күпме чәче агарган да, эчендә ниләр булганын үзе генә белә... Әллә әбинең өйдә берсеннән-берсе кечкенә биш баласы көткәнен белгән инде, әллә күңелендә бары яхшылык кына булган — бу яшь хатынны җәлли, тими аңа бүре. Суларга да куркып, кымшанмыйча бүре каршында күпме торган булыр иде икән, Камәрия әбиемне алырга дип автобус килеп туктый. Бүре автобус күренүгә үк артка чигенә башлый. Әбием исә, исән калганына шөкер итеп, ире — Абзалетдине янына ашыга.

Менә шулай матур итеп яшәп, биш бала тәрбияләп үстерәләр алар. Әбием бүген дә үткән бәхетле көннәрен искә алып, миһербанлы балалары тәрбиясендә Шыгырдан авылының ак яулыклы әбисе булып гомер кичерә.

**Рәис ӘХМӘТОВ,**
*7 «А» сыйныф укучысы*

## «Оныткანмын бит!»

**Ул дерт итеп уянып китте. «Оныткანмын бит!»** Әби белән шатлыгымны уртаклашырга оныткანмын. Әбисе бит, әбисе аны: «Талантлы, моңлы, нәни йолдызым син минем», — диеп сөеп үстерде. Мәктәптән кайткач, биш минутка гына диеп яткан иде югыйсә. Кочагындагы дипломны шулкадәр кочкан ки, бармаклары да арыган иде. Биш минут кына бит! Биш минут ятып торды. Шул арада төш тә күреп алырга өлгергән. Ә төшендә бүген аның белән булган хәл килеп керү — үзе бер могҗиза.

...Кып-кызыл күлмәктән Казанның мәһабәт бер Мәдәният йортында ул чыгыш ясый. Башкалар арасында аерылып тора кебек, көй агымына бии-бии җырлый. Гәүдәсенең бар күзәнәге җырлаган көйгә тирбәлә, җырның тәмен, ямен тоеп үзенчә әсәрләнә. Хәтта озын толымнары да, бу минутны тотып калырга теләп, моңлана кебек. Алай булмый мөмкин түгел, җыры, җыры нинди бит:

*...Миләүшәләр, миләүшәләр,*
*Гел шатлык өләшәләр.*
*Зәңгәр күзле миләүшәләр*
*Сеңел дип эндәшәләр.*

Җыр тәмам булды. Ул алкышларны ишетмәде, күрмәде, күзе жюри әгъзаларында иде. Йөзләр, меңнәр арасында аларны табып алды, алар да алкышлыйлар. Ул алкышлар астында сәхнәдән чыгып китәргә ашыкты. Ләкин аңа нинди билге куярлар бит, әнә шунысы күңелне борчый.

Бәйгедә катнашкан һәркемнең чыгышын карап бетерделәр. Менә тетрәндергеч минутлар. Өченче, икенче урын җиңүчеләре дә билгеләнде, ләкин аңа үзенең исемен ишетмәү кыен булып китте. Шунда жюри рәисе, алга ук чыгып:

— Беренче урынны алган талантлы, моңлы, нәни йолдызыбызны сәхнәбез түренә чакырабыз, — диде. — Җыры да үз исеменә тәңгәл, беренче урын хуҗасы — Миләүшә.

Ул фамилиясен ишетмәде. Сүз аның, бары аның турында бара иде, атлап түгел, очып диярлек сәхнәгә үтте. Диплом, матур чәчәкләр, хәтта кызыл тасманы да иңнәренә элделәр. Жюри рәисе:

— Ничекләр итеп җырладың, сеңлем:

*...Миләүшәләр, миләүшәләр,*
*Гел шатлык өләшәләр,*

– шулаймы?! Тормышыңда шатлыклар күп булсын. Гел шатлык өләшеп яшә, — диеп сүзен тәмамлады...

...Менә шуннан соң инде ул дерт итеп уянып китте һәм тиз-тиз зал ягына үтеп, телефон номерын җыйды, әбисе белән шатлыгын уртаклашырга теләде. Әбисе исә:

— Белдем, сиздем, кызым, — диде. — Синнән башка кем җиңсен инде, кызым. Моңлы бала син, талантлы бала, кызым. Миннән хәер-фатиха. Догамнан калдырмам, кызым!

Трубканың икенче башында әбисенең дога укыганы ишетелде: «Әгузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәнир-рахиим...»

**Миләүшә ФӘЙЗУЛЛИНА,**
*6 «А» сыйныф укучысы*

## Алма агачыннан...

**Менә ничә көн инде Илсурның башында бер генә уй бөтерелә: калыргамы 10нчы сыйныфка, юкмы? Китсәң, БДИ бирүдән куркып киткән, диячәкләр. Калсаң...**

Аның башында һәм йөрәгендә бу уйлар әле көчле бурандай бөтерелде, әле тынып торгандай булды. Кайдандыр җилләр исеп китә дә күңел зилзиләсен тагын куптара. Бу вакытта аның үз-үзен кая куярга белмичә бөтерелүен сизүче дә, күрүче дә булмады кебек.

Нигә шулай соң бу тормыш?! Нигә кеше гел сайланулар каршында тора?

Тыныч кына барган яшәешнең шулай үзгәрүенә ул үзе гаепле. Кулындагы бәхетен саклый белмәде.

Әйе, югалтты ул Алинәсен...

Нинди рәхәт, тыныч иде. Мәктәп коридорында очрашканда, бер-берeңә елмаеп китүләр, мәктәп ишегеннән бергә чыгулар, бергә имтиханнарга әзерләнүләр. Менә шул имтиханнардан соң, чыгарылыш кичәсендә әллә нәрсә булды да инде. Әйтерсең, берьюлы әллә ничә хәрби очкыч гөрелтесе күтәрелде. Ул иптәш кызлары уртасында Алинәсен күрде...

Аяклары, тез буыннары калтыранды. Җитмәсә, колагында әнисенең: «Кыз бала әнисенә охшый. Алкаш хатын белән яшисең киләмени?» — дигән сүзләре яңгырады. Ул, үзе дә сизмәстән, йөгереп барып, сөйгәне кулындагы бокалны тартып алды. Нәрсәләрдер кычкырды, нәрсәләрдер әйтте. Тагынниләр булыр иде икән, ярый әле иптәше Миша туктатты, өенә кайтарып куйды.

Менә җәй ахыры да җитә. Нишләргә?! Калсаң — аның күзенә ничек карарга? Китсәң — куркак булып күренәчәксең. Укытучыларның хезмәте дә кызганыч.

Кинәт кенә Илсур урыныннан сикереп торды да, бер нияткә килеп, өеннән чыгып китте.

Ә урамда ямьле кояш сынаулы караш белән Илсурны озатып калды.

**Азалия ХӘСӘНОВА,**
**Ләйсәния ХӘСӘНОВА** *(Азалиянең әнисе)*

## Зәринәгә зур бүләк

**Зәринә барсын да бер минут эчендә югалтты: сумкасын да, телефонын да, акчасын да... Һәм чит шәһәр уртасында япа-ялгызы басып калды.**

Әле яңа гына институтны тәмамлап, эш эзләп йөргән көннәрнең берсендә булды бу. Телефоннан курсташ кызы Ләйсирә шалтыратып, туган көненә кунакка чакырды. Әле бик күп вакыт үтмәсә дә, сагынып өлгергән иде инде Зәринә үзенең дустын.

Менә кабат Казанда ул. Ләйсирәнең адресын карыйм дип сумкасыннан блокнотын алуы булды, каяндыр карадан киенгән бер кеше килеп чыкты да Зәринәнең кулыннан сумкасын тартып алып, күз ачып йомганчы юк булды. Инде кая барырга белмичә торган арада каршысына таба килүче дусты Ләйсирәне күреп алды. Ләйсирә шәһәр кызы шул. Ул үзенең телефоныннан тиз генә әтисен җыйды. Килеп чыккан күңелсезлекне минут эчендә төкми-чәчми сөйләп бирде. Әтисе борчылмаска кушты, булышырга вәгъдә бирде.


Кызлар күптән күрешмәгәндәй сөйләшеп, серләшеп туя алмадылар ул көнне. Кичкә шау-гөр килеп дуслары да килеп кергәч, табыннар тагын да түгәрәкләнде. Зәринәнең кәефен күтәреп төрле кызыклы хәлләр сөйләргә тырышты алар. Зәринә исә эченнән генә бик борчылып утырды. Кинәт бүлмәгә Зәринәнең әтисе килеп керде. Кулына зур букет һәм матур итеп төрелгән

ике тартма тоткан иде ул. Матур теләкләр теләп, кызын туган көне белән котлады һәм кулындагы чәчәкләре белән бер бүләкне кызына тапшырды. Ә икенче бүләкне... Зәринәгә тоттырды. Зәринә кыенсынып кына бүләкне алды. Барысына да бик кызык тоелды бу. Зәринә дә зур кызыксыну белән тартманы ачып җибәрде. Ә анда... Зәринәнең әле иртән генә югалткан сумкасы ята иде! Зәринә, чынмы соң бу дигәндәй, Ләйсирәгә карады. Ләйсирә елмаеп җибәрде. Зәринә ашыга-ашыга сумкасын актара башлады. Бар әйберсе дә урынында иде. Инде баядан бирле тамам-тамам дип торган күз яшьләре Зәринәнең бите буйлап тәгәрәделәр. Әйе, шатлык яшьләре иде бу, шуңа да дуслары шау-гөр килеп Зәринәне котлый башладылар. Ә Ләйсирә дусты өчен чын күңеленнән сөенде. Күңеленнән әтисенә мең-мең рәхмәтләр укыды ул. Туган көненә иң зур бүләк шушы иде.

**Аюбхон ГИЕСХОНОВ,**
*6 «Б» сыйныф укучысы*

# «Танымыш» дәресе

***Бу кызыклы дәрес быел да дәвам итә! Иң күп дөрес җавап бирүчеләрне ел ахырында бүләкләр көтә. Җавапны эпиграмма рәвешендә бирүчеләрнең баллары күпкә югарырак булачак.***




*Шаржларның авторы* — **Зөлфәт ХӘЙРУЛЛИН.**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Һади ТАКТАШ**

## «Партияле» һәм партиясез шигырьләр турында

***(өзекләр)***

Минем яшь язучыларның күпләреннән:

— Синең язарга утырганда башыңда эшләнеп беткән әйтер фикерең буламы? — дип сораганым бар. Аларның бик күбесе, мондый сорауны беренче мәртәбә ишеткән шикелле, аптырап калгаладылар. Ә бит язучының укучы массага әйтергә теләгән конкрет идеясе булу, әлбәттә, кирәк. Монсыз бүгенгегә кирәкле әдәби әсәр тудыру мөмкин түгел.

...Безнең социализм өчен булган көрәшебездә бер функция дә үти алмаган, конкрет идеясе булмаган «безработный» шигырьләргә Теләшевтә бик күп мисаллар табып була. Менә аның «Җиңү чорында» дигән шигыре:

*Көнгә карап*
*Көлгән гигант завод*
*Эшчеләрне коча эш белән;*
*Ил батыры кебек*
*Җиңеп бара,*
*Мактанырлык бөек көч белән.*
*Станокны сөйгән токарьларның*
*Сталь йоткан төсле күкрәге,*
*Җиде сәгать, диеп, сменабыз*
*Мастер Гәрәй ямьле күкрәде,*
*Стеналар йотты Гәрәй тавышын,*
*Чуен йөзләр ачык елмайды,*
*Партиялеләр сөйгәч безнең уйны,*
*Эшче өчен шунысы уңайлы...*
*Завод,*
*Җырларымның иң батырын,*
*Иң матурын сиңа багышлыйм;*
*Синдә күрәм көрәш чәчәкләрен,*
*Күргәнем юк моңны-сагышны...*
*Җырларым да минем синдә туды,*
*Синнән чыкты байтак уйларым;*
*Менә бүген янып, ялкынланып,*
*Каршы алдым җиңү елларын.*

...Бу шигырь белән Теләшев нәрсә әйтергә тели? Бу шигырьнең төп идеясе нәрсә? Билгеле, бу шигырьдән боларның берсенә дә җавап табып булмый.

...Бәдрүш Мокамай иптәш үзенең «Игенчеләр»дә басылган «Кырдан бүләк» шигырендә укучыларга бик ялгыш фикерләр бүләк итә:

*Кулак оппортунист*
*Канлы куллар бар.*
*Ул дошманнар колхоз үскән саен*
*Кислородтан мәхрүм калалар...*
*Киң кырларда носилкалар тавышы*
*Яңгырап үтә колак яныннан,*
*Колхозчылар үлә-үлә эшли,*
*Җилкәләрен кашый ялгызлар...*

Билгеле, эшләп үлгән колхозникларны кырдан носилка белән ташый башласалар, ялгызлар җилкә кашу гына түгел, колхозга гомергә кирәселәре юк.

Мондый ялгыш фикерләр Мокамай иптәшнең әсәренә салынган төп фикерне җанландыруга яраклы булган образларны куллана белмәвеннән килеп чыккан. Үлә-үлә эшләү, кырдан носилкалар белән колхозчыларны ташу образы, бу колхоздагы социализм ярышын, иректә хезмәтне күргәзүгә ярдәм итә торган образлар түгел, киресенчә, бу капитализм илләрендәге, колонияләрдәге коллык хезмәтен җанландыра торган образ һәм сүзләр...

...Һәрбер сүз кызылармеец кебек үзенең постында булсын, үзенең ни өчен бу постка куелуын яхшы белсен.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## «Син гаепле...»

— Барысына да син гаепле, Туфан абый. Син булмасаң, бу хәлгә калмый идем мин. Рәхәтләнеп яшәп ята идем бит комунизымга чыгып. Күп тә калмаган иде бит комунизымга чыгарга. Вәт була иде ул чакта. Бер җирдә дә эшләмисең, рәхәтләнеп ятасың. Любуй нәрсә эчәсең, любуй нәрсә ашыйсың. Иртән баш төзәтергә — пажалыс-ты. Хатын сүкми. Председатель бәйләнми.

Син гаепле, Туфан абый. Комунизымга чыгабыз гына дигәндә, депутат булып сайландың да бөтенесен дә бетердең. СыСыСыРны да бетердең, Ленинны да бетердең, комунизымны да бетердең. Ярый, СыСыСыРы белән Ленин булмасын да ди, чурт с ним, ну комунизымга тимәскә иде. Менә хәзер нәрсә инде? Ни үзеңә юк, ни безгә юк. Ятасың авылда мужик булып. Элек Мәскәү тиливизырында гына утыра идең.

Ачуым бар сиңа, Туфан абый, бар. Комунизымда яшәп карарга хут бирмәдең. Үзең ише дипутатлар җыелдыгыз да харап иттегез комунизымны. Куй шуның өчен бер ярты. Комунизымда эчәсе аракыны үз кесәңнән эчер — ату гомер буе риза-бәхил булмаячакмын.

**Илдус ГЫЙЛӘҖЕВ**

## Катысын каты да бит

Бу төбәктә кукы диләр,
Сезнең якта какы ул.
Бездә никтер шарт-шорт килә,
Сөйләм теле каты ул.
Ирләрегез, мәй капкандай,
Йомшак әйтә «җәнем» дип,
Ә безнеке шатыр-ботыр:
Кырт кисәбез «җаным» дип.
Кыз күңеле бикле булса...
(Яшәп җыйган белем шул),

Ачкыч белән ачып була,
Әчкеч белән... белмим шул...

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Тәүге шигырь

Туган ягына кайткач (сиксәненче еллар башы бу), «Укып барабыз гәҗиттәге язмаларыңны, еш күренәсең, малаҗис!» дип, Марсель Галиевне котлыйлар икән якташлары.

Гәҗит ягына әйләнеп тә карамаганлыктан, ул моңа бик гарьләнгән. Казанга кайту белән «Социалистик Татарстан» редакциясенә киткән. Анда М.Галиев фамилиясе куеп, өч юл ярымлык информацияләр чыгара торган Мөшәррәф Галиевне табып: «Зинһар, дип әйтәм, һич югы, ике битлек мәкаләләр яз инде, ичмасам. Оятка калдырасың бит вак-төякләрең белән!» — дип үтенә икән бу.

«Әһ-һә!» дип уйлаган Мөшәррәф Галиев, эченнән генә. Шуннан соң Марсель Галинең шигырь китапларын портфелендә йөртә башлаган. «Мин — шагыйрь» дип, танышкан бер кызга өләшә икән теге китапларны.

Беркөнне урамнан искәрми дә үтеп китәсе Мөшәррәфне бер кыз туктаткан да:

— Нишләп телефоннан мин шылтыратканны белгәч җавап бирмисең? Йөргән буласың мактанып! «Мин — шагыйрь» дигән булып. Укып чыктым китабыңны, бер тиенгә тормый шигырьләрең! — дип, Марсель Галиевнең җиңел китабын Мөшәррәфнең йөзенә ыргыткан да китеп барган.

Шуннан соң Мөшәррәф Галиев өенә кайткан да Европага таба сузыласы газ трассасы турында ачудан тәүге шигырен язган:

*Уренгой. Помары. Самотлор. Ужгород.*
*Урын җәй, Тамара, Саматка, ажгырып.*

**Ленар ШӘЕХ**

## Шулай да була

Башкортстан Язучылар берлеге рәисе чагында халык шагыйре Равил Бикбаев бервакыт аксаклап йөри башлаган. Дуслары аннан:

— Аягыңа ни булды, Равил? — дип сораганнар.

Ул:

— Элек тезгә кыз утыра иде, хәзер тоз утыра, — дип җавап биргән.

## Акыллы уйлар

• Хушбуйлы кеше (хушбуй сөрткән) хуш уйлы дигән сүз түгел, буш уйлы да булырга мөмкин.

• Азатлык азуга китерә.

• Үзең ябык булсаң да, күңелең ябык булмасын.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

Ictimaği-mədəni tormışıbızdan

# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ТУРЫ ЭФИР

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татарстан – Яңа Гасыр» һәм «Эфир» телеканалларында уздырылган туры эфирда катнашты. Әңгәмә барышында ул 2016 елга планнар, республикада гамәлгә ашырыла торган социаль программалар, Татарстанның федераль үзәк белән мөнәсәбәтләре турында сорауларга җавап бирде. Быел социаль юнәлештәге утызлап республика программасы гамәлгә ашырылачак. Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, республика хакимияте белән федераль үзәк һәрчак аңлашып эшли, бу исә — яхшы мөнәсәбәтләр урнашуның нәтиҗәсе.

Әңгәмә барышында Татарстан мәктәпләрендә рус һәм татар телләрен укыту мәсьәләсе дә күтәрелде. Р.Миңнеханов республика халкына ике дәүләт телен дә үзләштерергә тәкъдим итте.

## КРЕМЛЬДӘ ТАНТАНА

Узган атнада Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, «Яңарыш» республика фонды химаячеләр советы рәисе Минтимер Шәймиев тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне торгызуга өлеш керткән депутатларга, җирле хакимият башлыкларына, оешма һәм предприятие җитәкчеләренә, шулай ук гражданнарга тантаналы рәвештә Хәйриячеләр китабының VI томын һәм Рәхмәт хатларын тапшырды.

Болгар каласы һәм Зөя утрау-шәһәре – кадерле ядкәрләребез. Бу тарихи урыннарда соңгы елларда киң колачлы эшләр алып барылды. Алар бүген бик күпләрне тартып тора торган тарихи-мәдәни һәйкәлләргә әверелде. Әйтик, 2010 елда Идел Болгарстанына килүче туристлар исәбе 50 мең булса, бу сан узган ел 360 меңгә җиткән.

Хәйриячеләр китабы — «Татарстанның мәдәни мирасы: борынгы Болгар каласы һәм Зөя утрау-шәһәре» проекты комплексында катнашып, республика тарихи-мәдәни һәйкәлләрне яңартуга өлеш кертүчеләрне бүләкләү һәм исемнәрен мәңгеләштерүнең бер формасы. Анда фондка өлеш керткән барлык кешеләрнең, предприятие, оешма җитәкчеләренең, ярдәмнең күпме булуына карамастан, исемнәре языла. Китапның алты томына барлыгы 48 мең иганәченең исеме теркәлгән. Анда кергән иң өлкән хәйриячегә 103 яшь булса, иң яше исә яңа туган сабый. Аның әти-әнисе бала исеменнән фондка ярдәм күрсәткән. Күп хәйриячеләрнең исемнәрен барлык томнарда да күрергә мөмкин. Хәйриячеләр китабының электрон варианты исә «Яңарыш» республика фонды сайтында урнаштырыла. Аны һәр кеше карый ала.

Китапның беренче томына биш мең хәйрияче кергән булса, алтынчысына 10 мең кешенең исеме язылган. Бу көнне Минтимер Шәймиев кулыннан 69 хәйрияче фондның Рәхмәт хатларын алды.

## ЖУРНАЛНЫҢ ЧЫГА БАШЛАВЫНА – 110 ЕЛ

Г.Тукай музее гасыр башында дөнья күргән әдәби, фәнни һәм иҗтимагый эчтәлектәге «Әлгасрел-җәдид» журналы чыга башлауга 110 ел тулуга багышланган кичә уздырды.

«Әлгасрел-җәдид» 1906 елның 15 гыйнварында Җаек шәһәрендә чыга башлый. Камил Мотыйгый — аның нашире һәм мөхәррире, ә Габдулла Тукай җаваплы сәркатип була.

Әдәби кичәгә Казан мәктәпләрендә белем алучы 5-8 нче сыйныф укучылары чакырылган иде. Алар өчен башта экскурсия үткәрелде, аннары балалар бүген актив язучы матбугат вәкилләре чыгышларын тыңлады һәм музей хезмәткәрләре белән бергәләп Татарстан мәдәнияте турында яңа журнал проектын әзерләүдә катнашты.

## ҺӘЙКӘЛЛӘР АРТА

Казанда композитор Рөстәм Яхин һәм шагыйрь Һади Такташка һәйкәл ачылачак. Моның өчен бюджеттан 12 миллион сум күләмендә акча бүлеп бирелгән. Бу хакта дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алулар сайтында хәбәр ителә. «Казан шәһәренең көндәшлек сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» әлеге һәйкәлләрне урнаштыруга тендер игълан итә. Заказга һәйкәл тирәсендәге территорияне төзекләндерү дә керә. Һади Такташка һәйкәл Казанның М.Сәлимҗанов һәм Һ.Такташ урамнары чатында, ә Рөстәм Яхинга Зур Кызыл урамындагы скверда куелыр дип планлаштырыла.

## КЫШКЫ ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Егерме елга якын инде күренекле әдибебез Шәйхи Маннурның туган көне Мамадыш районында Кышкы шигырь бәйрәме итеп зурлап билгеләп үтелә.

Шәйхи Маннур премиясе аның вафатыннан соң, васыяте нигезендә, 1982 елдан бирелә башлады.

Быел да Шәйхи аганың туган көненә Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары, шагыйрь Рәмис Аймәт, Шәйхи Маннурның мирас комиссиясе рәисе Шаһинур Мостафин, журналист һәм язучы Госман Гомәр, шагыйрь, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррир урынбасары – җаваплы сәркатип Марат Закир; Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, шагыйрьләр Әлфия Ситдыйкова һәм Айрат Суфиянов килгән иде. Бәйрәм чаралары Шәйхи Маннурның һәйкәле янында башланды. Район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Алёна Смирнова, язучылардан Шаһинур Мостафин, Вәрис Гали әдип ижатының бөеклеген искәртте, Миңгол Галиев Шәйхи Маннур сүзләренә язылган җырлар башкарды.

Быел Шәйхи Маннур исемендәге премия, Казан, Мамадыш һәм төрле авыллар сәхнәләрендә куелып, смотр конкурсларда җиңү яулаган «Аулак өй», «Җырлап керәбез, җырлап чыгабыз...» спектакльләре өчен, драматург Хәбир Ибраһимга һәм режиссёры Марат Баязитовка; Чаллы һәм Мамадышта дөнья күргән «Ядкәр», «Аһән», «Балачакка сәяхәт», «Күңел дәфтәреннән тәлгәшләр» китаплары өчен «Агымсу» әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзасы Мәнүсә Шәйдуллинага; Шәйхи Маннурның туган авылы Тулбайдагы музей-китапханәсен төзекләндерүгә, әдипнең иҗатын пропагандалауга зур өлеш керткән өчен Гөлназирә Талиповага бирелде.

### ЮБИЛЕЙЛАР

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында татар әдәбияты классигы, ТРның халык язучысы, СССРның Дәүләт премиясе, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәшировның тууына 115 ел тулуга багышланган искә алу кичәсе үткәрелде. Кичәдә язучының әсәрләреннән өзекләр укылды, аның сүзләренә язылган җырлар җырланды, фильмнардан өзекләр күрсәтелде. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов, ТРның халык шагыйре Равил Фәйзуллин, әдәбият галиме Фоат Галимуллин, прозаик, Түбән Камадагы «Җидегән чишмә» берләшмәсе җитәкчесе Фәтхулла Абдуллин, Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Гарифҗанов әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турында сөйләделәр, истәлек-хатирәләрен уртаклаштылар. Искә алу кичәсендә язучының улы Зөфәр Бәширов, оныклары Наилә Бәширова белән Гәүһәр Хәсәнова, оныкчыклары Камилә, Әнвәр һәм Зөһрә катнашты.

***

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрь, Һади Такташ исемендәге әдәби бүләк иясе Илдус Гыйләҗевка 70 яшь тулуга багышланган әдәби кичә булды. Анда юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбанов сөйләде. Бәйрәмдарны каләмдәшләре Рәдиф Гаташ, Марсель Галиев, Газинур Морат, әдәбият галиме Хатыйп Миңнегулов, «Чатыр тау» якташлык җәмгыяте исеменнән җәмәгать эшлеклесе, галим Фәндәс Сафиуллин, шагыйрь Рөстәм Зәкуан, сабакташлары исеменнән журналист-публицист Илсөяр Хәйруллина, артист Әзһәр Шакиров, Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе Айдар Шәмсетдинов, хакимият башлыгы урынбасары Дамир Гыйләҗев һ.б. котлады. Кичәдә И.Гыйләҗевның шигырьләре, аның сүзләренә язылган җырлар яңгырады.

### УТЫРЫШ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны рәис Рафис Корбанов алып барды. Утырышның көн тәртибенә ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар тәкъдим итү дә куелган иде. Яшерен тавыш бирү бюллетенена әдәби остаханәләрдән һәм Язучылар берлегенең Чаллы, Әлмәт бүлекләре тарафыннан тәкъдим ителгән язучылар Газинур Морат, Флёра Гыйззәтуллина, Зиннур Хөснияр, Марат Әмирханов, Резеда Вәлиева, Фәүзия Бәйрәмова, Илдус Гыйләҗев иҗатлары кертелде. Нәтиҗәдә, зур бүләккә Язучылар берлеге идарәсеннән беренче турда ук иң күп тавыш җыйган Газинур Морат (2014 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Кош хокукы» китабы өчен) икенче һәм өченче турларда җиңеп чыккан Фәүзия Бәйрәмова (читтә яшәүче татарлар турындагы әдәби әсәрләр, публицистик китаплар сериясе өчен) тәкъдим ителде.

Озак еллар Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында эшләгән, Россиянең һәм Татарстанның халык артисты **Наил Шәмсетдин улы Шәйхетдинов** 75нче яшендә вафат булды.

Озак еллар Татарстан китап нәшриятында мөхәррир булып эшләгән язучы-тәрҗемәче **Яхъя Мөхәммәтгали улы Халитов** (Яхъя Халит) 87нче яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: роман Р.ВАЛИЕВА «Заботы света», повесть С.ХАФИЗОВА «Разнесённый рой»; рассказ Р.ШАГИЕВА «Не уходи, папа!»; поэма Р.ШАРИПОВА,
стихи И.ИКСАНОВОЙ.
«110 лет со дня рождения Мусы Джалиля»: стихотворение М.Джалиля, стихи Р.НИЗАМИ, М.МИРЗЫ, Ф.МУСЛИМОВОЙ, Г.МУРАТА, Л.ЛЕРОНА, Р.ЗАЙДУЛЛЫ, Г.КУРБАНОВОЙ, Р.САЛАХОВА, Ф.ГИЛЯЗОВА, Э.ХАДИЕВОЙ, Р.МУХАМЕТШЫ; А.ШАМОВ. «Две встречи»; А.ШАМОВА. «История одного фотоснимка».
«100-я страница»: Р.МУХАМЕТША. «В здоровом теле нищенский дух?».
«Публицистика»: Ф.БАЙРАМОВА. «Татары на Дальнем Востоке».
«Литературная критика»: Р.БАТУЛЛА. «Что увидела Зулейха, открыв глаза?»
«130 лет со дня рождения Ф.Амирхана»: статья М.ВАЛИЕВА.
«Наши юбиляры»: статья Р.СВЕРИГИНА, посвящённая 70 летию С.ШАМСИ.
«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.РАХМАН.
«Белый парус»: Э.ЗАКИЕВА. «Он был силён и физически»;
К.ШАКИРОВ. «Неожиданная встреча»; рассказы Р.АХМЕТОВА, М.ФАЙЗУЛЛИНОЙ, А.ХАСАНОВОЙ, Л.ХАСАНОВОЙ, А.ГИЕСХОНОВА.
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Моабитская тетрадь. Муса Джалиль». *Картина художника Ильяса Айдарова*; Памятник Мусе Джалилю в Нижневартовске. *Автор – скульптор Махмуд Гасимов.*

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by R.VALIEV «Concerns of the world», story by S.HAFIZOV «Spaced swarm»; story by R.SHAGIEV «Do not go, Dad!»; poem by R.SHARIPOV, poems by I.IKSANOVA.
«110th anniversary of Musa Jalil»: poem by M.Jalil, poems by R.NIZAMI, M.MIRZA, F.MUSLIMOVA, G.MURAT, L.LERON, R.ZAYDULLA, G.KURBANOVA, R.SALAHOV, F. GILYAZOV, E.HADIEVA, R.MUHAMETSHA; A.SHAMOV. «Two meetings»; A.SHAMOVA. «Story of a photograph».
«100th page»: R.MUHAMETSHA. «In a healthy body beggarly spirit?»
«Publicism»: F.BAYRAMOVA. «The Tatars in the Far East».
«Literary Criticism»: R.BATULLA. «What did Zuleiha see opening her eyes?»
«130th anniversary of F.Amirhan»: article by M.VALIEV.
«Our heroes of the day»: article by R.SVERIGIN dedicated to the 70th anniversary of S.SHAMSI.
«Tukay and Tatar literature»: section is led by R.RAHMAN.
«White Sail»: E.ZAKIEVA. «And he was physically strong»;
K.SHAKIROV. «Unexpected meeting»; stories by R.AHMETOVA, M.FAYZULLINA, A.HASANOVA, L.HASANOVA, A.GIESKHONOV.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
From photo archives of the magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: «Moabit notebook. Musa Jalil». Painting by the artist Ilias Aidarov;
Monument to Musa Jalil in Nizhnevartovsk. Author — sculptor Mahmud Gasimov.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Моабит дәфтәре. Муса Җәлил».
*Рәссам Ильяс Айдаров картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Нижневартовскида Муса Җәлилгә һәйкәл.
*Авторы – сынчы Мәхмүд Гасыймов.*